# Казан УТЛАРЫ

ОКТЯБРЬ № 10
1966

# КИЛӘСЕ ЕЛДА...

Хөрмәтле укучыларыбыз!

Сезнең теләкләрегезне искә алып, редакция үз авторларына: «Киләсе елда журналга нинди әсәрләр тәкъдим итәсез!» дигән сорау белән мөрәҗәгать итте.

Җавапларның кайберләре. —

Г. Бәширов. «Туган ягым — алтын бишек». Автобиографик повесть.

Ф. Хөсни. «Язмыш шуклыгы». Повесть.

А. Расих. Атаклы татар революционеры Хөсәен Ямашев турында роман.

Г. Ахунов. «Хуҗалар». Роман.

Р. Төхфәтуллин. «Агымсу». Повесть.

И. Гази, Ә. Еники, А. Гыйләҗев, Э. Касыймов, Г. Мөхәммәтшин, Н. Фәттах. Повесть һәм хикәяләр.

С. Хәким, Н. Арсланов, З. Нури, М. Садри, Э. Давыдов, Ш. Галиев, Х. Камалов, С. Сөләйманова, И. Юзиев. Шигырьләр, поэмалар, җырлар.

Н. Исәнбәт. Ш. Бабич турында истәлекләр.

И. Нуруллин. Язучының позициясе. Мәкалә.

Р. Мостафин. Соңгы елларда безнең әдәбияттагы кайбер үзенчәлекләр. Мәкалә.

З. Мәҗитов, Г. Ахунов, Г. Хуҗиев, Ф. Миннуллин. Язучылардан Ә. Исхак, Г. Бәширов, Х. Камалов, Р. Төхфәтуллинның иҗат портретлары.

Болардан тыш редакция алдагы елда Совет властеның 50 еллыгына карата, фән, культура, көнкүреш, тәрбия, сәнгать темаларына очерклар, үзешчән сәнгать коллективлары өчен бер пәрдәлек пьесалар, скетчлар, интермедияләр; юмор һәм сатира әсәрләре бастыруны, әдәбият тормышы белән таныштырып баруны дәвам иттерәчәк.

Тагын нинди әсәрләр көтәсез!

Тәкъдимнәрегез булса, безгә язып җибәрегез.

*РЕДАКЦИЯ*

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ

*КЫРЫК БИШЕНЧЕ ЕЛ ЧЫГА*

**10**

**ОКТЯБРЬ**

**1966**

## Бу санда:

**РОМАН, ПОВЕСТЬ, ШИГЫРЬЛӘР**

**С. Рафиков. Авыл иртәсе.** Романнан өзек . . . . 3
**Ә. Ерикәй. Лирика** . . . . . . . . . . . . . 26
**З. Нури. Уйлануләр һәм елмаюлар.** Шигырьләр. . . 28
**С. Таҗетдинов. Үлемнән яшәүгә.** Документаль повесть . . . . . . . . . . . . . . 30
**Ш. Галиев. Яңа шигырьләр** . . . . . . . . 67
**М. Хөсәен. Автобиография, Яшәү кызык, Ашкыну.** Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . 72
**Б. Сөләйманов. Мин сөям; Син тугансың минем йөрәгемдә; О Кеше, әйтче, синме бу!!; Син аңларсың минем йөрәгемне; Азат бер кошка җим, тозак салып; Кеше; Бер күрүдә; Бокалдагы язу; Кыр казлары.** Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . 74

**КОНКУРСКА КИЛГӘН МАТЕРИАЛЛАР**

**Н. Гыйльми. Интермедияләр** . . . . . . . . . 76

**ОЧЕРК**

**Җ. Рәхимов. Кобзарь бүген Тукай кунагы** . . . . 84
**Н. Рамазан. Төньяк күршеләргә сәяхәт** . . . . . 94
**Н. Хәкимуллин. Европа тирәли** . . . . . . . 97

**НИЗАМИ ГАНҖӘВИНЕҢ ТУУЫНА 825 ЕЛ**

**Н. Ганҗәви. Явыз патша белән туры сүзле карт турында; Кибетче һәм төлке; Акылы булса; Чигенә җиттем җиһанның; Дүртьюллыклар.** Шигырьләр. . 108

**ФИКЕР АЛЫШУ, БӘХӘСЛӘР**

**Х. Госман. Татар поэзиясе тарихында Тукайның урыны** . . . . . . . . . . . . . . . . 112
**Редакциядән** . . . . . . . . . . . . . . . 124

КПССның
ТАТАРСТАН ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ИСТӘЛЕКЛӘР

**Ф. Бәкер. «Сәйяр» труппасы составында** . . . . . 126

Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

**И. Рәми. Якташым.** Истәлек . . . . . . . . . . . 129

УКУЧЫЛАР СОРАВЫ БУЕНЧА

**Ф. Фәсиев. Исемнәр дөньясына сәяхәт** . . . . . 137

ЧИТ ИЛ ЯЗУЧЫЛАРЫ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ТУРЫНДА

**И. Надиров. Тукай — чит телләрдә** . . . . . . . 145

ШАГЫЙРЬ ТУРЫНДА ШАГЫЙРЬ

**М. Садри. Арфа моңнары** . . . . . . . . . . . . 147

ЮМОР ҺӘМ САТИРА

**Ф. Хөсни. Сабан туе.** Хикәя . . . . . . . . . . 149
**Б. Рафиков. Аның хыялы; Иҗат итте; Гаҗәпләнгән кычыткан; Белмәсен бала-чага; Швейцар фикере; Тиз өлгергән тел белгече.** Шигырьләр . . . . . 153

РЕДАКЦИЯ ПОЧТАСЫННАН

**М. Ишмөхәммәдов. Ничек аңлаштылар икән!** . . 154
**Укучыларыбызга җавап** . . . . . . . . . . . . . . 155
**Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары** . . . . . . . . . 156

*Редакциягә килгән кульязмалар кире кайтарылмый.*

Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: җаваплы редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-68-21, бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*



Сәббух Рафиков

# АВЫЛ ИРТӘСЕ

С. КУЛЬБАКА рәсемнәре.

Ни өчендер самолет бер сәгатькә кичегеп килде. Һава кошы [1], җилләр уйнатып, тигез җир мәйданындагы куе яшел үләнгә килеп утыруга, чемодан, төенчекләр күтәргән юлчылар, йөгерә-атлый, самолетка таба юнәлделәр. Кемнәрдер нәрсәдер әйтеп кычкырдылар. Мотор-пропеллер гүләве әйтелгән авазларны йотып торганлыктан, Шәрифуллин аның ишетә алмады. Ак алъяпкыч бәйләгән урта яшьләрдәге ир кеше уенчыкка охшаган җыйнак кына баскыч кую белән, кешеләр самолеттан төшә башладылар. Шәрифуллин, шул кечкенә баскычның бер ягына терәлгән хәлдә, энисенең чыгуын көтте.

Ул шулай күзләре белән эзләгәндә, бөтенләй икенче кеше — төсебите ягымлы гына, таныш чырайлы берәү самолеттан чыкты. Шәрифуллин аның белән исәнләшергә дә өлгермәде, әлеге ягымлы таныш кыз, Вәлине күрмичә, аның яныннан кызу атлап үтеп тә китте. Ә Вәли әле һаман энисенең чыгуын өмет итеп, шул урынында калды. Менә соңгы кеше дә самолеттан төште. Очучылар сары кәгазь капчыкларга төялгән газеталарны да җиргә ташладылар. Кулларына билетларын тоткан бүтән юлчылар самолетка утыра башлагач кына, ул аптыраулы кыяфәт белән бу тирәдән китте. Янадан алты почмаклы аэродром йортына килеп җиткәндә, самолет, җилләр уйнатып, җирдән күтәрелеп бара иде инде. Вәли күзләре белән баягы таныш төсне эзләде. Эзләде дә, тапты да. Өстенә зәңгәрсу саржа плащ кигән, шул ук төстәге ефәк яулыгы астыннан кара чәчләре тузгыган, җыйнак, төз гәүдәле, биек үкчәле түфлие килешеп торган матур аяклы кыз, уртача зурлыктагы чемоданын җиргә куеп, бер кулына пөхтәләп төргән зур төенчек тоткан хәлдә, аңарга арты белән тора иде. Шәрифуллин аның янына килде. Башта беркадәр тартыныбрак, аннары хәтсез кыю рәвештә кызга карап торды да битенә йөгергән кайнарлыкны сизмичә әйтеп салды:

— Өнемме, төшемме? Халисә түгелме соң бу! Сине нинди җилләр ташлады монда?

---

[1] Шул исемдәге романнан өзек.

Кыз, төенчеген кара чемоданы өстенә куеп, Шәрифуллинга күтәрелеп карады һәм, кыю хәрәкәт белән, күрешергә дип үзе кулын сузды:

— Әтекәй генәм, Вәли абый, сез бит бу! Бик исән генәме? Үзең килеп дәшмәсәң, сине танырлык та түгел. Кара, калынаеп киткән, мыеклар җибәргән.

— Кунакка кайтумы?

— Әйе, Вәли абый, авылны сагындым, әниләрне сагындым.

— Ничек болай ялгыз гына?

— Минем беркемем дә юк...

— Кияүгә чыкмадыңмыни әле?

— Әле һаман җитешкәнем юк.

Шәрифуллинның текәп, йотылып карап торуыннан Халисә оялыпмы шунда, читенсенепме аска карады. Аның чәче төсле үк кара керфекләре бик кыска гына бер вакытка күзләрен каплап тордылар да аннары тагын күтәрелделәр. Моннан ары Халисәнең чырае-бите, айны каплаган болытлар таралып күк йөзе яктырган сыман, ачылып, нурланып китте. Башындагы бүтән төрле уйлары берьюлы таралгандай булды. Шәрифуллин да беркадәр каушап һәм тантаналы төстәрәк әйткәнен сизми дә калды:

— Менә гаҗәп, син һаман шул көенчә... исләрең китәрлек!

Әйтелгән бу мактау сүзләре ошаса да, Халисә ярым пышылдап:

— Сез бигрәк инде, Вәли абый, көлүегезме бу? — дигән булды. Беразтынып торгач, ул, нәрсәнедер исенә төшергәндәй, әйтеп куйды: — Хәзер инде Каенлы тау буйларында бүтәннәр уйныйдыр...

— Башкалар уйный... Бүтәннәр... Шулай инде: кеше туа, үсә, олыгая, картая... Яшь шытымнар чыга, алар тагы үсәләр... Гомер шулай тәгәрмәч кебек әйләнеп тора, — диде Шәрифуллин.

Бу сүзгә каршы Халисә эндәшмәде. Ул әле анда, әле тегендә карап ала, аның бөтен торышында ниндидер ашыгу, күзләрендә эзләнү, һәрнәрсә белән кызыксыну сизелә иде. Халисәнең телен йоткандай тын торуын күргән Шәрифуллин, әле очлары югалырга өлгермәгән уй җепләрен тотарга ашыгып, дәвам итте:

— Бер дә хәбәр-хәтерең ишетелми иде. Нинди җилләр алып кайтты сине? Кинәт кенә айдан килеп төшкән шикелле бу.

Халисә, үзенең баш турысыннан гына уйнап, бер-берсен куып барган ике ак күбәләккә карашын йөртте, сәерсенеп булса кирәк, иңбашларын сикертте дә, әллә бераз оялудан, алсу, тулы иреннәрен бөрештереп, шулай тын гына тора бирде. Аның сөйләшергә дәрте булмавын сизенгән Шәрифуллин, авылга кайтырга ашыга торгандыр, дип уйлады. Аннары ул Халисәгә әнисе карчык турында әйтте. Халисә карчыкны аэровокзалда күрмәгән икән.

Шәрифуллин аэродром йортына сугылып чыкты. Бүген башка самолет булмаячагын ачыклагач, авылга кайтып китәргә карар биреп, яңадан чирәмлеккә Халисә янына әйләнеп килде.

— Әни карчык бүген кайтмады инде. Может, иртәгәгә калгандыр. Әйдә, Халисә, киттекме?

— Ярый, синең, то-есть, сезнең очравыгыз бик җайлы булды әле, — дип, Халисә бер кулына чемодан, икенче кулына төенчеген алып, Шәрифуллин артыннан тарантас янына таба атлады. Шәрифуллин тарантаска салынган саргылт-кара арыш саламын кабартыбрак куйды да, аның өстенә брезент җәймә каплагач, кызга карады:

— Шулай йомшаграк булыр. Җайлап утыр, әйдә, Халисә. Үзеңне тирбәтеп алып кайтыйм әле бер.

Тарантас киң һәм иркен иде. Чемоданны аяк очына куйдылар. Ат кузгалып китте. Шәрифуллин еш-еш кына Халисәгә күз төшерде. Моннан берничә еллар элеккечә үк сөйкемле иде, ялкынлы иде Халисә. Бу якты күзләр, бу нурлы караш, бу тулып торган мөлаемлек һәм Халисә-

нең һәр хәрәкәтендә, һәр сүзендә үзен сиздерткән ниндидер дәрт Шәрифуллинның уйларын үткән көннәргә алып китте.

... Бөек Ватан сугышы бетеп, ике ел ярым вакыт узгач кына, Вәли Шәрифуллин солдаттан кайтты. Озак та тормый, абыйсы башка чыгып, өйләнмәгән егет Вәли төп йортка хуҗа булып калды. Шул кайтуының беренче ел сабан туенда, Каенлыдан ерак булмаган Югары Тегермәнлеккә үзләренә кардәш тиешле кешеләргә кунакка баргач, берәүгә күзе төште. Егет Югары Тегермәнлек авылына башка елларны да килеп-китеп йөргәнгә, мондагы күп кешене, бигрәк тә яшьләрне, үсмерләрне, кыз-кыркынны дигәндәй белә иде. Ул солдат хезмәте үтәгән өч ел вакыт эчендә байтак үзгәрешләр булган иде. Ул армиягә киткәндә япь-яшь кенә калган кыз-кыркыннар да үсеп өлгереп җиткәннәр иде инде. Шундыйларның берсе — элекке какча гәүдәле бәләкәй генә Хәлисә — буйга җитеп, тән-күкрәкләре тулып, яңа гына кызарып пешкән алманы хәтерләтә иде. Вәли аны көндез күреп, берничә тапкыр аңа сокланып карап үтте. Хәлисәне онытырга теләсә дә, һич тә булдыра алмады. Аннан соң, чишмә тавы буенда, кичке уенда, баштарак читтәнрәк карап торса да, түгәрәктә Хәлисәне күргәч түзмәде, аның янына керде, кызның җылы кулларыннан житәкләп алды. Җырладылар да, сүз алгалашырга да өлгерделәр. Кичке уен беткәч, бераз салкынча һавалы җәйге караңгы төндә, урамда сөйләшеп йөрделәр, капка төбендәге бүрәнәдә утырдылар.

Моннан соң алар еш-еш очраштылар. Бу сөю, бу дуслык елдан артык дәвам итте. Хәлисә буйга житкән чибәр генә, ягымлы гына кыз булса да, ул иптәш кызларыннан бер-ике яшькә кечерәк иде. Вәлинең аңа өйләнәсе килде, кешеләр кебек гаилә корасы килде. Ә Хәлисә тормышка чыгарга ашыкмады. Өндәүчеләр дә, ялынучылар да, хәтта куркытулар да кызга тәэсир итә алмады. Шуннан бер мәлне аралары суынды. Хәлисә үз авылларының дүрт кызы белән бергә Ярославльгә торф чыгару эшенә китте, ләкин ахирәтләре белән әйләнеп кайтмады, шунда калды. Баштарак хат алыштылар. Әмма, беркадәр вакытлар үткәч, Хәлисәдән хат килми башлады. Вәлигә калса, аның күңелендә Хәлисәгә карата өмет утлары шактый озак вакытлар сүнмәде. Әмма бара-тора аның күзе башкаларга төште. Вакыт узу белән, Хәлисәне оныта барды.

Алар яңадан күрешмәделәр. Бер-ике ел үткәч, Вәли Разия исемле бер кызга өйләнеп тә куйды. Әкрен-әкрен гомер үтә, сулар ага торды. Разия иң элек кыз бала тудырды. Аннан дөньяга ир бала килде. Вәли Шәрифуллин, төп йортта хуҗа булып, гомер кичерә бирде. Солдатка киткәнче үк бригадир булып эшләгән бу кешене, хезмәт итеп, дөнья күреп кайткач, урынбасар, аннары колхоз председателе итеп сайладылар. Башта ул бары тик Каенлы авылында колхоз председателе булып эшләде. Аннары бер ел үткәч, күршедәге авыл хуҗалыгы артеле белән кушылып, колхоз тагын да зурайды. Монысында да яшь, энергияле кеше дип, Вәли Шәрифуллинны председатель итеп калдырдылар. Хәзер «Якты көн»нең җитәкчесе менә шул кеше иде.

Алар Югары Тегермәнлек авылына килеп кергәндә, төш вакыты күптән авышкан, күләгәләр озын иде инде. Бер-берсенә карап сүзсез генә елмаештылар. Шәрифуллин Хәлисәне урта урамдагы канатларын киң җәйгән зур өянкеле өй турысында төшереп калдырды. Беркавым вакыт югалып, онытылып торды да, нәрсәдер исенә төшкән төсле, кабаланып дилбегәне какты.

* * *

Вәлинең әнисе Фатыйма карчык ике көн узгач кайтты.

Ул үзенең картлыгын оныткан төсле, өйдән ишек алдына, ишек алдыннан ындыр-курага, аннан бәрәңге бакчасына, күрше-күләннәргә, гүя читлектән очып чыккан кошны хәтерләтеп, житезләнеп йөрде. Карчык әйтеп бетермәслек сөенечле тойгылар кичерде. Аларга күрше-күләннәрнең сукмагы өзелмәде.

Ул элекке кебек тавыклар кунаклау белән йокларга ятмый, өйдәгеләр торып беткәч тә, почмакта йокымсырап утырмый, һәммәсеннән соң ята, һәммәсеннән иртә тора башлады. Килене Разия, карчыкка ял итәргә кушып, бу хакта сүз кузгаткач, тегесе:

— Якты дөньяны күреп туя алмыйм, шуңар аз йоклыйм, — ди иде.

Ул әле улы Вәлигә, әле килене Разияга, әле оныкларына карап тора һәм, үзалдына сөйләнгәндәй, әйтеп куя:

— Әй, газиз балаларым, мин сезнең төс-битегез, килеш-килбәтләрегезне зиһенемә китерә алмый идем. Әй, раббым, минем өчен дә кояш чыкты бит. Рәхмәтнең рәхмәте үзебезнең совет духтырларына!

Яшьтән үк жиңел сөякле Фатыйма әбинең тәне, йөрәге таза, буыннары нык, тешләре исән; ул алтмышны узу белән мышкылдап йөрүче бөкре карчыклардан түгел иде. Шуңа күрә, бигрәк тә күзләре ачылгач, аңа бар дөньясы түгәрәкләнгән кебек булды. Беркөнне ул килене Разияга озаклап карап торды. Разиянын буе ире Вәлидән аз кайтыш иде. Килененең төсендә ниндидер шәфкать нурлары уйнап тора кебек.

Фатыйма әби гомер-гомергә әйбәт холыклы, сабыр фигыльле хатыннардан саналды. Килене моны шушы йортка төшеп, берничә ел гомер кичерү дәверендә ифрат та ачык төсмерләде. Каенана белән килен бербереен ана белән кыз төсле якын күрәләр иде. Әлеге олы шатлыктан соң бу дуслык тагын да артты. Каенана килененә, ничәнче мәртәбәләр инде, үзенең куанычлы хисләрен сөйләвеннән туймады:

— И киленкәем, киңлеге, яктылыгы бу дөньяның! Ямена сокланып туярлык түгел чистый. Самолетта кайтканда, мин әйтәм, дөньяның яртысын күрдем әллә тагын. Балкып, яшәреп утырган урманнарны әйтәсеңме, ул бихисап болыннарны әйтәсеңме... Култык-култык сулар ялтырап аста кала, пароходлары йөреп тора, саллары агып бара. Ул авыллар нурланып, балкып утыралар. Бер дә әйтеп бетерә торган түгел. Ямьле шул бу дөнья, якты шул!

Каенанасының әйткәннәрен таң калып тыңлап утырган Разия андасанда үзе дә сүзгә кушылды:

— Шулай, әни, бу хәтле татлы итеп сөйләмәс идең, күзләрең ачылу куанычыннан инде бу. Синең өчен мин үзем дә сөенеп бетә алмыйм. Инде озак гомерләр яшәргә язсын.

Карчык Разияга якынрак килеп утырды:

— Әйбәт сүзең өчен авызыңа бал да май, килен, берүк шулай булсын. Барыбызга да шушылай рәхәт, тыныч торырга насыйп итсен. Мин күзле булгач, әле минә синең үзеңә дә юл ачыла.

Каенананың бу сүзләрен Разия өнәп житкермәде:

— Ничек дисең, әнкәй?

Карчык Разияның тулып торган йомшак, жылы иңбашларыннан сөеп куйды:

— И, ничек аңламыйсың, килен, колхоз эшенә чыга аласың, дим. Әле үземнең дә йөрисем килә кыр эшенә. Миңа, карт кешегә, балалар белән өйдә утырырга туры килер инде. Әйткәнемчә: сиңа юл ачыла. Инде, килен, шаулашып-гөрләшеп, башкалар белән басу, болыннарда эшләп әвәрә килерсең. Яшь чагында очар кош дөньяны гизгәндәй, басуда йөрмәгәч, син теге... Өйдә утырырга картайгач та житешерсең әле. Андый заманнар да итәккә килеп баса ул бер.

Разия моңсу күзләре белән карчыкка күтәрелеп карады:

— Юк, алай түгел, әнкәй...

Разия, һич кирәге булмаса да, алъяпкыч итәге белән борынын сөрткәндәй итте, көчәнеп елмаерга тырышты. Каенанасының бик урынлы әйтелгән сүзен җавапсыз калдырасы килмәде. Ул саклык белән, ләкин калтыраулы күкрәк тавышы белән әйтте:

— Әй, әнкәй, эш миндә генә түгел бит. — Разия тамак төбендә үсеп барган яшь төерен тыеп калырга бу юлы үзендә көч табалмый, уфылдап елап җибәрде.

Фатыйма карчык аны аркасыннан сыйпап юатырга кереште:

— Бу ничек булды әле, килен, таралдың да киттең димәсәм... Бигрәк тә йомшак күңелле инде, сине әйтәм.

Килене, җавап кайтарып тормастан, җәһәт кенә урыныннан күтәрелде дә ишек алдына чыгып китте.

Кояш баеп, хәтсез вакыт узгач кына, Вәли Шәрифуллин өенә кайтты. Әле яңа гына абзар алдында сыер савып, сөтен кар базына төшергәч, өйалды баскычына атлаган һәм шунда ук ире белән очрашкан Разия Вәлинең беркадәр кызарыбрак киткән күзләреннән һәм таныш эче истән аның җиңелчә исерек икәнен сизде. Вәли башка чактагы кебек, «улым, кызым», дип тә дәшмәде, кулларын җәеп балаларын иркәләргә ашыкмады. Өстәл тирәсенә кичке чәй эчәргә җыелгач та, ул үзен бик салкын тотты. Әнисе карчыкның да хәл-әхвәлен сорашмады.

Фатыйма әби бу хәлне улының эш артыннан йөреп арыган-талчыккан булуына кайтарып калдырды. Разия исә ни дип әйтергә дә белмәде. Иренә үпкәләү сүзләре ирештерергә каенанасыннан читенсенде. Шулай ук башка сәбәп табып, читләтеп суктырырга да теле бармады. Югыйсә үзе һаман эчке ялкын, эчке ут белән янып-көеп утырды. Чәй янында озак юанмадылар. Разия иң элек балаларны яткырды. Бераздан каенана кече якка чыгып ятты. Разия ире белән икесенә өйалдына урын җәйде.

Вәли урынга яткач, тиз генә йокыга китә алмады. Идәнгә җәелгән түшәк-ястыкта урын каты булмаса да, әле уңга, әле сулга борылып ятты. Алай да тынычлана алмагач, торып папирос көйрәтте. Ниндидер эчке пошыну, күңелендә авыр канат җәя барган борчылу Разия күзләреннән дә йокыны куа иде. Ахыр чиктә аның түземлеге житмәде:

— Сиңа ни булды? Әллә теленне йоттыңмы? Кайтканнан бирле сөйләшмисең бер сүз.

Вәли, яртысы гына тартылган папиросын сүндереп, түшәккә чалкан ята бирде. Болай да аның авызыннан сүз тартып ала алмагач, Разия тагын тел тибрәтте:

— Нинди исәпкә чумдың?

Бу минутларда башында бөтенләй башка уйлар йөргән ир теләр-теләмәс кенә Разияга борылып ятты, кулларын аның җылы муенына салды:

— Эш күп, Разия, эш күп, уйланмаслык түгел.

— Эш-эш дип инде ул чаклы!.. Артыңнан янып килми лә, башкалар нәә...

— Как килмәсен, янып килә шул. Ярый ла ул элек бер генә авыл иде, ә хәзер? Җитеш барысына. Бик чуар эшлиләр. Халыкта сознание дигән әйбер житеп бетми. Тегесе тик торып калган була, монысы житми. Райком алдында син барысына да җавап бир. Менә ничек бит ул! Ә син...

Вәли Шәрифуллин аракы белән алай артык дус булмаса да, болай үзе салгаларга ярата һәм бу хәл соңгы вакытларда ешая башлаган иде.

Разия калтыраулы тавыш белән сорады:
— Кайда эчтең?
— Анысы сиңа ник кирәк тагы?
— Яхшылыкка алып бармас бу эчү дигән нәрсә. Тәртәдән чыга башлавың шушы булмаса...
— Кара син аны, домашный прокурор. Кара, кара, патифон гел, бер боргач китте дә китте.
— Балалар атасы, хуҗа. Синең турында мин кайгыртмый, кем кайгыртсын.
— Я, куйсана, калдыр, мин бит эш кешесе. Сиңа һәр адымым саен отчет бирергә штоли?
Иренең алкы-салкы гына сүз катуыннан, ул гына да түгел, бары тик үзенә бирелгән сорауларга иренеп кенә җавап кайтарганы өчен, аңа карата күңеле суына барган Разия артык эндәшмәде. Аның күңелендә, ниндидер хәвеф буласын сизенгәндәй, борчылу тойгысы калыкты. Хатын үзенең муенына салынган иренең кулын саклык белән генә этәреп, үзе аз гына читкәрәк шуышып ятты. Аның онытылып елыйсы килде. Ләкин күзләренә яшь килмәде. Тик бары башында уй артыннан уй агыла торды.
Үз кичерешләре белән башы кайнаган Вәли дә сүз башламады. Ничектер, төнге караңгылык кебек урнашкан авыр тынлыкны бозарга берсе дә кыюсынмады. Җәйге кыска төн һәр икесенә әйтеп бетермәслек озын, төпсез карангы упкын шикелле тоелды. Бары тик таң беленер алдыннан гына Разия йоклап китте. Аннары Вәли күзләрен йомды.

* * *

Вәли Шәрифуллин гадәттә кояш чыкканчы ук йокысыннан тора. Ул бик иртә колхоз идарәсендә була, фермаларда йөри, алачыкка керә һәм, кояш шактый күтәрелгәч кенә, өенә сугылып чыга иде. Ә бу көннәрне ул ничектер барына суынып китте. Хәтта иртәнге радио хәбәрләрен дә тыңламас булды.
Берничә тапкыр бик соңга калып кайтты ул һәм, шуның белән, болай да исәпкә баткан Разияның эчке дөньясын калтыратып җибәрде. Шулай да хатын түземен югалтмаска тырышты. Үзен кулга алып, уйисәбен тышка чыгармады. Вәли исә һаман бертөрле җавап кайтарды:
— Киңәшмә, эш...
Әмма Вәли Шәрифуллинның күңеле һаман саен алмашына иде. Ул Югары Тегермәнлек авылына, бүтән чакларга караганда, ешрак килә башлады.
Шулай беркөнне ул Югары Тегермәнлек авылына килеп төшкәч, җигүле атын бригада дворында калдырды да үзе олы урамга чыкты.
Кояш баеп, аның офыкны бизәгән соңгы алсу нурлары да югала бардылар. Тиздән үзенең кара шәлен ябынып, җылы, дымлы һавалы кич керде. Авылның әле бер җирендә, әле икенче урынында утлар күренә башлады. Вәли Шәрифуллин, кая барырга белмәгән кеше шикелле, үз уйлары белән үзе буталып, югары оч урамнан әйләнеп килде... Бригада йортында ут яна иде. Шунда керде. Анда урта яшьләрдәге учетчы ир кеше исәпләп-чутлап утыра икән. Кайсы стена буендагы эскәмиягә урнашкан, урын тапмаган кайсыберләре ишек катына чүгәләгән кешеләр нәрсә турындадыр сөйләшәләр идеме шунда, бәхәсләшәләр идеме — Шәрифуллин ул тиклесе белән кызыксынмады. Ул, монда кемнедер эзләгән сыман, карашын кешеләрнең әле берсенә, әле икенчесенә төшереп чыкты да, учетчы белән азрак сөйләшкәч, китеп тә барды.
Бригада йортыннан чыккач та, Вәли күңелен томалап алган борчулы хисләреннән арына алмады. Караңгы урамнан атлаганда аның бер

ягыннан — кашларын җыерган Разия, икенче ягыннан — көләч, шома, яшь чырайлы, ягымлы карашлы Халисә барадыр кебек тоелды. Бу минутларда аның Разиядан ераклашасы, Халисәгә якынлашасы, ул гына да түгел, шул ягымлы чибәрне житәкләп, каядыр ерак китәсе, төн караңгылыгы эченә кереп чумасы килә иде. Шундый уйлар, шундый ашкынулар белән йөрәге кайнаган хәлдә, Шәрифуллин авыл уртасындагы кечкенә күпергә килеп керде һәм култыксага сөялгән көе тукталып калды. Аста, зәгыйфь кенә тавыш биреп, Каты саз инешенең агып ятуы ишетелде. Вәлинең башына кинәт кенә бер уй килеп төште: «Их, Каты саз, Каты саз, син язын бер ташыйсың да, аннан саегасың, сүнәсен. Сиңа хәзер һичкем карамый...» Ул үзенең хатыны Разияны кай ягы беләндер әлеге аз сулы инешкә охшатты. Ә яшьлегендә беренче булып сөйгән Халисәне шушы инешнең язгы тулы чагы белән тиңләде. Мәгәр Шәрифуллинга күпер өстендә озак торырга туры килмәде. Төнге тынлыкны бозып, арба тәгәрмәче тавышы колагына сугылды. Һәм, атлының күпергә якынлашуын сизенеп, ул моннан кузгалып китте.

Җәен авылга хас булганча, өйләрнең күбесендә утлар юк иде инде. Әлеге кечкенә күпердән чыгып бераз баргач, Халисәләр өе. Олы якта сыек кына ут янып тора. Урамга саргылт яктылык сипкән ике тәрәзәнең икесенә дә пәрдә корылган. Тәрәзә төбенә куелган гөлләр тышка чагыласы ут яктылыгын йотып, үзләренең челтәрле чуар күләгәләрен тышка сузганнар. Вәли койма буендагы буш эскәмияләргә бер утырды, бер торды. Өйгә керергә Халисәнең әнисе карчыктан читенсенде. «Неужели ул минем монда икәнне белми?» дигән уе бер генә минутка да башыннан китмәде. Ни өчендер вакыт тел белән әйтеп аңлата алмаслык озак үткән сыман тоелды. Ахырында ул урам буйлап йөрергә тотынды. Кай ягы беләндер башка кичләрдән аерылып торган бу кичтә аның күңелендәге ашкыну хисе торган саен үсә барды. Өмете бушка китмәде. Хәтсез ерактан икенче кат әйләнеп килүенә, капканы сак кына ачып, кемдер урамга чыкты. Җил белән килеп тулганган хушбуй исеннән аның Халисә икәнен Вәли бик тиз абайлап алды.

— Исән-сау гынамы, Халисә?

— Ә, Вәли абый икән әле.

Алар бер-берсенә якынлашканнарын сизми дә калдылар. Хатын-кызларга гына хас назлануга, иркәләнүле йомшак тавыш белән Халисә сүз кушты:

— Әй, Вәли абый, төнлә йоклап булмый диген, ә?

— Син кайтканчы йокылар шәп иде. Ә хәзер төнлә кояш чыккан сыман. Тәки синең турыда уйлап йөрим. Белмим, кай төшең тарта торгандыр. Әллә магнитың бар инде.

Халисә бермәлгә тынып калды. Әллә сүз тапмады, әллә оялды инде. Ике-өч минут үткәч кенә:

— Бигрәк инде, Вәли абый, килешмәгәнне... — диде.

— Килешмәсә, үзебез килештерәбез аны, — дип көлде Вәли.

Алар койма буендагы тар эскәмиягә килеп утырдылар. Ләкин Халисә үзенә терәлеп үк утырган Вәлидән читкәрәк шуышты.

Халисәнең күңел тынычсызлыгы үсә барганлыгы әллә каян сизелеп тора иде.

— Юк, Вәли абый, килешми сезгә, хатынлы кешегә. Минем янымa бүтән килмәгез. Халык арасында әллә нинди сүзләр таралуы бар...

Аның бу сүзләрен ишеткәч, Вәли авыр сулап куйды. Мыек очларын авырттырып бөтереп алды. Аның җилкәсе буйлап ниндидер бозлы дулкын йөгереп үтте. Хәтта бер як күз кабагы да җиңелчә генә тартып алды. Ул ашыгулы тавыш белән сөйләп китте:

— Әй, Халисә, Халисә, йөрәкнең иң түрендә утырасың бит син минем. «Яшь чагында кемне сөйсәң...» — син шул җырны беләсеңме? Тикмәгә чыгарылган җыр түгел ул...

— Җитәр, кирәкми. Сөйләмә аларны, — диде Халисә һәм битен куллары белән каплады.

— Шул, әйтеп бетерим инде. Син кайткач, Югары Тегермәнлек авылы матурланып китте, билләһи, менә...

Аннары, бераз борчулы уйланып торганнан соң, тагын кызу-кызу сөйләргә кереште:

— Син мине өйләнгән-фәлән, дисең. Юк, күңелем батмый минем аңа. Мин бит яратып өйләнмәдем. Ул чакта син кайтмадың, хәбәрең дә килмәде. Югалдың... Тормышта бит әллә нинди көтелмәгән хәлләр була... Озын сүзнең кыскасы, синнән башка тора алмыйм мин!..

— Моңарчы менә дигән итеп торгансыз бит әле.

— Торган, имеш?.. Ә ничек — монысы сиңа билгесез бит. Юк, әйткән сүземнән кайтмыйм мин.

Шәрифуллин шулай диде дә Халисәнең кулларына үрелде. Халисә калтыранып китте, үзенең йомры, җылы кулларын тегенең учларыннан кинәт кенә тартып алды.

— Син бигрәк, Вәли абый...

— Әй, бер дә харап инде. Читтә йөреп дикиләнеп беткәнсең. Ни... без бала-чага түгел инде, шуңа да...

Халисә җавап кайтармады, тагын читкәрәк шуышып утырды, авыз эченнән генә ниндидер җыр да көйләп алды бугай. Аны төрле каршылыклы хисләр биләп алды.

Ә Шәрифуллин аңа һаман нәрсәдер пышылдый...

Аяк астында ныклы туфрак сизми башлаган Халисә бераз икеләнеп тә куйды, уйларының очын югалта язды. Ул үзен, ниндидер экияттәге сыман, боз тавында тоя, аңарга өстә тору кыенлаша, тагы җитмәсә, көчле җил аны һаман аска куа, ниндидер бер билгесез якка сөйри — әллә хәвеф, әллә шатлык эченә сөйри кебек иде.

— Сәхнәдә артист булу яхшы. Ә тормышта артист булу ярамый. Минемчә шуны истән чыгармаска иде, Вәли абый. Аннары бит мин китәсе кеше. Кунакка гына кайткан кеше. Монда күп тормам. Тугантумачаларның күбесен күрдем инде. Тагын менә сезнең Каенлыдагы түтиләрне генә күрәсем калды. Отпускым бетә. Кичегергә ярамый. Аннан шелтә-фәлән булуы мөмкин.

— Минем синнән аерыласым килми, — диде Шәрифуллин.

Халисә йомшак кына көлеп, шаяртып куйды.

— Аерыласың килмәсә, әйдә, бергә киттек, — диде.

— Чын әйтәсеңме, ихлас күңелдән?

— Уен-чыны бергә...

Аптырашкарак калган Вәли Шәрифуллин, тавышына сизелерлек кискенлек, катылык чыгарганын тоймастан, дәвам итте:

— Халисә, чибәрем, элегрәк тәрәзәләренә такта кагып читкә киткән кешеләр хәзер яңадан авылга кайталар бит. Сине нихәтле яратсам да, ияреп китә алмыйм. Булмый! Авыр елларны китмәгәнне, хәзер ничек итеп туган ояны ташлыйсың. Булмый! Аннары, мине кем җибәрсен. Сайланып куелган кеше. Яхшымы-начармы, все же председатель.

Халисә, уйланып, сүзсез калды.

Шәрифуллин, бар дөньясын онытып, кинәт Халисәнең кулларыннан кысып тотты да янә кызып сөйләргә кереште:

— Син лучше үзең кал. Гел читтә йөреп туймадыңмыни инде? Мин сиңа зерә дә шәп эш бирермен. Подходящий эш... Үзең дә рад булырсың...

— Мин бит заводта, акчалы эштә.

— Монда да эш көненә буш таяк төшми хәзер. Ипекәйне буләбез, аз-маз акчасы да чыга. Аннан китереп, бәрәңгең, бакчаң, мал-туарың үзеңнеке. Квартирага түләсе юк. Шуларның барысын да чутлый башласаң, рабочыеңнан ким тормый авыл халкы.

Моңа каршы Халисә ни әйтергә белмичә, уйларының очын югалткан сыман, утыра бирде.

— Белмим шул. Мин инде шәһәр җиренә күнеп беттем. Аннары, җибәрмәсләр, Вәли абый. Мин анда начар исәптә түгел.

— Җибәрерләр, шундый майлап-җайлап, колхоз печәтен басып, отношение язып салырбыз заводыңа. Син күр дә мин күр, ике куллап риза булырлар.

Халисә эндәшмәде. Җәһәт кенә урыныннан торды.

— Ярар, житте, — диде ул. — Син бит семьялы кеше. Разияң янына кайт.

Шуны әйтеп, әкрен генә җил капканы ачты.

— Мин иртәгә дә киләм шушы вакытта, — диде Шәрифуллин.

Аның бу сүзләренә Халисә җавап кайтармады. Әллә үртәп, әллә кәефе шәплектән, аның җиңелчә генә көлгәне ишетелде.

Вәли әйткән сүзендә торды. Көнне ничек кирәк алай уздырып, кич белән тагын таныш капка төбенә килде. Колхозның Югары Тегермәнлек авылындагы кладовойчысына кереп, яхшы гына сыйланып та чыкканлыктан, аның кәефе бик күтәренке иде. Аракы исе килмәсен өчен авызына канәфер капты. Халисәгә калса, ул озак көттермәде, кичәгедән дә сафрак хуш исләр аңкытып, капка төбенә чыкты.

Авыл йоклый, урам тын. Йөрүчеләр күренми. Этләрнең дә өргән тавышлары бик сирәк ишетелә. Анда-монда сагашып кычкырган әтәчләр генә кай ара үзләренең дөньяда барлыкларын сиздертеп куялар иде. Болын ягыннан бөркелеп килгән бал исе, үлән-чәчәкләр исе татландырган ләззәтле һаваны рәхәтләнеп иснәп-иснәп, алар икәүдән икәү генә озак сөйләштеләр. Беркадәр йөреп тә килделәр.

— Үзебездә кал, беркая да китмә, — диде Шәрифуллин.

— Көне буе уйлап йөрдем. Әнинең дә җибәрәсе килми. Әллә нишләсе инде? — Бу сүзләрне Халисә аеруча ягымлы тавыш белән әйтте.

Икесе дә урыннарыннан тордылар. Бу юлы Халисә Шәрифуллинның үзенә сузылган кулларын этеп җибәрмәде, карулашмады. Шәрифуллин Халисәнең тыгыз, җылы күкрәгенә тәне тигәч, дөньясын онытып, аны кочаклап алды.

— Вәли абый, кеше күрер, ярамый, — дип пышылдады Халисә.

Шәрифуллин көлеп җибәрде:

— Бу караңгыда кеше түгел, чурт үзе дә күрмәс.

Бу көннәрдә Халисә саманнан салынган келәтне тыштан да, эчтән дә агартып, пөхтәләндергән һәм шунда куна иде. Ул бүген кичтән үк келәткә әйбәтләп урын җәеп куйды да, әнке януын һичкемгә дә белдермәскә тырышып, кемнедер көтте. Ләкин кемне көткәнен үзе дә белмәде...

Вәли нихәтле сыланса да, Халисәнең иреннәрен таба алмады — кыз һаман башын яшерде. Бер арада айнып киткәндәй, Халисә тегенең кочагыннан ычкынды, алай гына түгел, атылып чыкты. Үзе дә аңламастан, ниндидер тойгыларның тәэсире белән аның тамак төпләре кымырҗый башлады һәм ярсулы тавыш белән әйтеп салды:

— Бүтән килмәгез безнең капка төбенә!

— Нигә алай, акыллым, — диде Шәрифуллин гафу үтенгән сыман.

— Кулларыгызга бик артык ирек бирәсез. Белеп торыгыз, Вәли абый, мин сез уйлаган кеше түгел! — диде Халисә һәм, җилдәй очып, ишек алдына керде. Борылып та карамастан, шунда ук аның өйгә кереп киткәне күренде.

Вәли китеп, аяк тавышлары басылгач, шактый вакыт үткәч кенә, ул яңадан ак келәттәге йомшак урынына чыгып ятты.

Халисәнең йөрәгендә тартыш бара, ләкин аның ничек бетәчәген ул үзе төшенеп җитми иде әле.

* * *

Ул авылында калды. Шәрифуллин сүзләренә карап кына түгел, әнисен тынлап, үз күңеле тоюы белән калды.

Халисә әле кыз-кыркын чагында үз эшләре белән читкә киткәнче, тормыш авыр, көн күрү мәшәкатьле булган елларны күз алдына китерде. Балалык гомерләреннән алып күңеленә кереп утырган урамнар, ишек аллары, бәрәңге бакчалары белән зур-зур җир мәйданы биләп торган кечкенә, тәбәнәк өйләр (аңа шәһәрдән соң авыл өйләре бигрәк тә тәбәнәк күренде), ерактан ук сәлам бирүчән, кече күңелле кешеләр, йорт-хуҗалык арасында кайнашып йөргән мал-туар, тирә-яктагы иген басулары, авылдан ерак булмаган, хәзер тоташ яшел стена шикелле күренгән урман — һәммәсе дә аңа якын иде, туган иде, үз иде.

Тормыш кушу сәбәпле авылда борын-борыннан читкә китеп эшләү бик еш була иде. Гаилә, хуҗалыгында артык кул булган ир-ат, караңгы күзле кышкы көннәрдә читкә китеп, сезонлы эшләрдә йөриләр, аларның шунда төпләнеп калучылары, соңыннан гаиләләрен чакыртып алдыручылары да була иде. Сугыштан соң да читкә китүчеләр, яшьләр арасында солдат хезмәтен үтәгәч тә, туган ояга, туган туфракка кайтмаучылар аз булмады.

Халисә яшьлегенең чәчәккә бөреләнгән көннәрендә, моннан шактый еллар элек, ул чагында бригадир булып эшләгән Әтәч Мәлик сүзләрен исенә төшерде. Әтәч Мәлик ни диде әле ул чагында? «Болай барса, колхозда эшләргә кеше калмый. Күпләр авылдан эзләрен ялтыраталар. Тиздән авылда өйләнерлек егет, кияүгә барырлык кыз табып булмас...»

Мәлик бабайның шул сүзләрен хәтереннән кичергәч, Халисә их тыярсыздан көлеп куйды.

Ул авылдан аерылып торган соңгы еллар эчендә Югары Тегермәнлекнең тернәкләнә баруы, тәрәзәләре кояшка караган такта яки шифер түбәле яңа өйләрнең артуы, салам түбәләрнең торган саен кысрыклана баруы, әүвәлге елларны тыкрык арасы саен очраган, тәрәзәләренә такта кадакланган ташландык өйләрнең бер дә күренмәве, күпләрнең чит җирләрдән авылга әйләнеп кайтып, тормыш корулары Халисәнең икеләнүләрен берьюлы җимереп ташлаган кебек булды. «Аның сүзләре дә хак», — дип фикер йөртте ул Вәли Шәрифуллин әйткәннәр турында.

Менә берничә көн инде, кояш чыкканчы йокыдан торып, «ак канатлар» янына эшкә баруга әкренләп күнегеп килгән Халисә башыннан шундый уйлар үткәрде. Бүген дә ул иртән үк тавыкларга җим сипте дә, бәләкәй арба тартып, кычыткан, үлән җыярга якындагы урманга юнәлде. Көньяктан җылы җил исә; тирә-якта балкып нурланган саф яшеллек диңгезеннән күккә караса, бер-берсеннән өзелә-аерыла каядыр ашыгып аккан кар кебек ак болытларның матурлыгына сокланып таң калды. Печән өсләре якынлашып килгән җәйнең бу тулы, бу җылы, бу ямьле чакларында табигать кочагында аеруча рәхәт, аеруча күңелле иде. Җәйге күренешләргә сокланып туя алмаган Халисә урман юлы белән атлады. Һава шундый ләззәтле, шундый татлы, һәр тараф шундый хозур иде монда! Халисә ашыкмады. Әле яңа гына үзләре бәйләгән шәлләрен куанып ябынган кызларны хәтерләтеп, юкәләр саргылт-аксыл чәчәкләрен талгын гына селкетеп утыралар, алар тирәсендә бал кортлары кайнашалар иде. Аның чокырлы-чакырлы тар гына бу юлдан бер дә туктамый, гел барасы килде. Мондагы көч арттыра торган һавада Халисә бер талпынса күккә очып китәр сыман тойды үзен. Тора-бара ул, эше турында уйлап, йөрәген ниндидер өметләр белән ашкындырган хисләргә артык юл куярга теләмәде. Үлән кирәк иде, витаминга бай кычыткан кирәк иде кошларга. Халисә кы-

чыткэнның күп урынын тапты, аны җәһәт-җәһәт йолкып, капчыгына тутырырга тотынды.

Ярты сәгать тә узмагандыр, ул, дөмбәсләп тутырылган өч капчык салынган бәләкәй арбаны җиңел генә тартып, урманнан чыкты. Инде тавыклар фермасына якынлашканда, арттан автомашина килгәнне күреп, юл бирде. Артында тузан баганасы калдырып, машина килеп җитте һәм тукталып калды. Кабинадан ике ир кеше төштеләр. Аларның берсе шофер, икенчесе колхоз председателе Шәрифуллин иде. Әле күптән түгел генә булса кирәк, кара мыек тибеп чыккан шофер, иелеп, машинасын караштыргаларга кереште. Чигүле якалы ачык күлмәк өстеннән зәңгәрсу куртка, шул ук төстәге чалбар, башына кара күн фуражка, аягына кыска куннычлы күн итек кигән, чырае кояшкилдә йөреп көрәнсу төскә кергән Шәрифуллин, Халисә янына килеп туктагач, күрешергә кулын сузды:

— Мә бишне, уң булсын! Шәп кенәме?

Халисә, монда өченче артык кеше дә булгач, ничектер читенсенде, үләнгә буялган кулын оялган төстә тиз генә Шәрифуллинның киң учыннан тартып алды. Үзенә текәлгән күзләрдән карашын яшерде, аска карады.

— Хәлләр ничек, Халисә, эшләр? — дип сорады Шәрифуллин.

— Алай зерә дан да түгел, җимертеп зарланырлык та түгел.

— Уртачарак, значит? Шулаймы?

Моңарга каршы Халисә бер сүз дә әйтмәде. Шәрифуллин әкрен тавыш белән яңадан дәвам итте:

— Нигә үлән ташып йөрисең интегеп? Әйдә, сал капчыкларыңны машинага, уфалласы-ние белән фермага илтеп куйыйм үзеңне. Әй, Халисә, Халисә, шулай нужаланып йөриләрмени? Бригадирдан ат сорарга ярамаганмыни? Үзләре белеп ат китереп тоттырмаслар алар сиңа. Мин аларны...

Кече яшьтән үк мондый эшкә күнеккән Халисә председательнең бу сүзләрен уртаклашырга теләмәде. Шәрифуллин бәләкәй арбаны автомашина бортына салырга җитешкәнче, Халисә арба тәртәсеннән үзе тотты:

— Кирәкми, Вәли абый, ике атлам җирне болай да кайтып җитәрмен. Кеше көлдереп әллә! Хәзергә әле ат та кирәк түгел, ни дә...

— Болай авыр ла. Анңары килешеп тә бетми безнең заманда.

— Килешмәсә тагы! Эштән курыккан юк алай.

— Кыстамыйм алайса, ярый, ярый. Үземнең дә бер сугылып чыгасым бар әле сезнең янга. Житешеп булмый тәки. Эш, төрле мәшәкать, менә моннан, — Шәрифуллин уң кулын муенына куеп күрсәтте.

Ул Халисәне машинага утырту турында икенче мәртәбә әйтеп карагач та, Халисә риза булмады. Ахырында Шәрифуллин иңбашларын сикертте, Халисәгә карап, гаҗәпләнгәнрәк рәвештә җылы гына елмайды да кабинага кереп утырды. Тиздән, тузаннар уйнатып, автомашина тагын китеп барды.

Халисә үз юлында булды.

Басу капкасын чыгып, ярты километрлар чамасы җир киткәч — тавыклар фермасы. Ул артык зур түгел, саманнан салынган, кабык түбәле. Бу караltыдан читтәрәк, түр ягыннан бер, ян-ягыннан икенче тәрәзә тишелгән, мунча-хәтле кечкенә генә өй. Аны каравылчы өе дип йөртәләр. Тавыклар фермасының җыйнак кына ишек алды бар. Ул кайчандыр читәннәр белән әйләндереп алынган булса да, вакытлар үтү белән үрмә чыбыкларның яртысы гына калган, күп урында иңеп, авып, «кара мыекларын» туздырып ята иде.

Ә тавыклар? Бигрәк йолкышлары бар, бигрәк йонсызлары. Югыйсә, азык та бирәләр бит. Нилектән болай? Җәйнең тулы вакытлары,

ә кошларның йомырка салулары бик чамалы, бик чамалы. Ничек итеп эшне юлга салып, рәтләп җибәрергә?

Әле фермада күптән түгел генә эшли башлаган Халисәнең күңелен шундый сораулар борчыды, шундый утлар телде. Мәгәр, ныграк эшкә тартылган саен, аның шаянлыгы югала, көләчлеге кача, аптыравы үсә барды, башына каршылыклы уйлар килә торды. Ул кайчакта тасма телләргә алданып авылда калганына һәм аннан да бигрәк ак канатлар арасында эшкә кергәненә үкенгәли башлады. Бу хезмәттән ваз кичсә, әле ул яңа кеше, фермага башы керсә, аягы кермәгән дигәндәй... әмма шулай да уңайсыз иде. Мондый тойгы Халисәдән бер тотам да калмады. Боларга өстәлеп, аның йөрәк түрендә үзе аңламый торган әллә нинди каршылыклы башка хисләр дә кузгала торды.

Халисә авылда калырга риза булгач, Шәрифуллин аны фермада беркадәр эшләп күрше авылга кияүгә киткән бер кыз урынына кошчы итеп урнаштырды. Ул ферманың начармы, яхшымы икәнен әйтмәде. Тик: «Җиңел эш, сиңа подходящий эш» кенә диде. Тиз арада Халисә мондагы кешеләр белән танышып өлгерде. Ачыктан-ачык әйткәндә, фермада берничә ел буе эшләп каешланып беткән, монда бары хезмәтне ансат санап кына кергән өлкән яшьләрдәге шадра Мингаян Халисәгә беренче күрүдә үк ошамады. Ул гаять авыр санлы, акрын кыймылдаучан гына түгел, җитмәсә фермага төрле көндә төрлечә, йокысын туйдыргач кына килә, килгәч тә озак юанмый, тегендә-монда китә, биләмгә чаба иде. Мингаянның эремнән дә әче телле, гайбәтчән, кире кеше булуы хакында Халисә азмы-күпме белә иде белүен. Бу хатын башта үк аны ифрат төксе каршы алды. Үзенең шактый калын гәүдәсенә яраклаштырып, капчык шикелле итеп теккән чуар күлмәгенә чак кына сыеп тора төсле иде Мингаян. Беренче көннәрдә үк татарча дүрт почмаклап бәйләгән бөрчекле яулыгын әледән-әле иң өстенә җыйнабрак куя-куя, ризасыз төстә сөйләште ул Халисә белән. Кыскасы, Халисәгә ферма үзенең тамыр-сабакларын ерак җибәргән тәртипсезлеге белән куркыныч кебек күренде. Ул эшкә тотыну белән аның иң әчен пошырган нәрсә казыкка аякларыннан бәйләп түбәгә асылган өркеткеч ябалак булды. Ул Мингаянга сорау бирде:

— Бу ник кирәк монда?

— Шушы хәтле кош-корт арасында, әллә син теге, ник кирәк булмасын. Ул киндер орлыгы арасына куелган карачкы кебек. Ябалаксыз, әллә син тагы, менә әкият. Борынгылардан калган гадәт! — Шадра Мингаян үзен фермада гаять иркен, баш кеше, хуҗа кеше итеп күрсәтергә тырышты. Әмма Халисә аның белән ризалашырга теләмәде:

— Һич кирәге юк ул үләксәнең, Мингаян түти.

— Тапты сүз. Үләксә, имеш. Ул ябалак инде икенче елын эленеп тора, беләсең килсә. Ул кибеп беткән ич. Каз хәтле иде башта. Бу котсыз нәстәкәй, тырнагына тавык эләктереп киткәндә, Әтәч Мәлик мылтык белән атып алды аны. Шуннары тавык-чебешләргә тиюче булсынчы! Югыйсә, башта тәлке дисәң, карчыга-ябалагы дисәң, гел чәлдереп китәләр ие ак канатларны, гел каныгалар ие.

Халисә барыбер Мингаянның сүзләрен хуп күрмәде:

— Мингаян түти, алып ташлыйк аны. Иске заман гадәтләрен саклау нигә кирәк? Авыру тараткыч була аның ишеләр...

— Сөйләмә юкны, гөлкәй. Ул ашарга сорамый лабаса.

Мингаян белән сүз көрәштерүнең файдасызлыгын сизеп, Халисә ябалак турында бәхәсләшүдән туктады. Әмма бу әле аның чигенүе түгел иде.

Халисә икенче көнне фермага таң белән килде. Сүзен сүз итте, әйткәнендә торды. Ул, ферма ишеген ачып куеп, аңа терәү салды да шул ишеккә тотына-ябыша түбәгә үрмәләде. Һәм казыкка аягыннан бәйләнгән ябалакны таягы-ние белән суырып җиргә ташлады. Үзе түбәдән

төшкәч, бер кулына ябалак асылган казык, икенче кулына тимер көрәк алып, кошчылык фермасыннан читкәрәк китте һәм, чокыр казып, карачкыны шунда күмеп тә куйды.

Халисә фермага килгәч, үзенең кызулыгы белән оныткан икән. Ул бит каравылчыны күрмәде. Карана-йөри торгач тапты. Каравылчы карт — Әтәч Мәлик — кечкенә өйнең мич артына укмаштырып куелган тар гына сәкедә йоклап ята иде. Ул Халисәнең ишектән кергәнен сизмәде, ахры, урыныннан кузгалмады, борынын сызгырта-сызгырта йоклый бирде. Гүя кире ягы белән йокыдан торган шикелле, эченнән пошынган, усалланган Халисә кычкырып әйтте:

— Төнен дә шулай каравыллыйсыңмы, Мәлик бабай?

Әтәч Мәлик картларга хас булмаган бер җиңеллек белән урыныннан торды:

— Ул кайсы? Атам! Билләһи, атам! — Карт, кулларын мылтык төзәгән рәвешле көйләп, йокылы күзләрен көч-хәл белән ачып, Халисәгә текәлде. Каршында кем торганын күргәч, кинәт йомшап китте: — Ә, син икәнсең әле, кызым. Болай ник таңны куркытып йөрисең, балдай татлы йокыларыңны калдырып. Безнең шадра әнә слушийлар конторга барганда гына килә, банкада эшләгән апалар кебек. Ә син? Яңа себерке чиста себерә димәсәм...

Халисә эндәшмәде. Бераздан икесе дә ишек алдына чыктылар.

— Бабай, тикшер, һәрнәрсә үз урынындамы? — диде Халисә.

Мәлик карт монда барган булды, тегендә терек-терек йөренгән итте, кетәклеккә кереп чыкты.

— Һәрнәрсә үз урынында, кызым.

— Ә ябалак?

— Мәнә сиңа, хәерсез. Ул карачкы кемгә кирәк булды икән? Җил очыргандыр. Алай дисәң, күренми җирдә. Вәйт җен оргыры...

— Болай йоклап каравылласаң, тавыкларың-ниләрең белән ферманы күтәреп китсәләр дә сизмәссең, бабай.

— Юк, кызым, юк. Ябалак уписка кертелмәгән ул. Аның өчен мин җавап тотмыйм. — Аннары карт, шаяртуын бүлеп, җитди рәвештә дәвам итте. — Әзрәк ятып торыйм дигән идем. Күзләремне йокы баскан, ләгыйнь. Прсидәтелгә-мазарга теш араңнан сүз чыгарма инде, кызым. Артымнан картлык куа башлады бугай, урынга башым тиюгә күзләр йомыла, валлаһи...

— Курыкма, бабай, әйтмәм. Икенче йокламассың бит?

Карт эндәшмәде.

Шадра Мингаян, гадәтенчә, кояш яхшы ук күтәрелгәч кенә килде. Ябалакның алып ташланганын сизенгәч, пыр тузды, ата күркә кебек кабарып, дуларга керешге:

— Прсидәтелләргә ярарга тырышасың. Синең иртә килүеңнән ни файда? Янәсе мактау сүзләре ишетәсе килә аның. Ишетерсең әле. Күкәй буры да, күкәй буры дип күзеңне дә ачырмый башлар бераздан.

Халисә, аның сүзләрен ишетмәгән шикелле, тегә һич көтмәгәндә икенче яктан китереп суктырды:

— Мингаян түти, икебез дә эшкә бервакытта килик. Болай эленкесалынкы йөрү килешми.

Мингаян иң элек ни әйтергә белми аптырап торды, аннары чыгырыннан чыгып, кычкырып сөйләргә тотынды:

— Мәнә тагы, ишет ишетмәсәң. Ул гына җитмәгән икән. Кала җирендә рабучий халкы сәгатьләп эшлиме? Эшли. Мин әле монда сигездән дә арттырып җибәрәм. Тот капчыгыңны, әкият.

— Ферманың бер дә рәте-чираты юк бит. Шуңа эчең бер дә пошмыймыни синең?

— Пошса соң, мин ни чара кыла алам? Мин үзем утырып күкәй

сала алмыйм лабаса, чибәркәй. Әнә прсидәтелләр кайгыртсын, аларның башы дәү...

Ул көнне алар башка сөйләшмәделәр. Кәефе киткән Мингаян көне буе кашын җимереп йөрде. Шулай да үзе бүтән көннәрдәге кебек фермадан иртә китмәде. Тик кичкырын гына, җиңелгән кыяфәт белән, әмма чәнчеп, телгә килде:

— Бар икән нәфсесе киң кешеләр... Алай мине бик күпсенсәң, үзең генә кал. Эшлә! Барыбер медаль ала алмассың. Минем йортымда малтуарым, тегесе-монысы бар. Таң тишегеннән торып монда килә алмыйм мин. Тавыклар миннән башка да йөри беләләр. Син әле бәлки аларны подручкым алырга да кушарсың. Үтә кызыл тиз уңа ул, беләсең килсә, чибәркәй.

Зәһәр һәм хәйләкәр Мингаянның бу сүзенә каршы Халисә берничек тә җавап кайтармады. Ул, кичен каравылчы Мәлик карт килгәч тә, фермадан китәргә ашыкмады.

Җәй көне дә аягына киез итек киеп йөри торган, бераз арка бөкресе чыккан чандыр гәүдәле бу карт, бик тә шаян табигатьле кеше булып, тавыклар фермасында берничә ел инде каравылчылык хезмәтен үти иде. Фермага килешли, аңа читәнле тар тыкрыкта Мингаян очрап, Халисә турында тетмәсен тетеп хурлап сөйләргә дә өлгергән иде инде. Карт, Халисәнең күңелсез чыраен күргәч, түзмәде:

— Шадра усал белән борчагыгыз пешми бугай, кызым. Ифрат алама хатын шул ул. Көн уздырып, сандали туздырып йөри торганнарның берсе, чурт. Көнгә бер тавыш чыгармаса, аның күңеле булмый, ашаганы тамагына аркылы ята. Син аның сүзләрен тыңлама, кызым. Үзеңчә эшлә. Иншә алла, бик күңел куеп йөрисең шикелле. Көяләк җанлы син, билләһи.

— Бер исәбенә кереп, эшкә тотынгач, ерып чыгасы килә бит. Җиренә җиткерәсе килә. Йөзгә кызыллык китерәсе килми, бабай, — диде Халисә.

Каравылчы карт белән Халисә беренче көннәрдән үк шулай дуслашып киттеләр. Ләкин картның кызык гадәтләрен Халисә белеп җиткерми иде әле.

Читән буйларында Мәлик карт кешеләргә: «Мин төнге эштәге адәм. Колхоз милкен, җәмәгать милкен солдат кебек саклыйм. Менә ничә ел инде, төнлә бер тамчы да йоклаганым юк. Көндезләрен генә азрак черем итеп алам», — дип сөйләнсә дә, каравылда чакта һәр көн билгеле чамада йоклаштыргалый иде.

Халисә урманнан үлән җыеп кайтканда, ул китмәгән иде әле. Ләкин Халисә ферма ихатасында картны күрмәде. Тик бераздан гына каравылчының нидер әйтеп кеткелдәп көлүе колагына килеп сугылды. Әтәч Мәлик кечкенә өй артында икән. Ул өй бүрәнәсе янына чүгәләп утырган да, авызын ачкан килеш, телләрен чыгарып, хәлләре бетеп әтәчләр сугыштыра иде. Сак кына янына килеп туктаган Халисәне күргәч тә, карт, аңарга артык илтифат итмичә, үз шөгыленда булды:

— Бирешмә, бирешмә, әй, тиле Гарәфи! Күзең чыкканмыни! Кикригеннән, кызыл фәсеннән элдер шәкертнең. Шулай җебеп торалар рәзе... Хи-хи... Үшән... Син шул упшымҗитиядә тавыклар арасында торып, үзең дә тавыкка әйләнгәнсең. Эх, сатана, элдер! Ахти, җегетләр...

Берсе чуар, икенчесе чалбарлы ак әтәч дөньяларын бетереп сугышалар иде. Әтәчләрнең икесен дә карт бертигез күрә, ахры, чуары җиңә башласа, агын, агы җиңә башласа, чуарын яклап, әледән-әле тавышкуәт биреп тора иде.

Мәлик карт ачуланыпмы, гаҗәпләнепме шунда, янында күзәтеп торган Халисәгә карады:

— Менә шулай шаяртып та алабыз, кызым, кайчакта. Гел каш җыерып кына йөрергә димәгән бу дөньяда, шадра Мингаян сыман пыр



тузып. Чалбарлы белән Чуарны әйтәм, ферма эчендә алар сугышмыйлар, бер-берсенә кырын карап кына йөриләр. Икесе бергә ялгыз гына туры килделәрме — бетте инде, тыеп булмый аларны. Китә сугыш, китә кан коеш, наступление дә, наступление... Син миңа ачуланмыйсыңдыр бит, кызым?

Халисә ни әйтергә белмәде. Тик, ничек кенә булмасын, аның йөзендә төкселек елмаю сызыклары белән алмашынды. Бераздан карт, әтәчләрне аерып, икесен ике тишектән кетәклеккә куып кертте. Озакламый үзе дә Халисәгә ияреп фермага атлады. Монда әтәчләр тавышына түземе житмичә, карт ике куллап колакларын каплады. Халисә кычыткanны вак-вак бәйләмнәр белән стена буйларына элеп куйды. Аларны тавыклар сырып алып, чукып ашарга тотындылар.

— Менә бит аларга, мәхлукларга ни кирәк икән,— диде Мәлик карт.

Каралты эчендә һава авыр, тынчу иде. Халисә тәрәзәләрне күтәреп куйды. Фермада ярым шәрә яки бөтенләй диярлек шәрә кош-кортлар да күренгәли иде. Житмәсә, үч иткән шикелле, андыйларын үткәндә-сүткәндә бүтәннәре чукымый калмый. Халисә Мәлик картка аптырап карады:

— Болар белән нишләргә, бабай?

Мәлик карт, гадәтенчә, сирәк ак мыегын бөтереп алды һәм, үзенә киңәш иткәнгә куанып, хуҗаларча басынкы тавыш белән җавап кайтарды:

— Болар белән нишләргәме? Йоннарын йолкып интегәсе юк. Ул чуттан эше беткән. Күзне йомып суярга да казанга салырга, и беттекитте. Кунак чакырырга да була аннары... Үземнекеләр булса, валлаһи, суеп ашар идем. Ату бит ярамый, колхоз милке.

— Андыйларга яңадан каурый-йон үсмәсмени?

— Ай-һай, бу тиклесе безнең кодрәттән килер микән?

— Хуҗалыкта һич шәрә тавык күрмәссең. Ә монда, бабай? Аерым япсак андыйларны?

— Монда ишле бит алар, кызым, тавыклар ярминкәсе димәсәм. Утарларын киңәйтәсе бар. Монда аларга коеныргa көллек дисәң, көллеге юк. Ябылуда торалар. Күрше Чапай колхозының зерә дә шәп фермалары. Пулный пүрәткә аларда. Бездә әтәк-сәтәк кенә шул. Председателенең дә күзе төшми бу якка.

— Килермен, ди, булышырмын, ди ич.

— Өстәл артында утырган кеше вәгъдәне кызганмый инде ул анысы. Бара-бара үзең күрерсең әле менә, кызым.

Бүтәннәре беркадәр тынып торган кыска гына арада, бер шәрә этәч калын яңгыравыклы тавыш белән бик аһәңле итеп кычкырып җибәрде. Халисә белән Мәлик карт, гаҗәпләнеп, шуңа карадылар. Әтәч, тырмалып, канап беткән кызыл муенын сузып, тагын ике-өч тапкыр кычкырды. Мәлик карт көлеп җибәрде:

— Күлмәк-ыштанын салып ташлаган, кара син аны, тиле Гарәфине, ничек кычкыра. Шайтан мәлгунь шушы үзе түгелме икән? Кара, кара, тавык куган була, хәстрүш. Шушы булып шушының дәрте булгач...

Мәлик карт, бераз торгач, өзелгән сүзне тагын ялгап җибәрде:

— Шадра белән теге кияүгә киткән кыз китереп терәделәр кошларны.

Мәлик карт фермада озак юанды. Буе белән авып яткан читәннәрне утыртты. Тишек-тошыкларны каплады. Соңга гына калып эшкә килгән Мингаянның кәефе-рухы белән хисаплашмастан, Халисә кетәклекне тазартырга кереште. Бара-тора Мингаян да бу эштән читтә торып кала алмады.

Халисә ант эчеп куйды: «Шушы ферманы адәм рәтенә кертмәсәм, дөньяда йөрмәм!» Ул кояш баеп күз бәйләнер вакыт җиткәч кенә өйләренә кайтты.

Вәли Шәрифуллинга карата үзе дә сизмәстән ачуга якын ниндидер бер хис, бер тойгы аның күңелендә торган саен көчлерәк баш калкыта барды: «Кичләрдә безнең капка төбен таптый. Миңа сагыз кебек сыланырга йөри. Ә фермага эз дә басмый». Халисә шулай уйлап, иренен авырттырганчы тешләвен дә сизми калды.

* * *

Кичтән сөйләшенгән буенча, Шәрифуллин белән партоешма секретаре Әхнәф Садыйков басу карап кайтырга тиешләр иде. Ләкин, ни өчендер, партоешма секретаре тиз генә килмәде. Дөрес, вакыт иртә иде әле. Шулай да Шәрифуллин пошына башлады. Ул, түземе югалып, әллә ничә тапкыр тәрәзәгә карады. Кемнеңдер урамда казлар куып баруын, берничә хатын-кызның көянтә-чиләкләр белән чишмә тавы ягыннан су алып кайтуларын күрде. Аны бу күренешләр артык кызыксындырмады, тиз генә тәрәзәдән карашын алып, стена календарена күз төшерде. Узган көнгә алынмый калган битне ертып алып укырга кереште. Бары тик мотор тавышы ишетелгәч кенә, ул календарь укуыннан бүленде. Ике-өч минуттан партоешма секретаре Әхнәф Садыйков үзе дә колхоз идарәсе йортына килеп керде. Ул һәркайчандагыча әйбәтләп кырынган, шунлыктан иякләре күм-күк, өстеннән сирәк төшә торган гимнастеркасының җиз сәдәпләре ялтырый, фуражкасындагы кызыл йолдызы ут кебек янып тора иде. Шәрифуллин аңа баштанаяк сөзеп карап торды, председательнең чырае яктырып китте:

— Нигәдер соңлады парторг. Бүтән чагында зерә дә аккуратный булгач, мин сине бүген дә кичекмәс дигән идем. — Шәрифуллин җәһәт кенә сәгатенә күзен төшерде. — Киттекме?

Садыйков, аның сүзләренә җавап кайтарырга ашыкмыйча, билендәге сары каешын рәтләп куйгандай итте. Кабинеттан чыктылар. Садыйков педальгә баскач, мотор гүли башлады, һәм мотоцикл, зәңгәрсу төтен сызыгы калдырып, кузгалып та китте.

Күл буе чирәмлеге исеме белән йөртелгән төшне узып, ярты километрлар баргач та, сул якта арыш, уң якта кукуруз басулары башланды. Кукуруз начар, чүпле, сирәк, җитмәсә шактый урыннарда квадратлар дөрес чыкмаганнар иде. Садыйков алай-болай бу хакта сүз

кузгатса, Шәрифуллин үзенчә тапкыр гына җавап та әзерләп куйды. Партоешма секретаре, әллә башка турыда фикер йөртеп, әллә түземлелек күрсәтеп, ни өчендер тынлык саклады. Тагын бер биш-ун минутлар үткәч, кукуруз басулары бетеп, юлның һәр ике ягында тоташ арыш игеннәре җәелде.

Монда инде Шәрифуллин иркен сулыш алды. Аның бер дә ашыгасы килми иде инде. Шунлыктан мотоциклын һаман җитез куган Садыйковка кычкырып әйтте:

— Нигә ул кадәр куасың, әкренрәк булмыймыни? Арттан куып киләмиләр лә.

Алай да тыңламагач, тегенең җиңеннән тартты:

— Чабыш атыдай алып барасың. Күзләр атылып чыгар хәлгә җитте инде.

— Хитри син, Вәли дус. Кукуруз басуында, эш хөрти төштә, нихәтле чапса да риза булып бардың. Ә монда, арышның шәбрәк җирендә, әкрен барасың килә...— Садыйков башлаган сүзен әйтеп бетерә алмады, аның башындагы фуражкасы төшеп калды да ул тиз генә тормозга басты һәм мотоциклын туктатты. Садыйков фуражкасын алып башына киюгә, Шәрифуллин:

— Менә бит, фуражкаңның да төшәсе килгән икән. Син артык борчылма, Садыйков, кукурузның шәп җире дә бар аның, — диде.

— Ә монысы, без үтеп киткәне?

— Квадратлар дөрес чыкмаган шул. «Беларусь» белән эшкәртешле түгел. Кул белән чүпләрен утасаң, бердән, нихәтле эш көне кирәк, икенчедән, үзкыйммәт күтәрелә. Моны инде яшел конвейер өчен генә файдаланырга туры килер.

— Шулай дип аклансаң гына. Ничек кенә булмасын, дустым, кукуруз участокларын аерым механизаторлар җаваплылыгына беркетмичә начар итәбез без. Күршеләр әнә...

— Беләм, беләм, — дип, Садыйковның сүзләрен бүлдерде Шәрифуллин. — Үзеңнең күз алдында ич. Хуҗалык бәләкәй түгел. Әле теге эш әле бу эш дигән шикелле... Колхозда бит эш дигәне тавык чүпләп бетерешле дә түгел. Бер төрле планлаштырасың, ә ул икенче төрлерәк килеп чыга.

Авылда торган саен, кырларда йөргән саен уй-карашлары киңәя барган Садыйковның эш-планнар турында үз фикерләре туып килә иде инде. Чыннан да, менә кукурузны кирәгеннән артык күбрәк чәчәләр түгелме соң? Аннары, юрганыңа карап аягыңны сузмагач, бик алай җанны куандырырлык та килеп чыкмый бит. Әле әзләре дә суынып бетмәгән шушы артта калган елларның берсендә кукуруз бик уңып аның яртысы алынмыйча әрәм булып калуы турында да Садыйковның колагына килеп сугылган иде. Орлыгы көньяктан килгән бу үсемлекнең безнең тарафларга ияләшеп җитмәве аркасында диикме, яки булмаса, сводкада алдынгы булу өчен, кукурузны туфрак тиешенчә җылынып бетмәс борын чәчү сәбәпле диикме, — аның һич тә күңел куандырырлык уңмаган еллары да була лабаса. Бәлки монда елның ничек килешен исәпкә алып җиткермәү дә өстәлә торгандыр. Күңел ишегеп шакып торган, аны борчылырга мәҗбүр иткән бу мәсьәлә турында Садыйков шул рәвешле фикер йөрткән хәлдә, яңадан башлаганына кайтып төште:

— Нигә кукурузны кирәгеннән артык күп чәчү белән мавыгабыз һаман? Башка культураларны кысрыклыйбыз. Хуҗалыкка зыян булып төшә ич бу...

— Син үз акылыңдамы? — дип каршы төште Шәрифуллин.

— Төшенмим.

— Монда төшенмәслек бернәрсә дә юк. Безнең колхозда бу иң элек миңа кагыла. Югарыдан бирелгән күрсәтмәне үтәмәскә минем дә ба-

шым ике түгел, иптәш парторг. Менә әле бергәләп эшли-эшли үзең дә күнегерсең.

Председательнең әле яңа гына өзеп-кистереп әйткәннәрен ишетмәгән кебек, Садыйков һаман үз сүзен сүз итте:

— Безгә җиткерелгән план болай да бик зур. Әлеге дә баягы шул бүтән игеннәрнең сулышын тарайтырлык киң планны егерме биш-утыз процентка арттырып үтәү ник кирәк булгандыр тагы?

— Бәлки киметергә кирәк булгандыр планны, — дип зәһәрле елмайды Шәрифуллин.

— Һич тә шикләнмичә!

Шәрифуллин инде кычкырып, ярсуланып әйткәнен дә сизмәде:

— Моңа югарыдан берәү дә юл куймас. Анда синең белән минннән акыллыраклар утыра. Райком...

— Күрсәтмәләр колы булуны ташларга вакыт, минемчә. Без монда ни өчен ул чакта? Җирнең язмышын без үзебез хәл кыларга тиеш дип аңлыйм мин.

Бу минутларда төсенә җитдилек чыккан Шәрифуллинның ачуланыпмы янсә уйланыпмы тын калуын аеруы кыен иде. Хәер, Садыйков бу турыда уена да кертеп чыгармады.

Алар һәр ике яктан арыш игеннәре кысып тарайткан басу юлына — йомшак яшел чирәм өстенә утырып, аз гына вакыт ял итеп алдылар. Шәрифуллин папирос көйрәтеп җибәрде. Аның авыз-борыныннан чыккан зәңгәр төтенгә карамаска тырышып, Садыйков кесәсендәге кеч-кенә төргәктән конфет алып капты. Ул әле шушы арада гына тәмәке тартуын ташлаган, ләкин янындагы кешеләр тартканда, күңеле кытыклана, шундый чакларда конфет суыра иде. Садыйковның үз гомерендә тәмәкене өченче мәртәбә ташлавы булып, монысында инде ул ничек тә сүзендә торырга ант итте. Шәрифуллин, әлеге бәхәсне онытка кебек, авыз читенә елмаю сызыклары чыгарып әйтте:

— Чын тәүфикъ иясе булып эверелдең син. Гел устав буенча гына яшисең. Аракы эчмисең, тәмәке ташладың, хатын-кызлар артыннан да йөрмисең бугай...

— Я, тагы? — Садыйковның чыраендагы көләчлек сүнеп, төсе җитдиләнеп китте.

— Тагымы? Хәзергә шулай җитеп торыр. Бу бит, малай, дөньяга тумаганнар, аннан китереп, җир астында ятучылар гадәте. Дөнья булгач, бераз аның рәхәтен дә күреп калырга кирәк. Бар нәрсәдән дә отказ итә башласаң...

Садыйков, ачуланырга да, ачуланмаска да белмәгән бер кыяфәттә, аптырабрак калды. Чөнки Шәрифуллин үзенең уйламыйчарак әйткән сүзе белән аның иң авырткан җиренә тиде. Тәмәке, аракы турындагы сүз әле кечкенә мәсьәлә иде, аныңча. «Ә менә хатын-кыз турында нигә шулкадәр тупас итеп сүз уйнатырга?» Яшен тизлеге белән аның башыннан әнә шундый уйлар агып үтте.

Әхнәф Садыйковның матур гына башланып киткән гаилә тормышы һич көтмәгәндә җимерелде дә куйды. Аның хатыны Рабига моннан бер ел элек баладан үлеп китте. Баласы да, анасы артыннан озак тормыйча, салкын җир куенына керде. Үзе сөеп, йөрешеп алган хатыны фаҗигасе Әхнәфнең йөрәгенә кара кан булып савылды.

Урынсызга сүз көрәштергән Шәрифуллин хәзер менә Садыйковның йөрәген тагын кузгатып җибәрде. Кайдандыр, томаннар арасыннан, аксыл йөзенә саран гына елмаю сызыклары чыккан моңсу карашлы Рабигасы аның алдына килеп баскандай булды. Йөрәге кысылды.

Әхнәф әлеге авыр хәлдән һаман айнып җитмәгәнгә күрә, яңадан өйләнү мәсьәләсен һаман кичектереп килә иде.

Шәрифуллинның салгалавын Әхнәф белә, аны кызмача килеш халык арасында да күргәне бар, һәм аның хатын-кыз мәсьәләсендә то-



танаксызлык күрсәтүе турында кешеләрдән азмы-күпме ишеткән иде. Моңа чаклы ул, эчтән үзе ризасызлык күрсәтсә дә, бу хакта Вәлинең йөзенә бәреп әйтергә ничектер җаен туры китерә алмады. Дөресрәге, читенсенеп йөрде. Менә әле Шәрифуллин үзе сүз башлагач инде тынып калмады:

— Синеңчә, доньяда эчәргә дә типтерергә генә. Килешә алмыйм мин синең моңдый фикерең белән.

— Кара, мин уйнап кына...

— Юк, уеның-чының бергә кебегрәк синең. Мин инде эчүең турында кабатлап тормыйм. Хатын-кыз мәсьәләсендә дә йөгәнсезләнә башлагансың диләр. Әйе, хәтереңә авыр алма, сүзләр йөри, дускай.

— Нинди сүзләр, кем әйтә аларны?

— Мин уйлап чыгарган сүз түгел. Синең хатының бар. Алма кебек ике балаң бар.

— Я, куеп тор аларны. Син бигрәк әкият доньясына чумдың, Әхнәф дус.

— Бер дә әкият түгел. Минем сиңа дусларча әйтәсем килә. Тормыш юлы бер кыеклый башласа, аны турайту кыен була, дип укыганым бар минем ниндидер китапта.

Вәли үзен гаепле санарлык сәбәпләр күрмәде, эчтән усаллана барган хәлдә, акланырга тырышты:

— Бигрәк юкка күсәк күтәрәсең син. Мин кем белән йөрим, нигә читләтеп суктырасың?

Садыйков кырын яткан урыныннан торып утырды һәм Шәрифуллинның күзләренә текәлде. Үзенең бу сүзләрен әйбәт уйдан чыгып әйтергә теләгәнен ирештерде:

— Син кызма әле. Мин күсәк күтәрмим, син күтәрәсең аны. — Ул, аз гына аскы иренен тешләп торгач, дәвам итте: — Сине читтән кайткан Халисә белән чуала диләр.

Халисә исеме телгә алыну белән, Шәрифуллинга рәхәт булып китте. Ул, үзенә чәнчеп әйткән сүзләргә каршы, көлә-көлә җавап кайтарды:

— Әллә миңа кызлар белән сөйләшергә ярамыймы. Иске таныш... Бары шул гына, башка берни юк. Менә, бел!

— Булмаса бик яхшы. Гайбәт йөри. Син беләсең, сүзләрне колак янында борып җибәреп булмый. Ярый, сөйләшкән сүз ике арада калсын. Ачуланма. Мин иптәшләрчә әйтәм сиңа...

Әкрен генә әйтелгән бу сүзләр Вәли Шәрифуллинның колагына бик каты килеп сугылдылар. Ул көчәнеп елмайды:

— Ну акыл бирәсең син кешегә! Ну секретарь безнең... — Шуны әйткәч, ул сүз таба алмаудан гаҗиз кыяфәттә тын калды. Аннары әкрен, әмма эчке ризасыз тавыш белән өстәде: — Ярар, ярар, значит син җитмешне узган картлар сукмагына басарга кушасың. Уйлап карарбыз мондый киңәшне.

— Турысын әйткән туганына ярамаган, диләрме әле? Серкәң су күтәрми синең, Шәрифуллин, — дип, Әхнәф иң беренче булып урыннан торды.

Мотоцикл чирәмле тар басу юлларыннан, артында ара-тирә сыек кына тузан калдырып, саф, татлы һавалы яшел дулкыннар арасыннан калкулык-үзәннәрне үтә-үтә, алга чапты.

Кояш үзенең рәхимле елмаюы белән кырларны, бөтен җан ияләрен иркәли, ак канатларын җилләр иркенә куеп, берсеннән-берсе калышмаска тырышып аккан күперенке болытлар кай ара җиргә күләгә төшерсәләр дә, аларны җылылык һәм нур җиңә иде. Алар басуларны үтеп, байтак җирләрне карап йөрделәр. Арыш һәм сабан ашлыкларның күренешләре һәр икесенең күңелендә канәгатьләнү хисләре тудырды. Калган бригадалардагы ике-өч басуда кукуруз үсемлекләренең чибәр икәнлекләрен күреп, Әхнәф Садыйковның да борчылуы кими барды.

Еланлы елга чирәмлегенә башлаш участокта, яшел чуклар эчендә, рәт араларын эшкәртүче механизаторлар күренде. Шәрифуллин белән Садыйков беркадәр вакыт механизатор егетләр янына тукталып, сөйләшеп торганнан соң, яңадан үзләренең юлларын дәвам иттерделәр. Еланлы елга чирәмлеген үткәндә, Шәрифуллин бу урынны сөреп ташларга, киләсе елга анда кукуруз чәчәргә кирәклеге турында фикер төйнәп куйган булса да, секретарь белән алдагы күңелсез сөйләшүне хәтеренә китереп, бу хакта сүз ачмады. Башына килгән беренче исәпне әйтеп ташлады:

— Әйдә, урман аша китик, Алмалыга да кереп чыгарбыз.

— Бик шәп фикер. Мин ике куллап риза, — диде Садыйков.

— Может, бригадир да очрар. Торф чыгару ничек бара икән, — диде Шәрифуллин.

Мотоцикл казылмалы урман юлыннан алга элдерде. Монда, баштанаяк яшел киенгән агачлар күләгәсендә, һава тын, дымлы, тәнгә рәхәт бирүчән салкынча иде. Ике километрлар чамасы җир киткәч, алда якты зур аланлык ачылды, һәм, бер тар гына чокырга салынган күперне чыгуга, урман эчендәге тигез генә урынга утырган Алмалы поселогы башланды. Кечкенә авыл. Бер генә урам. Ләкин бу бүтән авыл урамнарына һич тә ошамый, гаять киң иде. Әйтерсең лә, беренче тапкыр күргән шикелле, урам уртасындагы агачлык һәм куе чирәмлек һәр икесенең карашын үзенә җәлеп итте. Алар мотоциклны бер юан гына агач төбенә куйдылар да рус капкалы ишек алдына таба атладылар. Шәрифуллин:

— Менә помбригадир өе. Әйдә, сугылып чыгыйк, — диде.

Тар гына ишек алды. Алты почмаклы такта түбәле яңа өй. Ишек алды түрендә лапас-абзар. Икенче як койма буенда кечкенә умарта бакчасы. Шуның белән янәшә — келәт сыман каралты. Кара балчыклы тигез ишек алдына берәр йөк чамасы ямь-яшел печән таратылган. Йомры гәүдәле, яулыгын өч почмаклап бәйләгән яшь кенә кыз кул тырмасы белән печәнне ачык лапаска таба этәрә. Аның кулында тырма җиңел йөри. Тәмле печән исе, җиләк исе белән аралашып, сулышка керә. Бәрәңге бакчасы ягыннан кызның анасы күренде. Какча гына төз буйлы, өстенә озын кара күлмәк кигән урта яшьләрдәге хатын сүз кушканчы, кыз әйтеп өлгерде:

— Әни, кунаклар бар.

Кара күлмәкле хатын күзләрен кысып, уң кулын каш өстенә куеп, килүчеләргә карады:

— Ә, Вәли, синме? Исән-сау гына йөрүме? Иптәшең беләнме? Сиклатар дисеңме? Әйбәт.

Өй алдының киң ишеге ачык булып, аннан буяу исе килеп тора иде.

— Өйгә керергә кыстамыйм инде. Төнәгеен идән-сайгакларны буядык әле менә, — диде хуҗа хатын.

Кояш кыздыра, ишек алдында һич түзеп торырга әмәл юк иде. Хуҗа хатын каралтының ишеген ачты. Шәрифуллин белән Садыйков шунда керделәр. Каралты дигәне кар базы өстенә салынган җир идәнле кечкенә лапас икән. Лапаска иске татар өйләрендә була торган сәке ясалып куелган иде. Безнең дуслар әлеге сәке читенә утырдылар.

— Тамак бик кипте, сусатты, — диде Шәрифуллин.

Хуҗа хатын шунда ук салкын әйрән китерде. Һәр икесе рәхәтләнеп, яратып эчтеләр.

Шәрифуллин хуҗа хатынга сорау куйды:

— Абзый көндез кайтамы?

— Кайткан көнне кайта, кайтмаган көнне — юк.

— Аның үз янына кагыласы штоли? — Шәрифуллин Садыйковка карады. — Помбригадир Гәрәй абзый тына торган кеше түгел ул. Нәрсә булса да эш турында кайгыртудан бушамый. Алар быел дөнья хәтле торф чыгардылар инде.

— Әйе, алай тик ятмый инде. Һаман шул колхоз чутыннан кайгыртып йөргән көне, — дип, председатель әйткәннәрен куәтләп җибәрде хатын.

— Ну, торасыз дөньяның оҗмахында! Каралтылар да бик җыйнак сезнең.

Хатын, күз читләре белән генә елмаеп, Вәлигә карады:

— Бер бездә генәме соң? Каралты-кура хәзер бик күп кешеләрнең төзек инде ул. Авылыбыз үзе бәләкәй генә булса да, алай зарланырлык түгел. Биргәненә шөкер, курмысы дисәң, курмысы бар, игене дисәң, игене уңа. Кругум урман асты безнең монда.

Алар шулай сөйләшкәндә кыз ишек алдында күренгәләп йөрде. Ул киптерергә тараткан печәнне җыеп бетергән иде инде. Әхнәф бер уңайда әңгәмәгә кушылды:

— Кем, апа, кызыгыз кайда эшли?

— Эшли дип, ул бит әле яшь, бала гына.

Нәкъ шул чакта кыз ниндидер йомыш белән каралтыга килеп керде. Әнисенең Садыйковка җавап сүзен ишетеп, уңайсызлана калды. Кызарынды һәм үзе дә сүз кыстырырга өлгерде:

— Әни, ташла инде мине баласытуыңны.

Моннан биш ай элек кенә партоешма секретаре булып сайланган Әхнәф Садыйков Алмалыдагы кешеләрне әле һаман ныклап белмәве өчен уңайсызланып куйды, аның колак очлары янарга тотынды. Бригадир ярдәмчесен күргәнче үк инде, шушы ябык хатын белән сөйләшү барышында, Алмалы кешеләренең колхоз эшенә бик сүлпән катнашуларын төшенеп алды Садыйков.

— Үзе матур булса да, колхоз тормышыннан читтә яши Алмалы, — дип куйды ул бер арада.

Хуҗа хатын аңа кашларын җыерып карады. Кыз аптыраулы кыяфәттә әйтеп ташлады:

— Мондагы матурлыктан тун тегеп булмый шул, абый. Минем фермага кереп эшлисем килә. Ә ул бездән ерак. Җитмәсә тагын ни клуб юк монда, ни кино күрсәтмиләр.

— Тик тор. Бар, әнә үз эшеңне бел, — дип боеру тавышы белән әйтте аңа әнисе.

Ләкин кыз урыныннан кузгалмады. Әхнәф уйга калды.

Бригадир ярдәмчесе аларга авылны чыккач очрады. Ул җиңел тарантаска җиккән ат белән урман ягыннан кайтып килә иде. Аңа, авыл җитәкчеләре белән бергә, яңадан торф чыгаручылар янына барырга туры килде. Вак кына таллар күренгән киң иңкүлектә балталар, тимер көрәкләр белән коралланган кешеләр эшлиләр иде. Алардан бер читтәрәк өч-дүрт урында торф өемнәре. Вәли Шәрифуллин Садыйковка борылды:

— Ну, малай, ашлама мәсьәләсендә күпләрнең борынына чиертәбез хәзер. Печәнгә төшкәнче әллә ничаклы чыгарып була әле торфны.

Садыйковка калса, монда кешеләрне тагын да күбрәк тупларга, өемнәрне тагын да зурайтырга кирәк сыман тоелды. Аның бу уйларын җөпләгәндәй, бригадир ярдәмчесе әйтә куйды:

— Кәсне шулай чыгарабыз инде. Астан су бик тиз тибә түлке. Аннары китереп, эш куллары да азрак.

Садыйков аның бу сүзен күтәреп алды:

— Бу алтын вакытны һич тә кулдан ычкындырырга ярамый. Өстәмә көчләр кирәк монда.

Садыйков белән Шәрифуллин торф чыгаручылар янында шактый озак тукталып калдылар.

Алар яңадан урман юлына чыгып, әкрен генә барганда, уң якта аланлык башланды. Садыйков, аланлык түрендә ат сыман киек күреп, Шәрифуллинның пиджак итәгеннән тартты һәм тиз генә моторны сүндерде.

— Нәрсә бар ул хәтле искитәрлек? — диде Шәрифуллин. Киек, алан түрендәге агач янында, башын күтәргән хәлдә, боларга карап тора иде. Бераздан аны Шәрифуллин да күрде:

— Бәй, поши бу.

— Әйе, шул.

— Алар үрчеде хәзер безнең урманнарда. Эх, нинди симез, елкылдап тора. Моннан нихәтле ит...

— Аны атарга ярамый бит.

— Төрле кеше бар дөньяда. Әлексә штраф, әләкмәсә... итен ашый.

— Нинди матур! Нинди матур! Монда кайткач беренче күрүем, — дип сокланды Садыйков.

Алар биеклеге олы торыклы ат кебек, арт саны, сырты елык-елык килеп торган көрәнсу төстәге бу матур һәм дәү киеккә хәтсез карап тордылар. Әнә китәр, менә китәр дип каушау кичергәндә, поши муенын сузып, башын күтәреп, үзе безнең юлчыларга карады. Аның башы ат башыннан киң һәм зуррак та булыр. Зур колаклары селкенеп куйдылар.

— Мин пошиның күзләрен дә күрдем. Гаҗәп матур киек! — диде Әхнәф.

— Әйтәсе дә юк!

Аларның күз алдында поши, салмак кына хәрәкәт белән, урманга агачлар арасына кереп китте һәм суга чумган шикелле юк булды. Дусларына хәерле сәфәр теләгән шикелле, аның артыннан яфрак, ботаклар, чыж-чыж сөйләшеп, киек киткән юлны бикләп калдылар. Поши киткәч тә әле алар шул урында берничә минут баскан килеш карап тордылар.

Байтак юл урап, басулар әйләнеп кайткач та, Әхнәф Садыйков тәнендә арыганлык сизмәде. Аның уйларында бер күренешне икенчесе алмаштырды. Тагы бер арада Алмалыны күз алдыннан үткәрде, җәйнең матур вакытында бик күпләрнең өйдә утыруы гаҗәпләндерде аны. Бу кем гаебе белән шулай? Аның әлеге соравына тормыш үзе җавап бирә кебек. Алмалыда колхозның бертөрле дә производство тармагы юк ич. Шунлыктан кешеләр үз кабыкларыннан чыкмыйлар. Шуңа күрә

анда бертөрлелек, күңелсезлек. Секретарьның уйлары куерганнан-куера барды.

Вәли Шәрифуллин да, ялгызы гына калгач, башыннан төрле уйлар кичерде. Болай Садыйков белән сөйләшкәндә үзен гайрәтле, бирешмәс сыман тотса да, чынлыкта исә, бу сөйләшү аның күңелендә авыр тәэсир калдырды. Моңарчы Халисәгә булган мөнәсәбәтендә ул үзенә хисап биреп эш итмәвен аңына китерде. Үзенең гаиләсеннән, Разиядан һаман читләшә баруын, күңеле белән Халисәгә якыная баруын хәтереннән үткәрде. Әлеге шушы эчке януларга өстәлеп, хуҗалык эшендәге төрле мәшәкатьләр, партоешма секретареның кисәтүләре Шәрифуллинның күңелен тырнап, кайнатып тордылар. Бара-тора ул күңелендә шундый уй беркетте: «Болай ярамас, сүзләр дә йөри башлады. Миңа су уртасында калырга ярамый. Я уң ярга, я сул ярга чыгарга кирәк. Әйе, бу минем шәхси эшем. Үз эшем».



## Әхмәт Ерикәй

●

Тамчыласа тамчы, тамчыласын,
Тамчыласын шаулап, шыбырдап;
Энже бөртегедәй җем-җем итеп,
Иөзек кашы төсле елкылдап.

Чәчәкләнсә шомырт, чәчәкләнсен,
Чәчәкләнсен хуш ис таратып;
Илһам биреп барлык былбылларга,
Бал кортларын үзенә каратып.

Җитәкләсә сукмак, җитәкләсен,
Җитәкләсен алга, гел алга;
Сукмак икән һәрчак әзер торсын
Олы юлга алып чыгарга.

1964.

●

Томан артындагы басулар
Якын гына төсле тоела;
Көннәр мавыктыргыч, тик алар
Күзгә яфрак кебек коела.

Үткән көннәр кире кайтмыйлар,
Аптыраштa кайчак каласың,
Кызганасың үткән вакытны,
Борчыласын, дулкынланасың.

Яши алмыйм ләкин каңгырып,
Үткән гомер өчен кайгырып...
Коелсалар көннәр, чәчәк сыман
Коелсыннар җимеш калдырып.

1965.

●

Эзләсәм дә яңа сүз табалмам,
Аңлаталмам мин бу юлы да:
Йөрәгемдә серләр океаны,
Тик сөйләмим мин ул турыда,
Тик сорашма син ул турыда.

Күзләремне йомсам, сине күрәм,
Минут саен карыйм юлыңа;
Йөрәгемдә хисләр өермәсе,
Тик сөйләмим мин ул турыда,
Тик сорашма син ул турыда.

Нинди ашкынулар, нинди дәртләр
Көч бирерләр икән җырыма?
Йөрәгемдә хыял киңлекләре,
Тик сөйләмим мин ул турыда,
Тик сорашма син ул турыда.

1965.

●

Ямьләп тора йөргән җирләремне
Ак каенның яшел бөдрәсе;
Ак каенлы борма юллар буйлап
Йөгерәсе килә, йөгерәсе.

Йөгерәсе килә, карамыйча
Үзәннәргә, сазлар, урларга;
Тик ашкыну көче тарта мине
Югарыга таба урләргә.

Йөгерәсе килә офыкларга,
Юллар шактый ерак булса да;
Офыкларга барып җитәрмен дип,
Күңел әле һаман ышана.

1965.

●

Аякларым кабат арымасын,
Беләкләрем кабат талмасын,
Яшьлек тә бит безгә ике килми,
Кайгылар да кабатланмасын.

Ике килми көннәр һәм еллар,
Мин теләмим кабатланырга;
Хыялланам гомерем эчендә
Кошлар кебек канатланырга.

Кире кайтмый аккан елгалар,
Кире кайтмый үткән гасырлар;
Аяк терәп тормыш сыртына,
Яшьләр яңа тарих ясыйлар.

Көч-кодрәте белән дәү заман
Алып килә чорга яңа дан;
Кабатланмый җирдә берни дә,
Бөтен нәрсә туа яңадан.

1964.

●

Елмайганга каршы елмаеп үт,
Якын күреп үт;
Зиһенең айнык булса, үзең башлап
Сәлам биреп үт.

Кул бирсәләр, син дә кулыңны бир,
Юл бирсәләр, юл бир;
Кимсетсәләр, гафил булып калма,
Сдачаны мул бир.

Төшсәң әгәр шаулы океанга,
Йөзеп үт;
Богау кидерсәләр кулларыңа
Өзеп үт.

Батырлар да, талантлар да үлми,
Моны һәркем белә;
Үтә куркак белән ялкау гына
Бөтенләйгә үлә.

Балкып яшә! Әгәр үлсәң, сине
Сагынсыннар;
Мәңге сагынсыннар, юлларыңа,
Эшеңә табынсыннар.

1965.

●

Киләчәкнең шаулы бер көнендә
Я мин булмам, я син булмассың;
Сине сагынып я мин йоклый алмам,
Я син күзләреңне йоммассың.

Еллар үтеп китә, сизмисең дә,
Кеше гомере кыска, бик кыска;
Уйлап туймый кеше, сулап туймый,
Гашыйк булып туймый тормышка.

Эзләнүдән туймый кеше фикере,
Тибеп туймый кеше йөрәге;
Ике гасыр яшәсә дә кеше,
Сүнмәс иде яшәү теләге.

1964.

●

Без яшь идек. Гүзәл яшьлекне без
Асыл ефәкләргә төрмәдек;
Назламадык аны, һәм шулай ук
Әрәм-шәрәм итеп йөрмәдек.

Яшьлегебез хәзер инде безгә
Томан аша гына күренә;
Еллар узган саен ераклаша,
Күңел генә аңа үрелә.

Мәйданнарда, гомер юлларында
Сирәк очрый инде кордашлар;
Күптән инде әби булып беткән
Без яратып йөргән туташлар.

Тормышны без мыскал белән түгел,
Зур үлчәүләр белән үлчәдек;
Яшьлекне дә якты киләчәкнең
Нигез ташы итеп түшәдек.

1966.

●

Кәефләнеп иртән уянам мин,
Ягымлы йөз керсә төшемә;
Боекканда дару шифа түгел,
Күңел сүзе кирәк кешегә.

Тик яшь кебек җылы, саф сүз генә
Күтәрәлә рухын кешенең;
Уйдырма сүз ханҗәрдән дә яман
Йөрәгенә хәтта көчленең.

Якты чырай, дуслар хәстәрлеге —
Тормыш ташкынында зур терәк;
Мин үзем дә сусыйм игътибарга,
Үземә дә җылы сүз кирәк.

1966.

*Зәки Нури*

# Уйланулар һәм елмаюлар

## Дөреслек

Ут капканда сүрелми һәм сүнми ул,
Җил какканда бөгелсә дә сынмый ул.
Каралып та, таралып та ятмый ул,
Нинди суга салганда да батмый ул.

Киртәләрен юлның кичә ала ул,
Юлда барыбер маяк булып кала ул.
Аңа каршы көчне ялган табалмый,
Чөнки сулар үргә каршы агалмый.

## Юлларыбыз

Юлга чыксам, никтер, уйлыйм кайчак:
Мин диңгездә, ә син һавада,— дим,—
Йөзү кыен сиңа диңгез айкап,
Менә алмыйм очып һавага мин.

Бу дөрес уй. Инде күпләр белә
Ерак юлда бик күп булганны без.
Диңгезләрне биек күкләр белән
Кавыштырмый калмас юлларыбыз!

## Байлык һәм сайлык

Бай булалар дуслары күп кешеләр,
Белеме зур булган кеше бай була.
Белемсезләр тирән суга төшмиләр,
Андыйларның йөзүләре сай була.

Җыр яраткан кеше күңеле бай була,
Касәң тирән булса — ширбәт күп керер.
Юл күрмәгән бик мактанчык тай гына:
«Мин анамнан элек тудым»,— дип йөрер.

## Сүз һәм күз

Әйтте берәү: миңа матур йөз кирәк,
Йөзне бизәп янып торган күз кирәк!..

Ә мин әйттем: шуны, дускай, бел,— дидем,—
Чын матурлык күңелләрдә ята ул,
Ә күңелгә алтын ачкыч — тел,— дидем,—
Сөйләшмичә аңлашулар хата ул.

Тел күрке — сүз. Киңәшчең ит сүзне син,
Сайлаганда җанга якын күзне син.

## Бердәмлек

Телим сезгә аерылгысыз бердәмлек:
Кәгазь белән каләм төсле булыгыз!
Уртак булсын җилкәләргә менгән йөк,
Бер җыр булып калсын җирдә юлыгыз.

Телим сезгә шундый тату бердәмлек:
Бармак белән тырнак булып калыгыз!
«Ялгызлыкның куркынычын күрмәдек!»
Дигән сүзне кыю әйтә алыгыз.

## Нәрсәне эшләмәү яхшы?

Кешеләрнең киң күңелен тар итмәү,
Эштә юкны буш сүз белән бар итмәү,
Узам! дигән мактанчыкка юл бирмәү,
Кесәсендә таш йөрткәнгә кул бирмәү.

Исереп атлап тар урамны киң итмәү,
Көн яктысын ай нурына тиң итмәү,
Тәбрик сүзен ялагайдан сөйләтмәү,
Аюны бал ятарырга өйрәтмәү...

## Киңәшне яклап

Юлны юлчы, ә юлчыны юл аңлый,
Кем күп йөрсә — юлны күбрәк шул аңлый.
Киңәшсезләр чын көрәшче булалмый,
Чебешкә тилгән киңәшче булалмый.

Ары барып бире бәрелим димәсә,
Җилкәнче юлда җил белән киңәшә.
Ә әдипнең киңәшчесе син, тәнкыйть.
Ләкин бул син дөрес, тирән, киң тәнкыйть!

## Зурлык

Нәни ермак зур көртләрне агыза,
Нәни очкын зур янгыннар кабыза.
Зур агачлар үсә нәни бөрелән,
Юл кыскара — туктамасаң йөрүдән.

Тамчы булып өстәлсен зур агымга
Барчабызның, дуслар, матур эше дә.
Бер нур булыйк барча көннәр таңында,
Шуннан да зур бәхет бармы кешегә?

## Явызлар һәм ачык авызлар турында

Бәрән капка ачмас бүре керсен дип,
Куян юлга басмас аучы күрсен дип.
Яшәгәндә әле ерткыч-явызлар,
Кирәк түгел андый ачык авызлар.

Кирәк түгел яман эшкә юл кую,
Усаллар ниятен яклап кул кую.
Андыйларга рәхимсез ут сиптерик,
Төбе-тамыры белән йолкып киптерик!

## Өр-яңа әкият

Тик кичәге янгырдан соң шытты ул,
Бүген исә трибунага чыкты ул.
Китте тезеп: ничек иҗат итәргә...
Кемнәр үрнәк... кемнән башлап китәргә...

Бер сүз әйтсә, ике цитат китерде,
Сибелде сүз — бүрткән борчак шикелле.
Без елмаеп кайтып киттек өйләргә...
Калды бу хәл әкият итеп сөйләргә.

## Кыеннан курку

„Бинектәге яфрак миңа кирәкми!..» —
Дигән Куян, башын терәп бер талга.
Ә бер Филнең, түзмәс минем йөрәк дип,
Гомер буе менгәне юк бер тауга.

Кешенең дә пошмаслары булгалый—
Тик әзерне, тик түбәннән кырка ул,
Биргәне бар — җитә безгә шул да, ди,
Кыен эшкә көч куюдан курка ул.

## Аю белән аю баласы

— Әгәр аучыга тап булсам,
Ничек каршы торыйм, әнкәм?
Башны саклап калыр өчен
Нинди хәйлә корыйм, әнкәм?

— Хәйлә күп ул. Әмма ләкин
Шуны искә алу яхшы:
Мылтыклы кеше күзенә
Күренмичә калу яхшы!

## Бюрократ васыяте

Арагыздан киткән чакта
Шушы сүзем калсын минем:
Карамаска сезнең якка
Ике күзем калсын минем.

Бүлмәм калсын — кеше килеп
Чират тормый кермәс өчен.
Телем калсын — «Ярый!» диеп
Уңай җавап бирмәс өчен.

Кулым калсын — катлы-катлы
Приказ язып торыр өчен.

Миннән риза түгел затның
Колакларын борыр өчен.

Кулым калсын — эшнәләрнең
Бүләкләрен алыр өчен,
Миңа каршы дәшмәгәнне
Мактап имза салыр өчен.

Калсын минем колакларым
Кеше зарын ишетмәскә.
Калсын минем аякларым
Мәҗлесләргә кичекмәскә...

## Ябалак

Кәгазь — алда, каләм — кулда.
Кукыраеп утыра ул да.
Эшен дуслар җайладылар —
Завхоз итеп сайладылар.
Күзләр инде ялт-йолт итә,
Счет һаман шалт-шолт итә.
Саный урман байлыгын ул—
Көнлеген һәм айлыгын ул.
Үзен эштә ут дип саный,
Миннән зур зат юк дип саный.

Дусын тәбрик итәр өчен,
Хәлен белеп китәр өчен,
Беркөн Чыпчык керә аңа,
Сәлам һәм кул бирә аңа.
Ә Ябалак карамый да.

— Ник дәшмисең? Кара, нигә
Үз дусыңны танымыйсың?
— Ә син кем соң? Танымыйм шул.
— Без бит күптән, иптәш, белеш!
— Я, ник килдең, нишләп йөреш?
— Бөтен урман сөйләп йөри,
Пышылдап һәм көйләп йөри
Сукырайган икән син, дип...
Чынлап сукыр икәнсең бит!
Күреп чыгыйм диеп килдем
Шуны үз күзләрем белән...

Килешмәскә мөмкин түгел
Чыпчыкның сүзләре белән:
Хәтәр чир ул кукыраю —
Масаюдан сукыраю.

*Сәгыйт Таҗетдинов*

# ҮЛЕМНӘН ЯШӘҮГӘ

## Документаль повесть

**Русчадан В. НУРУЛЛИН тәрҗемәсе.**

**«Әйе, иректә яки төрмәдә намус белән батырларча сугышып үлгән иптәшләрнең онытылуларын теләмим мин...»**

***Юлиус Фучик.***



*Таҗетдинов Сәгыйт Абдулла улы 1901 елда хәзерге Оренбург өлкәсе Саракташ районы Карагуҗа авылында көтүче семьясында туа. Бик яшьләй эшкә керешеп китеп, Октябрь революциясенә кадәр атасына көтү көтешә. Ә 1919 елда, үзе теләп, гражданнар сугышына китә һәм, пулеметчы буларак, Махно, Мамонтов, Петлюра бандаларына каршы актив көрәшеп йөри. Шуннан аның тормышы хәрби хезмәт белән бәйләнеп китә. 1921 елда ул командирлар курсында укый, 1923 елда берләштерелгән татар-башкорт хәрби курсын тәмамлый, шул ук елны партия сафына алына. 1928—1937 елларда, башта рота, аннары батальон командиры булып, Казанда хезмәт итә. 1938—1941 елларда хәрби академиядә укый, подполковник дәрәҗәсенә күтәрелә. Фашист илбасарлары илебезгә басып кергәч, фронтка китә. Әмма озак сугышырга туры килми аңа. 1941 елның октябрендә, каты яралы хәлендә, фашистлар тарафыннан әсир ителә. Башта аны бер лагерьдан икенчесенә күчереп йөртәләр, соңыннан Дахау концлагерена озаталар. Анда ул ике ел тоткында яши.*

*Хәзер иптәш Таҗетдинов отставкада. Әмма ул хәзер дә бик күп җәмәгать эшләре алып бара: колхозчылар, эшчеләр, студентлар, мәктәп балалары һәм солдатлар белән әледән-әле очраша, докладлар ясый. Ул Бөтенсоюз «Белем» җәмгыятендә, Оренбургтагы край өйрәнү музееның гыйльми советында һәм «Революцион, сугышчан һәм хезмәт даны клубы»нда член булып тора. Соңгы елларда Сәгыйт ага Дахау концлагеренда әсирләрнең тормышын һәм фашизмга каршы көрәшен чагылдырган повесть язды. Журналыбызның бу санында аның шул повестен урнаштыра башлыйбыз.*

### Җиде тәмугның берсе

Ике граната. Берсе — озынча, агач саплы. Икенчесе — түгәрәк, безнең «лимонка»га охшаш. Әгәр мин яки бүтән бер кеше шул гранаталарны күзәтү пункты окобыннан алып кире ыргытырга өлгергән булса, ул чагында, ихтимал, минем язмыш бөтенләй башкача булган булыр иде. Дивизиянең икенче эшелонына куелган сугышчан бурычны ачыклап торганда, телефон трубкасын ташлап, агач саплы гранатаны алып ыргыттым ыргытуын, әмма шул арада коточкыч

каты шартлап икенче граната ярылды. Башыманиндидер авыр әйбер белән китереп органдай булып, аягым утка баскандай өтелеп китте һәм мин җиргә егылдым. Шул вакыт күземә немецларның окопка сикереп төшүләре чагылып калды... Күрәсең, күпмедер вакытка аңымны җуйганмын.

— Комиссар? Комиссар? — дип немецлар акырып торган чакта һушыма килдем.

Күкрәгемә туп-туры автомат көпшәсе төбәлгән — немецлар минем якадагы өч шпалны күреп алганнар иде.

— Юк, юк! Комиссар түгел! Офицер! — дип кычкырдылар сугышчылар.

Сугыш башланганга нибары дүртенче ай гына булуга карамастан— бу хәл 1941 елның 2 октябрендә булды — без инде беләбез: немецлар бөтен политработникларны, аларча әйтсәк, комиссарларны рәхимсез рәвештә юк итеп баралар. Комиссар дигәннән, мин командалык иткән беренче укчы полк комиссары Сизов Дрогобуж-Ельня участогында немецлар безнең фронтны өзәр алдыннан гына һәлак булды — түбәнтен генә очкан немец истребителеннән атылган пуля аның нәкъ йөрәгенә тигән иде.

Күзләремне каплап алган канлы элпә аша күрәм: әлеге шартлау мине генә түгел, минем адъютантны һәм дүрт элемтәчене дә авыр яралаган икән. Якында гына ятучы яшь солдатның эчен граната кыйпылчыгы ярып киткән һәм аның йөзенә инде үлем аклыгы да тарала башлаган.

Немецлар — мин аларны беренче мәртәбә шушылай якыннан күрәм — кискен, ямьсез тавышлар белән ниндидер боерыклар бирәләр. Безнең сәламәт сугышчылар, әйтеп бетергесез ачулы кыяфәт белән, берни аңламыйча, иңбашларын җыералар. Кызыл битле тәбәнәк немец, ишарәләп, мине һәм башка яралыларны плащпалаткаларга салырга һәм әсирләрне җыю пунктына алып барырга куша.

Беркайчан да онытмам мин ул көнге хәлләрне! Авырайган, бик нык сыкрап-сызлап торган башта һаман бер фикер кайный: мин әсир! Сон бу бит үлемнән дә яманрак! Ничек болай булуын һич аңлый алмыйм. Әле кайчан гына сугыша башлаган идек, инде немецлар безнең җир буйлап һаман саен эчкәре атлыйлар... Украинаны бөтенләй диярлек алдылар. Белоруссияне... Һәм мин, тәҗрибәле офицер, гражданнар сугышында катнашкан кеше, шушылай ансат кына, көтелмәгәндә әсирлеккә эләктем... Ярдәмсез, канга батып ятам... Фронтка китәр алдыннан полкта үткәрелгән митинг хәтергә төшә. Ораторлар немецларны берничә ай эчендә туздырып ташларга вәгъдә бирәләр... Ул чакта югарыдан бирелгән боерык хәзер ачы ирония булып яңгырый: Берлинның үзәк мәйданында парадта катнашыр өчен үзең белән парад киемнәре алырга... Тиз генә җиңү урынына, менә сиңа... Хурлыклы әсирлек!.. Әсирлектә мине ниләр көткәнен аз гына күз алдыма китерә алган булсам да, ул минутларда мин түзә алган булыр идем микән?..

Колонна ярты чакрымга диярлек сузылган. Немец солдатлары окоплардан, чокыр-чакырлардан һәм урман кырыйларыннан йөгерә-сөртенә совет сугышчыларын эзлиләр. Сакчы да арткарак калган, чөнки кайдадыр атыш башланган һәм барысы да шунда ташланганнар иде.

Мине плащпалаткада алып баручы солдатлар тигез атламыйлар, чайкалдыралар, шунлыктан яраларым тагы да катырак сызлый... Сазлыклы, түмгәкле урыннардан баруыбыз, ямьсез көзге пейзаж, янып яткан немец танклары хәтеремдә калган. Ниндидер бер юеш үзәнлеккә җиткәч, сугышчылар туктадылар:

— Иптәш командир, ачыгыз күзегезне! — дип пышылдап әйткән тавыш ишетелде.

— Партия билетларын нишләтәбез?

Бу сорау мине ярым һушсыз хәлдән бик тиз айнытып җибәрде. Баш чатнап-чатнап авырта, чигә тамырлары ярылырдай булып тибә. «Безнең партия билетлары ничек тә дошман кулына эләгергә тиеш түгел!» дип уйлыйм мин. Ләкин кая яшерергә соң аларны? Бер генә чара — күмәргә генә мөмкин. Урман сукмагының уң ягында, кызгылт-сары яфракларын кылтыратып, бер усак үсеп утыра.

— Шушы агач төбенә күмегез! — дип боерык бирәм. Озын буйлы бер сугышчы ашыга-ашыга пәке белән чокыр казый. Коры кул белән генә булса да, аңа тагын ике сугышчы булыша. Кызыл тышлы сигез кенәгәне кемнеңдер кулъяулыгына төреп, өстә коры яфрак, аннары туфрак белән күмеп куялар. Бу минутларда миңа башым гына түгел, йөрәгем дә яраланган кебек тоела...

Җыю пунктында яралыларны аннан-моннан гына бәйлиләр. Әсирләр һаман өстәлә тора. Кайберләрен, мине алып килгән кебек, плащ-палаткаларга салып китерәләр, кайберләре, иптәшләренә тотынып, титаклап килә. Немец солдатлары әсирләргә мылтык түтәләре белән төрткәлиләр. Ачулы тынлык. Ә бит монда өч йөз кеше җыелган югыйсә. Минә әсирләр белән тулы аланга немец офицерлары утырган җиңел машина килеп чыга. Алар арасында җиңенә кара свастика теккән бер генерал да бар. Һәм шунда мин беренче мәртәбә нацистлар сәламләшүен ишетәм: «Һайль Гитлер!» Моны, кулын алга сузып, бер майор кычкыра. Генерал да нәкъ аныңча итеп җавап бирә.

Хәрби әсирләрдән сорау алу башлана. Бу эшне майор башкара. Башта ул безнең турыда күп белүе белән шаккатырмакчы була:

— Сезнең полк командиры булуыгыз безгә мәгълүм,— ди ул, миңа күрсәтеп. — Без беләбез: сезнең дивизия командиры — генерал Бобров. Сезнең өчен сугыш бетте инде. Бөек Германия гаскәрләре сезнең җир буйлап җиңеп баралар. Озакламый без Мәскәүдә булачакбыз.

Аннары ул үз янында торган генералны — корпус командирын — безнең дивизиянең кайда оештырылуы һәм аның нинди төп артиллерия белән коралланган булуы кызыксындырганын әйтә.

Мин, агачка аркам белән сөялеп, җирдә утырам. Кан күп югалганлыктан, бик туңам, күңелем болгана. Колагыма ук иелеп, майор теге сорауларны саф рус телендә яңадан кабатлый. «Немецлар шулкадәр беркатлы микәнни соң: ничек инде тиктомалга, ансат кына совет офицеры хәрби серне ачып салыр дип өметләнә икән алар? — дип уйлыйм мин.— Бәлки, алар безне куркудан әйтерләр дип уйлый торганнардыр. Җан саклап калыр өчен, үзебез белгәннең барысын да сөйләп бирербез дип ышаналардыр?..»

— Дивизиянең кайда оешканлыгын белмим — полкка күптән түгел генә килдем, — дим мин. — Ә икенче сорауга җавап бирмим... Мин ант кабул иткән... Илемә хыянәт итәргә теләмим... — Аннары татарчалатып: — Бар, олагыгыз әле моннан, — дим.

Майор, минем соңгы сүзләремне аңламыйча, кабат сорый. Аннары, кәефе кырылганга йөзен җыерып, тагын бер сорау бирә:

— Сез коммунистмы?

— Юк,— дим мин. Иң изге нәрсәдән шушылай баш тарту чиксез-чамасыз авыр, әмма мин: «Һәр фашист шакшысына партиялеме-юкмы икәнемне әйтеп торырга мәҗбүр түгелмен!.. — дигән фикер белән үземне юатырга тырышам.

Башым шаулап-чатнап торуга карамастан, хәзер инде мин кайбер нәрсәләрне аңлый башлыйм: әйе, командирларның фамилияләренә кадәр белгәч, немецларның разведкасы начар эшләми булып чыга бит! Бәлки тиеш булмаган нәрсәләрне кайбер әсирләр әйткәндер? Бик күңелсез хәл бу...

* * *

Өченче октябрь. Мин Рославль лагеренда. Көн салкын, пычрак. Туктаусыз кар катыш яңгыр ява. Аяк астында балчык чыпырдый. Башкалар белән бергә мине дә бер катлы таш бинага урнаштыралар. Белмим, элек монда нәрсә булгандыр. Мәктәп булган булса кирәк. Пыялалары ватык, хәтта кайбер тәрәзәләрнең рамнары ук каерылып ташланган. Шуннан үзәккә үткеч ачы җил өреп тора, яңгыр тамчылары чәчри. Авыр яралы сугышчылар һәм офицерлар арыш саламы җәелгән идәндә яки аскы нарларда яталар. Җиңелрәк яралылары нарларның икенче катына урнаштырдылар.

Немецлар безгә медицина ярдәме күрсәтергә кирәк санамый. Утсыз, сусыз, бернинди уңайлыксыз бу таш йортны лазарет дип әйтергә ярасә — ул лазаретның бөтен хезмәт күрсәтүче персоналы хәрби әсирләрдән тора. Алар хәлләреннән килгәнчә безнең газапларны җиңеләйтергә тырышалар. Ләкин медикаментлар, яра бәйләрлек материаллар, хәтта су да булмаганда — ни эшли аласың? Җыю пунктында күрсәтелгән беренче ярдәмнән соң өч көн үткәч кенә минем ярага да чират житте. Кан сеңеп, катып, ябышып беткән бинтларны тире һәм чәчләр белән бергә шатырдатып куптарып алдылар. Озаклап, авырттырып юганнан соң, тагын шул ук каткан бинтлар белән бәйләп куйдылар. Халыкны куркытыр өчен, дин башлыклары тегә дөнья бар, анда җиде тәмуг бар, гөнаһлы кешеләр, имештер, шул тәмугларга эләгәчәк, анда коточкыч кыен булачак дип сөйлиләр. Рославль лагере кайчакта шул җиде тәмугның берседер кебек тоела миңа...

Очсыз-кырыйсыз озын тоелган йокысыз төннәрдә аеруча читен. Уңнан да, сулдан да, өстән дә ыңгырашу, шыншу, саташу тавышлары ишетелеп тора. Почмакта ятучы бер яшь солдат, балаларча үзәк өзгеч итеп ялварып, бер өзлексез эчәргә сорый: «Су, су-у бирегез!.. Бер генә йотым... Бер генә йотым!..» — ди. Аннары ул, һушын җуеп, тынып кала... Йоклаучылар да, йоклый алмый интегеп ятучылар да күңел өшеткеч ачы бер тавышка кинәт сискәнеп-тетрәнеп китәләр:

— Танклар! Танклар! Ыргытыгыз инде гранаталарыгызны! Ишетәсезме — ыргытыгыз!

Аяклары чәрдәкләнеп сынып беткән бер лейтенант саташып кычкыра моны. Аның янындагы икенче берәү ыңрап-ыңрап озак елаудан тыны бетеп буыла башлый. Кем булыр икән ул? Битен кара сакал-мыек баскан, зур гәүдәле, терсәге тиңентен ике кулы да өзек әсир микән әллә? Хәер, ул түгелдер. Ул кичә үк үлде бит инде... Ырлар елаганны ишетеп ятудан да читен хәл юктыр!..

Яралы аяк үтереп сызлый, баш кургашын тутыргандай авырайган һәм бик каты авырта, адәм чыдамаслык сасы ис тынны буа. Ватык тәрәзәләрдән җил кереп торса да, лазареттагы сасыган яра, пычрак бинт, пычрак тән исләренә һич тә түзә торган түгел.

Нигәдер, төнлә көндезгегә караганда да ашыйсы ныграк килә. Тәүлегенә бер тапкыр ашаталар. Чикмәнле бәрәңге, хайванга ашата торган чөгендер — бөтен ризык шул. Хәтта икмәк тә юк. Бервакыт ун-унбиш көн элек үлгән ат итеннән шулпа пешерделәр (аларны алгы сызыктан алып кайтканнар иде). Тиресе-ние белән пешерелгән ит кисәкләреннән үләксә исе килә иде...

Лагерьда су исәплэп кенә бирелә. Су торбалары сафтан чыккан, суны, мичкәләргә тутырып, кайдандыр еракта әсирләр үзләре алып кайталар...

Ләкин бу тән газаплары җан газаплары алдында бик кечкенә булып кала. Үзеңнең көчсезлегеңне тою, янында гына яраларыннан үлеп ятучы иптәшләреңә ярдәм итә алмавың җанны телгәли. Шунда ук миеңне икенче бер утлы фикер телгәләргә тотына: анда сугыш бара, Вата-

ның өстенә куркыныч ябырылып килә, ә син монда тере килеш череп ятасың һәм берничек, берничек тә ярдәм итә алмыйсың!..

Бу уйларны онытып торыр өчен, үткән көннәрне искә төшерәм. Нигәдер күбрәк бала чак күз алдына килә. Менә мин, яшь бер малай, көтү көтеп йөрим. Бездә, Оренбург өлкәсенең Саракташ районы Карагужа авылында, табигать искиткеч. Авылны як-ягыннан Урал сырты читендәге матур-матур таулар урап алган. Ул таулар башыннан, зәңгәрсу төтен белән капланган сыман, очсыз-кырыйсыз киң дала, иген басулары үзенә бертөрле матур булып күренәләр...

Лазаретның сасы һавасы аша йомшак дала җиле исеп киткәндәй тоела. Оренбург даласы! Аны сагынуымның чамасы юк! Бигрәк тә язын һәм җәй башында матур була ул. Майның беренче атналарында хәтфәдәй яшел үлән өсте кызыл, кызгылт-сары һәм сап-сары тюльпан чәчәкләре белән чуарланган була. Аларның ачык таҗлары кояш яктысында шундый матур булып күренә, әйтерсең, язны котлап, дала төрле төстәге утлар яндырып куйган.

Соңрак, июнь башларында, кылган үләне үсеп китеп, даланы көмешсу-яшел ефәк белән каплангандай итә. Талгын гына искән җилдә кылганлы дала иксез-чиксез диңгез кебек тирбәнә. Көзен исә кылган мамыкланып, чал төскә керә һәм дала кар белән капланган төсле тоела. Кыскасы, дала яши, аның үз тереклеге бар. Менә, елт итеп, оясыннан йомран килеп чыга да арт аякларына басып сызгыра башлый. Биектә-биектә, зәңгәрсу-аксыл күктә, бер акрынаеп, бер яңадан көчәеп, тургай тавышы яңгырый.

Бала чакта миңа шактый ким-хурлык, михнәт-нужа күрергә туры килде. Әйтүләренә караганда, минем этием — Абдулла Тажетдинов, муллалыкка укып чыгып та мулла булырга теләмәгәне өчен, бабай тарафыннан каргалган кеше була. Атасы йортыннан куып чыгарылганнан соң, Октябрь революциясенә кадәр, семьясын туйдыру өчен, аңа байларга хезмәт итеп, аларның көтүен көтеп, бик кыенлык белән тормыш итәргә туры килгән. Шул бәхетсезлеге өстенә, кулак айгыры тибеп этинең кулын сындырган һәм ул гомеренә инвалид булып калган иде (уң кулы хәрәкәтсез булып салынып тора иде).

Минем дә, бертуган апаларым һәм абыйларымның да яңа кием кигәне булмады. Безнең кием һәрвакыт урып-җыю вакытында, печән өстендә эшләшкәне өчен әнигә байлар биргән иске-москылардан гыйбарәт була иде. Землянкабыз да иске һәм кечкенә иде. Кышкы салкыннарда әни безнең бердәнбер малыбызны — сыерны да шул землянкага кертә торган иде. Унике квадрат метрлы землянкада алты кеше һәм бер сыер!

Әтигә бик кечкенәдән булыша башладым мин: җәен аның белән кулак Гафаровның көтүен көтә идем (эти ул кешедә егерме сигез ел эшләгән), ә кышын бай казак Александр Лавровка батрак булып яллана идем. Без көтүне беренче үлән шытып чыкканнан алып, ноябрь урталарына кадәр көтә идек. Тауларда бөтен тирә-якны дер селкетеп күк күкрәгән, ялт-йолт яшен яшнәгән вакытлар хәтергә сеңеп калган. Ул чакларда мин үзем турында түгел, ничек булса да сарыкларны югалтмау турында уйлый һәм терлекләрне игенгә керүдән сакларга тырыша торган идем, чөнки игенне таптатсаң, бик каты эләктерәләр иде! Ә көзге суыкларда туңганым, сарыкларның җылы туннарына көнләшкән чакларым күпме булды. Ләкин саф һава, физик хезмәт, әллә ни мактарлык булмаса да, сәламәт ризык организмны чыныктырган, күрәсең, мин базык буйлы, таза малай булып үстем...

Йокысыз үткән лагерь төннәрендә, яралылар һәм үлеп баручылар ыңгырашкан, саташкан вакытларда мин үземнең бала һәм егет чакларымдагы шатлыклы, бәхетле көннәрне искә төшерергә тырышам. Ә ан-

дый көннәр иң фәкыйрь, хәтта хәерче малай тормышында да булабит.

Күңелемә шундый бер хәл сеңеп калган. Фәкыйрьлек аркасында миңа юньләп уку мөмкинлеге булмады. Башлангыч мәктәпнең дүрт классын тәмамлаганнан соң, батраклыкка киттем. Бай жиренә тирес түгәм, аның терлекләрен карыйм. Әмма уку турындагы уй бер генә минутка да күңелемнән чыкмый. Кичләрен мәктәптә муллаларның русча укырга өйрәнүләре турында белгәч (муллалыкка указ бары тик русча укый һәм яза белгән кешеләргә генә бирелә иде ул чакта), мин дә аларның дәресләренә йөри башладым. Муллалар барысы да диярлек картлар, русчага һич тә төшенә алмыйлар иде. Арттагы партага утырып, мин ул зиһенсез муллаларга еш кына пышылдап әйтеп тора башладым. Тора-бара укытучы да бу хәлне сизеп алды һәм мине чал сакаллы картларга үрнәк итеп куя башлады. Ә бервакыт миңа бер китап тоттырды да:

— Менә шушыны укып чык та соңыннан әчтәлеген сөйләрсең. Шуннан мин синең нәрсә аңлавыңны күрермен,— диде.

Ул күрсәткән хикәяне үзебезнең землянкадагы сукыр ут яктысында кич буе кат-кат укыдым. Бик күп сүзләре аңлашылмый, чөнки рус телен мин бик аз белә идем. Шулай булса да, әлеге хикәяне күңелдән ятладым. Икенче көнне, сыерчык турындагы бу хикәяне чатнатып сөйли башлагач, укытучым бик нык гаҗәпләнеп әйтте: «Ой, энекәем! Сиңа һичшиксез укырга кирәк. Укысаң — ерак китәчәксең син!» — диде.

Шушы урында күңелле истәлекләрем өзелә: мине укыткан өчен аена өч сум түләргә әтинең акчасы булмады, шуңа күрә мин ул чакта русча укый алмый калдым.

* * *

Лагерьда вакыт бик акрын үтә. Тәрәзәгә аксыл яктылык төшә. Вагык тәрәзәләрнең кайберләре такта яки фанер белән капланган. Шунлыктан бинада һәрвакыт эңгер вакытындагы шикелле ярым караңгылык хөкем сөрә. Мин күршем белән сөйләшәм. Күрше дигәнем — рота политругы Алексей Тимофеев. Аның ике күзе дә сукырайган. Маңгаен һәм яңакларын зәңгәрсу төрткеләр һәм яра эзләре каплап алган. Беренче тапкыр мине аның белән рәттән салган көнне ул терсәкләренә таянып битемне капшый — танышырга тели башлагач, мин хәтта куркып киткән идем. Алексей карлыккан тавыш белән шыпырт кына үзенең ничек яралануы турында сөйли башлады:

— Төштән соң, — диде ул, — безгә каршы бик каты ут ачтылар. Ә аннары немец танклары бәреп кереп, туп-туры безнең окопларга таба шуыша башладылар. Рота командиры иртән һәлак булган иде. Сугышчыларга канау артына посарга һәм немец пехотасын ут белән каршы алырга боерык бирдем. Беренче танкны ваттыра алдык без: чылбырын өздердек... Күрәм, аның артыннан икенчесе туп-туры безгә таба килә, окопка тәмам якынлашкан инде. Шартлау, дөбердәү... Бары тик егетләргә: «Ят!» дип кычкырырга гына өлгердем — танк үзебезнең өскә килде дә газ сиптереп җибәрде, ә мин йөзем белән өскә караган идем... Күзне яндырды, тирене пешерде... Нәрсәгә ярыйм инде хәзер мин?..

Бу яшь егет бигрәк тә кызганыч. Юатырга ниятләп, нинди дер сүзләр әйткән булам мин аңа. Әмма, үзем дә беләм, сүз белән генә ярдәм итеп буламы соң мондый хәлдә?

Тимофеев яткан нар янына аның ротасыннан яшь кенә дүрт солдат китерәләр. Алексейны канаудан алар алып чыккан икән. Сугышчылар Тимофеевның политрук икәнлеген немецлардан яшерәләр. Бу дүрт яшь солдатның сукыр командирлары турында чын күңелдән кай-

гыртып йөрүләрен, кулларыннан килгәнчә аңа ярдәм итүләрен, күңелен күтәрергә тырышуларын күргәч, җанга бераз җиңелрәк булып китә...

Без — яралыларга бик читен. Әмма сәламәт әсирләрнең дә хәле безнекеннән җиңел түгел. «Сәламәт» дигән сүзне бу очракта, әлбәттә, якынча мәгънәсендә генә аңларга кирәк. Мондый шартларда берничә мең кеше арасыннан абсолют сәламәт бер генә кешене дә, белмим, табып булыр иде микән? Сөякләргә үтеп керә торган көзге суык җил, яңгыр булуга карамастан, «сәламәтләр» барысы да чәнечкеле тимер чыбык белән уратып алынган мәйданда — ачык һавада яшиләр. Тәрәзәдән миңа ул мәйданның бер өлеше күренеп тора. Әнә башын якасына яшереп, кулларын юеш шинеленең җиңнәренә тыгып, тораташтай хәрәкәтсез калган бер солдат бөкрәеп утыра. Аның янында гына офицер шинеле кигән ике әсир юеш йомычкалардан учак ягып җибәрергә азапланалар. Шулар тирәсендә сакал-мыек баскан бер солдат нервланып, туктаусыз арлы-бирле йөренә. Бик үк пычрак булмаган калкурак урында — чәнечкеле тимер чыбык буенда — бик яшь бер солдат ятарга әзерләнә. Аның битендә кан әсәре калмаган, иреннәре күгәреп дердер калтырый, күз төпләре кара янып чыккан. Ул егетнең буылып-буылып йөткерүе хәтта миңа да ишетелеп тора. Менә ул бөгәрләнеп юеш җиргә ята, ә ютәле һаман басылмый, бөтен гәүдәсен дер селкетә. Ачудан бугазыма төен утыра. Цивилизацияле варварларны — фашистларны каһәрләргә тотынам. Рославльдә әсирләрне урнаштырырлык биналар беткәнмени соң? Нигә аларны, хайваннар кебек, ачык һавада — пычракта, яңгыр, кар астында тотарга кирәк икән?

Күп меңләгән әсирләр төркемен тәүлегенә берничәшәр тапкыр эсэсчылар «тарап» чыга. Еврейләрне һәм политработникларны эзлиләр. Берәмләп кенә эсэсчылар бер эш тә майтара алмый. Үзләре белән һәрвакыт берничә автоматчы ияртеп йөриләр. Ә алларыннан, бәен өзәрдәй булып, овчарка бара. Матур, акыллы эт ул овчарка. Ләкин монда аңа карата күңелдә нәфрәт туа, чөнки ул монда вәхшиләргә хезмәт итә.

Немецлар лазаретка керергә куркалар. Пычраклыктан, халык күплектән, шаккаткыч тизлек белән бет үрчи монда. Гражданнар сугышы чорындагы бер плакат күз алдыма килә: «Беттән саклан — Врангельдан куркынычрак алар!» — дип язылган иде анда. Шулай булмыйча: ул паразитлар тимгелле тиф тарата бит! Дөрес, әлегә лазаретта тимгелле тиф юк югын, әмма кузгала да алмый торган авыр яралылар, яралары авыртуы өстенә, беттән дә җәфа чигәләр ләбаса!..

Бер, ике атна үтә. Аяктагы яра үзен туктаусыз сиздереп торса да, мин инде акрынлап урынымнан тора башлыйм. Күңел, чак кына булса да, күтәрелеп китә. Яхшы ашата башлаганнар яисә лазаретны җылытканнар икән дип уйламагыз тагын. Күңелне минем кебек бәхетсезлеккә эләккән иптәшләр җылыта. Эчкерсез сөйләшү, кешенең хәленә керү, йомшак ягымлы сүз җылыта күңелне!

Акрынлап үзем белән бер бүлмәдә ятучы яралылар белән танышам. Монда китерелүебезнең икенче көнендә үк минем янга озын буйлы, җирәнрәк чәчле, утыз биш яшьләр чамасындагы бер офицер килде. Аның саргылт-аксыл йөзендә газап һәм арганлык билгеләре. Әмма күзләре бик үткен, батыр карый. Ул — подполковник Алексей Александрович Северюхин, укчы полк командиры.

— Аягыңны борчымаммы? — дип, ул акрын гына минем нар читенә килеп утырды.

— Зыян юк, подполковник, утырыгыз!

— Димәк, яралы хәлдә әсир алдылар? — ди ул, минем өскә ябылган бушлатны ипли-ипли.

Северюхин минем кай яктан булуымны сораша, аннары үзе турында сөйли. Сугышка кадәр ул Ижевскида яшәгән, Удмурт АССРның Верховный Совет члены булган икән.

— Боларны мин танышу өчен генә, кызык өчен генә сөйләмим, иптәш Тажетдинов, — диде ул. — Ышанычны югалтмау өчен, без бер-беребезне яхшы белергә һәм үзара ярдәм итешергә тиеш. Монда мин сездән алдарак эләктем. Барысын да күрдем... Һәм аңладым. Хәрби әсирләргә мөнәсәбәт турындагы халыкара конвенцияләр буш аваз гына монда... Фашистлар безне аларның сугыш дошманы булган өчен генә түгел, барыннан да бигрәк, без — совет кешеләре, аларның сыйнфый дошманнары булганга куралмыйлар... Бөтен ихтыяр көчеңне, бөтен чыдамлыгыңны җыярга кирәк. Югыйсә — беттең...

— Нәрсә, Алексей Александрович, иптәшне безнең «җәннәт» тормышы һәм аның гадәтләре белән таныштырасызмыни? — дигән тавыш ишетелде минем арттан. Мин аның кем тавышы икәнен беләм: лагерь врачы, безнең шикелле үк әсир Солодовников ул. Иртән яраларны юарлык та су булмаганга, аның бик нык кәефе кырылган иде. Солодовников тышка чыгып киткәч, минем белән янәшә ятучы солдат хөрмәт белән әйтеп куйды:

— Хәзер администрациягә барачак: тавыш күтәрергә! Берсеннән дә курыкмый. Дарулар таләп итә, бинтлар... Бер дә хәтер саклап тормый!..— диде.

Соңыннан мин Солодовниковның, чыннан да, үз-үзен аямыйча, яралыларга, авыруларга ярдәм итүен һәм башка медицина персоналларын да үз вазифаларын шулай үтәргә мәҗбүр итүен бик күп мәртәбәләр күрдем. Аның кешелекле ярдәме күпләрне үлемнән йолып калды.

Безнең лазаретта яшәүче тагын бер офицерны кызганмыйча мөмкин түгел. Чамасыз ябык, коточкыч агарынып калган ябык йөзле кеше ул, каралып беткән шинелен һәрвакыт сул кулы белән тотып йөри. Күрәсең, шинеле яралы иңбашын басмасын дип шулай итә торгандыр. Йөри ала торган яралылар берәр кешенең нары янына җыелганда Андрей Семенович Прудников — әлеге офицер — һәрвакыт алардан читкәрәк китә.

— Нигә полковник сездән читләшә? — дип сорадым мин бер көнне Солодовниковтан. Врачның зур күзләре ачулы ялтырап китте:

— Чөнки бик нәзәкатьле, оялчан кеше ул... Ә бу әшәке фашистлар аңа ярасын тиешенчә төзәтергә ирек бирмиләр. Аңлыйсызмы, Сәгыйт Абдуллович, әгәр врач кулында кирәкле медикаментлар булмаса, медицина берни эшли алмый. Полковникның иңбашы авыр яралы, ярасы азган, үлекли башлаган, авыр ис килеп тора... Менә шуңа күрә Андрей Семенович кешеләрдән читтәрәк булырга, аларны борчымаска тырыша... Ә сезнең организмыгыз бик таза, каныгыз да яхшы. Медикаментлар булмауга, канлы-пычрак бинтлар белән бәйләүгә дә карамастан, сезнең яраларыгыз төзәлеп килә. Монда сепсистан үлгән күпме кешене күмдек инде без!.. Әле тагын күпмесен күмәрбез...

Әйе, бу салкын, сасы, юеш йортта үлем бик иркен хис итә үзен. Талымлап тормый, мәктәп бусагасыннан гына чыгып фронтка килгән яшь-яшь егетләрне дә, Деникин, Колчаклар белән сугышып йөргән өлкән ирләрне дә сөякчел бармаклары белән буып сала. Беркемне дә кызганмый ул! Безнең бинадан көн саен унлаган мәет чыгарып торалар. Әмма нарларда һәм идәндә яралылар кимеми. Без, газета укымасак, радио тыңламасак та, әсирләрнең һаман саен арта баруына карап, фронтта эшләрнең шәптән булмавын күреп торабыз, бу хәлгә актырыйбыз, хәсрәтләнәбез. Җитмәсә тагын, безне саклаучы немецлар утка бензин сибеп торалар. Бигрәк тә таза, сипкелле бер немецны күралмыйм мин. Аның үз-үзеннән бик канәгать булуы чучка баласыныкы шикелле алсу йөзенә бәреп чыккан. Ул безнең бүлмәгә кергән саен

минем подполковник булуымны белгертэ торган шпалларга карый да авызын ерып: «Рус, Маскау капут!» — ди.

Без бу сүзгэ ышанмыйбыз, эмма искитмэгэн кыяфэт белэн аларны тыңлап тору да җиңел түгел шул.

Лэкин немецларның барысы да теге чучка кыяфэтлесе кебек оптимист түгел. Кайвакыт безнең бүлмэгэ сакта хезмэт итүче бер өлкэн унтер-офицер кергэли. Немец армиясенэ алынган француз капралы икэн ул. Француз-немец-рус сүзлэрен катнаштырып, ул немецларның ничек итеп француз шэһэрлэрен яндыруларын, бернинди гаепсез кешелэрне атып үтерүлэрен сөйли.

— О мосье! Фюрер Гитлер сошель зума! — дип, мэгънэле итеп, капрал бармагы белэн маңгаена төртеп күрсэтэ. Кайчак безгэ дару, икмэк кисэге алып килэ. «Үземнең запас», дип дусларча күз кысып куя.

Көннэр бик акрын үтэ... Без һаман өметлэнеп, көтеп яшибез: сэламэтлэнүебезне, фронттан яхшы хэбэрлэр килүен көтэбез. Кайчан җиңү сэгате җитэр икэн?.. Ашарга кайчан пешкэн чөгендер китерерлэр икэн?.. Бик күп сөйлэшэбез. Бэхэслэшэбез. Үткэн тормышларны искэ алабыз, үзебез катнашкан яисэ башлап йөргэн хэрби операциялэрне тикшерэбез. Э көннэр барыбер бик акрын уза. Кайберэүлэрнең инде рухы төшэ башлый. Андый төшенке күңеллелэр белэн иң шэп көрэшэ белүче кеше — Фрунзе исемендэге 5 нче укчы дивизия командиры генерал-майор Иван Андреевич Пресняков. Аны безнең лазаретка, авыр яралы хэлендэ, миннэн берэр атна чамасы соңрак китерделэр. Тышкы яктан башкалардан берни белэн дэ аерылып тормаучы, чандыр, тэбэнэк буйлы, хэрбилэрчэ җыйнак гэүдэле, өлкэн яшьтэге бер кеше ул. Иван Андреевич немецлар белэн яки үзе яратмаган кешелэр белэн хөкемдар, «генерал» тавышы белэн сөйлэшэ. Өметсезлеккэ бирелгэн кешелэрне юатканда, үз семьясы хакында сөйлэгэндэ, качу турындагы планнары белэн уртаклашкан чакларда исэ Пресняковның тавышы йомшак, ягымлы, күңелне эретеп җибэрерлек. Эйе, без барыбыз да диярлек, яраларыбыз төзэлэ төшкэч, ничек булса да, бу тэмугтан качу һэм яңадан фашистларга каршы сугыша башлау турында сөйлэшэбез. Лэкин элегэ шул сөйлэшүдэн ары китэ алмыйбыз, чөнки без нарда ятарга мэҗбүр эле, без хэзергэ бары тик немецлар тудырган шушы коточкыч кыен шартларда үзебезнең кешелегебезне саклап калырга гына тырышабыз эле.

...Менэ ноябрь ае да килеп җитте. Тышта инде тундыргалый, соры күктэн ярма сыман каты кар да ява башлады. Минем белэн күрше койкада ятучы Иван Андреевич:

— Сэгыйт Абдуллович, бер нэрсэне хэтерлэп калыгыз: эгэр немецлар үзегез белэн исэплэшүен телэсэгез, беркайчан да офицер формагызны салмагыз, — ди. — Ул сезгэ үзегезнең кем булуыгызны, Совет Армиясе вэкиле икэнлегегезне искэртеп торыр... Э икенчедэн...

Иван Андреевич тынып кала. Соңгы көннэрдэ бик ябыкты ул: ашау начар булганлыктан, яраланган вакытта югалган каны кайтмый эле. Бүген капрал аңа бер кисэк икмэк биргэн иде. Иван Андреевич шуның яртысын миңа бирмэкче була... Юк, юк! Мин бит аннан тазарак та, яшьрэк тэ...

— Икенчедэн,— ди генерал бераздан соң,— һэрбер немецның күңелендэ прусс солдафоны утыруын онытмаска кирэк. Алар чин, дэрэҗэ алдында баш иягэ эзер торалар. Петлицагызда шпалларыгызны саклагыз. Эгэр сезне фашист, кеше буларак күрмэсэ, подполковник буларак күрер... Һэм кимсетүдэн, җэберлэүдэн тыелып калыр...

Сүз уңаеннан эйткэндэ, табак битле каравылчының Иван Андреевич якасындагы генерал тамгаларына сокланып, кызыксынып каравын күргэч, мин үзем дэ шундыйрак фикергэ килэ башлаган идем. Бу сөйлэшү минем ул фикеремне тагы да ныгыта төште...

Тыштан ишек шакыдылар. Ярым караңгы бүлмәгә ике кеше килеп керде, берсе хатын-кыз булса кирәк. Кем икән ул?

— Генерал-майор Пресняков монда торамы? — дип сорады озынрак буйлы ир кеше.

— Мин монда,— дип җавап бирде Иван Андреевич.— Ни йомыш?

Таныш булмаган әлеге кеше нар янына килде. Без аның бик әйбәт драп шинеленә, чип-чиста итеп кырылган алсу йөзенә кызыксынып карыйбыз.

— Полковник Кравец,— диде ул, үзен күрсәтеп.— Бусы минем хатыным...

Барысының да карашы оялыбрак калган сары чәчле чибәр генә хатынга төбәлде.

Полковник Кравец, Иван Андреевичның авыру хәленә кереп:

— Нигә сез комендантка мөрәҗәгать итмисез, иптәш генерал? Ул сезгә полицайлар белән бер казаннан ашарга рөхсәт итәр,— диде.

— Полицайлар беләнме? — дип кайтарып сорады Иван Андреевич. Йөзе караңгыланып китте. Беравык ул кайчандыр Совет Армиясе офицеры булган полковникның купшы гәүдәсенә текәлеп карап торды, күзләрендә ачу кабынды.

— Мин, хөрмәтле полковник, мондагыларның барысы шикелле үк, хәрби әсирмен... Миңа бернинди дә өстенлек кирәкми... Полицайлар казаныннан — бигрәк тә...

Пресняков шулай диде дә полковникка аркасы белән борылды.

Кравец аптырап бер урында таптана башлады, безгә мөрәҗәгать итеп, нидер сөйләнергә кереште, әмма без аның сүзләренә игътибар итмәдек. Озакламый «кунак» хатыны һәм үзләрен саклап йөрүче конвоир белән чыгып китте.

— Һава сафланып китте! — дип куйды арабыздан берәү.

Полковник килеп киткәннән соң күңелдә ниндидер уңайсыз төен утырып калды. Бу хәлдән соң өч көн үткәч, безнең бүлмәгә полковникның конвоиры кереп:

— Сезнең офицерларыгыз бигрәк акыллы икән: әсирлеккә хатыннары белән бергә биреләләр. Менә хәзер аны хатыны һәм бөтен әйберләре белән каядыр алып киттеләр,— дигәч, шул кешегә карата нәфрәтебез тагы да арта төште.

Бераз алгарак китеп булса да, полковник Кравец белән тагын бер очрашуым турында әйтеп үтәсем килә. Мин аны сугыш беткән көннәрдә, башка хәрби әсирләр белән бергә тикшерү пункты аша үткән чакта очраттым. Полковник мине таныды һәм үзен әсирлеккә яралы хәлендә төште дип әйтүемне үтенергә тотынды. Рославль лагеренда аның саусәламәт икәнен һәм безнең белән чагыштырганда бик яхшы киенгәнлеген күрә торып, мин ничек аның ялганына шаһит булыйм?

## Котелок ни сөйли

Котелок, бакыр янсә алюминийнән ясалган гади солдат котелогы, лагерьда иң кыйммәтле әйбер санала. Котелогың булмаса — харап монда! Баланданы (бәрәңге яки чөгендер шулпасын) да, каваны да (кара төстәге бурда, «кофе», янәсе), җилекләргә үтеп керә торган көзге пычрак көннәрдә һәм кышкы ачы салкыннарда үлемнән коткара торган бердәнбер нәрсә — кайнар суны да шуңа салабыз. Яшереп алып кайткан бәрәңгене дә шул ук котелокта пешерәбез. Һәм шуңа салып без эчке киемнәребезне дә кайнатабыз, чөнки бөҗәкләр явыннан бары тик шул юл белән генә бераз котылып торырга мөмкин. Әйе, котелок — безнең дустыбыз, ачлыктан, сусаганнан һәм бетләрдән коткаручыбыз!

Ләкин котелок кайвакыт үзенә хас булмаган эшне дә эшли — әсирләр күргән газап-михнәтләрнең шаһиты да була икән.

Артиллерия капитаны Грязновны бик ошаттым мин. Ул яшь әле, сугыш алдыннан гына артиллерия академиясен тәмамлаган. Ягымлы, ачык йөзле, кара кашлы бер кеше. Аның белән сәгатьләр буена теләсә нинди сүз сөйләшеп утырырга була. Грязнов үзе әйбәт сөйләүче генә түгел, башкаларны да күңел биреп тыңлый белә. Ә мондый әйбәт сыйфат теләсә кемдә очрамый!

Бервакыт аның котелогына күзем төште. Гади бер солдат савыты булырга тиеш инде ул, әмма бу ни хикмәт соң? Грязнов котелогының бөтен тышы вак-вак рәсемнәр, ниндидер билге-тамгалар һәм бик матур хәрефле язулар белән чуарланып беткән.

— Нәрсә бу, капитан? — дип сорадым.

— Минеке бу,— диде Грязнов елмаеп.— Монда лагерьларда үзем кичергән төрле хәлләр, үткән юлларым язылган.

Шуннан соң капитан, китап укыгандай, котелогын «укырга» тотынды. Ул әйбергә уеп язучылар арасында үскән, аларның бу нечкә һөнәрен бик яхшы белә икән. Дөрес, аның тиешле кораллары юк, әмма, аның җитез бармакларына эләккәч, гади кадак та әллә нинди хикмәтләр чыгара.

Бу вакытта минем дә яссы гына зур бер котелогым бар иде инде.

— Телисезме, сезгә дә әсирлектәге бөтен «истәлекле» даталарны котелогыгызга уеп бирәм? — диде миңа Грязнов бер көнне. Теләмимме соң инде!..

Өч көннән соң инде минем котелок чуарланып-бизәкләнеп тә бетте. Аңа бик күп кирәкле саннар, сүзләр язылды, матур-матур рәсемнәр ясалды. Котелогым белән мактанырга дип Пресняков янына бардым.

— Бик шәп нәрсә бит бу! — диде генерал, сокланып.— Бик оста уйлап табылган... Тормыш хәлләре, фактлар онытыла ул, кәгазьгә язылган язуларны саклар урын юк, аннары алар озакка чыдамыйлар да. Ә бу — бездән дә озаграк яшәячәк, — диде.

Грязнов Иван Андреевич котелогын да кулына алды. Башта котелокның уртасына имән ботаклары белән каймаланган калкан уйды Бу — какшамау, ныклык символы. Ялтырап торган котелок бакырына имән яфракларын шундый ачык һәм матур итеп төшерде — исең китәр! Ә калкан тирәсенә чолгатып-чолгатып даталар, кыска-кыска язулар һәм «Кайда гына булсаң да — рус икәнлегеңне онытма!» дигән сүзләр язды. Пресняков моңа бик канәгать булды.

— Алтын икән кулларың, капитан! Бу «көндәлек», һичшиксез, миннән озаграк яшәр,— диде ул кат-кат.

Безнең кадерле генералыбыз хаклы булган икән. Егерме елдан соң мин Иван Андреевичның вафат булганлыгын ишеттем: безнең иптәшләр мине әлеге шул бизәкле котелогыннан белгәннәр. Ничек белгәннәр — ансын соңрак сөйләрмен.

...Бер бүлмәдә без дүртәү яшибез: Пресняков, Северюхин, Прудников һәм мин. Бу бүлмәне генералның үзенә генә биргәннәр иде, ләкин ул безгә дә үзе янына урнашырга рөхсәт итүләрен таләп итте. Монда хәзер нарлар түгел, койкалар куелган. Матрац урынына салам тутырылган тишек капчык, ә урын җәймәләре һәм одеял урынына — шинель белән бушлат. Бүлмә ягылмый, аны үз тыныбыз белән генә «җылытабыз», шунлыктан урам һавасы белән безнең бүлмә һавасы температуралары арасында әйтерлек аерма булмый. Бездә тик җиле генә юк.

Бер татар әсире кичә иртән миңа тагын берничә пешкән бәрәңге китереп бирде. Аларны Иван Андреевич белән ашадык. Әсир татарлар монда унлап кеше, барысы да рядовойлар. Аларның хәле безнекеннән әйбәтрәк: солдатларны көн саен диярлек лагерь тышына эшкә алып чыгалар. Ә безгә, офицерларга, физик эш эшләтү бик үк килешеп бетмәс дип саныйлар, күрәсең. Дөресрәге, качар дип куркалар. Менә шул «естеклек» безгә бик кыенга килә: лагерьдан чыксаң, ичмасам, берәр

ашар әйбер табарга мөмкин, ә лагерь паегында гына утырсаң — теге дөньяга китәсеңне көт тә тор. Шул хакта беркөнне мин бер әсир Казан татарына сөйләгән идем. Шуннан соң көн саен диярлек әле берсе, әле икенчесе миңа я бер-ике бәрәнге, я икмәк кисәге, яисә пешкән чөгендер китерә торган булдылар. Егетләргә нинди генә рәхмәтләр әйтсәм дә, аз булыр кебек. Алар ярдәм итмәсә, мин, бигрәк тә Иван Андреевич, күптән аякларыбызны сузган булыр идек инде. Безнең койкалар кара каршы куелган һәм йокысызлыктан интеккән төннәрдә без төрле темага әңгәмә алып барабыз. Иван Андреевич еш кына үткән көннәрен искә ала. 1914 елны ул укытучылар семинариясен тәмамлаган, әмма укытырга туры килмәгән, сугышка алынган.

— Мин, Сәгыйть Абдуллович, гади солдаттан башладым, солдат буткасын күп ашарга туры килде миңа. Казан хәрби училищесын тәмамлаганнан соң, офицер иттеләр. Февраль революциясен офицер, җәяүле разведка начальнигы булып каршыладым. Ә Октябрьдан соң Солдат комитетына сайладылар... Сез Шкуро, Махно, Петлюра һәм башка шундый хәшәрәтләр белән көньякта сугыштым дисезме?.. Ә миңа Совет республикасын төньякта ак бандалардан чистартырга туры килде... Себер — минем хәрби мәктәбем булды. Анда полк белән командалык иттем.. 1920 елга кадәр адмирал Колчак белән мәшәкатьләнергә туры килде...

Ә мин, үз чиратымда, яшь кенә егет килеш 2 нче Дон дивизиясендә пулеметчы булып хезмәт иткәнемне сөйлим. Төз ата торган идем мин, ә бервакыт зур мактауга да лаек булдым — генерал Шкуро корпусының атлы разведчикларын тереләй эләктерергә ярдәм иттем.

Мондый сөйләшүләрдән соң, Иван Андреевич гадәттә сүзен болай дип тәмамлап куя:

— Әйе... Башлавын әйбәт башлаган идек, ә менә азагы барып чыкмады... Зыян юк, Сәгыйть Абдуллович! Сәламәтләнергә дә аякка басарга гына кирәк... Әсирлектә дә сугышырга мөмкин!

...Бүген миңе, подполковник Иван Григорьевич Горношевичны һәм тагын ике әсирне икмәк алырга җибәрәләр. Пекарня һәм склад Рославльдән алты километр ары урнашкан. Мин инде аксамыйм, әмма төннәрен аякның сызлавына һич чыдый торган түгел. Шулай да, әгәр?.. Юк! Качарга мөмкинлек килеп чыккан очракта да бу аяк белән ерак китеп булмас...

Төш турында әйләнеп кайттык. Лагерьда нинди-дер ыгы-зыгы. Бөтен өлкән офицерлар — егерме бишләп кеше — урамга тезелеп куелган. Иван Андреевич безне чакырып алды да:

— Сез анда йөргәндә монда хикмәт чыкты... — диде. — Барлык өлкән офицерларны каядыр күчерәләр, Могилев ягына булса кирәк. Анда хәрби әсирләр өчен махсус лагерь әзерләнгән дип сөйлиләр.

— Фронттан ераккарак озатмакчылар алайса, — диде капитан Грязнов, сүзгә кушылып. Аннары ул миңа үзенең «18/XI—41— Могилевка киттек» дигән сүзләр уелган котелогын күрсәтте.

Озак та үтми, безне сугыш юлларында йөреп калтырчага әйләнеп беткән бер иске автобуска төяделәр.

Прудников, кулы белән шинелен тоткан килеш, автобус басмасына көч-хәл белән менде. Солодовников кулыннан килгәннең барысын да эшләүгә карамастан, аның иңбашы һаман начар иде әле. Доктор да монда — безне озатырга чыккан. Аның ягымлы, талчыккан йөзе автобус тәрәзәсе аша соңгы тапкыр чагылып кала. Бу яхшы кешенең язмышы бездән соң ничек булыр икән?..

Менә соңгы җимерек корылмалар да күздән югалды инде. Рославль артта калды.

Мин автобус тәрәзәсе янында кара күмергә әйләндерелгән авылларны, снарядлар актарып бетергән җимерек шәһәрчекләрне — район

үзәкләрен әрнеп карап барам. Иван Андреевич та тәрәзәгә төбәлгән. Йөзендә — чиксез борчылу: «Ярабби! Ни рәвешле таптап, пычратып бетергәннәр бит безнең җирне!» — дип пышылдый ул.

Шактый җанланып киткән офицерлар тынып кала. Барысының да күңелендә туган илне кызгану, аны яклап көрәшергә мөмкинлек булмау хәсрәте...

Кичкә таба җил көчәйде, җәяүле буран кузгалды. Безнең автобус шоссе буйлап атлаучы бик озын әсирләр колоннасын куып житте. Арыган, хәлсезләнгән, салкыннан күгәреп чыккан йөзләр, ертык шинельләр, тишек итекләр... Ян якларында сакчылар, секунды белән өстенә ыргылырга торган очлы колаклы овчаркалар. Әнә яшь кенә бер солдат туң түмгәккә сөртенеп егыла. Ул торып өлгерә алмый. Сакчы җилкәсенә автомат түтәсе белән суга һәм немецча нидер акырырга тотына... Аның котырынган кыяфәтле ямьсез йөзе нәкъ минем тәрәзә турыннан уза. Юл читендә кызылармеец утыра. Ул агарынган йөзен кулы белән тоткан, күзләре йомык — кузгалырлык та хәле калмаган. Сакчы килеп җитеп, аның янтыгына тибә. Кызылармеец, кисеп аударгандай, җиргә ава. Сакчы автоматына тотына... Аткан тавыш автобус гөрелдәвен күмеп китә. Ә колонна һаман атлый да атлый...

— Каторжаннарны Себергә куганда да артларыннан атка җиккән чаналар белән барганнар — авыруларны шунда утыртканнар... Ә болар... нинди вәхшилек, нинди әшәкелек! — ди Северюхин, авыр тынлыкны бозып.

Кречевта кунарга тукталабыз. Ниндидер бер таш бина. Түзә алмаслык салкын. Йокларга һич мөмкин түгел. Иван Андреевич цемент идән буйлап арлы-бирле йөренә.

— Менә нәрсә, Сәгыйт Абдуллович,— ди ул.— Мин инде Прудников белән Северюхинга әйттем. Мөгаен, Могилевта безгә бергә яшәргә туры килмәс. Минем анда инспектор булып баргалаганым бар. Ихтимал, безне авиация шәһәрчегенә, элек очучылар яшәгән квартиралларга урнаштырырлар. Биналар ягылмыйдыр инде, элек алар пар белән жылытыла торган иде. Ләкин һәр квартирада плиталы кухня бар. Шунда эләгергә чамалагыз, плиталар белән җылынырга тырышырбыз... Юлда барганда мин күп уйладым. Йомшаклар түзми, үләләр. Әлегә мин физик яктан йомшакларны күздә тотам. Физик яктан үлмәскә — хәзергә безнең төп бурыч шул. Ә аннары... Ә аннан аргысы турында үз вакыты житкәч сөйләшербез...

Менә Могилев лагерена да җиттек. Иван Андреевичның сүзе дөрес булып чыкты: лагерь авиация шәһәрчегендә оештырылган. Лагерь эчендәге комендант — Галкин Петр Петрович. Ә тышында эсэсчы обер-лейтенант Химлес — зур комендант. Безгә, өлкән офицерларга, Петр Петрович кухняга урнашырга ярдәм итте. Алты квадрат метрлы кухняда алтау яшибез. Үзебез өчәр катлы нарлар ясадык. Плитага лагерь эчендә янардай нәрсә тапсак — шуны ягабыз. Немецлар вәгъдә иткән уңай шартлар, гадәттәгечә, буш куык кына булып чыкты. Шул ук тыгызлык, шул ук ачлык, шул ук пычрак. Пычраклык һәм бет монда тагын да күбрәк әле: өч ай буена мунчасыз, эчке киемнәрне алыштырмыйча һәм һәрвакыт киенеп йоклагач, шулай буласы билгеле инде! Күршемдәге солдат Гриценко әйтмешли, безнең киемнәрдә бет мыжлап тора.

Безнең кухняга күп кеше җылынырга кереп йөри. Әле яңа гына полковник Александр Иванович Семенов кереп чыккан иде. Без аны «Гебен зи мир» дип атыйбыз, чөнки ул, бик тырышып, немец телен өйрәнергә агитацияли һәм бу мәсьәләдә уңышка да ирешә инде. Җае килгән саен, немецлардан бөтенләй күңеле чыгуы турында әйтә ул: шундый югары культуралы миллләт үзләре, ә хәрби әсирләр лагеренда кеше ышанмаслык тәртипсезлекләргә юл куялар, ди.

Мәскәү ополчениесеннән килеп, Киров исемендәге 9 нчы укчы дивизиясенең тәэминат начальнигы булып хезмәт иткән Чардин да безгә еш керә. Бик белемле, акыллы кеше ул. Сугышка кадәр Тимирязев исемендәге авыл хуҗалыгы академиясендә укыткан. Бик сөйкемле итеп елмая торган, уйчан һәм мөлаем карашлы Чардин әле сугышка кадәр ук армия тәэминатына кертелгән концентрат рецепты уйлап тапкан булган. Фәнни дәрәҗәсе барлыгын белеп, зур-зур буртларга өелгән бәрәңгеләрне сайлаганда немецлар аны киңәшкә чакыралар. Чардин аннан һәрвакыт берничә бәрәңге алып кайта, һәм без ул бәрәңгеләрне үзебезнең плитада пешерәбез.

Профессор — Чардинны без шулай дип атыйбыз — чүгәләгән килеш, Гриценко табып кайткан утыннарның плитә мичендә януын карап тора, үзе бертуктаусыз диярлек кашына: бөҗәкләр аның фәнни дәрәҗәсе белән исәпләшеп тормый шул. Кинәт профессор елмаеп куйды:

— Беләсезме, иптәшләр, минем искә нәрсә төште әле? Толстойның «Сугыш һәм тынычлык» романындагы Пьер Безуховның французларда әсирлектә булган чагын сурәтләгән бүлек. Анда, якынча, менә мондыйрак фикер бар. Кыенлыклар Пьерны куркытмый. Үлгән атлардан кисеп алынган ит аңа тәмле һәм туклыклы тоела, бетләр дә әллә ни җәберләми, салкын көннәрдә хәтта тәнен дә җылыталар иде, ди Лев Толстой...

Кайчандыр ак булса да, хәзер инде кап-кара төскә кергән солдат күлмәгенең җөйләрен бик игътибар белән карап утырган Гриценко утка бер төкереп куя да, күңелсез генә итеп:

— Язучылар!.. Үз тәннәрендә бет туйдырмаган алар, менә шуңа уйлап чыгаралар... «Җылыталар», имеш. Кирәк бит!..— диде.

Могилевка килгәннең икенче көнендә ишеттек: монда тимгелле тиф инде күптән башланган икән.

Мондагы әсирләргә икмәк өләшү «тәртибен» дә шул көнне үк үз җилкәбездә татыйбыз. Яктыра да башламаган кышкы иртә. Көнчыгышта да яктылык билгесе күренми әле. Авыру аягымны иплӛбрәк куеп, әзрәк җылынып киткән шикелле генә булган идем — тышта колак тондыргыч тимер тавышы яңгырый башлады. Кухня урнашкан барак янына баганага асып куелган рельс кисәгенә сугалар икән. Мин, тагы бераз гына булса урынымда ятып тормакчы булып, кузгалырга ашыкмыйм, әмма шул арада җиңенә полицай чүпрәге бәйләгән аюдай таза бәндә, ишекне тибеп ачып, атылып бүлмәгә килеп тә керде. Кулында авыр күсәк. Шунын белән ул торырга өлгермәгән кешеләргә төртергә һәм, кемнең кай җиренә эләккәнен дә карап тормастан, киерелеп-киерелеп сугарга керешге.

— Менә безне хәерле иртә белән дә котладылар инде,— диде Гриценко, күңелсез генә шаярган булып. Ул шаярта белүен онытмаган икән әле.

Кара, озын еландай сузылып, бөтен лагерь ишек алды буйлап шаушу чират тезелгән. Берничә мең әсиргә икмәкне ике тәрәзә аша гына өләшәләр. Пычкы чүбенә он катыштырып пешерелгән бер сынык икмәк алыр өчен, берничәшәр сәгать чиратта торырга кирәк. Бер урында басып торырга ярамый — хәзер катып үләсең. Шуңлыктан әллә ничә мең кешенең барысы да, ниндидер коточкыч бер бию башкаргандай, туктаусыз селкенеп-тыпырдап тора. Авыру кешеләрне бүлмәдәш иптәшләре, носилкаларга ямсә шинельләргә салып, күтәреп алып киләләр, үз өлешен һәркем үзе алырга тиеш! Минем артта да носилка күтәреп торалар. Баганадан төшкән ут яктысында носилкада хәрәкәтсез яткан кешенең күгәргән йөзе күренә. Агач ботагыннан аның битенә коелган бәс бөртеге эреми, күзләре билгесез бер ноктага төбәлгән.

— Иптәшләр! Үлгән бит инде ул! — дим мин аптырап, носилка күтәреп торган кешеләргә карап.

— Тавышланмагыз, иптәш подполковник! Сездән башка да беләбез... Төнлә үлде... Аның өлешен әрәм итеп булмый лабаса!.. Тереләргә эләксен ичмаса! — диләр.

Нишлисең, алар хаклы! Әмма шулай да үз өлешен көтеп яткан мәеткә карагач, әллә ничек кыен булып, тәннәр чымырдап китте... Өлешемне алып китеп барган чакта, нииндидер каты әйбергә сөртенеп, егылып киттем. Иелеп карасам — тагын бер мәет. Күрәсең, аны да минем арттагылар кебек, алып килгәннәр дә, аның өлешен эләктергәч, көндез мәет күмү командасы алып китәр әле дип, калдырып киткәннәр.

Мин — хәрби кеше. Малай чагымнан ук сугышларда йөрдем. Сугышта бик күп үлгән кешеләрне күргәнем бар. Әмма Могилевтагы мәет әрдәнәләренә һич тә күнегә алмадым. Әсирләрдән торган тотенкоманда мәетләрне лагерь читендәге каберлеккә чыгарып өлгерә алмый. Тәүлегенә биш йөзләп кеше үлә, шуларның дүрт йөзләбен генә күмәләр. «Калдык»лар лагерь ишек алдындагы изолятор янында үзләренә чират тигәнне көтә...

Кайчакта үлде дип чыгарып куйган кешеләр, салкын һавада аңнарына килеп, мәетләр өеме арасыннан шуышып чыгалар да баракларына таба үрмәли башлыйлар. Әле бүген иртән генә шундый «мәет»не — офицер Мельниковны безнең баракка алып керделәр.

Мәетләр утын агачы кебек әрдәнәләп өелгән. Суык аларны шакырдатып катырган. Чанага өеп төягән чакта мәетләрнең кулы яисә аяклары уңайсызрак туры килсә, күмү командасының башында торган эсэсчылар ул кул-аякларны, ботак юынгандай итеп, кисеп кенә ташлыйлар. Алдан әзерләнеп куелган такталарга «йөз» дип язылган булуга карамастан, бер чокырга өчәр йөз мәет тутырып күмәләр. Шулай итеп, әле сугышның беренче айларында ук фашистлар үзләренең җинаять эзләрен яшерә башладылар.

Ачлык, суык, тиф шундый хәтәр нәрсә — аларга каршы торуы бик кыен. Иван Андреевич безне үзе яши торган кухняга җыя. Ул тагын да ябыга-куырыла төшкән, әмма күзләрендә тәвәккәллек һәм очкын бар әле.

— Менә нәрсә, иптәшләр,— ди ул.— Кул кушырып үлем көтеп утыруны теләсә кем дә булдыра... Хәрәкәт итәргә, чаралар эзләргә кирәк. Иң элек, әлеге берничәшәр сәгать суыкта икмәккә чират торуны бетерергә кирәк. Ул нәрсә немецларга көлке генә булып тоела. Ә анда кешеләр үзләренең соңгы көчләрен һәм сәламәтлекләрен югалталар. Безгә лагерь эчендә хуҗа булырга кирәк. Шул өч йөз грамм икмәкне оешкан төстә алып, баланданы да шулай ук бөтен баракка берьюлы алып кайтып булмыймыни?..

Пресняков үз дигәнен итте, генерал чины каршында немецлар шүрләбрәк калды. Бүгеннән башлап, Прудников әсир белорусларга өлкән булачак. Украиннар группасын Северюхин җитәкләячәк, миңа офицерлар арасында өлкәнлек итү йөкләнә. Кул астыбыздагы кешеләрне без көн саен исемлек буенча барлап чыгабыз, икмәккә дә, баландага дә сафка тезеп алып барабыз. Икмәк бирелә торган тәрәзә янында ахмакларча буталышу юк хәзер, чиратта да тәртип яхшыра төште. Кечкенә булса да, безнең җиңү бу!

...«Дөньяда бер рәхимсез патша бар: ачлык исемле ул»,— дигән юллар искә төшә. Әле шушы көннәрдә генә Грязнов миңе бер читкәрәк алып китте дә:

— Сәгыйт Абдуллович, син бүген изолятор яныннан үткән идеңме? Анда бернәрсә дә күрмәдеңме? — диде.

— Мин ул әрдәнәләргә карамаска тырышам!.. Күңелле урын түгел ич.

— Ә мин бүген карадым...— Безнең котелокларга елъязма уеп баручының йөзе җыерылып китте. — Фу, әйтергә дә куркыныч!.. Күз алдыңа китерәсеңме, азрак итә булган мәетләрнең итләре кисеп-кисеп алынган... Кешеләр кеше үләксәсе белән туклана...

Берничә көннән соң бу хәбәргә яңалары өстәлде. Лагерьда төннәрен тере кешеләрне аулыйлар имеш, дигән хәбәр таралды. Йортлар арасында караңгы почмаклар күп. Шунда посып, кеше ашаучылар бараклардан чыккан әсирләрне саклап торалар да әләктереп алалар, имеш. Бу хәбәргә ышанырга да, ышанмаска да белмәдек. Шулай да кичләрен ялгыз чыкмаска тырышабыз. Бөтенләй кеше ышанмаслык ук хәл түгел бу. Ачлык кайбер кешеләрне кешелек йөзен югалтуга кадәр китереп җиткерде. Чүп-чар күмә торган чокыр тирәсендә тимер чыбыктан ясалган ыргак белән чокырдан ашарга яраклы ташландыкларны әләктереп алырга өметләнеп йөрүче тере скелетларны һәрвакыт күрергә була. Әле күптән түгел генә каланчада ямансулап утырган сакчы, күңелен күтәрмәкче булып, шундагы ике кешегә автоматыннан атты. Берсе, башына пуля тиеп, туп-туры ташландык чокырына барып төште дә шундагы шакшы эченә батты, ә икенчесенең корсагы яраланган иде. Без, ул вакыт ишек алдында булган берничә кеше, аны барагына илтеп куйдык.

Ачлыктан, үлем куркынычыннан ахыр чиккә җитеп интеккәнлектән, әсирләр кешелек сыйфатын югалта. Ә менә нацистлар нигә кешелек сыйфатларын югалталар, нигә аларда кызгану хисе юк! Каланчадагы сакчы нәкъ үзе кебек үк кеше сасы, пычрак сыеклык эчендә тончыгып ятканда рәхәтләнеп көлеп торды. Коточкыч хәл түгелмени инде бу, я?..

Төшке аштан соң безне ишек алдына куып чыгаралар һәм һәр барак кешеләрен аерым-аерым итеп тезәләр. Уртага лагерь администрациясе яки ниндидер немец офицерлары килеп баса. Бер читтә конвойчылар һәм этләр белән уратып алынган, шинель яки гражданский киемнәрдән йөзләп кеше басып тора. Менә лагерь начальнигы алга чыга. Конвойчылар «Ахтунг, ахтунг!» дип акырып җибәрә. «Игътибар, игътибар!» — дип, аларга полицайлар кушыла.

Менә приказ уку башлана. Мин ераграк торам. Сүзнең ни турыда икәнлеген бик начар ишетәм. Күп кенә фамилияләрне санап чыгалар да, бөтен кешегә ишетелерлек итеп: «...кеше ашауда гаепләнүчеләрне атарга» дигән сүзләрне укыйлар. Без тәмам өнсезләнеп торабыз... Юк, монда нәрсәдер бар...

Ә бер атнадан тагын шул ук хәл кабатлана. Тагын йөзгә якын кешене, кеше ашаган өчен дип, үлемгә хөкем итәләр. Бездә дә, башка баракларда да сүз һаман шул турыда бара. Иван Андреевич кухняда эшләүчеләргә — алар немецлар белән ешрак очраша — бу атуларның чын сәбәбен белеп кайтырга боерыч куйды...

Шулайдыр дип уйлаган идек шул. Масса рәвешендә кеше ашау — нацистларның чираттагы ялганы, партизанлыкта яки партизаннар белән элемтә тотуда гаепләнгән гражданский кешеләрне һәм качарга тырышкан хәрби әсирләрне юк итү өчен уйлап чыгарылган сәбәп кенә булып чыкты.

— Нинди кабахәтлек! — ди «Гибен зи мир», ачуланып.— Кешеләрне үтереп кенә калмыйлар, кеше ашау ярлыгы ябыштырып, аларның рухын да пычратырга тырышалар.

— Ә фашистлардан тагы ни көтәсез? — ди аңа Иван Андреевич.— «Никадәр начар булса — шул кадәр әйбәт» дигән принцип белән эш итә бит алар. Барысы да кешене кимсетү, әсирләр арасында дошманлык тудыру өчен эшләнә...

Баракның көнчыгышка караган тәрәзәләреннән койма белән әйләндереп алынган бер мәйданчык күренеп тора. Без аны «әт абзары» дип йөртәбез. Анда немецлар үлемгә хөкем ителгәннәрне ябалар. Анда по-

литработниклар, еврейләр, Могилевтан һәм аның тирәсеннән тотылган партизаннар. Ялан аяк һәм эчке күлмәк-штаннан гына калдырып, «куркыту өчен» аларны берничәшәр сәгать суыкта тоталар. Аларга карагач, йодрыклар үзеннән-үзе йомарлана. Ләкин нәрсә, нәрсә эшләргә була соң? Бары тик нәфрәт кенә төен булып күңелгә утыра. Берсен дә онытмас күңел, берсен дә! Онытмас та, кичермәс тә!

Һәр иртә саен без тәрәзәләргә ябырылабыз. Үткән төн нәрсә алып килгән? Атылган кешеләр урынына кемнәрне куып керттеләр икән бу каргышлы койма эченә?..

* * *

Атна артыннан атналар үтә тора... Лагерь полициясе начальнигы Иванов, элекке өлкән лейтенант, безнең бүлмәгә берничә тапкыр кереп чыкты инде. Минемчә, бу аның үз фамилиясе түгелдер. Кайбер сатлык җаннарның һәм дошман ягына күчкән кешеләрнең аз гына булса да намус дигән нәрсәсе, иптәшләре алдында уңайсызлана белү хисе сакланып кала торган була иде, әмма Ивановта ул нәрсәнең исе дә юк. Ул үзенең әшәкелек эшләвен башына да китерми, шартларга җайлашам дип йөри. Немецларга ул бик тырышып хезмәт итә һәм карьерага ирешү турында хыяллана. Бу яшь кенә кешенең шулкадәр оятсыз булуына исем-акылым китә!..

Беркөнне Иван Андреевич, лагерьның баш врачы Груздев һәм мин, ватык тәрәзәләргә кагарга фанер сорап, аның квартирасына кергән идек. Белмим, бу кадәр күп келәмнәрне Иванов кайдан җыеп бетергәндер. Идәнгә дә келәм җәелгән, стеналар да келәм белән тулган. Без бик яхшы, алтынлаган рам янында басып торабыз. Әсирлеккә эләккәннән бирле мин үземнең йөземне беренче мәртәбә күрәм. Сакал-мыек баскан, каралып-керләнеп беткән шинель кигән, яшькелт-соры битле шушы арык кеше — мин үзем. Совет Армиясе подполковнигы икәненә ышанасы килми. Ә тук, хушбуй исе аңкып торган, яңа, ыспай немец формасы кигән Иванов оятсыз рәвештә плюш диванга җәелеп утырган да немецлардан өйрәнгән тәкәббер караш белән безне тикшерә.

Ул фанер алырга дигән язуга кул куйгач та, безне җибәрергә ашыкмады, хыялга бирелеп сөйләнергә кереште. Аның хыяллары да нәкъ хәзерге тормышы кебек иде.

— Ә беләсезме,— диде ул, мактанып,— әгәр эшләр киләчәктә дә шулай барса, мин карьера ясаячакмын бит. Сугыш беткәндә, бәлки, дивизия командиры булырмын...

Пресняков, моңа ачуы килеп, урынында таптангалап тора һәм авызы эченнән генә нидер мыгырдана иде. Аның күзләрендәге нәфрәтне сизгәч, Ивановның купшы-канәгать кыяфәте бик тиз юкка чыкты.

— Ә сез тиенле акчаның ике яклы булуын беләсезме, егетем? — диде аңа Пресняков.— Бераү «иләк» дип чөя, ә аңа «күн» төшә... Әгәр үзегезнең тоткан урыныгыздан файдаланып, әсирләргә ярдәм итә торган булсагыз — ничектер кичерергә булыр иде әле. Ә сез?..

Иванов нидер мыгырданды, ләкин Пресняков аны тыңлап та тормады.

— Киттек, иптәшләр! — дип ишеккә юнәлде. Ивановның полиция начальнигы булуына да, безнең язмыш аның кулында икәнлегенә дә исе китми аның. Иван Андреевич өчен иң кадерле нәрсә — дөреслек, һәм ул аны, кемнең кем булуына карамастан, күзенә бәреп әйтә.

Ивановтан тыш, украиннар секторында полиция начальнигы булып эшләүче ниндидер Николайчик белән дә танышырга туры килде. Ул мине үз янына чакыртты. Дөресен генә әйткәндә, барган чакта күңел шактый борчылды. Бу үләткә нәрсә кирәк икән тагы? Меңләгән әсир-

ләрне, еврейләрне һәм политработникларны үз кулы белән аткан хәшәрәт ич ул!

Зур, симез гәүдәле Николайчик өстәл артында утыра иде. Өстенә ниндидер венгр киеме, башына каракүл бүрек — кубанка кигән.

— Минем кулда синең полкта намуслы кешеләрне атканнар дигән мәгълүматлар бар,— диде ул, миңа карамыйча гына, дорфа итеп.— Аларны бары тик Кызыл Армиядә хезмәт итәргә теләмәгән өчен генә атканнар...

Бервакыт минем полкта, хәрби трибунал карары нигезендә, Мәскәү өлкәсенең Загорский районнан алынган Зайцев дигән бер солдат-дезертирны атканнар иде. Күрәсең, моңа шул турыда җиткергәннәрдер.

— Сез — полиция начальнигы,— дидем мин аңа,— ихтимал, беләсездер: Совет Армиясендә дә, буржуаз армияләрдә дә — барысында да дезертирларга карата бер үк төр җәза кулланыла. Һәм хөкемне дә полк командиры түгел, бәлки махсус орган чыгара. Үзегезгә мәгълүм булганча, безнең армиядә аны хәрби трибунал дип атыйлар.

— Димәк, син ул очракны инкарь итмисең. Бик шәп!.. Без сине махсус күзәтү астына алабыз...

Николайчик сүзендә торган, минем карточкага тиешле билгесен куйган булса кирәк. Мин моны шуннан чыгып әйтәм: дүрт ел әсирлектә булу дәверендә кеше аттыру турында күп тапкырлар минем исемә төшерделәр.

Безнең лагерь ишек алдында базар, дөресрәге, толкучка бар. Кайсылары икмәк паегын сигаретка алыштыра, кайсылары киресенчә — сигаретны нинди дә булса азыкка алмаштырып ала. Лагерьдан тышта эшләп, берәр котелок бәрәңге яки берәр кисәк дуңгыз мае эләктереп кайта алган солдатлар да бу зур хәзинәләрен үзләренә кирәк булган берәр нәрсәгә алмашалар.

Элек 3 нче ранг хәрби инженер булган Керовны да ул базарда еш очратып була. Карап торырга ябык кына булган ул кеше лагерьда инженер вазифасын үти: бараклар, складлар һәм башка шундый нәрсәләрне төзүгә җитәкчелек итә. Аның ирекле пропускысы бар, ягъни ул, бернинди каршылыкка очрамыйча, көненә берничә тапкыр лагерьдан чыгып-кереп йөри ала. Эх, шундый пропуск безнең берәребездә булса! Әмма Керов, безнең бәхетсезлектән файдаланып, үзе өчен табышлы итеп сатып-алу турында гына уйлый. Бик ансат кына алып кайткан бер котелок бәрәңгесен дә безнең базарда утыз сумга сата! Ә үзе партиягә кандидат идем дигән була әле!

Прудников аннан сатып алып пешергән бәрәңгене кулына ала да, аптырап:

— Менә сиңа инженер! Нинди хайван бу, ә! — ди.

## «Теләсәгез ничек саклагыз...»

Беркөнне төшемдә төн буе селедка ашадым. Бик тиз ашап бетердем мин аны, аннары озак итеп тозлы һәм бик тәмле башын суырдым... Төшке ашка тагын шул ук тәмсез баланда бирделәр. Ул болай да тәмсез, ә тозсыз килеш — бигрәк тә. Икмәгеннән дә чүбек тәмнәре килә, ул да тозсыз. Һәм бу тозсыз диетаның матдәләр алмашуына тәэсир итми хәле юк. Күп әсирләр шешенде, барысының да диярлек теш уртларыннан кан килә башлады.

Иван Андреевич безнең «идән асты» (без аны үзебез шулай дип йөрибез) группасын җыярга керешә.

— Я, кул кушырып, шешенеп утырабызмы, әллә берәр чарасына керешәбезме?.. Чарасына керешергә! Яхшы! Миңа 1926 елгы Женева конвенциясе текстын табып бирергә вәгъдә иткәннәр иде. Анда әсирләр

белән ничек мөгамәлә ителергә тиешлек турында аерым пункт бар. Шуның нигезендә лагерь начальнигына протест язарбыз.

Иван Андреевичка ул конвенцияне кем табып бирә алгандыр — әйтә алмыйм, әмма ике көннән соң Женева конвенциясе безнең кулда иде инде.

Протест бик кискен һәм дәлилле язылды. Аңа биш кеше: Пресняков, Прудников, Медведев, Северюхин һәм мин кул куйдык. Лагерь врачыннан ул протестны лагерь начальнигына тапшыруын үтендек.

Бер, ике көн узды. Начальникларның тавыш-тыны юк әле. Ә без барыбыз да үзебезнең чиннарыбызны әйтеп кул куйган идек: генерал-майор, полковник, подполковник... Шул да тәэсир итмәс микәнни?..

Кичке сәгать унбер. Без инде йокыга ятарга әзерләндек. Көтмәгәндә бүлмәгә конвойчы килеп керде:

— Тазетдинов! Әйберләреңне ал да минем арттан,— диде.

Мин «әйберләремне» — бердәнбер котелогымны алып, аның артыннан иярдем. Протестка кул куйган кешеләрнең башкалары барак коридорында тора иде инде. Көтәбез.

Күңелле хәл булыр дип көтмибез, әлбәттә. Штраф лагерена, карцерга һәм атарга менә шушылай җибәрәләр.

Иван Андреевич безнең сөмсере коелган йөзләребезгә карый да:

— Менә нәрсә, дусларым,— ди.— Ни генә эшләтсәләр дә, Совет Армиясенең өлкән офицерлары икәнлегебезне онытмыйк. Нык тотыгыз үзегезне! Түбәнлеккә төшмәгез, бернинди шәфкать сорыйсы булмагыз!..

Без үзара һәм башка иптәшләребез белән хушлашабыз — төрле хәл булуы мөмкин бит! Бик озак көткәннән соң, ниһаять, унтер-офицер килеп керде һәм безгә казарма астындагы подвалга төшәргә боерды.

Анда безне стена буена бер рәткә тезеп куйдылар. Ике автоматчы һәм бер тәрҗемәче (Идел буе немцы, элекке совет лейтенанты) иярттеп, штаб-фельдфебель килеп керде дә безне исемлек буенча барлап чыкты. Аннары, кесәсеннән безнең протестны алып:

— Бу гаризаны сез яздыгызмы? — дип сорады. Без «әйе» дигәч, сөйләп китте: — Сез, коммунистлар, монда тоз сорап яткан буласыз, ә Советлар Россиясендә безнең әсирләргә нинди мөгамәлә күрсәтүләрен, аларны ничек мәсхәрә итүләрен, тикшерми-нитми тотып атуларын беләсезме? Ә сез үзегезгә яхшы мөнәсәбәт, яхшы ризык сорыйсыз. Аннары, кемнәр соң сез әле ул кадәр! Сезне Россиянең үзендә дә сатлык җаннар дип кенә исәплиләр, анда да бер тиенгә кирәксез кешеләр бит сез!..

Шуннан соң фельдфебель безне өч тәүлеккә икмәктән мәхрүм итәргә дигән боерыкны укыды.

Тәрҗемәче сүзен бетергәч Иван Андреевич кискен бер тавыш белән:

— Мин — Совет Армиясе генералы, сез әйткәнчә, илен саткан кеше түгел,— диде.— Сез — фельдфебель, түбән чиндагы кеше, һәм сезнең безнең белән болай тупас тонда, җитмәсә үзегез хәл итә алмый торган мәсьәлә буенча, сөйләшергә хакыгыз юк. Мин безнең гаризаны лагерь начальнигы яисә лагерь кемгә буйсына — шул кеше тикшерүен таләп итәм!..

Тәрҗемәче генералның бу сүзләрен тәрҗемә итеп бетергәч, фельдфебель хәтта югалып кала язды. Генералның командирларча кыю сөйләшүе эсэсчыга бер чиләк салкын су сипкәндәй тәэсир итте. Мондый типлар көчсез, чарасыз кешеләр каршында гына этәчләнә алалар шул. Ихтыярлы, көчле характерлы кешеләрдән шүрли алар... Фельдфебель тәрҗемәчегә пышылдап кына нидер әйтте дә, тегесе тәрҗемә итте:

— Тоз иртәгә булыр, әмма лагерь начальнигы мондый протестларны бүтән язмавыгызны сорый,— диде.

«Сорый» диме?! Без үзебезнең генералыбызга сокланып карыйбыз. Ныклыкка, куркусызлыкка менә кемнән өйрәнергә кирәк!

Шуннан соң инде безнең рационга тозны күбрәк сала башладылар.

* * *

Украина белән Белоруссияне немецлар басып алган. Илебезнең чәчәк атып утырган районнарын кара күмергә; завод, шахталарын — җимереккә әйләндергәннәр; кырларда бодай урынына чүп үләне үсә; колхоз малларының берсе дә калмаган. Ә немецларга күмер, металл кирәк. Алар Украинада җитешә торган дуңгыз мае, ак икмәк һәм «яйка» (йомырка) турында хыялланалар. Украин һәм белорус әсирләрен илләренә җибәрә башлыйлар. Немецларның исәбе бик гади: буйсынган коллар үз хуҗаларына турылыклы хезмәт итәрләр — промышленностьны торгызырлар, авыл хуҗалыгын тергезеп җибәрерләр һәм алар көче белән табылган байлык, эшелоннарга төялеп, бөек Германиягә агыла башлар!

Безнең лагерьда — ихтимал, башка лагерьларда да шулай булгандыр — әсирләрне өйләренә кайтарып җибәргәндә немецлар үзләренә бик зур файда итеп калдылар. Аларга әсирнең украинмы, белорусмы булуы мөһим түгел. Аларга аның взяткага нәрсә бирүе кадерле: сәгать бирәме, акчамы, портсигармы, сыер яки дуңгыз маемы — барысын да алалар, берсеннән дә тартынмыйлар иде.

Безнең группа да йоклап ятмады. Иван Андреевич «профессор» Чардинны украин «итәргә» кирәк, диде. Чардин бик бетәшкән, лагерьда озак яши алмаячак иде. Уртак көч белән сатып алырга дип әйбер әзерләдек (кемнеңдер сәгате иде булса кирәк). Аннары каршыга икенче мәсьәлә килеп басты: Чардинны бөтен әчке киемен сырып алган бөҗәкләрдән ничек тә арындырырга кирәк иде. Монысына минем котелокның файдасы тиде. Кайнатып алынган киемнәрне плитә каршында киптердем дә аска салып яттым. Кем белә, бәлки, Чардинга иртәгә үк китәргә туры килер.

«Украиннар» группасына Чардин белән бергә полковник Глинкинны һәм тагын ике иптәшне керттек.

Әйбәт кенә җайладык шикелле: безнең «украиннар» азат ителгәннәр исемлегенә кертелеп, Украинага җибәрелде.Ниләр көтә икән анда аларны? Һәрхәлдә — лагерь түгел инде... Икенче партия оештырабыз, анысына Иван Андреевичны да кертәбез. Ул Украинага барырга җыенмый, аңа бары тик тиешле документлар белән пропуск кына кирәк.

— Фронт линиясенә барып чыгарга кирәк... — ди ул, безнең белән планнарын уртаклашып.

Немецлар, белә торып, генерал-майорны, әлбәттә, җибәрмәячәкләр. Берәр башка әмәлен табарга кирәк. Ләкин ничек? Бәлки Запольский?.. Бу аның үз фамилияседерме, ялган фамилиядерме — без анысын белмибез. Аның немецларга, җитмәсә гестапо хезмәтенә, ничек килеп эләгүе дә безгә мәгълүм түгел. Ул бик сак кеше, безгә шундый яшертен, оста итеп булыша — немецлар пычагымны да сизмиләр.

Иван Андреевич ышана аңа.

— Запольскийның вөҗданы газаплана торгандырмы яки ул анда берәр максат белән хезмәт итәдерме, әйтә алмыйм, шулай да менә боларны карагыз әле, иптәшләр... — диде бер көнне Иван Андреевич, Плотников исеменә әзерләнгән документларны күрсәтеп. — Плотников күптән түгел тифтән вафат булды... Киевтән иде ул... Миңа аның документларын Запольский җибәрткән, Анна Акимовна аша...

Анна Акимовна Елистратова — күз врачы. Ул лагерьда сирәк-сирәк булгалый, әмма Запольский белән бер дә алай очрашканы юк иде ши-

келле. Дөресен генә әйткәндә, без аңа хәтта шикләнебрәк карый идек: немецларга хезмәт итү аның файдасына сөйли торган хәл түгел ләбаса!

Ләкин хәзер боларның барысы да башка төс ала башлады. Анна Акимовна мәнә мондый вариант тәкъдим итте: ул көнчыгышка качарга теләүче әсир шофер йөртә торган машина табачак. Менә шул машинага Иван Андреевич та — генерал формасында түгел, әлбәттә, Плотников булып — утырып китәргә тиеш.

Кичен мин, Прудников һәм Северюхин Иван Андреевичка ориентир булып хезмәт итәрлек схема-карта сыздык. Аннары фашистларның лагерьда кылган барлык явызлыкларын язып чыктык. Ул-бу булып, немецлар укый алмасын өчен, кайдандыр Гриценко алып кайткан сөт белән яздык аларны. Язулы кәгазь битләрен камыр белән марляга ябыштырдык, мамыкка төреп бушлат эченә тегеп куйдык. Генерал үз эше белән йөрүче крестьянга охшасын өчен, иске бушлатка тектек. Иван Андреевич үзенең генерал формасын бүлмәдәше лейтенант Федя Харламовка калдырды. (Генерал башка әсирләр белән аралашмасын өчен, немец администрациясе кушуы буенча, Федя моңарчы Иван Андреевичның адъютанты вазифасын үти иде.)

Салкын январь көне. Северюхин һәм мин лагерь капкасы төбендә Иван Андреевич белән саубуллашабыз. Кысып кочаклашабыз, хәерле юл телибез. Сизәм, күзләремә яшь тыгыла... Чалара башлаган сакалмыеклы, начар гына таякка таянган, иске бушлат кигән бу кешенең совет генералы, 5 нче дивизия командиры булуын немецлар да, әсирләр дә башларына да китермиләр...

Безнең белән бергә сакчы Австрия немецы да куана: карт камрад исән килеш өенә кайтып китә, янәсе! Озаклап, Иван Андреевич тәмам күздән югалганчы карап торабыз. Эх, юлы уңышлы булсын, эләкмәсен генә иде инде!..

Сигез көн үтеп китте. Без Иван Андреевич белән шофер фронт сызыгына уңышлы гына барып җиткәннәрдер инде дип уйладык. Ләкин... тугызынчы көнне, иртәнге тикшерүдән соң, мине кинәт полицай гестапога алып китте. Лагерьның баш врачы Груздев, Федя Харламов һәм лагерь полициясе начальнигы Иванов та шунда кабул итү бүлмәсендә иделәр. Без бер-беребезгә карашып алдык. Монда чакыртуның мактар өчен түгеллеге һәркемгә билгеле. Берничә минуттан соң безнең янга гестапо гауптманы белән ике бик таза эсэсчы чыктылар. Гауптман безне күз йөртеп тикшереп алды да, Федяга текәлеп:

— Генералның качуын нигә хәбәр итмәдең? — диде.

Адъютант эндәшмәде. Нәрсә дисен ул?

— Я, ничек? Җавап бирәсеңме-юкмы? — дип сорады яңадан гауптман.

Харламов һаман эндәшмәде. Ул бик яшь әле. Дулкынланудан аның төсе киткән, бармаклары бертуктаусыз бушлат итәген капшый. Фашист стена буенда торган эскәмиягә ымлап күрсәтте. Анда, гадәттә, тән җәзасы бирәләр.

Эсэсчылар Харламовны әләктереп алып, өске киемен тартып төшерделәр, эчке күлмәген күтәреп куйдылар да эскәмиягә йөзтүбән китереп салдылар. Иванов бер эсэсчы белән Федяның башын һәм аякларын тотты, икенче эсэсчы чыбыркы белән ялангач тәненә сугарга кереште. Чыбыркы һавада чыжлап барып төшә дә тәнгә бата. Һәр суккан эз башта агарып тора, соңыннан кызарып күбенеп китә. Берничә тапкыр сукканнан соң тире ярыла, шартлап кан чыга. Тагын берничә тапкыр суккач, кан эскәмиягә ага башлый.

Федя баштарак кычкырып ыңгырашып ятты, аннары тынып калды һәм бөтен тәне белән калтыранырга тотынды. Йөзенә тир бәреп чыкты, бәбәкләре киң булып ачылганга, соргылт күзләре кара булып күренә иде.

Егерме биш тапкыр сукканнан соң, Федяны эскәмиясе белән бергә күтәреп ишек алдына чыгардылар. Аның тәне әле яңа гына тиресе туналган түшкәне хәтерләтә иде.

Гауптман, миңа мөрәҗәгать итеп:

— Бүлмәдә өлкәне сез, — диде. — Генерал сезнең белән еш очрашкан, бүлмәгездә домино уйнаган, сөйләшеп утыра торган булган. Сез, әлбәттә, аның ниятләрен белгәнсез. Нигә хәбәр итмәдегез?

Гауптман минем нәфрәтле карашымны тоеп, соравын тагын бер тапкыр кабатлады.

— Без, офицерлар, Пресняковның качуы турында берни дә белмәдек, — дидем мин. — Ул сезнең аерым исемлектә торды, аерым бүлмәдә яшәде, планнарын безгә сөйләгәне булмады.

Лагерь врачы да нәкъ шулай дип җавап бирде.

Гауптман арлы-бирле йөренә башлады, аннары полиция начальнигына боерып:

— Ач паекка утыртырга! Ә сезгә уйларга киңәш итәм. Югыйсә сезне дә генерал адъютанты белән булган хәл көтә, — диде.

Әйе! Без гауптман киңәшен тыңлыйбыз: уйлыйбыз. Безне әшәке мөгамәлә, чыбыркы белән куркытырга һәм буйсынучан колларга әверелдерергә теләгән фашистларның бу эше барып чыкмавы турында уйлыйбыз. Алар рус крепостнойлары белән түгел, бәлки СССР гражданнары белән эш итүләрен онытканнар, күрәсең.

Өч көн буена безгә икмәк һәм баланда бирмәделәр. Ә безне гестапога чакырткнның икенче көнендә Иван Андреевичны лагерьга китерделәр. Аны бездән аерым, лагерь штабына урнаштырдылар, өстеннән махсус сак куйдылар, янына керергә һәм сөйләшергә дә рөхсәт итмәделәр.

Генералның качуы нигә болай уңышсыз чыккан соң? Иван Андреевич нәкъ билгеләнгән көнендә генә лагерьдан чыгып ычкына алмас дип, аңа әзерләнгән документларга Запольский киләсе көн числосын куйган булган икән. Ләкин машина вакытында килгән һәм Иван Андреевич кояш баеган вакытларда лагерьдан сиксән километрлап китеп тә өлгергән. Әмма шоферның кинәт хәле киткән. Ул юлны юньләп аермый башлаган һәм бераздан кабинада бөтенләй һушын җуеп, сыгылып төшкән. Пресняков урынында башка берәү булса, ихтимал, шоферны машинасында калдырыр иде дә юлны дәвам итәр иде. Ләкин Иван Андреевич андыйлардан түгел шул. Бөтенләй таныш булмасалар да, үзе белән бергә качарга җыенган авыру кешене дошман кулына калдырып китми ул. Башта шоферны якын-тирәдәге берәр авылга урнаштырмакчы, аннары гына юлын дәвам итмәкче була. Әмма шунда документларына киләсе көн числосы куелганы исенә төшә! Мондый документны авыл бургомистрына ничек итеп күрсәтмәк кирәк? Ә бургомистр, һичшиксез, документ сораячак!

Менә шунда Иван Андреевич ялгышлык эшли: числоны карандаш белән төзәтеп куя. Әллә ни белемле булмаса да, төзәтелгән цифр бургомистрны шиккә төшерә. Пропусканы ул әйләндергәләп карый да йомышчысына:

— Полиция начальнигын алып кил әле... Ул очына чыксын, — дип боерык бирә.

Йомышчы чыгып киткәч, ачуыннан үз-үзен белештермичә, Пресняков авыл старостасының тетмәсен тетәргә керешә:

— Син нәрсә, кабахәт! Немецларга сатылдыңмы? Совет власте кире кайтмас дип уйлыйсыңмы? Ничек кенә кайтыр әле ул һәм сиңа да тиешле җәзасын бирер! Тиз генә шоферны берәр йортка урнаштыр, ә мине җибәр. Мин — совет генералы, синең мине тоткарларга хакың юк! — ди.

Шулчак бүлмәгә полиция начальнигы килеп керә һәм бургомистр аңа шикле карт турында сөйләп бирә...

— Әйе, кызыбрак кителде ул чакта. Ул хәерсез янында үземне башкачарак тотасы калган икән... — диде генерал, соңыннан үз-үзен тиргәп.

Генералны кыр жандармериясе кулына тапшыралар һәм яңадан лагерьга кайтаралар. Соңыннан аның белән качарга җыенган шоферның да шул көннәрдә тифтән үлгәнлеге ишетелде.

Качарга маташуы өчен без Иван Андреевичны атмагайлары дип курыккан идек. Әмма моңа да Запольскийның катнашы зур роль уйнады булса кирәк — генералга тимәделәр. Ә бераз вакыт үткәч, аңа хәтта безнең белән очрашырга, сөйләшергә дә рөхсәт итә башладылар.

* * *

Шулай итеп, немецлар әсирләрне Украинага һәм Белоруссиягә җибәрүдән туктадылар. Ышанычлы хезмәтчеләр ясый алмауларын аңладылар, ахры. Хәер, яндырылган, җимерелгән шәһәрләр, авыллар күз алдында булганда, исән калган кешеләрдән фашистларның ул авылларда һәм шәһәрләрдә нинди явызлыклар эшләп китүләрен ишетеп-күреп торганда бу турыда сүз булу мөмкинме соң? Әсирлектән кайтучыларның күбесе шундук урманнарга китеп партизан отрядлары төзиләр яки, төзелгәннәренә кушылып, яңадан фашистларга каршы көрәшә башлыйлар. Бары тик бик азы, Совет властена ачу саклаган кулак калдыклары гына немецларга хезмәт итәргә кала.

Хәзер лагерьдан качу кыен. Немецлар совет халкының үзгә бер халык булуын, аны ут һәм кылыч белән генә тез чүктерергә мөмкин түгеллеген торган саен күбрәк аңлый баралар. Лагерьда сак көчәйтелде, эшкә дә машинага утыртып, күбрәк конвойчылар белән йөртәләр, ышанычсыз кешеләрне аерып, башка лагерьларга озаталар. Әмма, шуңа да карамастан, кешеләр качарга тырышалар. Качып китүче тотылса, я аны аталар, я имгәткәнче җәзалыйлар, ләкин әсирләр аннан да курыкмыйлар. Һаман иреккә омтылалар.

Утыз меңлек әсирләр төркеме иртән мәйданга җыела. Барысы да машинага эләгергә тырыша: коточкыч тавыш, сүгенү, кысылыш. Машинага эләгү — ә анда нибары 4—5 кенә машина — лагерьдан тышка чыгу дигән сүз. Анда ашарга яраклы ризык табарга, шул тирәдә яшәүче халык белән бәйләнешкә керергә һәм, жае чыкса, качып китәргә мөмкин. Башка көннәрне без Горнашевич белән никадәр тырышып та машинага эләгә алмый идек. Ә бүген безне һич тә көтмәгәндә бәхет басты: машинага ыргылучы яшьрәк, үткенрәк кешеләргә кычкырып һәм автомат түтәсе белән төрткәләп тору туйдырды булса кирәк — эсэсчы, кул изәп, безне, читтәрәк басып торган өлкәнрәкләрне, чакырып алды...

Лагерь тышында хәтта искән җилдән дә ирек исе килә. Безне ниндидер немец солдатлары ашханәсенә бәрәңге әрчергә алып килделәр. Аның кухнясында берничә рус хатыны да эшли икән. Алар безнең ябыклыкны күреп аһ та ваһ килделәр, лагерьдагы тормыш турында сораштылар. Аннары аларның берсе зур гына табакка аш салды, бер бөтен икмәк бирде. Без ашыйбыз да ашыйбыз, ашаудан аерыла алмыйбыз. Корсакларыбыз инде бүселеп чыкты, йоткан аш кире килер дәрәҗәгә җитте, ләкин үзебез һаман да туймыйбыз...

Көн буе бәрәңге әрчедек, плитәгә утын яктык. Тәрәзә аша немец гәүдәләре чагылып-чагылып китә иде, конвойчы ишек төбендә рус «фрауы» белән шаярып тора иде. Кызганычка каршы, качарга бер дә җайлы түгел шул!..

Кичен хатын-кызлар безнең чүпрәктән теккән янчыкларга бәрәңге тутырып бирделәр. Бу яңа пешкән бәрәңгеләрне исән-сау алып кайтсак, Иван Андреевич шатланып бетә алмас инде!..

Сагынудан, зарыгудан түзәрлек чама калмаганда, без җырлап котылырга тырышабыз. Акрын гына, сакчы ишетмәслек итеп кенә җыр башлыйбыз. Безгә Иван Андреевич та кушыла, кайчакта үзе үк башлап җибәрә. Күбесенчә рус халык көйләрен җырлыйбыз. Пресняков нечкәрәк саф бер тавыш белән җырлый, бигрәк тә «Орленок»ны әйбәт чыгара. Ул җырлап туктагач, күңелләре йомшарып, рухлары күтәрелеп киткән иптәшләр генералны урап алалар да:

— Иван Андреевич, мәгез, сигарет тартып җибәрегез!

— Сигарет нәрсә ул! Менә пешкән бәрәңге ашагыз, ичмасам, авызда эреп кенә китә! — диешеп, һәркем кулыннан килгәнчә аңа үз хөрмәтен күрсәтергә тырыша.

Иван Андреевич шахмат, домино уйнарга бик ярата. Бик күпләрне «кәҗә» калдыра ул. Ләкин кайчак үзе дә оттыргалый. Ә безнең мондагы гадәт буенча, оттырган кеше, өстәл астына кереп, кәҗә булып кычкырырга тиеш. Монысы инде бик мәзәк була. Оттырган чакларында генерал, бер дә сукранмыйча, «кәҗә»гә әйләнә.

Бервакыт мин Северюхин белән алдан киңәшеп куйдым да, Пресняков оттыргач:

— Иван Андреевич, сез бездән яшегез белән дә, чинытыз белән дә олырак. Сезне өстәл астына кертү ничектер килешми... Бүтән алай эшләмәгез, яме! — дигән идем.

— Юк, — диде генерал, көлеп. — Сез алай әйтмәгез, Сәгыйт Абдуллович. Иптәшләргә кызык булсын өчен, аларның күңелләрен күтәрер өчен керәм бит мин анда. Безнең хәзерге хәлдәге кешегә күңел күтәренкелеге кайчак бер сынык икмәктән дә кадерлерәк була. Борчылмагыз, өстәл астында азрак утырып чыкканга карап кына минем генерал дәрәҗәмә зарар килмәс...

* * *

Безнең бүлмә-кухня ничектер клуб сыман бер нәрсә булып китте: халык шундый күп — тын алырлык та түгел. Гриценко иң өске, өченче катта сөйләнеп-хыялланып ята:

— Бу вакытта безнең колхоз язгы чәчүгә әзерләнеп беткән була торган иде инде... Тракторлар, чәчкечләр парадтагы кебек тезелеп торыр иде... Их, үтерә бит шулар сагындырып! — ди ул.

Бүлмәгә Иван Андреевич килеп керде:

— Җылы сөяк сындырмый, диләр, анысы шулай! Әмма... Сәгыйт Абдуллович, әйдәгез әле, бераз ишек алдында да йөреп керик булмаса, — дип, мине тышка алып чыкты.

Күк йөзе зәп-зәңгәр. Кояш нәкъ яз көнендәгечә кыздыра. Хәер, яз җитте ләбаса: март ахыры бит инде. Бераз җир исе белән кушылган саф һава башларны тагы да әйләндерә. Шушы үткән кышта безнең тагы да ябыкканлыгыбыз, чәчләребезнең тагы да агарганлыгы, киемнәребезнең тагы да туза төшкәне кояш яктысында бигрәк тә ачык күренә. Шулай да кәеф әйбәт безнең: хәзер инде туңып үлүдән куркасы юк, хәзер, бәлки, качарга да ансатрак булыр. Бәлки, фронт хәлләре дә яхшы якка үзгәреп китәр, бәлки, әсирләрне алмашу башланыр... «Бәлки»ләр бик күп...

Тотен-командада эшләүче әсирләр кары эреп, боткаланып беткән юлдан мәетләр төялгән чана тартып киләләр. Кайсылары арурак икәнен аңламассың: тереләренең дә, үлеләрнеке кебек үк, йөзләреннән кан качып, күгәреп калган. Могилевта бу кышны күпме солдат һәм офицерыбыз һәлак булды икән безнең? Ихтимал, берничә кан койгыч зур

сугыш вакытындагыдан да күбрәк кырылгандыр. Шуңа күрә әсирләр: «Могилевта безгә могила булачак», — дип шаярткан булып әйтә торганнар иде.

Иван Андреевич күмә баручыларга карап торды да, офтангандай итеп:

— Газап-михнәтләрне күп күргән кешенең күңеле ката, ул битарафка әйләнә диләр... Бик каты күңелле буласы иде дә бит... Алай җиңелрәк булыр иде... Ләкин юк шул, барып чыкмый. Хәер, усаллыгы да күп җыелды инде... Ун кешегә җитәрлек... — диде.

Мин аның хәлен бик яхшы аңлыйм. Үземнең дә күңелем ташып чыгарга тора. Бераз сүзсез баргач:

— Безне тагын бүтән җиргә күчерерләр, ахыры, Иван Андреевич,— дидем. — Офицерларны махсус оештырылган лагерьга җибәрәчәкләр икән дигән сүз йөри.

— Бик ихтимал! — диде Иван Андреевич. — Безне солдатлар белән бергә калдыру немецлар өчен файдалы түгел бит.

Әсирләр мәнфәгатен яклавы белән, Пресняков лагерьда көннән-көн күбрәк танылa бара. Хәтта иң бетәшкән, бөтенләй өметләрен җуйган солдатлар да аны күргәч ихтыярсыз төзәтенеп куялар һәм кагыйдә буенча тиеш булганга гына түгел, бәлки, теләп, чын күңелләреннән аңа честь бирәләр.

Лагерь администрациясе Пресняковка үз өлешен алырга барырга да, су алып кайтырга да рөхсәт итми. Ул эшләрне Федя Харламов башкара. Генералга тышта да билгеле бер урында гына йөрергә рөхсәт ителә.

Хәер, башка офицерларның да солдатларга тәэсире немецлар теләгәнчә түгел, киресенчә...

— Яңа лагерь турында «матур» хәбәрләр йөри. Лагерь администрациясе тарата торган ул хәбәрләргә караганда, анда кереп-чыгып йөрү дә ирекле, ашау да искиткеч яхшы булачак, хәтта һәр офицерга денщик та беркетәчәкләр, имеш...

— Берсенә дә ышанмагыз! — ди Пресняков, тиз ышанучан кайбер кешеләрне айнытырлык итеп. — Үзегез уйлап карагыз: безне андый «җәннәт»тә тотуның немецларга ни мәгънәсе бар? «Денщик», имеш!.. Ә үзебез ачтан шешенеп ятабыз... Безне икенче лагерьга күчергәндә качып-таралып бетмәсеннәр дип шикләнә алар, шуңа күрә шундый нәрсәләр вәгъдә итәләр! Аларга ышанырга ярыймы соң?

* * *

Без инде икенче лагерьга күчеп барабыз. Бик озаклап, этапларда туктала-туктала, кысыла-төртелә барабыз...

Менә Борисово станциясе. Барлык әсирләрне вагоннардан ипи алырга чыгаралар. Өлешләрне озын буйлы, кара чәчле һәм кара күзле бер кеше биреп тора (үзбәк булса кирәк). Ул икмәк алган һәр кешенең яңагына чабып кала һәм шул ук вакытта Совет власте белән Коммунистлар партиясен дә сүгә. Бу тамашаны читтән карап торучы немец офицерлары эчләре катып көләләр. Ләкин Иван Андреевич моңа озак түзеп тора алмады. Тиз генә сафтан чыгып, немецларга ярарга тырышкан әлеге кара полицай янына килде дә:

— Хәзер үк тукта кыйнавыңнан! Югыйсә немецлар командованиесенә хәбәр итәм. Әсирләрне шушылай мыскыл итәргә кем хокук бирде сиңа, әшәке җан? — диде.

Пресняковның генерал формасын күргәч, кыйнаучы янында торган обер-лейтенант аптырабрак калды һәм: «Әсир генерал нәрсә әйтте?» — дип тәрҗемәчедән сорады. Эшнең асылына төшенгәч, ул ипләп кенә

әлеге полицайның яңагына бер-икене тамызып алды, һәм аңа өлешләрне «өстәмә»сез генә өләшергә боерды.

Кыйналган эт шикелле куркып, бөрешеп калган полицайдан көлмичә түзә алмадык.

— Әһә, куштан алабай, эләктеме үзеңә. Хуҗаларыңның рәхмәтен ишеттеңме? Болай гына да итмәсләр әле киләчәктә! — диде Салеев Петр Иванович.

Безгә кабып йотардай итеп караса да, полицай кулына ирек бирми хәзер...

Кречево станциясенә җитәбез һәм, шунда ике тәүлек тукталып торганнан соң, Молодечнога — офицерлар лагерена кеше туплый торган пунктка — алып киләләр.

Монда башка лагерьлардан китерелгән офицерлар да байтак икән инде. Шулар арасында Николай Иванович Митрофанов та бар. Иван Андреевич аның белән күптән таныш икән. Алар Фрунзе исемендәге бишенче дивизиядә — Пресняков командир, Митрофанов оператив бүлек командиры булып — бергә хезмәт иткән булганнар.

Митрофанов — зифа буйлы, сөйкемле йөзле, интеллигент кыяфәтле бер кеше. Революциягә кадәр патша армиясендә офицер булган. Гражданнар сугышы елларында Төньяк Кавказ округының штаб начальнигы вазифасын үтәгән. 1922 елдан алып, Ватан сугышы башланганчы запаста торган. Николай Иванович берничә чит телне яхшы белә, немецча да чатнатып сөйләшә иде.

Монда бишенче дивизиянең штаб начальнигы полковник Самойлов, утыз җиденче дивизия командиры генерал Данилов, майор Чернов һәм башкалар да бар иде.

Иван Андреевич аларны очратуына сөенде дә, көенде дә. Үзеңнең хезмәттәшләреңне һәм танышларыңны әсирлектә күрү бик күңелле хәл түгел шул!

Майор Черновка исем китә минем. Бер минут та тик утырмас, Грязнов кебек алтын куллы кеше икән ул. Күрәсең, шуна дуслашканнардыр да алар. Доминосын үзләре ясау турында әйткән дә юк инде, әле күптән түгел генә консерва банкаларыннан шундый итеп генерал йолдызлары ясаганнар — чын йолдыздан аерып та булырлык түгел.

Әнә хәзер дә Чернов шашка тактасы ясап утыра һәм үзенең ягымлы калын тавышы белән: «Теләсәгез ничек саклагыз, ә мин барыбер качам!» — дип җырлый. Грязнов исә кайсыныңдыр котелогына «көндәлек» уя. Ә тышта җир йөзенә бөтен матурлыгы белән яз килә! Ярым юеш, сасы баракларда утыру бик читен, шуңа күрә ярты сәгать тышта йөрү бәхетеннән дә зур бәхет юк безгә...

Бараклар арасындагы тар тыкрыктан, бик эшлекле кыяфәт белән атлап, лагерь начальнигы — майор чинындагы барон Кляйбен (әллә Кляйденме — төгәл хәтерләмим) килеп чыкты. Җитмеш яшьлек бу карт — Көнчыгыш Пруссиянең бик зур алпавыты, диләр.

— Шайтаным калганмы аңа монда! — дип, Пресняков якынлашып килгән лагерь начальнигына яны белән борылды.

Мондый көтелмәгән хәлдән барон аптырап калды. Баганадай катып, бераз генералга күзләре белән кадалып торды да, шашынып:

— Нигә лагерь начальнигын сәламләмисез? — дип кычкырды. Ачудан аның бөтен гәүдәсе калтырый иде, усал зәңгәр күзләре ниндидер яшькелт төскә керде.

Тәрҗемәче безгә аның соравын кабатлап әйтеп бирде.

Иван Андреевич ашыкмый гына баронга таба борылды да, тәрҗемәчегә мөрәҗәгать итеп:

— Лагерь начальнигына әйтегез: ул әле майор гына, ә мин — генерал-майор. Мин аны түгел, ул мине сәламләргә тиеш! — диде.

Бу җаваптан соң, барон бер мәлгә, судан ярга чыгарып ташланган чуртан кебек, авызын ачып, сүз әйтә алмыйча торды. Аннары коточкыч әшәке итеп сүгенергә тотынды. Ул сүгенеп туйгач, без китеп бардык һәм бер тыкрыкка борылып кереп, баронның сүзен әйтә алмыйча авызын ачып торуын, ачулы кыяфәтен күз алдыбызга китереп, күзебездән яшьләр килгәнче көлештек.

— Соң мин хаклы идем бит, Сәгыйт Абдуллович, әйеме? — диде Пресняков, ниһаять, көлеп тукталганнан соң.

Мин, генералга сокланып карап:

— Әлбәттә, хаклы идегез, Иван Андреевич! — дидем.

Әсирлектә кешенең эчке сыйфатлары бик тиз ачыла. Кешелекле, зур әхлаклы кешеләр мондый шартларда тагын да әйбәтрәк, саф күңеллерәк булып калалар, гомуми эш өчен бернәрсәләрен дә кызганмыйлар. Безнең Иван Андреевич та шундый. Ә үз-үзләрен генә яратучы, гел үз файдаларына гына эш итәргә омтылучы куркак җаннар бөтенләй башка якка үзгәреп китә. Тыныч вакытта алар, ихтимал, җыелышларга да вакытында, төгәл йөрерләр, семьяда да үзләрен ярыйсы гына тотарлар, сәүдә һәм коммуналь хуҗалык эшләрендәге кимчелекләрне дә тәртеп күрсәтерләр, кыскасы — «тәртипле» кеше булып йөрерләр иде. Әмма монда, лагерьда, икейөзлеләнергә туры килми. Минут саен үзен сагалап торган үлем алдында кешенең чын йөзе ренгент аппаратыннан карагандай ачылып китә: берәүләр үз иптәшләре каршына куркусыз батыр булып, икенчеләре ышанычсыз шакшы җан булып, өченчеләре просто совет гражданины бурычын үтәүче (лагерь шартларында монысы да батырлык инде аның!) булып, дүртенчеләре әле сатылып ук җитмәгән, әмма рухи яктан шундый түбән тәгәрәгән — сатылырга бер адымда гына калган кешеләр булып килеп баса. Кешелекләрен һәм ихтыяр көчләрен югалткан андый бәндәләргә карау читен дә, кызганыч та: алар һәрвакыт мич тирәсенә елышалар, полицайлар янынннан түбәнчелек белән бөкрәеп кенә узалар, кешедән тәмәке төпчеге теләнәләр яки аны идәннән җыялар. Ул мескеннәрнең уенда бер генә нәрсә — ничек итеп булса да ризык юнәтү. Немецлар тикмәгә генә аларны полицайлыкка һәм шымчылыкка иң кулай элементлар дип санамыйлар шул.

...Шулай итеп, без озакламый Кальвариягә — теге «бөтен шартлары уңайлы» булачак офицерлар лагерена барып җитәчәкбез. Полковник Дерюгин һәм полковник Карапутин ул көннең җитүен дүрт күз белән көтәләр. Иван Андреевич аларга анда бернинди дә «җәннәт» булмаячагын әйтә-әйтә арыды инде, шуннан соң: «Әйдә, юкны өмет итеп юансыннар шунда!» — дип кул селтәде.

Дерюгинны без «кулинар» дип йөртәбез. Ул сугыш беткәч пешертәчәк ризыкларының бик озын итеп исемлеген төзеп куйган. Флотча кәбестә ашының, себер пилмәннәренең һәм эремчеккә йөзем җимеше кушып пешерелә торган казан бөккәннәренең искиткеч тәмле булуы турында ул тыңлаучыларның авызыннан сулар китерерлек итеп сөйләп утыра.

Бер вагонда без утызлап кеше. Кайсыларыбыз нарларда, кайсыларыбыз идәндә ята.

— Ә сез беләсезме, безнең вагон тамбурында нигәдер овчаркалы конвойчы күренми бит, — ди Чернов.

Ул, идәндә яткан килеш, тимер чыбык белән идән ярыкларын чистарта.

— Әйе шул, мин дә игътибар иткән идем аңа, — ди полковник Самойлов, аңа җавап итеп.

Шунда Черновка кемдер пәкесен суза. Ул чистарткан ярыктан артка таба агылып калган җир һәм кара шпаллар күренгәли башлый.

— Ирекккә менә шушылай чыгарга мөмкин бит! — ди Чернов, рухланып. Аның йөзенә сыек кына алсулык йөгерә, күзләре елтырый башлый.

— Ярый торган фикер бу! — ди Северюхин, аңа кушылып. — Берничә сәгатьтә без кеше сыярлык ярык уя алабыз бит. Ә төнлә...

— Мондый эш өчен башыңны чабып өзәрләр, — ди полковник Медведев.

Иван Андреевич чүгәли дә җентекләбрәк идән такталарын карарга керешә.

— Әйе... Ирекккә чыгу юлы менә шушында, — ди ул аннары. — Тик исегездә тотыгыз, иптәшләр: сизсәләр — барыбызга да үлем булачак... Барыбыз да шул хәлгә риза булганда гына качарга әзерләнергә мөмкин.

— Барыбер бер үләсе инде! — дип, Федя Харламов күгәргән кадак белән ярсып-ярсып идән тактасын чокырга да керешә.

— Калын гына идән тактасын тишәр өчен кораллар әллә ни шәп түгел инде: ике кечкенә пәке, кадак һәм тагынниндидер бер тимер кисәге. Ләкин ирекккә чыгасы килү теләге бер генә минутка да күңеленнән чыкмаганда ул тактаны тешең белән дә кимерергә әзер булырсың!

Чиратлашып, бик сакланып кына идәнне чокыйбыз. Берәрсе керә калса, тишекне капларга дип, бушлатларны әзер тотабыз. Калын такталар акрынлап юкара бара. Инде тишеккә кул сыярлык та булды. Тагын бераз гына тырышасы да... Аннары төн җитү белән без иректә инде...

Ләкин... Кинәт паровоз кычкыртып куйды һәм эшелон, барышын акрынайтып, ялан кырда туктап калды. Тышта шау-шу, кычкырыш, эт өргән тавышлар ишетелде. Без бер мәлгә урыныбызда катып калдык, аннары тишеккә киемнәрне капладык. Менә безнең вагон ишеге дә кинәт дөбердәп ачылып китте. Автоматларын болгап-болгап, вагонга берничә сакчы сикереп менде. Безне бер почмакка кысрыклап, аяклары белән идәндәге саламны, киемнәрне актарырга керештеләр. Озакламый теге тишекне дә таптылар...

— Эшләр начар! — диде Иван Андреевич, пышылдап.

Ә сакчылар дөнья кубарып тузынырга тотындылар! Кычкыра-сүгенә тишеккә такта кадакладылар, идәнгә юеш ком җәйделәр һәм безгә нәрсәдер эшләргә боердылар.

Чишенергә кушалар икән. Өстебездән шинель, бушлатларыбызны салдык. Сакчылар һаман акырыналар, автомат түтәләре белән китереп төртәләр. Без немецча аз-маз аңлыйбыз инде: эчке күлмәк-штаннан гына калып, идәнгә утырырга куштылар. Аннары киемнәребезне алып чыгып киттеләр. Ишекләр яңадан шыгырдап ябылды, поезд кузгалып китте.

Без бик туңа башладык, бер-беребезгә елышыбрак утырдык.

— Кара син ул кабахәтләрне, нәрсә уйлап чыгардылар бит! Штансыз кая качасың хәзер!.. — диде Грязнов аптырап.

— Дуңгызлык эшләргә аларга куш инде, — диде Чернов. — Шулай да пәкене яшереп алып калдым әле мин!

Ничек булды соң әле бу? Нигә алар, кыр уртасында поезд туктатып, безне тентергә керештеләр? — диде Прудников.

— Вакыты җиткәч, барысын да белерсең. Эш барып чыкмады, шунысы кызганыч, — диде Иван Андреевич. Тыштан ул тыныч күренә, әмма, сизелеп тора: аңа да бик кыен. Идәнне тишәргә ул — өлкән офицер рөхсәт итте бит! Безне ни эшләтерләр икән инде?..

Поезд барышын акрынайта төште. Паровоз сузып-сузып кычкыртты да эшелон туктады. Янә ишек ачылып китте һәм безне төрткәли-төрткәли вагоннан төшерделәр. Без, кулга кул тотышып, тыгыз туплам булып

басып торабыз. Фашистлар эсирләрне нәкъ менә шушылай, эчке кием-нән генә калдырып аталар...

Ләкин үлем безне бу юлы да читләтеп үтәр, ахрысы. Безне «куркыту өчен» генә шушылай тезгәннәр. Икенче бер вагонда да офицерлар идәнне тишмәкче булганнар икән. Алар шактый зур тишек ясаган булганнар, ләкин тамбурда барган сакчы шикле тавыш ишеткән... Менә шуннан соң немецлар тревога күтәргәннәр, бөтен вагоннарны тикшерергә тотынганнар.

«Башлап йөрүче» алты офицерны конвойчылар каядыр алып киттеләр. Атарга ук микәнни?.. Ә безне вагоннарга куып менгерделәр. Яңадан көпчәкләр тыкылдарга тотынды. Без, бер-беребезне җылытырга тырышып, идәндә өелешеп утырабыз.

Очсыз-кырыйсыз кебек сузылган ике тәүлек буена безгә икмәк тә, су да бирмәделәр. Сусауга һич чыдар эмәл юк. Хәтта тиктормас, аптырый белмәс Чернов та тынып калды. Әнә ул, озын, ябык бармаклары белән тезен кочаклап, Грязнов янында утыра, кипкән иреннәрен чак кыймылдатып:

— Минемчә, шушылай газап чигеп, җәфаланып үлүгә караганда, пуля тиеп, тиз генә дөнья куюың мең өлеш артыграктыр... — ди.

## Офицерлар лагере

Озын төннәрнең әйбәт ягы да, начар ягы да бар. Бездән беркадәр алданрак 1600 кешелек офицерлар эшелонының башлыгы булып Минскидан килгән генерал Наумовтан, капитан Копытовтан, полковник Бахаревтан һәм полковник Богдановтан сакланырга кирәклеге безгә билгеле инде. Дөрес, моңарчы Наумовның әллә ни зыяны тигәне юк эле. Ул да иртәнге тикшерү вакытында безнең кебек үк салкында калтырый, кайчандыр кыйммәтле генә драп булса да, хәзер инде безнеке шикелле үк тузып беткән шинель киеп йөри...

«Люкс-лагерьда» — офицерлар лагеренда — без инде берничә атна торабыз. Немецлар вәгъдә иткән яхшы шартлар, әлбәттә, буш сүз булып чыкты.

Кальвария — Көнчыгыш Пруссия чиге буендагы кечерәк кенә Литва шәһәре. Безне кайчандыр Литва хәрби частьлары яшәгән казармаларга урнаштырдылар. Монда, чыннан да, гел офицерлар гына: немецлар солдатларны алар йогынтысыннан коткарырга кирәклеген аңлаганнар, каһәрләр! Анннары, партизаннар хәрәкәте көннән-көн көчәя барган Белоруссиядә эсирләр тоту да куркыныч. Әсирләр — «тиз кабына торган материал» бит. Партизаннар белән элемтәгә керсәләр — бигрәк тә.

Шулай итеп, безне фронт линиясеннән һәм партизаннар хәрәкәт итә торган зоналардан еракkарак җибәрә торалар. Димәк, безнең үзебезгә активрак булырга кала: бүтән чара юк.

Без бер-береннән чәнечкеле тимер чыбык белән аерып куелган өчәр катлы ике казармада яшибез. Монда алты мең чамасы әсир бар. Бүлмәләр шып-шыр: тупас итеп ясалган икешәр катлы нарлардан башка, урындык та, өстәл, тумбочка да юк. Ашаганда да нар араларында басып ашарга туры килә. Баланданы кухняга барып аласы. Әсирләрнең күбесе котелок юнәтеп өлгермәгән эле, шунлыктан алар баланданы я каскаларына, я чүплектән тапкан консерв банкаларына, я фанердан ясаган ящикларга, ә анысы да юклары исә шинель итәкләренә салдырып алып кайта. Ризыкны нииндидер Иваненко өләшә. Әй, эт тә кеше инде! Савытына баланда салдырырга килгән әсирләрнең яңагына аш чүмече белән сугу — аның иң яраткан эше. Кайчакта «кызык өчен» өлешнең яртысын әсирнең кулына түгә, тегенең кулы пешкәч, угалануына ихахайлап көлеп карап тора. Монда ачлык Могилевтагыдан да

яманрак. Анда, ичмасам, солдатлар лагерьдан читтә эшләгәндә берәр төрле ризык табып кайтып, ярдәм итә торганнар иде.

Ачлыкка түзә алмыйча, әсирләр үлән, хәтта ачы әремгә кадәр ашап бетерделәр. Инде хәзер аны да табып булмый, лагерь ишек алды таптакыр. Чәнечкеле тимер чыбыкның тышкы ягында үләне дә, әреме дә җитәрлек, әмма аларга кызыгып карап торудан башка берни эшләр хәлең юк. Әле шушы көннәрдә генә, ат кузгалагы яфрагы алырга дип кулын тышкы якка сузган өчен, бер офицерны каланчадагы сакчы атып үтерде.

Без ялангач нарларда йоклыйбыз. Өс-баш тузып-тетелеп бетте инде. Ә ишек алдындагы складта бик күп кием-салым өелеп ята. «Теге дөньяга» киткән кешеләрнеке алар. Инде бөтенләй ялангачка калган әсирләргә генә кайчакта кием бирәләр. Кичә генә безнең бaрактагы бер офицерга да мундир биргәннәр иде, мундирның җилкәсе тишек, канга буялган булып чыкты. «Атылган кешенеке инде бу», — диде офицер, чирканып. Әмма өстенә кимичә булдыра алмады!

Безнең генераллар — Пресняков, Данилов һәм Наумов — өчесе бер бүлмәдә, бездән аерым торалар. Шулай да Иван Андреевич күбрәк вакытын безнең белән үткәрә.

— Наумовның үз-үзен тотышы ошамый миңа, — ди ул. — Пессимист... җиңүгә ышанмый... Шайтан белсен аның нинди бәндә икәнен! — ди.

Наумовның әшәкелеген озакламый үзебез дә күрдек. Беркөнне эсэсчылар зур дәрәҗәле немец генералын — корпус командирын — каршыларга әзерләнә башладылар. Хәтта безнең «люкс-лагерь»да да тәртип кертмәкче булып, әсирләрдән плацны, юлларны себерттеләр, ком сиптерделәр.

Менә, ниһаять, генерал да килде һәм тантаналы шартларда совет генералларын үзенә күрсәтүләрен таләп итте. Немец генералы үзен Наполеон итеп хис итә һәм «Җиңүченең җиңелүчеләр белән очрашуы» дигән темага спектакль уйнап күрсәтергә ниятли иде булса кирәк.

— Плацка тезелергә! — дип акырыша башлады сакчылар. Озакламый алты меңгә якын кешене тезеп тә куйдылар. Уртага — саф каршына корпус командиры һәм аны озатып йөрүчеләр басты.

Генерал Наумов сафтан чыкты да, хәрбиләрчә чак-чок басып, корпус командиры каршына китте. Без, ирексездән, аның шәп баруына сокланып карап торабыз. Әмма шул вакыт башка да килмәслек бер хәл булды: Наумов немец генералы каршына килеп басты да үзен:

— Элекке патша армиясе фельдфебеле Наумов! — дип тәкъдим итте.

Офицерлар беркавымга шаккатып тынып калдылар. Аннары сафлар буйлап:

— Куркак!

— Сатлык җан!

— Кара ничек ярарга тырыша! — дигән ачулы пышылдаулар ишетелде. Наумов чәйнәп ташлардай булып үзенә текәлгән меңнәрчә нәфрәтле карашлар астында кире урынына юнәлде. Ул килеп баскач, пычрагы ягылудан курыккандай, Пресняков читкәрәк тайпылды... Аннары Наумовның колагына гына нидер әйтте, тегесе башын аска иде.

Менә корпус командиры янына Иван Андреевич атлап китте. Кара, гәүдәсен ничек горур тотып бара безнең кечкенә генерал! Аның бөтен кыяфәте: «Мин әсир, ләкин җиңелмәгән!» — дип әйтеп тора кебек. Корпус командиры каршына җитеп туктагач, ул плацтагыларның бөтенесенә дә ишетелерлек итеп:

— Дивизия командиры, Совет Армиясе генерал-майоры Пресняков! — диде.

Аннан соң Данилов барды һәм, тамагы карлыкканлыктан шактый көчәнеп, ул да үзен Совет Армиясе командирына тиеш булганча тәкъдим итте.

Без берничә көн буена тынычлана алмадык, һаман Наумовның әшәкелеген тикшердек.

— Нинди психологик әзерлеге булгандыр бит инде моның. Үзенә ышанып дивизия тапшырган дәүләтен сатканга кадәр дә барәр кабахәтлек эшләгәндер ул, — диде Николай Иванович Митрофанов, аптырап.

— Әлбәттә, нәрсәдер булгандыр инде, — диде Северюхин, аның сүзен җөпләп. — Югыйсә ничек шушылай кинәт кенә барысын да сызып ташлый алсын?.. Әйтәм аның турында нindiдер ямьсез сүзләр сөйлиләр иде!

Наумовның Ватан сугышында нинди әшәкелекләр эшләгәнлеген һәм ни өчен үзен фельдфебель дип атавын без соңыннан гына белдек.

Әле немец гаскәрләре Украина һәм Белоруссия җиренә керә башлаган чорларда ук, үзенең дивизиясен ташлап калдырып, Наумов җиңел машинага утыра да Минскига, семьясы янына, китә. Ә немецлар Белоруссиянең башкаласын басып алгач, үзенең генерал формасын дворник алъяпкычына, коралын — себеркегә алмаштыра. Ләкин бу маскарад озакка бармый. «Дворник»ны танып алалар да немецларга әйтәләр. Ә немецлар аны лагерьга озаталар.

Димәк, Наумовның генерал дәрәҗәсеннән ваз кичүе — элекке кабахәт эшләренең логик нәтиҗәсе була. Наумовның шуннан соңгы язмышы да нәкъ үзе теләгән юлдан китте: Власов армиясе оештырыла башлау белән ул илен саткан түбән җаннарга хезмәткә күчте.

Могилевта һәм Молодечнода вакытта без фашистларга каршы көрәштә беренче адымнарны ясап, актив кына тупланган булсак, монда, Кальвариядә, ул көрәш планлы, кыю һәм оешкан төстә алып барыла башлады. «Планлы» дигәч тә, боларның нинdiдер язма планнары, исемлекләре булган һәм үткәргән утырышларының беркетмәләрен язып барганнар икән дип уйларга ярамый, әлбәттә. Бик нык яшеренеп эш иткәндә генә нәтиҗәгә ирешеп булачак икәнлеген без барыбыз да бик яхшы аңлыйбыз. Шунлыктан җитәкче үзәктә кемнәр торганын күбебез белми дә. Мин үзем, мәсәлән, нигездә, Пресняков, Самойлов, Чернов, Прудников, Северюхин, Митрофанов һәм Малышевлар белән эш итәм. Активка, ихтимал, башка иптәшләр дә керә торгандыр, әмма мин аларны белмим. Алар антифашистик группа җитәкчеләренә — Иван Андреевич Пресняковка һәм полковник Самойловка гына билгеле.

Бу көрәштә максатыбыз нинди соң безнең? Барыннан да элек, без әсирләрне бергә туплап, аларга һәм мораль, һәм физик ярдәм итү, башбаштаклыкка каршы бердәм протест ясау, Власов армиясенә һәм Германиягә эшкә озатылачак командаларга язылуга каршы көрәшү бурычын алга куйдык. Качарга әзерләнү дә безнең изге бурычларыбызның берсе иде, әлбәттә...

Баланда өләшкәндә Иваненко бүген дә бик әшәкеләнде: баланда суы белән минем кулны пешерә язды һәм бер яшь кенә капитанның авызына аш чүмече белән төртте.

Бу турыда сөйләгәндә Иван Андреевич бик борчылып тыңлап торды. (Генералларның өчесенә дә ашамлыкны китереп бирәләр, шунлыктан ул чиратта нинди хәлләр булуын белми иде.)

— Кичекмәстән лагерь начальнигы исеменә рапорт язарга кирәк, — диде ул аннары. — Хәзер безнең алда торган иң беренче мәсьәлә — монда да, Могилевтагы кебек, лагерь хуҗалары булуга ирешү.

Икенче көнне рапорт әзер иде инде. Анда әсирләр белән каты мөгамәлә иткән кешеләрнең аш өләшү һәм башка шундый җаваплы эшләрдә эшләргә хакы юклыгы, чөнки андыйлар әсирләрнең бары тик ачу-

ларын гына кабарта икәнлеге бик дәлилле итеп аңлатылды. Моның чыннан да шулай булуын немецлар үзләре дә аңлый башлаган иде булса кирәк: рапорт биргәнгә ике-өч көн дә үтмәде, бүлмә, барак, кухня башлыкларын, дежурныйларны һәм дневальныйларны Пресняков биргән исемлек буенча билгеләп куйдылар.

Бу үзгәрешләр безнең өчен никадәр шатлыклы булуын сөйләп торуның хаҗәте юктыр. Ләкин, кызганычка каршы, шеф-повар Иваненко да, полиция начальнигы — элекке Деникин офицеры да урыннарында калды. Аларына безнең көчебез җитмәде...

* * *

Көн ямьсез, күңелсез, бераз яңгыр да төшкәләп тора. Өлешкә алган су да эчелеп, эрзац-икмәк кисәге дә күптән ашалып бетте. Ачлык бер ярты сәгатькә тукталып калгандай булды, эчне ул кадәр үк бормый әле. Бараклардагы дежурныйлар төнлә үлгән кешеләрне арбаларга төйиләр. Төяүчеләре дә бик арык, мәетләрдән тик аякларында басып торулары һәм кыймылдаулары белән генә аерылалар. Әмма җентекләбрәк караган кешегә бүген аларның күзләре ныграк ялтыравы, хәрәкәтләре җитезрәк булуы сизелеп тора. Ләкин җентекләп карар кеше юк. Полицай Павлов, талымсыз хайвандай, мичкә тикле корсагын бәрәңге һәм дуңгыз мае белән дыңгычлап тутырган да кикеренгәләп әсирләрне ашыктыра: «Шнель, шнель!» — ди ул, эсэсчыларга охшатырга тырышып. Иодрыклары дәү тимерче чүкеченнән бары тик сары йонлы булуы белән генә аерыла аның. Андый йодрык белән аягында чак басып торган әсирне генә түгел, үгезне сугып егарга була.

...Арба тирән чокыр янына килеп туктады һәм әсирләр мәетләрне чокырга тутыра башладылар. Бу хәл көн саен шулай кабатланып тора һәм көн саен, шуны күргәч: «Килер бер көн, мене сине дә шундый билгесез чокырга күмеп куярлар, туган-тумачаларың да, якын иптәшләрең дә каберенне таба алмас!» — дигән уй йөрәкне өшетеп җибәрә.

Полицай иренеп кенә күмүчеләрнең эшләвен карап тора. Аннары, күрәсең, бу күренештән туептыр, аларга арты белән борыла да, зажигалкасын учына каплап, сигарет кабыза башлый... һәм, көтмәгәндә баш түбәсенә көрәк белән сугудан өнсезләнеп, авып төшә. Баш өстенә күтәрелгән көрәкләрне абайларга гына өлгереп кала ул... Аннары тагын, тагын сугалар...

Полицайның гәүдәсен әлеге уртак кабергә ыргыталар. Этка — этләрчә үлем! Дүрт офицер ашыга-ашыга чокырны күмәргә керешә. Әнә ул инде җир белән дә тигезләнде, калкып чыга да башлады... Ә хәзер тизрәк алда каралып күренгән урманга качарга кирәк!..

Кичке барлау гадәттәгедән бик күп озакка сузыла. Бер саныйлар, ике саныйлар, санаганны тагын саныйлар... Аннары бүлмәләр, бараклар буйлап тикшереп-эзләп йөриләр.

— Полицай Павлов белән күмү командасының дүрт кешесен таба алмыйлар, — ди Грязнов минем колакка пышылдап. Гестапо капитаны гауптман Кох кычкырудан һәм сүгенүдән карлыгып беткән тавыш белән ашыгып-ашыгып нидер сөйли...

— Кара инде син фашистларның явызлыгын! Нинди эшәкелек уйлап таптылар бит! — ди Митрофанов, башын чайкап.

— Нәрсә ди соң алар, Николай Иванович?

— Заложник итеп биш кешене кулга алмакчылар. Әгәр качканнарны тапмасалар...

— Акрынрак!.. Хәзер фамилияләрен атыйлар.

Тәки без уйлаганча булды: заложник итеп Пресняковны, Наумовны, Самойловны, Даниловны һәм Черновны билгеләделәр. Аннары аларны сафтан чыгардылар да капка янындагы каравыл өенә алып кит-

теләр. Ул өй янында тагын бер кечерәк бина бар. Карцер ул. Качкан кешеләрне тапканчы заложниклар шул карцерда тотылачак.

Ул төнне баракта бик күп кеше йокысыз үткәрде. Нинди коточкыч хәл: әгәр полицайны үтергән (аның гәүдәсен кабердән таптылар инде) дүрт офицерны тотсалар — атачаклар, әгәр алар исән-сау килеш качып котыла алса — безнең иптәшләрне юк итәчәкләр!

Шул ук төнне карцерда менә мондый хәл була: инде әйткәнемчә, бик тәвәккәл һәм булдыклы Чернов, барын да тикшереп-карап чыкканнан соң, лагерьдан качуга караганда, бу карцердан качу ансатрак булачак дигән фикергә килә. Аннары шул уен Самойловка (Пресняков, Наумов һәм Данилов икенче коридорның аргы башындагы бүлмәдә булалар) сөйләп бирә һәм алар икәү качарга әзерләнә башлыйлар. Ә үзләре качканнан соң барактагы бүлмәдәшләрен җәзаламасыннар өчен, Самойлов бер кәгазь кисәгенә менә шушы сүзләрне яза: «Лагерь начальнигына. Без качканнан соң, беркемне дә җәзаламагыз. Ул турыда берәү дә белмәде. Без сезнең начар саклавыгыздан качабыз. Безнең урында булсагыз, ихтимал, сез дә шулай эшлә...» Самойлов җөмләсен тәмамларга өлгерә алмый кала. Карцер ишеге кинәт ачыла да ике сакчы килеп керә. Самойлов язуын тиз генә өстәлдә яткан китап арасына кыстыра. Сакчыларның берсе карцердагы тәртипне тикшереп йөргән арада икенчесе, эче пошудан булса кирәк, әлеге китапны актарырга тотына. Ә Самойлов белән Чернов ут йотып, куркышып торалар. Менә сакчы китапны актаргалап чыга да урынына ташлый. Ләкин... китап өстәлгә барып төшкәч ачылып китеп, теге язу сакчының аягы янына ук очып төшә. Сакчы аны алып укый.

Немецлар Самойловның сакка карата язган «тәнкыйтен» искә алалар: иртәгесен үк карцерны һәм лагерьны ике рәт чәнечкеле тимер чыбык белән уратып чыгалар, моңарчы сакта торган украиннар урынына үз сакчыларын куялар һәм «бер кеше качканга лагерьдагы бөтен әсирләр җавап бирәчәк» дигән боерык язып эләләр.

Әйе, болай булгач, берәмләп качуның мәгънәсе бетте. Шуны искә алып, антифашистик группа күпләп, бөтен лагерь белән качу өчен әзерлек алып барырга кереште.

Кальвариягә килгән көнне станция перронында мине, авыру кеше буларак, атлар килеп җиткәнче әсирләрнең биштәрләрен сакларга (үзләрен җәяү алып киттеләр) калдырганнар иде. Менә шул чакта миңа лагерьның сак ротасы командиры, элекке Совет Армиясе лейтенанты булган кеше (кызганычка каршы, аның фамилиясен оныткранмын) белән танышырга туры килде.

— Күптән әсир булдыгызмы? — диде ул миңа, кызганулы караш белән күз төшереп. Мин җавап биргәч:— Ничек алай килеп чыкты соң?— дип сорады. Фашистлар сагында хезмәт итүче кеше белән сүз озайтып торасым килмичә, мин бер-ике сүз белән генә яралы килеш эләгүемне әйттем. Беркавым икебез дә сүзсез тордык. Атлар һаман килми иде әле. Полицай кояш җылысына чайрап йокымсырый башлаган иде инде.

— Мин Мәскәү кешесе, — диде ул, кинәт уянып китеп. — Радио Мәскәүне бомбага тоталар дип сөйли... Эх!..

Мин сак командирының йөзенә карадым. Провокациягә тартырга маташамы әллә бу? Ә ул миңа фашистларның кабахәтлеге, партизанлыкта гаепләп, бик күп җирле кешеләрне атулары турында сөйләргә керешә. Күзләрендә хәсрәт, тавышында бик нык борчылу сизелә иде. Мин, ирексездән, ул сөйләгәннәргә ышана ук башладым: күңеле чынлап торып газапланмаган кеше болай сөйли алмас!..

Беренче күрүемдә үк Пресняковка әлеге яшь офицер турында әйттем. Генерал үзенә генә хас үткенлек һәм зирәклек белән тегене берничә көн күзәтеп йөрде дә:

— Рота командирына ышанырга була. Хәтта бөтен лагерь белән качу кебек бик җитди һәм бик җаваплы эштә дә ышанырга мөмкин аңа! — дигән нәтиҗәгә килде.

Качарга бик озак һәм бик җентекләп әзерләндек. Әйтергә генә ансат бит: алты меңгә якын кешене лагерьдан алып чыгу гына түгел, аларның алдагы язмышын да ачыкларга кирәк! Беренче өметебез — Кальвария тирәсендәге урманнарда хәрәкәт итүче партизаннар белән очрашу. Алар белән очраша алмасак, үзебез генә сугышачакбыз. Безнең пулемет һәм автоматларыбыз булачак. Хикмәт шунда, качасы төнне рота командиры сакка безнең белән китәргә риза булган кешеләрне куячак һәм алар коралларын да үзләре белән алып качарга тиешләр иде...

* * *

1942 елның июль башы. Качар өчен кулдан килгән барлык нәрсә әзерләнеп бетте шикелле. Компасыбыз да бар, бинт һәм мамык та, азмаз ашамлык та булдырдык. Бүген Федя Харламов зонаның тышкы ягына чыгарга һәм, сак ротасы командиры белән бергәләп, без чыгып шылырга тиешле капкаларның йозагын ачып куярга тиеш.

Безнең командада барысы да әзер, шартлы сигнал гына көтеп торабыз.

Минем дә биштәрем бәйләнеп, котелогым билемә тагып куелган. Шунда кайсыдыр килеп керде дә: «Федя Харламов зонаның тышкы ягында!» — диде. Димәк, озак калмады. Ләкин вакыт чамасыз акрын үтә. Мин хәтта нервланып калтырана ук башладым инде. Соң шулай булмыйча, уен эш түгел бит: я исән-сау качып котыласың, я әләгеп харап буласың!

Тагын бер-ике озын сәгать үтеп китте. Һәм кинәт... Нәрсә бу? Нигә прожекторлар утлы телләре белән лагерьның бөтен почмакларын капшый башлады әле? Әнә, бер көтү гестапочыларны ияртеп, полиция начальнигы Копытов та чабып бара. Коридорда конвойчыларның да дагалы итекләре чакылдый башлады һәм безнең бүлмәнең ишеге каерылып ачылып китте. Сакчылар, барысының да урыннарындамы икәнен белү өчен, нарларны тикшерергә керештеләр. Минем аяклар кинәт камырдай йомшап китте, лып итеп идәнгә утырдым. Куркудан түгел, юк! Качарга өлгерә алмый калуыбызга кайгырудан бу. Нәрсә булды икән соң? Нигә безнең һәр яктан уйлап, җентекләп төзелгән планыбыз, озак вакытлар әзерләнеп йөрүебез бер сәгать эчендә харап булды?

Һәр эш, гадәттә, аерым бер очраклыкка бәйле булып кала.

Бүлмә башлыгы, батальон командиры Богданов — бергәләп качу планы турында белмәүче ышанычсызрак кешеләрнең берсе — кичке барлаудан соң Харламовның каядыр юкка чыгуын сизеп алган да полиция начальнигына хәбәр иткән икән. Полиция начальнигы, үз чиратында, бу хәлне лагерь комендантына җиткергән һәм шуннан соң тревога күтәргәннәр. Бөтен лагерь белән качу мөмкин булмавын аңлап, сак ротасы командиры ике автомат алган да, Федя Харламовны ияртеп, качып киткән...

Аларның язмышын мин күп еллардан соң гына ишетеп белдем: качкыннарны фашистлар шул ук төнне куып җиткәннәр дә ике арада атыш башланган. Әнә шул тигезсез көрәштә рота командиры һәлак булган, ә Федя Харламовны кулга алганнар. Соңыннан аны да атканнар булса кирәк.

...Безнең качарга әзерләнүебез һәм ул эштә Пресняковның башлап йөргәнлеге хакында фашистлар да сизенгән, ахры. Бүген аны лагерь начальнигы янына алып киттеләр. Борчылудан нишләргә дә белмибез: анда тикмә чакыртмыйлар бит инде аны!

— Әнә, ниһаять, Пресняков кайтып та килә. Ирен читләрендә чак кына уйчан елмаю һәм борчылу сизелә. Безнең сорау белән төбәлгән карашларыбызны күреп:

— Тагын кызыклы фашист әкияте, — диде ул. — Мине самолет белән Берлинга озатмакчылар... немецлар үз батырлыкларын гасырларга калдырырга телиләр, имеш... Барлык милләтләрнең хәрби начальниклары, шул исәптән мин дә, Икенче бөтен дөнья сугышы тарихын язачакбыз... Бик әйбәт һәм культуралы эш, шулай бит?!..

Фашистларның бу әкиятенә Пресняков та, без дә ышанмыйбыз.

Иван Андреевич аэродромга илтә торган җинел машинага утырып кузгалып киткәч, барыбызның да йөрәкләре чымырдап, сулышларыбыз кысылып калды...

Сизенүебез дөрес булган икән. Пресняковны бернинди Берлинга да алып китмәгәннәр. Башта аны Һаммельбург лагерена, аннары Флюсенбург лагерена озатканнар һәм анда барып җиткән көнне үк — 1943 елның 5 январенда — башка лагерьга җибәрәбез дигән булып, зонадан читкә алып чыкканнар да танк гаскәрләре генерал-майоры Советлар Союзы Герое Шепетов һәм тагын ун политработник белән бергә аны атып үтергәннәр. Гәүдәләрен крематорийда яндырганнар. Икенче көнне күмү командасы кешеләре Шепетовның орден эзләре беленеп торган гимнастеркасын һәм Иван Андреевичның имән калкан — какшамас ихтыяр символы уелган котелогын алып кайтканнар.

Әйе, кешеләр төрлечә үләләр. Кайберәүләре мораль таркалуга, рух төшенкелегенә бирелеп, үлмәс борын мәеткә әйләнә. Икенче берәүләр, үлемгә һәм аны алып килүчеләргә нәфрәт белән караучылар, фашистлар белән туктаусыз көрәш алып бара, кыюлык һәм батырлык үрнәкләре күрсәтә.

Иван Андреевичның әсирлектә дә үзен куркусыз, горур тотуын, кукрайган немец офицерларының кикрикләрен бер-ике авыз сүз белән шиңдереп җибәргән чакларын әсирләр бик озак вакыт сагынып сөйләделәр. Аеруча менә мондый бер хәл күңелләренә сеңеп калган иде. 1942 елның җәендә Кальвария лагерена вермахт капитаны килеп төште. Аристократик нәзек бармакларына зур алтын йөзек кигән бик купшы шул капитан лагерьдагы безнең бөтен өлкән офицерларны бергә җыйдыртты да, каршыларына дөнья картасын элеп, Германия армиясенең ничек итеп җир шары буйлап җиңеп алга атлавын сөйләргә керешге. Шунда, сүз арасында, армияләре озакламый «тигр» дигән танклар белән коралланкач, фронттагы эшләре тагын да җәйлырак бара башлаячагын да әйтте ул.

— «Тигр»лар тиздән фронтка җибәреләчәк инде. Аларга бернинди көч тә каршы тора алмый һәм сугыш озакламый немецлар файдасына тәмам булачак! — диде капитан.

Шушы сүзләрне әйткәннән соң, оратор әсирләргә бик канәгать кыяфәт белән карап торган чакта, Иван Андреевич урыныннан торды да, гадәтенчә, ашыкмый гына:

— Капитан әфәнде! Мәгълүм булганча, «тигр»лар эссе илләрдә генә яши бит алар, Көнчыгыш фронтта үзләренә йөкләнгән бурычны аклый алмаслар: салкын климат «тигр»лар холкына туры килмәс бит, — диде.

* * *

...Беркөнне лагерь начальнигы Шамала Митрофановны лагерьда тәрҗемәче булырга кыстап карады:

— Ач яшисең киләмени, командир?! — диде ул. — Сиңа «принципиальлегең» өчен беркем дә орден бирмәячәк, ә аякларыңны сузуың бик ихтимал. Шуны аңларга вакыттыр бит инде? Ә тәрҗемәчеләрнең эш җайлы, тамак тук, аң бул аны! — диде.

Николай Иванович тегенең бу сүзләреннән күзгә күренеп эреп киткән сыман булды, әмма ризалык бирмәде.

— Шул хайваннар белән бер табактан ашаганчы, мыскыллы боерыкларын тәрҗемә иткәнче, әсирләрне кыйнауларын карап торганчы — ачтан үлүең мең өлеш артык! — диде ул безгә, «агитатор» киткәннән соң.

Гаҗәеп әйбәт күңелле һәм яхшы ниятле кеше ул безнең Николай Иванович! Һәртөрле көчләүне, вәхшилекне, тамак өчен барысын да сатарга әзер торучыларны җаны-тәне белән сөйми.

— Немец телен өйрәнергә кирәк, — ди ул еш кына Северюхин белән миңа. — Дошманга каршы кулга корал тотып кына түгел, сүз белән дә сугыша белергә кирәк. Игътибар иткәнсездер, немецлар бер боерыкны ике тапкыр кабатларга яратмыйлар. Кабатлау урынына автомат түтәләрен эшкә җигәләр. Димәк, сезнең өчен бер әйткәнне аңлап калу яхшырак.

Һәм ул безгә немец телен өйрәнүдә үзе дә ярдәм итә иде, үзебез дә кулга эләккән иске немец газеталарын тетелеп беткәнче укыйбыз, чөнки алардан, якынча гына булса да, фронт хәлләрен чамаларга була иде... Менә шулай итеп, тора-бара без немецча ярыйсы гына «сукалый» һәм немецларның боерыкларын бер әйтү белән аңлый башладык.

Менә мин озын караңгы коридор буйлап барам. Таш плитә җәелгән идән аяк атлаган саен, шак-шок килеп, яңгырап кала. Коридорның аргы башында — туалет. Бүлмәләрдә һәм коридорларда ут яндырырга рөхсәт итмиләр. Ә монда, туалетта, көне-төне ут яна. Шунлыктан әсирләр кичләрен шушында «ут яктысына» җыелалар. Дөрес, һавасы бик үк шәптән түгел инде түгелен, әмма, аның каравы, монда үзара сөйләшеп алырга, яңалыклар ишетергә һәм рәхәтләнеп тәмәке тартырга мөмкин. Хәер, иң яшерен сүзләр коридорда сөйләнелә, чөнки лагерь начальниклары һәм сакчылар бик йөрмиләр анда...

Әле яңа гына ашаган булсак та, карын ачлыгы аз гына да басылмады. «Менә бит шайтан алгыры! — дим мин үз-үземә сөйләнеп. — Гомерең буе ачыгып яшә инде, ә? Моннан да зур гаделсезлек бармы икән?..»

Кайчакта үз карыным үземә дошман булып күренә башлый. Чөнки ул миңа уйларга, фикер йөртергә комачаулый. Әгәр аның коткысына бирелсәң, «барып чыгасың»ны көт тә тор. «Барып чыккан» дип без ахыр чиккә җитеп бетәшкән әсирләрне атыйбыз. Аларның күзе һәрвакыт акылын җуя башлаган кешеләрнеке кебек төссез, мәгънәсез ялтырый, ә йөзләре кызганыч елмаюга да, сыкрану-газаплануга да тартымрак бер мескен кыяфәткә кергән була. Алар бары тик бер нәрсәне — ничек кенә булса да тамак туйдыруны гына уйлый. «Барып чыккан»нар коридорда да ничектер янтаеп, бөкрәеп, стенага елышып йөриләр. Ачлык аларның кешелек горурлыгын тәмам басып киткән. Сүз уңаеннан әйткәндә, аларның язмышы да бик ямьсез бетә: я алар дистрофиядән үләләр, яки лагерь «тинтәкләре»нә — полицай һәм шымчыларга әвереләләр...

Шул чак Иван Силыч Веретьконың калын тавышына уйларым бүленеп кала. Безнең лагерьга әле күптән түгел генә эшелон белән килгән кеше, элекке дивизия комиссары ул. Аның чын фамилиясе Вдовенько, имеш, диган сүзләр дә йөри.

— Бер генә минутка, иптәш Таҗетдинов! — ди Веретько, иңемә зур, җылы кулын салып.— Мин бу лагерьда айдан артык торам инде, әмма офицерларны эшкә лагерьдан читкә алып чыкканнарын күргәнем юк әле. Әллә гел шулаймы монда?

— Әйе... Начальниклар безгә яраклы эш таба алмыйлар... Дөресен генә әйткәндә, качарлар дип шүрлиләр. Бары тик кухняга поварларга ярдәм итәргә генә җибәрәләр.

— Начар... Бик начар алайса... Әйтегез әле, подполковник, күптәннән әсирлектәме инде сез?

Мин әлек тә Веретькога күз салгалап йөри идем. Сабыр холыклы, бераз сипкелле йөзле, коңгырт-кара күзле, алга чыгыбрак торганиякле бу кеше әлек тә ошый иде миңа. Чөнки аның кыенлыкларга тиз генә бирешми торган көчле ихтыярлы булуы әллә кайдан сизелеп-күренеп тора иде.

Мин комиссарга әсирлеккә ничек эләгүемне, сугышка кадәр кайда хезмәт итүемне сөйләп бирдем. Ләкин, минемчә, ул минем турыда моңарчы да кайбер нәрсәләрне белгән булырга кирәк. Чөнки аның болай бердән ачылып китүен башкача ничек аңлатмак кирәк.

— Яшерен-батырын түгел, иптәш Тажетдинов,— дип башлады ул сүзен. — Мин беләм, Пресняковны моннан җибәреп, лагерь командованиесе каршылык күрсәтүче группаны җитәкчесез калдырган... Дәрәҗәм буенча монда иң өлкәне буларак, аның вазифасын мин үз өстемә алырга тиеш. Хәер, эш минем дәрәҗәмдә генә дә түгел. Хәрәкәтсез яту — җинаять ул, минемчә. Сугыш әсирлектә дә дәвам итә... Шулай бит? — диде.

Сүзсез генә кул кысыштык: әйе, без әле сугышачакбыз! Пресняковның безнең белән бергә булмавы кызганыч, әлбәттә. Ләкин аның эшен дәвам иттерүчеләр, аның кебек үк, дошманны күрә алмаучылар, аның кебек үк, иреккә омтылучылар бар! Шунысы куанычлы!

*(Дәвамы бар.)*

*Шәүкәт Галиев*

Ил өстәле мул булсын дип,
Кырда иген иккән Кеше,
Рәхмәт сиңа!
Җир өстендә нур булсын дип,
Иделләрне җиккән Кеше,
Рәхмәт сиңа!

Данлы җирнең, газиз җирнең
Улы булып туган көнем,
Рәхмәт сиңа!
Җыр булырлык сүзләр биргән
Матур телем, туган телем,
Рәхмәт сиңа!

Минем гомер, нәсел җебе буйлап,
Бик еракка барып тоташа —
Килгән күпме үлемнәрне җиңеп,
Килгән күпме хәвеф, ут аша.

Гасырларны кичеп агып килгән
Миңа бабайларның каннары,
Сеңгән аңа күз яшенең тозы,
Алсулыгы сеңгән таңнарның;

Кубыз, сорнай, гөслә моңнарыннан
Нечкәргәннәр күңел кыллары,
Ә күзләргә рәсем булып төшкән
Болгар сылуының сыннары.

Бөтен тарих үткән йөрәк аша,
Берсеннән дә читтә калмаган —
Гүзәллекләр аны иркәләгән,
Хаксызлыклар аны талаган.

Гомер арты гомер алмашынган,
Офык арты офык ачылган,
Тел очына килгән җырударны
Әйтәлмәүдән бабай ачынган.

Күңелләрдә калган бик күп хисләр
Бөреләнгән икән җыр булып —
Каләм тоткач, гасыр төпләреннән
Басым белән чыга ыргылып.

Алар әйтеп өлгермәгәнне дә
Мин әйтергә бүген тиешле,
Шигырь ритмын бирә буыннардан
Күчеп килгән йөрәк тибеше.

Ничек миңа шуның кайнарлыгын
Һәм исерткеч дәртен тоймаска —
Минем каным мең ел куәт җыйган
Шәрап кебек кайнап кояшта!

## Тормыш сәхнәсендә

Иксез-чиксез зур бер сәхнә тормыш,
Уртасында йөргәч тоймыйбыз —
Гомер буе шунда һәркайсыбыз
Үзебезнең рольне уйныйбыз.

Баш режиссер монда Заман үзе.
Вакыт — гримчы, карап яшенә,
Кемнәрнедер алсу битле итә,
Кемнеңдер чал кертә чәченә.

Өс-баш үзгәрүгә өлгералмый
Костюмчылар тора офтанып.
Сөйләттермәк булып әзер сүзләр
Суфлерлар да йөри буталып...

Көнгә-төнгә карамыйча монда
Караңгылык була, яктылык —
Явызлыклар кайчак өстен чыга,
Соң булса да җиңә яхшылык.

Мохтаҗлык юк һич тә конфликтка,
Һәммәсе дә гаҗәп тормышчан —
Без һәрвакыт аның уртасында,
Үлгәнгәчә, алып тумыштан...

Маскалар бар, киючеләр дә бар,
Яраталар әйбәт битлекне —
Елмаеп теш күрсәтә дә... тешли,
Бик астыртын эшли этлекне.

Бер күрүдә аерылса икән:
Кайсы уңай, кайсы тискәре...
Таный белү өчен кешеләрне,
Карый белү кирәк эчкәре.

...Син дә шушы тормыш сәхнәсендә,
Үз хакында ничек уйлыйсың —
Үзеңә бер читтән кара әле,
Үзең нинди рольне уйныйсың?

## Имгәнгән күңел

Йөрәген ул һаман саен
Тыеп килгән,
«Ярамый!» дип төрле чикләр
Куеп килгән.

Өйрәткән гел: кайберләрен
Эчтән тын, дип,
Сүзең — көмеш, эндәшмәвең —
Чын алтын, дип.

Инде хәзер теләсә дә
Кузгалалмый,
Бүтәннәргә көч бирерлек
Сүз табалмый.

Тынмаган да, ашкынуын
Ул ашкына,
Бик кыюсыз, сабыр гына,
Юаш кына...

...Офыкларны иңләп-буйлап
Очар бөркет
Чыпчык булып чүпли хәзер
Җирдә бөртек...

●

Игенчеләр
Тимер тәрән белән
Җирне ерта —
Ниятләре изге.

Бакчачылар
Үткен пәке белән
Ботак кырка —
Ниятләре изге.

Докторлар да
Скальпельләр белән
Тәнне яра —
Ниятләре изге.

Әдипләр дә
Кайчак каләм белән
Чәнчеп ала —
Ниятләре изге!

●

Ачуланган сүзләреңне
Тыңлап карыйсым килә,
Сагынуларга салып сине
Сынап карыйсым килә.

Ничегрәк булырсың икән,
Ирешсәм зурлыкларга?
Йөз чөермәссенме икән,
Юлыксам хурлыкларга?

Моның һәммәсен белергә
Бер гомер кирәк икән...
Тормыш юлларына чыктык,
Сыната күрмә, иркәм!

●

„Сөймәгәннән хат килсә,
Турап-турап суга ат —
Күңелләре суынсын.

Сөйгәнеңнән хат алсаң,
Дөрләп торган утка як —
Мәңге сүнмәслек булсын!»

...Кемдер әйткән ырым бу —
Ышанмыйм мин юкларга.
Ә шулай да, хатымны
Яктың, ахры, утларга...

●

Каргалар йөз ел кычкыра,
Тамаклары карлыгып,
Сандугачлар сайрап үлә,
Йөрәкләре ярылып...

Мәхәббәтемне җыр белән
Әйтимче туган җиргә,
И, Табигать, кызган мине,
Карга гомере бирмә!..

●

Акыллы киңәш
Бирүе ансат,
Алай, болай бул,
Дию ансат.

Шул киңәшләрне
Тотуы кыен,
Шундый хәлләргә
Үзебез калсак...

●

Үткәннәрне уйлыйм да мин
Үкенерлек хәлләр табам —
Бик кыюсыз булгансың дип,
Үз-үземне тиргәп алам.

Үткән — беткән, бушка сыкрап
Истәлекләр уятма син,
Үкенерсең озакламый
Бүгенеңне уйлап та син...

●

Теңкәбезгә тиеп торалар —
Онытырмый үзен юньсезләр —
Күз алдында синең гел шулар,
Шулар тирәсендә гел сүзләр.

Истән чыга яхшы кешеләр,
Игътибардан алар мәхрүмнәр,
Соңга калган җылы сүзләрне
Ишетәлми китә мәрхүмнәр...

●

Күргәзмәне карап йөри агай:
— Почет икән безнең хезмәткә! —
Исе китеп, әкияттәге сыман
Мәрмәр сарайларны күзәтә.—

Бик зиннәтле итеп, затлы итеп
Алтын-көмешләргә манганнар.
Шәп буласы икән бу акчага
Авылларда клуб салганда...

●

Чәчләре чүмәлә сыман —
Әллә ни кыландырган,
Күлмәкләрен бигрәк инде
Тәненә сыландырган.

Керфек — ялгаулы, күз — кыек,
Мондыйларны санламыйм.
Ә үзем күзне алалмыйм —
Бу ни хәлдер, аңламыйм...

●

Җилбәзәк кыз диләр сине,
Үзем дә күреп торам.
Күреп торам, белеп торам,
Син диеп үлеп торам...

Сизсәм дә гомер буена
Иза чигәчәгемне,
Синсез булмый, син юньсезгә
Бәйлим киләчәгемне!

●

Зәңгәр күзләреңә карыйм —
Зәңгәр боз кисәкләре,
Җылынырга, җылытырга
Һич тә юк исәпләре.

Кызыл иреңеңә карыйм —
Ут шикелле яналар,
Күзләреңнең зәңгәр бозын
Эретер әле алар...

●

Күзләр карарга оялa,
Иреннәр тартыналар —
Сүз әйтергә талпыналар,
Әйтәлмичә тыналар.

Вакыты җиткәч, күзләрең
Йомылып кала икән,
Иреннәр дә сүзсез генә
Аңлаша ала икән...

●

„Ник шулкадәрле
Салкын син?» — дисең,
Яшрен ялкынны,
Димәк, сизмисең.

Сакланам бит мин
Синең ут күздән,
Янгын чыкмасын,
Димен дә түзәм...

●

Бер дә гөнаһсыз булырга
Түгел лә мин фәрештә.
Бозылган шайтан да түгел...
Чама беләм һәр эштә;

Икесеннән дә бераз бар,
Җирдә яшим, кеше бит.
Гаҗәпләнмә, иптәшкәем,
Мин дә синең ише бит!

●

Күрсәгез чибәр хатынын
Култыклап барган ирне,
Кызыгып каласыз инде,
Бәхетле дисез инде.

Күнеккән ул ир күпләрнең
Игътибар иткәненә.
«Эх, ди, мин дә сезнең кебек
Соклансам читтән генә...»

●

Авырткан төштән кул китми, беләм,
Яраткан кешедән күз китми, беләм.
Яраткан кешең — авырткан төшең —
Ул хакта синең сүз бетми, беләм.

Ничә ел инде янымда ярым,
Янымда ярым, бик тыныч җаным.
Авыртмагачтын сизмим икән мин,
Белмим икән мин йөрәгем барын...

●

Шагыйрь сөйли халкы исеменнән,
Халык сүзен итә үз сүзе.
Дан алса ул бирә халкына,
Ә җавапны тота бер үзе.

●

Эчтән еласам да, тыштан көлдем,
Сиздермәдем
Бәгыремне ниләр телгәнне...
Ансы ярый. Тик кичерми халык
Тыштан елап, эчтән көлгәнне.

●

Эшчәннәрнең эше сөйли,
Эшлексезләр үзе сөйли.
Сүзгә карап бәя биргән
Бәндәләрне җенем сөйми!

●

Әллә теңкәгә тигәнгә
Җыелышлар казасы —
Тел бистәләрен тыңлагач,
Килә кыска язасы.

## Имән чикләвеге

Кечкенәсен үзе кечкенә,
Имән ята аның эчендә.
Син дә шулай күпне сыйдыр,
Дүрт юллы шигырь!

●

Еллар үтә, танышларың арта,
Дуслар гына кими баралар;
Югалтулар авыр булгангадыр,
Бик тиз табылмыйлар яңалар...

●

Көз килә, көз килә,
Илләргә туклык килә,
Иңнәргә ныклык килә,
Күзләргә мутлык килә,
Сүзләргә шуклык килә!
Көз килә, көз килә!

●

Караңгылык ничек югалды соң,
Күз аллары кинәт нурланды?
Ап-ак шәмнәр кебек ак каеннар
Якттырталар икән урманны!

●

Кышкы урман нигә тып-тын дисәм,
Шыбырдашмый икән яфраклар.
Күңеленә тынгы тап, дигәндәй,
Сабыр гына ята ап-ак кар.

●

Юлларның кызык узылмаганы,
Китапның кызык укылмаганы,
Язларның тансык күрелмәгәне,
Кызларның тарта үбелмәгәне!..

●

Көлә-көлә чабып үтә кызлар,
Мине генә никтер моң баса,
Мин аларны куып җитәр идем,
Җитәкләгән балам булмаса...

●

Уйнап-көлеп йөргән араларда
Ничәмә ел үтеп киткән бит;
Сенелем диеп кенә йөри идем,
Иркәм дияр чагың җиткән бит!

●

Очрашу бар безгә, кавышу юк,
Күңелләрдә — моңлы җәрәхәт...
Ә шулай да, җирдә син барлыкны
Белеп яшәү үзе бер рәхәт.

●

Уты гына уйный офыкларда,
Күкрәве юк ерак яшеннең;
Өнсез яшен — яшьлек мәхәббәтем,
Яктың гына күреп яшим мин...

# Югалган шагыйрь

«Китапларның да язмышы була».

*Борынгы мәкаль.*

Ерак төбәктә, тын бер авылда
Яшь бер мөгаллим күзләрен йомды —
Кулыннан төште кауры́й каләме,
Яшь бер шагыйрьнең йөрәге тынды.

Юк, ул чак шагыйрь үлмәде әле!
Сөйгән ярында җырлары калды,
Яулыкка төреп сандыкка салды,
Качып укырга кулына алды.

Үтте күп гомер, саргайды кәгазь,
Саргайды кыз да, дөньядан китте,
Көмеш чулпылар, җыр дәфтәрләре
Истәлек булып кызына күчте.

Яшәде кызы баш күтәрмичә,
Мәшәкать, шөгыль азмы тормышта?
Борыннан килгән шәҗәрә белән
Шагыйрь йөрәге ятты тырыста.

Юк, ул чак шагыйрь үлмәде әле!
Ничәмә тапкыр калды янгыннан,
Туып та үсеп һәм дөнья куып
Ничәмә буын үтте яныннан.

Укый белмәгән бер оныкк аны
Әбидән калган дога дип белеп,
Әверналәр һәм каба кырына
Кыстырып куйды чормага менеп.

Юк, ул чак шагыйрь үлмәде әле!
Килер ул телгә, ал гына, укы.
Җырлар күптәнге, әмма бүген дә
Таныш андагы мәхәббәт уты.

Кешегә диган күпме сөенеч
Онытылып ята, ята күмелеп,
Пәрәвезләрдән аны аралап
Аласы гына юкса үрелеп...

...Чынмы, ялганмы — хәбәр таралган,
Әгәр дә өйдән табалар икән
«Комган хәрефле» иске бер китап —
Тотып тормагә ябалар икән!..

Шүрләгән хуҗа, шагыйрьне дә ул
Тиз генә йолкып төшкән чормадан,
Һәм китапларның барысын бергә
Киндерә белән кат-кат чорнаган.

Шагыйрь яраткан якты бер көндә
Айның батканын сагалап торган,
Авыр таш бәйләп чоңгылга аткан,
Җырларны шулай суга батырган.

...Былт-былт куыклар чыккан бик озак,
Әлмәктәй бөҗра уйнаган күлдә.
Ерак төбәктә, өч йөз яшендә,
Ил белми калган зур шагыйрь үлгән...

*Мәхмүт Хөсәен*

## Автобиография

Гаиләдә без өч сабый үстек,
Жиңгинеке өчәү өстәлде.
Әти,
  әни,
    әби,
    жиңги...
Ун жан
Урап утырдык зур өстәлне.
Әбекәем,
    старшина сыман,
Хәстәрләде аш-су якларын.
Ит эләксә,
    бәйрәм булды безгә,
Унга бүлдек шикәр шакмагын.
Әмма ләкин күңел төшермәдем,
Еш тартсам да йөгән юклыкның.
Балачагым күрде Артекларны,
Шунда сиздем көчен дуслыкның.
Эх!
Казаннарны төштә күргән мәлдә
Басып керде Гитлер илемә.
Вузга түгел,
    окопларга киттем,
Брезент билбау буып билемә.
Иркәм белән йолдыз санар чакта
Танк астында яндым-каралдым...
Ак биләүгә гүя биләделәр,
Күзләрсез дә яшәп карадым.
Ниләр генә күрсәтмәде фашист,
Асты өскә жирнең айкалды!..
Мин кайтсам да каты яраланып,
Газиз әткәм калды... кайтмады!..
Әмма ләкин күңел төшермәдем,
Кыю кичтем сугыш газабын.
Мең сөенеп исән калуыма,
Килеп кердем сиңа, Казаным!
Әй син, яшьлек, сынатмыйсың икән,
Иңнәреңә нужа өйсәң дә.
Ямен, яшьлек югалтмыйсың икән,
Кара янып утта көйсәң дә!
Өй суыкмы,
    тамак тукмы-юкмы?..
Уйламый да аны яшьлегең;
Кайнар сөю урый йөрәгеңне,
Акылыңны нурлый яшь белем.
Чаба идем кичен «ччталка»га,
Маңгай бәдрәм жилгә таратып.
Лекцияләр — көндез,
Кичен — кызлар...
Йөрдек укып,
  сөеп,
    яратып!..
Жырлап эшлим хәзер,
    жырлап яшим!
Мәжлесләрдә булам тамада.

Тик алай да
минем яман атны
Сөйләүчеләр очрый арада.
Әмма ләкин исем китми аңа,
Язуымны беләм онтылып.
«Һ. б.» ларда түгел,
күнелләрдә
Шаулый жырым дәртле мон булып.
Оч син жырым алмаз киңлекләргә
Эзләреннән йолдыз-корабның!
Оч син жырым, туган илне зурлап —
Мәңге талмас шул чак канатың.
Оч син, жырым
Космодромың — тормыш кырым.
Оч син, жырым, оч,
Галәмнәрне коч.
Оч син, жырым, оч!
Оч!!
Оч!!!

## Яшәү кызык

Яшәү иркен, яшәү кызык миңа.
Һәрбер кеше туган шикелле,
Ишеген киң ачып: «Әйдүк, Мәхмүт!» —
Дип чакырып торган шикелле.
Ә мин барам.
Керәм.
Кунак булам.
Күңелләрен күрәм.
Көлдерәм.
Эчләр ката минем мәзәкләрдән,
Күзләрдән яшь чыга мөлдерәп...
Уйдагыча иркен кыланам мин,
Иркен тотам һәр мәл үземне;
Үпкәләр дип уйлап-нитеп тормыйм,
Кылт ярам да салам сүземне.
Кешеләр дә мине үз итәләр,
Яраталар шаян холкымны;
Шуңадыр шул алар һич яшерми
Йөрәкләрендәге дулкынны.
Ә ул дулкын аларның уй-хисен
Җырларыма минем күчерә;
Шул дуамал тугызынчы дулкын
Гайрәт бирә миңа көч бирә.
Рәхмәт сезгә мине үз күргәнгә,
Үстергәнгә мине мең рәхмәт!
Әй, кешеләр, сезнең шундыйлыкны
Яза алсам иде мин рәтләп!
Ул чагында миннән бәхетлерәк
Әдип булмас иде дөньяда.
Сизәр идем шул чак
мин үземне
Бөркет итеп шигъри кыяда!

## Ашкыну

*Җыр*

Иделем, гел сиңа ашкынам,
Дулкыннар атылган ярыңа.
Ашкынам, сөенәм...
Ә кайчак көенәм.
Тынгылык табалмыйм җаныма.

Иделем, гел сиңа ашкынам,
Суыңда коенган талларга,
Ашкынам, талпынам...
Ә үзем тартынам
Күзенә тутырып карарга.

Иделем, гел сиңа ашкынам.
Җаныма яз бирә таң ату;
Бер рәхәт бер кыен...
Аңарда бар уем —
Шул микән әллә чын яратү?!

*Булат Сөләйманов*

## Мин сөям

Мин кешене сөям,
Кеше —
Саф күңелле, ачык йөзле булсын.

Мин кояшны сөям,
Кояш —
Һәрвакытта көлеп торсын.

Мин тормышны сөям.
Тормыш —
Гел яз булып чәчәк атсын.

Тынычлыкны сөям.
Йөрәгемне суырып күкрәгемнән
Өскә чәям,
Ак күгәрчен булып күккә ашсын.

●

Син тугансың минем йөрәгемдә,
Мин туганчы газиз анамнан.
Себер, Себер!
Бер син генә җирдә
Минем мәхәббәтем казанган.

Монда минем ата-бабаларым
Яшәгәннәр гомер-гомергә.
Туры килеп
Читтә егылып калсам,
Күңелем кайтыр минем Себергә.

## О Кеше, әйтче, синме бу?!

Ракеталар күкне айкый,
Йолдызларга юл сала.

О Кеше, әйтче, синме бу?!

Атом бомбалары шартлый,
Кайдадыр сугыш — җир яна.

О Кеше, әйтче, синме бу?!

## Син аңларсың минем йөрәгемне

Таң нурлары уйный көнчыгышта,
Урман чумган сихри моңнарга.
Син аңларсың минем йөрәгемне,
Әйдә, иркәм, барыйк тыңларга,
Урман чумган сихри моңнарга.

Таштан ташка сикреп чишмә ага,
Җырлый-җырлый ага кайларга?
Син аңларсың минем йөрәгемне,
Әйдә, иркәм, барыйк тыңларга,
Ага икән чишмә кайларга?

Уйный-уйный яшел куакларда,
Сандугачлар сайрый таңнарда,
Син аңларсың минем йөрәгемне,
Әйдә, иркәм, барыйк тыңларга.
Сандугачлар сайрый талларда.

Әйдә, иркәм, барыйк тыңларга
Чишмә җырын, урман моңнарын.
Син аңларсың минем йөрәгемне,
Чиртеп кара күңелем кылларын,
Син аңларсың сөю моңнарын.

●

Азат бер кошка жим, тозак салып,
Тимер читлеккә куйдылар ябып.

Елады кошчык иреген сагынып,
Очасы килде канат кагынып...

Аны ишетеп күргән кешеләр:
— Аh, нинди матур жырлый ул,— диләр!

## Кеше

Кеше жыр жырлый чишмәгә
Белми —
Күңеле аннан да сафрак.

Кеше жыр жырлый урманга,
Белми —
Хисе аннан да моңлырак.

Кеше жыр жырлый дөньяга,
Белми —
Йөрәге аннан да яктырак.

Кеше жыр жырлый кояшка,
Белми —
Үзе аннан да олырак.

## Бер күрүдә

Ялга тынган диңгез кебек
Тып-тын иде,
Очрадың да
Давыл купты күңелемдә —
Бер күрүдә.

Өстен томан сарган күлдәй
Моңсу иде,
Карашыңнан
Ут кабынды күзләремдә —
Бер күрүдә.

Сабый бала кебек йөрәк
Йоклый иде,
Хәзер инде
Кайнар кояш күкрәгемдә —
Бер күрүдә.

## Бокалдагы язу

Шәрап түгел, салып бирдем мәхәббәтем,
Эч син, иркәм, тамчысын да калдырма,— дип.
Шул мәхәббәт ялкынында син дә исер,
Минем генә йөрәгемне яндырма,— дип.

## Кыр казлары

Минем туган кырларыма
Салкын көз дә килеп житте.

Карап торам: жылы якка
Кыр казлары очып үтте.

Кыр казлары очып үтте
Күк болытлар арасыннан:

Миңа моңсу — яңгыр түгел,
Күз яшьләре ява сыман...

# КОНКУРСКА КИЛГӘН МАТЕРИАЛЛАР

*Н. Гыйльми*

# ИНТЕРМЕДИЯЛӘР

## *Лекция*

Пәрдә ачыла. Сәхнәдә урындыклар, эскәмияләр. Лекция бара. Тыңлаучылар качып беткән диярлек. Бернечә генә кеше калган. Лекция барышында алар да берәм-берәм чыгып шылалар. Бер Сәли генә кала. Чөнки ул гырылдап йоклый. Уянып як-ягына карый да тагын йоклап китә. Бер башта кафедра. Кәли текстка бик нык иелеп, аны тирләп-пешеп уку белән мәшгуль.

**Кәли.** Бу залга авылның күп төрле профессия кешеләре җыелган. Кем генә юк бирелә. Бөтенегез авыл хуҗалыгын химияләштерү һәм интенсивлаштыру юлларын тирәнрәк өйрәнү өчен килгәнсез. Ике сәгатьлек лекция сезгә күп нәрсә биргәндер дип уйлыйм. Шулай, иптәшләр, авыл хуҗалыгын химияләштермичә һәм интенсивлаштырмыйча иген уңышын да, терлекчелекне дә үстереп булмый. Әйдәгез, алдынгы тәҗрибәгә, фән казанышларына үзебезнең колхозда да «яшел урам» бирик! Лекция тәмам, сорауларыгыз булса, рәхим итегез.

Шуннан соң гына ул, тексттан күзләрен алып, «зал»га карый, хәйран булып, күзлеген бер кия, бер сала, ничек караса да, «зал»да бер Сәли генә. Кәли кафедрага йодрыгы белән китереп суга. Сәли сискәнеп уяныл китә.

**Сәли.** Ә?

**Кәли.** Кая халык?

**Сәли.** Нинди халык?

**Кәли.** Лекция тыңлаучылар! Регистрациядә 101 кеше бар иде. Ә хәзер берүзең калгансың, күзле бүкән. Әйт, ник тараттың халыкны?

**Сәли.** Халык таралганда, үзең кайда идең соң?

**Кәли.** Мин лекциям эчендә, фән дөньясында идем. Халыкны карап торырга вакыт бармы минем! Әйт, нигә тыңламадылар лекцияне?

**Сәли.** Журналдан күчереп язган лекциясен тыңлап вакыт әрәм иткәнче, кайтып йоклыйк дигәннәрен ишетеп калдым.

**Кәли.** Үзең дә ияреп китсәң калган!

**Сәли.** Клуб мөдире ич мин. Ишекне кем биклап чыгар?

**Кәли.** Ярар, бетердек. Менә путевка! Имзаңны куй. 101 кеше катнашты, халык лекциядән бик канәгать, диген. Миңа шул җитте!

**Сали.** Хәзер кая юл тотасың?

**Кали.** Сезнең авылда өч көн булам әле. Иртәгә «Хирургиядә операциягә әзерлекнең әһәмияте» дигән лекциямне тыңларсыз.

**Сали.** Сез врачмыни? Менә әйбәт булды. Әнием авырый иде. Зинһар карап кына китегезче!

**Кали.** Каян килеп врач булыйм мин! Әйткәнне тыңла башта. Тагын «Аучылык нигезләре» дигән лекциям бар.

**Сали.** О! Сез аучы! Менә шәп! Мине дә алып барсагыз иде бер!

**Кали.** Фу, сукыр черки икәнсез. Нинди аучы булыйм мин? Лекциямнең темасын әйтәм мин сиңа! «Музыканы ничек аңларга» дигән лекциямне икенче килгәндә укырмын инде. Бу юлы күбрәкнә китәр.

**Сали.** Музыка белгече икәнлегегезне башта ук әйткән булсагыз, бу лекциягездән берәү дә качмый иде. Пианинода бер сыздырып җибәрсәгез, йоклаганнары да уянып китәчәк. Әнә бит, әрәм тора. Уйный белүче юк. Безгә әзрәк өйрәтеп китсәгез иде ичмасам. Хәзер үк бераз сайратып җибәрегез әле. Я инде, абый!

**Кали** (тирләрен сөртә, аңа бик уңайсыз). Мин хәзер үк китәрмен, ахры!

## *Үзгәртеп кору*

**Кали.** Туйдырды. Һаман бер үк әйберне бертөсле кабатлау туйдырды. Сәнгатьтә дә яңа формалар, моңарчы исем кушылмаган нормалар табарга кирәк. Ягъни сәнгатьнең искергән формаларын алып ташларга, анда да тамырдан үзгәртеп корулар башларга вакыт. Бүген ук, хәзер үк, шушы номердан ук! Син ничек карыйсың, Сали?

**Сали.** Мин синең нәрсә уйлаганыңны белмим ич.

**Кали.** Мин артык күпне уйламыйм. Бүгенге концерт алып баруга конструктив үзгәрешләр кертергә генә ният бар.

**Сали.** Үзгәрүләр болай да ходайга шөкер булды инде.

**Кали.** Юк, бу бик кирәкле үзгәртү. Моны эшләсәк, сәнгать ун метрга алга китәчәк, концертыбыз да тизрәк бетәчәк. Ягъни, темп үсә, темп! Минем фикерләр синең аңыңа һаман барып җитә алмый, ахры. Юк, алар барып җитә. Син аларны үзең кертмисең. Бар бит шундый нәчальниклар да. Бүлмәсе янына килеп туктыйсың. Тик эчкә генә үтеп булмый. Ярый, бу башка тема. Менә шулай, Сали малай. Сәхнәдә берьюлы ике номер башкарабыз. Иң беренче үрнәкне үзебез күрсәтик. Беребез баянда, беребез скрипкада берьюлы ике төрле көй сыздыра алабызмы? Алабыз!

**Сали.** Әкият бу. Хәтта әкият тә түгел. Тузга язмаган хәл.

**Кали.** Һәр яңалык шундый каршылыкка очрый инде. Синең бу сүзләреңә консерватизм дип кенә карыйм мин. Эксперимент өчен булса да сынап карарга тәкъдим итәм.

**Сали.** Клоунланып карыйк. Тамашачыны бер көлдереп алу — ярый торган эш.

**Кали.** Баянда — «Кандыр буе». Башкара — мин, Кали абзагыз. Скрипкада — «Юача». Башкара — шушы, ягъни Сали энегез үзе. (Икесе дә уйныйлар.) Күрдең, үзгәртеп кору үзен тулысынча аклады. Ә хәзер инде җырлап карыйбыз. Кали абзагыз — «Өмә җыр»ын, Сали энекәшегез «Көймә кила»не әйттерәчәкләр. (Икесе дә җырлыйлар.)

**Сали.** Үзгәртеп алу шушының белән тәмам. Концертыбыз программа буенча дәвам итә.

## *Вәкил*

**Сали.** Иптәшләр! Концертыбызның чираттагы номеры!..

**Кали.** Чү, чү, чиратламый тор әле. Чираттагы номерга чират җитмәгән. Хәзер вәкил киләчәк.

**Сали.** Кайсы вәкил? Габдуллаҗан Вәкилеме? Гомердә концертка килми ул. Семьясына үзе концерт бирә.

**К ә л и.** Культура хезмәте күрсәтүнең яңа төре бу. Семья концертлары булдыруга мин каршы түгел.

**С ә л и.** Вәкил концертын тыңласаң, акча түләп качарсың. Репертуарын пивнойда төзеп кайта да, өендә хатынына, балаларына — һәрберсенә аерым номерлар багышлый.

**К ә л и.** Җәмәгатьчелек үзенә нәрсә багышларга уйлый икән.

**С ә л и.** Иптәшләр суды бу хезмәтне 30 сум белән билгеләп үткән дигән сүз бар. Ярар, туган, Вәкилне көтмибез, башлыйбыз. Башка бер көнне үзенә бер сатирик куплет белән бүләкләрбез әле.

**К ә л и.** Вәкилне көтмичә булмый.

**С ә л и.** Көтмибез. Габдуллаҗанның исерек Вәкилен көтеп, концертны туктатып торуга кем риза булсын.

**К ә л и.** Берни аңламыйсың син, Габдуллаҗан Вәкиленең миңа нәрсәгә кирәге бар икән, ул вәкил диммени соң мин сиңа?

**С ә л и.** Бездә бүтән Вәкил юк. Башлыйбыз дигәч башлыйбыз. Иптәшләр, концертыбызның чираттагы...

**К ә л и** (йөгереп килеп Сәлинең авызын тота). Вәкил килмичә башламыйбыз, дип әйтеп торам ич мин сиңа!

**С ә л и.** Башлыйбыз. Иптәшләр...

**К ә л и** (Сәлинең авызын тота). Башласаң, вәкил алдында үзең җавап бирерсең. Әһә, әнә үзе дә.

**Х ә л и.** Исәнмесез, кадерле камфирансы иптәшләр!

**С ә л и, К ә л и.** Исәнмесез.

**Х ә л и.** Танышыйк, мин КОПРКАТИ вәкиле булам.

**С ә л и.** Гафу итегез, күпер каты вәкиле дисезме?

**Х ә л и.** КОПРКАТИ вәкиле. Ягъни мәсәлән, концерт программасын карау, тикшерү вәкиле. Кыскартып әйткәндә, КОПРКАТИ була.

**С ә л и.** Шушы вәкилне көттекмени инде без?

**К ә л и.** Габдуллаҗан Вәкилен түгел, билгеле.

**Х ә л и.** Хәзер безнең бурыч бүгенге концертның программасын җентекләп тикшерү икәне аңлашылгандыр.

**С ә л и.** Концертның бер бүлеге бетте ич инде. (Кәли аңа усал итеп карый.)

**Х ә л и.** Бетсә дә тикшерәбез. Китерегез программагызны. Тамашачылар көтә, озакка сузмыйк.

«Яз көннәре бигрәк ямьле». Бармый, егетләр. Концерт түгел бу. Язның һәр көне дә ямьле булмый. Бигрәк тә чәчүгә начар әзерләнсәң. Шуны сәхнәдә җырларбызмы?

**С ә л и.** Җырладык инде без аны. (Кәли аңа тагын да усалрак итеп карый.)

**Х ә л и.** Мин анысын ишетмәдем. Шулай да ризалык бирә алмыйм. Сыздым мин аны! Монысы нәрсә? «Сайра, сандугач!» Шушы булдымы җыр? Сандугачка команда бирә алмыйсың, энекәем. Теләсә сайрый, теләмәсә — юк. Моны да алып аттык. «Каз канаты». Бала-чага булмагыз инде, пожалысты. Шул ерунда турында җырлап яту безгә килешәме соң. Моны да сыздык. «Сарман» дигәнме? Башка районнар әшенә тыгылмагыз, егетләр. Сарман үзе генә җырлый күрсен.

**С ә л и.** Гафу итегез, иптәш күпер каты вәкиле.

**Х ә л и.** КОПРКАТИ вәкиле!

**С ә л и.** Сезгә соравым бар.

**Х ә л и.** Эштән соң бирерсең. «Соравым бар», дип әйтүегез белән дә тамашачыларның алтындай кыйммәтле вакытларының күпмедән булса да бер өлешенең җилгә очуына сәбәпче икәнегезне шаять аңлыйсыздыр дип уйлыйм.

**С ә л и.** Төшендерүегез өчен рәхмәт. Минем соравым бик мөһим. Аны концерттан соңга калдырып булмый.

**Х ә л и.** Ну, әйтегез, әмма бик кыска булсын. Бернички сүз белән генә һәм бик тирән эчтәлекле итеп, шул минутта ук минем аңыма килеп җитәрлек итеп бәян кылыгыз. Ато, беләсез, тамашачыларны ялыктыруыгыз, файдалы хезмәт өчен, дәүләт һәм халык алдындагы бик әһәмиятле бурычларны үтәү өчен кирәкле вакытларының мәгълүм процентын юкка чыгаруыгыз мөмкин.

**Сэли.** Соравым бик кыска, сез кем булып эшлисез?

**Хэли.** Ах, мин сезгэ әйтмәдәммени? Гафу итегез алайса. Район ашханэсенең мөдире булып эшлим мин. КОПРКАТИ комиссиясенэ сайлаганнар да, мена сезгэ вәкил булып бару, сезнең эшләрне тикшереп, менюгызны, гафу итегез, программагызны яхшыртуда ярдәм итү бурычын йөкләделәр.

**Сэли.** Гафу итегез, тагын бер сорау бар. Сез татар җырын, музыкасын кайчан булса да тыңлаганыгыз, җыр текстларын укыганыгыз бармы?

**Хэли.** Син, егет, бер генэ сорау бирэм дидең ич. Алай вәгъдэсез булырга ярамый. Мәсьәлә бик җитди. Менюгыз, әй, программагыз уйлап төзелмәгән. Бүген хәл итәлә торган удар бурычларны чагылдырмый. Кырга тирес чыгару айлыгы бара. Менюгызда, әй, программагызда ул юк. Металл ватыклары җыю уңкөнлеге игълан игэлүен дә газетадан укыгансыздыр. Ул да программадан төшеп калган.

Кыскасы, бу программаны күрше бүлмэгэ чыгып бирэр сәгать бик җентекләп тикшерәсе бар. Әйдәгез, иптәшләр! Тамашачыларның вакытын алмыйк, эшне тиз тотыйк.

**Кэли.** Э син хәзер антракт игълан ит тэ безнең янга йөгер.

Чыгалар.

**Сэли.** Иптәшләр, хәзер бер сәгатькә антракт... дип әйтә бу дип уйламагыз тагын. Кызганычка каршы, мондый хэсрэт вәкилләре дә була шул. Э без берьюлы ике куянны атыйк. Алар программа тикшерсеннәр. Без концертны дәвам итик. Чираттагы номер — күмэк бию.

## *Мәктәп юлы*

**Кэли.** Сэли Сәлиевич, сиңа үтенеч бар.

**Сэли.** Китер.

**Кэли.** Нәрсә китер?

**Сэли.** Гаризаңны, дим!

**Кэли.** Нинди гариза?

**Сэли.** Үтенеч бар дисең ич. Язмача кирәк.

**Кэли.** Мин телдән генэ әйтэм.

**Сэли.** Телеңне «дело»га теркэп булмый.

**Кэли.** Язмача соңыннан булыр. Син миңа берәр сәгатькә югалып торырга рөхсэт ит!

**Сэли.** Магазин тирэсенэ ният бармы? Теге һаман йөз граммлап сатып ята ди анда.

**Кэли.** Юк ла! Җыелышка! Малай укый бит. Хатын ата-аналар җыелышына барырга кушкан иде.

**Сэли.** Малаең кайсы мэктэптэ соң?

**Кэли.** Э? Менэ анысын... анысын... анысын... белмим бит, әй! Кайсында икән соң?

**Сэли.** Директорын да белмисеңме?

**Кэли** (күңелсез). Юк!

**Сэли.** Класс җитэкчесен? Берэр укытучысын?

**Кэли.** Аларын ишеткән дә бар иде. Хәтердә калмаган шул. Бер блокнотка теркэп тә куйган идем, югыйсә. (Актарына, бер блокнот ала, тиз-тиз карый.) Әһә, менә, менә! Шаукатов Гали — директор.

**Сэли.** Соң бит бу промкомбинат директоры.

**Кэли.** Тукта, тукта! Монда фамилияләр күп. Шакиров Нури. Класс җитэкчесе шушы түгел микән?

**Сэли.** Һай, алла колы! Архив мөдире ич ул. Яп әйдә блокнотыңны. Ач концертны! Халык көтэ.

**Кэли.** Тегендә мине дэ көтэлэрдер? Бер генэ җыелышта да булганыбыз юк.

**Сэли.** Мэктэп күләмендәге җыелышмы, класста гынамы?

**Кэли.** Класс җыелышы, ди.

**Сэли.** Малаеңның кайсы класста укуын беләсеңме соң?

Кәли. Бигрәк мыскыл итәсең тагы. Шуны да белмәскә!

Сәли. Я кайсы класста?

Кәли. Бәйләнде бер! Сиңа ник кирәктер ул. Былтыр алтынчыда иде.

Сәли. Күчкәндер бит?

Кәли. Үзем дә шуны уйлап торам. Күчеп бетмәде бугай ла, хәерсез. Күчтеңме дигәч, азрак күчтем, дигәне генә хәтердә.

Сәли. Бар, күчкәнен-күчмәгәнен белеп кайт, тамашачыларга әйтерсең. Концертның икенче өлешен башлыйбыз.

## Тапмаган

Кәли кайтып керә, тиргә баткан, изүләре ачык, көчкә-көчкә өлый.

Сәли. Ни булды? Берәрсе тукмадымы әллә?

Кәли. Нинди берәрсе? Бөтенесе тукмады.

Сәли. Милициягә әйтәсеңме?

Кәли. Начальнигы үзе шунда иде. Авызын ерып утырды.

Сәли. Шаярып кына тукмаганнардыр. Чынлап тукмасалар, начальник хәтле начальник көлеп утырмас иде.

Кәли. Чынлап тукмадылар. Бик чынлап! Сүзебезне тыңламасаң, тагын тукмарбыз, диделәр.

Сәли. Кемнәр икәнен таныдыңмы?

Кәли. Танып нишлисең инде.

Сәли. Прокуратурага барасың.

Кәли. Прокурор үзе шунда иде.

Сәли. Шул яклап калгандыр әле.

Кәли. Калды ди хәзер. Иң элек шул тукмый башлады.

Сәли. Әллә нәрсә бутыйсың син. Караңгы идеме соң анда?

Кәли. Нишләп караңгы булсын ди. Әллә ничә лампочка гөлт итеп тора. Үземнең генә күз алларым караңгыланды.

Сәли. Ә кайда тукмадылар соң сине?

Кәли. Кайда булсын — мәктәптә!

Сәли. Мәктәптә? Таптың алайса?

Кәли. Тапмадым ла!

Сәли. Үзең мәктәптә дисең, үзең тапмадым дисең.

Кәли. Мәктәбен таптым, җыелышта гына яклаучы тапмадым. Бөтенесе мине тукмарга тотынды...

Сәли. Һич төшенмим. Нәрсә белән тукмыйлар?

Кәли. Нәрсә белән булсын, тәнкыйть белән тукмыйлар!

Сәли. Малаең күчкәнме соң?

Кәли. Күчкән. Арттагы партадан алдагы партага күчереп утыртканнар.

Сәли. Алайса без дә алдагы номерга күчәбез.

## Тоз һәм яңгыр

Кәли. Ишек алдына тоз бушаттырдым, күз-колак булыгыз (өстәл янына килә, утыра, күзлеген кия). Минем язма боерыгым булгач, складка урнаштырырсыз.

Сәли. Яхшы, Кәли Кәлиевич. Бер күзем анда, бер күзем монда булыр. Тик миңа шунысы аңлашылмый, тоз белән нишләрбез икән?

Кәли (кәгазьләр актара). Аңлашылмый, имеш! Тозның нәрсәгә икәнен дә белми!

Сәли. Беләм дә бит. Без сәүдә оешмасы да түгел. Тире дә җыймыйбыз, балык та төтмыйбыз. Жалобаларны гына тозлап куймасак шул.

Кәли. А! Менә ничек! Имеш, «Росглавторчермет» вәкиле Кәли Кәлиевич кирәкмәгән товарлар җыя! Имеш, Кәли Кәлиевич жалобаларны черетә. Тәнкыйтегез өчен рәхмәт, Сәли Сәлиев! Юкса, үзем белми идем.

**Сәли.** Тәнкыйтькә колак салу беркем өчен дә хәрам түгел, Кәли Кәлиевич.

**Кәли.** Колак салып йөрергә вакыт кирәк. Аннан соң, дөресен әйткәндә, операциядән соң колак та катыланып китте.

**Сәли.** Жалобаларны да укыштыргаларга ярый.

**Кәли.** Директиваларны укып өлгерсәм дә бик җиткән. Ә жалобаларны пенсиягә чыккач, иркен арада. Я, җитте минем вакытым юк. (Кәгазьләргә күмелә, укый, кәгазь кырыйларына ашыгыч резолюция сала.) Босфор Мидхатовичка! Монысы Кадир Кәбировичка. (Күк күкри.)

**Сәли.** Кәли Кәлиевич. (Кәли дәшми.) Кәли Кәлиевич. (Тагын күк күкри.)

**Кәли.** Мин — занято! (Яңгыр коя башлый.)

**Сәли.** Кәли Кәлиевич, дим. Бер генә минутка!

**Кәли.** Минутым да алтын. Бушагач дәшәрмен.

**Сәли.** Кәли Кәлиевич, дим, яңгыр килде бит. (Күк күкри.)

**Кәли.** Беренче генә килүе түгел, кәтеп торсын!

**Сәли.** Кәтми бит, Кәли Кәлиевич. Ургылыпмы ургыла!

**Кәли** (һаман да башын күтәрми). Бу нинди дисциплинасызлык. Яңгыр Сабировичның шундый әрсезлеге мине күптәннән борчый.

**Сәли.** Сез мине аңламыйсыз. Яңгыр Сабирович димим ич мин.

**Кәли.** Нәрсә бутыйсың соң син! Рәтләп әйт. Кем килгән, өлкәдән берәр кеше юктыр бит?

**Сәли.** Өлкәдән булса кирәк, әнә, тәрәзәдән карагыз!

**Кәли** (ниһаять, башын күтәрә). А, яңгыр, дождь! Ә син нәрсә карап торасың? Тузны әретеп бетердең ич.

**Сәли.** Мин сезнең язма боерыкны көтәм.

## *Өлкән конферансье*

*Кәли белән Сәли икесе ике яктан керәләр. Кәлинең ике кул кесәдә. Ул аны бер тапкыр да алмый.*

**Кәли** (рәсми тонда). Килегез әле, Сәли Сәлиев!

**Сәли.** Киләм ич.

**Кәли.** Күрәм. Я, тукта, шунда синең нокта.

**Сәли.** Тукта, тукта дияргә кем булдың әле син?

**Кәли.** «Син», имеш. Сез дип сөйләшергә вакыт. Я, тыңла: бу минуттан башлап син...

**Сәли.** Нинди «син» ул? Сез дип сөйләшергә вакыт.

**Кәли.** Бүлдермә дилә синә!

**Сәли.** Әйтмәдең ич әле.

**Кәли.** Менә хәзер әйтәм. Бу минуттан башлап син минем ярдәмче. Мин өлкән конферансье итеп тасдыйкландым.

**Сәли.** Синмени?

**Кәли.** Тагын «син». «Сез» дигән сүзне телеңә әнә белән язмыйча булмый инде. Шулай, Сәли Сәлиев, хәзер син минем әмерләремне тыңла: беренчесе, кичәбез тәмам булганчы, ягъни программа үтәлгәнче концертны берүзең алып барасың.

**Сәли.** Ә син нишлисең?

**Кәли.** Фу, белмәсәң белмәссең икән, тагын «син!» Мин нишлим, имеш! Мин җитәкчелек итәм, сиңа күрсәтмәләр бирәм, кимчелекләреңне тәнкыйтьлим, кушканымны үти алмасаң, шелтә бирәм, аннан соң да төзәлмәсәң, эшеңнән бушатам. Аңлашылдымы? Әллә синең белән җитәкчелек итү бик җиңел булыр дип уйлыйсыңмы?

**Сәли.** Җиңел булмас, әлбәттә! Я, икенче, өченче бурычларыңны сайрап күрсәт.

**Кәли.** Нәрсә! Сайрап! Кем белән сөйләшәсең син?

**Сәли.** Кәли беләндер дип уйлыйм.

**Кәли.** Ярый, тыңла, язса язып ал! Хәер, соңыннан үзем машинкада яздырып бирермен. Икенче бурычың шул — эш вакытыңны әрәм үткәрмәскә, халыкка фай-

дәлы хезмәт күрсәтергә. Өченче бурычың — кешегә ягымлы, игътибарлы булу, аның сорауларына колак салу. Хәзергә менә шулар. Ярый, үти башла!

**Сәли.** Нәрсәне үти башлыйм?

**Кәли.** Бирделәр бер аңгыраны. Ничек эшләргә моның белән. (Кычкырып.) Бездельник! Нинди эшкә генә өйрәндең соң син?

**Сәли.** Трактор йөртә беләм, мич чыгарам, идән буйыйм, биим. Ә син нинди эш беләсең?

**Кәли.** Миңа сорау бирергә, мине тикшерергә кем булдың әле син! Аңа бурычларны аңлатасың, ә ул, культурасыз, минем белән, үзенең җитәкчесе белән сатулаша! Бар, эшеңдә бул!

Ашыгып Хәли керә.

**Хәли.** Иптәшләр, гафу итегез. Өлкән конферансье турындагы приказда ялгыш киткән.

**Кәли.** Анда бөтенесе ачык.

**Хәли.** Өлкән конферансье итеп Кәли түгел...

**Кәли.** Кәли түгел? Ничек инде ул Кәли түгел?

**Хәли.** Кәли түгел шул, Сәли билгеләнә.

**Кәли.** Ә? Сәли? Сәли билгеләнә? Ничек инде ул?

**Хәли.** Ничек булсын — шулай. Сәли өлкән конферансье була, Кәли — аның ярдәмчесе. Ярый, дәвам итегез. (Китә.)

**Кәли.** Сез... сез... өлкән конферансье... Котлыйм, Сәли Сәлиевич! (Аның каршына килеп.) Сезнең әмерләрегезне көтәм.

**Сәли.** Әмер шундый. Икәү бергә кулга-кул тотынып, тирләп-пешеп, концертны дәвам итәбез.

## *Миллионерка*

**Кәли.**

Очраттым мин бер чибәрне,
Гашыйк булмый чара юк.
Чибәрлеге бер хәл әле,
Байлыгына чама юк.

**Хәли.** Байлык — бер айлык. Аңа кызыгучының акылы бер айлык та юк.

**Кәли.** Һәй, ул кызның байлыгын күрсәң, син дә, каршына тезләнеп, һуштан язар идең.

**Сәли.** Тезләндем, диген, ә?

**Кәли.** Тезләнсә, ни булган?

**Сәли.** Кыз каршында түгел, байлык каршында тезләнгәнсең син!

**Кәли.** Кыз каршында да, байлыгы каршында да. Беләсеңме, миллионерка бит ул, миллионерка!

**Сәли.** Нинди байлыгы бар соң ул тиклe?

**Кәли.** Һә, һә! Күңелеңә вәсвәсә төшәме?

**Сәли.** Төште, ди! Син мескеннең нинди чүп-чар алдында баш июен генә беләсем килә.

**Кәли.** Я, тыңла, нинди байлыклары барын санап күрсәтим. «Бриллиант». Бер булдымы?

**Сәли.** Хуш, бер булды, ди.

**Кәли.** «Алмаз». Ике булдымы?

**Сәли.** Хуш, ике булсын, ди.

**Кәли.** «Алтын». Өч булдымы?

**Сәли.** Алтыны да бармыни? Каһәр суккан икән. Урлагандыр. Алтыны белән бергә милициягә илтергә кирәк үзен.

Кэли. Минем сеелемне «Алтыны» белэн милициягэ тотып бирергэ кем булдың әле син?

Сэли. Ә нишлэп яшереп ята. Бриллиантларны, алмазларны кайдан алган?

Кэли. Бер дэ яшереп ятмый, белдеңме? «Алтын»ы барын да, «Бриллиант»ы барын да, «Алмазы» барын да һәркем белэ.

Сэли. Ә мин ничек белмим?

Кэли. Фермага барып кара — белерсең.

Сэли. Ферманың ни катнашы булсын монда?

Кэли. Бик бар, нэкъ менэ ферманың катнашы бар. Белмэсэң, бел — «Алтын» да, «Бриллиант» та, «Алмаз» да — сеелемнең көнгэ бер пот сөт бирэ торган сыерларының кушаматлары.

Сэли. Ә?

Кэли. Мэ! Син иң атаклы сыер савучыны милициягэ тотып бирмэкче, аның көнгэ бер пот сөт саудыра торган «Алтын»ын тартып алмакчы буласыңмы?

Сэли. Ә нишлэп байлык туплаган, каян килеп миллионерка булган?

Кэли. Каян килеп миллионерка булмасын! «Елочка» агрегатында сыер саудырамы, саудыра. Миллион литр сөт савып алдымы? Алды! Шулай булгач, миллионерка була түгелме?

## *Төзеп бетердек, дигэч*

Кэли. Мин бүген үземнең шатлыгымны тамашачылар белэн уртаклашырга телим.

Сэли. Иң элек абзыең белэн уртаклашырга иде.

Кэли. Ярар, башта сиңа гына әйтэм. Читенлеклэр күрсэк күрдек, кызыл почмакны төзеп бетердек бит.

Сэли. Беттемени? Котлыйм, котлыйм. Материалга аптырамадыгызмы соң?

Кэли. Аптыраган чаклар күп булды инде.

Сэли. Һэй, хикмэтле төен! Шунда бездэн ярдэм сорарга ярамаган икэн. Безнең төзү оешмасында ни сорасаң, шуны табасың. Берсүзсез җибэрткэн булыр идем.

Кэли. Чынлап әйтэсеңме? Яшэ, Сэли! Кайчаннан бирле кирпеч эзлэп йөрим. Синнэн генэ сорыйсы икэн. Иртэгэ үк машина җибэрэм үзеңэ.

Сэли. Тукта, ашыкма, син бит төзеп бетердек, дидең.

Кэли. Бетте бетүен, морҗа чыкмаган шул. Кирпечтэн эш калды.

Сэли. Бүтэнен сорасаң, бер хэл иде. Кирпеч бетте шул, малай. Кичэ килсэң дэ, ярдэм итэ алыр идем.

Кэли. Хәерле булсын! Бер эрҗэ кадак җибэрсэң дэ ярый.

Сэли. Морҗадан башкасы бар ди үзе. Кадак та бетте шул. Бүген соңгысын кактык. Соңга калгансың.

Кэли. Аз гына коры штукатурка табасың да табасың инде.

Сэли. Аннан да коры калдың инде — бетте. Төзеп бетерү шул буламы? Күз буяучы икэнсең.

Кэли. Буяучы дигэннэн, буяучысын табар идек, аз гына идэн буявы кирэк бит, Сэли.

Сэли. Менэ ышан сиңа! Әле тегесе юк ди, әле монысы!

## ОЧЕРК

*Җәмит Рәхимов*

# КОБЗАРЬ БҮГЕН ТУКАЙ КУНАГЫ

...Тормыш кичердек сайрашып,
Тел, лөгать, гадәт вә әхлак алмашып.

*Г. Тукай.*

## I

Быел Гаяз Гарифуллин үзен картаебрак киткәндәй хис итә башлады. Җәйнең коры һәм җылы килүенә карамастан, авырып җәфаланды. Басулардагы эшләр анардан башка һич бармас кебек, тәүлек буе янып-көеп йөри дә берничә көнгә урынга ята. Идарәдә дә, райкомда да кат-кат әйттеләр, йөрмә, ят, исәнлегеңне сакла, диделәр. Сыкрый-сыкрый булса да постын ташламады. Менә инде көзге кыр эшләренең соңгысы — чөгендер алу бетеп бара. Шулай да отпуск алырга ашыкмый председатель. Ун ел буе колхоз дилбегәсен кулында нык тоткан, елның елында мул уңыш алып, районда гына түгел, өлкәдә дан казанган, СССР халык хуҗалыгы күргәзмәсендә катнашып, дистәләрчә дипломнар, мактау кәгазьләре алган колхоз җитәкчесе быелгы уңышның язмышы хәл ителми торып тынычланамы соң?! Далада адашкан җайдак кебек, бүген дә ат менеп бригададан бригадага, бер басудан икенчесенә йөрде. Чөгендер төяп кайсы кырда, кайсы юлда, яисә авыл уртасында батып яткан автомашиналарны чыгарышты. Җирән кашкасы гына түгел, үзе дә пычракка батып бетте. Ниһаять, өенә кайтып ятты.

Көзге яңгыр тәрәзәне өзлексез кага. Кухня ягында хатыны Рәхимә савыт-сабалар шалтырата. Әнә шуларны тыңлап ята торгач, изрәп киткән. Йомшак кына ишек шакуга сискәнеп куйды, «Керегез» дигәнен сизми дә калды.

— Хәзер генә кайттылар, — дип акланырга тотынды хат ташучы үсмер Мәүлетбай, исәнләшергә дә онытып, — юллардан тәгәрмәчле тракторлар да үтәрлек түгел. — Почтальон, кровать янындагы урындыкка бер кочак газета-журналлар куеп, китәргә ашыкты.

Хат ташучының, иртәне көтмичә, эт чыкмас пычракта газеталар таратып йөрүе тикмәгә түгел инде. Гарифуллин үрелеп кенә ут элдерде һәм газеталарга сузылды. Кабаланмый гына «Правда»га күз йөртеп чыкты. «Сельская жизнь»ны караштырды, ләкин гадәттән тыш хәбәр тапмады. Аннан өлкә газетасына текәлде. Беренче битен күргәч тә, торып утырганын сизми дә калды. Аның күзләре «Тугандаш Украинадан хат» дигән рубрикада иде.

Аягын урындык басмасына куеп, юрганын иңенә бөркәде һәм зур кызыксыну белән укый башлады:

«Украинадагы Щорс исемендәге колхоз һәм Татарстанның Чирмешән районындагы Тукай исемендәге авыл хуҗалыгы артеле хезмәт ияләре ярышының беренче унъеллыгы төгәлләнә.

Үткән ел ахырында тукайлылар делегациясе бездә булды. Ул чагында 1964 елга йомгак ясадык. Быелгы эшкә йомгак Тукай исемендәге колхозда ясалачак. Октябрь башында безнең делегация Татарстанга китәчәк.

Колхозчыларыбыз исеменнән тукайлыларга кайнар сәлам һәм иң яхшы теләкләр җибәрәбез.

Кунакчыл Татарстан җирендә тиздән очрашканга кадәр, кадерле дуслар!

**Ф. ШЕВЧЕНКО,**
*Черкасс өлкәсе, Корсунь-Шевченко районының Щорс исемендәге колхозы председателе.*
**М. БОНДАРЕНКО,**
*колхоз агрономы.»*

Җәйге челләдән соң шинеп калган игеннәргә шифалы яңгыр явып үтте диярсең. Гарифуллинның сырхаулары юкка чыккандай булды, урыныннан торып бүлмәне урап килде. Үзе дә абайламастан кухняга барып керде.

— Рәхимә, кунаклар каршыларга әзерлән.

— Ни бәйрәм, ни якшәмбе — ниткән кунак ул, — диде хатыны, иренең нәрсә турында сөйләгәнен аңламастан.

Икәүләп хатны тагын бер кат укып чыктылар. Ерак Украинадагы танышлары — агроном Бондаренконы, колхозның элеккеге председателе Змунчиловны, савымчы Филоненконы, тракторчы Плащенконы, башкаларны исләренә төшерделәр, алар белән үткән күңелле көннәрне күз алдына китерделәр. Шулай да Рәхимәнең яңа хәбәр беләи дөньясын онытып утырыр вакыты түгел иде, кичке аштан соң мәктәпкә, педсовет утырышына ашыкты.

Украинадан кунаклар киләсе Гарифуллин өчен яңалык түгел иде. Быел көз алар делегациясе киләчәге сөйләшенгән, инде кунаклар каршылау өчен кайбер чаралар да күрелгән иде. Шулай да бүгенге хат дулкынландырды аны. Күршеңне, янсә кияү белән кызыңны чәйгә дәшү генә түгел бит. Бергәләп хуҗалыкны карарлар. Биш авылдан торган колхозда чатаклыклар да юк түгел. Ярышу чын дусларча булса да, кунаклар алдында кызарасы килми бит инде.

Гарифуллин күңеле белән бөтен бригадаларны, фермаларны «әйләнеп чыкты». Машина-трактор паркына «барып кайтты». Кунакларны каршылау, урнаштыру, сыйлау мәсьәләләрен башыннан кичерде. Утыра торгач, уй-исәпләре эчендә тәмам чуалып бетте. Нидер эзләп этажерка янына килде, андагы китап-дәфтәрләрнең астын-өскә китереп, актарына башлады. Ниһаять, каты тышлы бер «Дело» алып, диванга утырды. Онытылмас хатирәләрне кабат исенә төшерү ләззәтле иде аңа.

...Март кояшы биегрәк күтәрелеп, авыл өстендә язгы авазлар шатлыклырак яңгырый башлаган чак иде. Язгы тамчылар белән бергә авылга яңа хәбәр килде. Имеш, бу яздан колхозда чөгендер игелә башлаячак. Хәбәрнең дөресме, түгелме икәнлеге турында бәхәсләр тынып өлгермәде, Яна Кади урамында таныш булмаган кешеләр күренә башлады. «Украинадан килгәннәр икән», диделәр. Чөгендер үстерергә өйрәтмәкчеләр, имеш. Кунакларның икесе авылда озаккарак калгач, хәбәр ныгыды, ышанычлы төс алды. Таза гәүдәле ир-атны агроном диделәр. Ә утыз-утыз биш яшьләр чамасындагы мөлаем хатын чөгендер игүче звено башлыгы икән.

Шундый көннәрнең берсендә Тукай исемендәге колхоз коммунистлары, активистлар, аксакаллар киңәшмәгә җыелдылар. Алар арасында Щорс исемендәге колхоз агрономы Михаил Бондаренко белән атаклы звеновод Ефросинья Майко да бар иде.

Колхоз председателе Гаяз Гарифуллин техник культура — чөгендернең әһәмияте, экономик файдасы турында кыска, ләкин ышандырырлык дәлилләр китерде. Республикада шикәр җитештерү промышленностеның үсеш перспективаларына тукталды.

— Агрономга йөз гектарлап җир табарга туры килер, — дип бетерде ул сүзен.

— Җире булыр, — диде агроном Җәүдәт ага Сәйфиев. — Тик кайсы культураны булса да рәнҗетергә туры киләчәк. Бодайны киметәбезме, борчакнымы?! Аннан килеп, нәрсә артыннан чәчү мәслихәтрәк булыр. Аннан чәчү әйләнеше...

— Ул яктан әнә иптәш Бондаренко ярдәм итәр, — диде партком секретаре Галимҗан Хәмидуллин, — син конкрет әйт: ничә гектар чәчәбез?

Утырыш башланганнан бирле сүзгә кушылмый утырган Гата ага Икътисамов кырау кунган чәчләрен сыйпап алды һәм ашыкмый гына сүзгә кереште.

— Гектары белән ашыкмыйк әле, җәмәгать. Чөгендер бодай түгел, комбайн белән генә җыеп алынмый. Күрдек инде Германда ничек үстергәннәрен. Кәтмән дә кирәк. Утый-утый тырнакларың калмый. Шулай бервакыт фрау Эльза...

— Әкиятеңне калдырып тор әле, Гата абзый. Хәзер бит машина заманасы, — диде яшьләрдән кемдер.

Карт, кинәт кайнап чыккан самовардай, сикереп торды. Аннан китте сөйләп...

Авылның ихтирамлы карты Гата Икътисамов белән дә килешми ярамый иде. Башта ук күп чәчеп хурлыкка калуың бар. Карт нигезсез сөйләми. Үз гомерендә күпне күргән Гата агай авылда «чөгендер профессоры» булып исәпләнә. Бакчасында чөгендер үстерә. Аны үзе ясаган ниндидер станнарда кысып, тәмләткечләр, шәраплар әзерли. Боларның барына да Германиядә өйрәнеп кайткан. Заманында көнбатыш «цивилизациясен» нык татыган. Беренче дөнья сугышы вакытында биш ел әсирлектә булган, немец байларына бил бөккән. Шунда чөгендер үстереп маңгай тирен түккән.

Шулай да Гата аганың моннан ярты гасыр элеккеге тәэсирләренә карап, куркып калмадылар тукайлылар. Быелга аны 60 гектарда чәчәргә булдылар. Яңа культурага иң кулай урын дип авыл кырыендагы «Тукай юлы» буен билгеләделәр.

Михаил Семенович икенче көнне үк инициативаны үз кулына алды. Аның акыллы сүзләре, бетмәс энергиясе күпләрне сокландыра иде. Чөгендер игү буенча штаб сыман нәрсә оештырылды. Унбер звено төзелде. Звеноларга Тәскирә Булатова, Лотфия Салахова, Мөхтәрәмә Мөкътәсимова кебек колхозның иң уңган хатын-кызлары җитәкче итеп билгеләнде. Гата агайның сәләте дә ярап куйды. Шушы яздан башлап «Шикәр чөгендере игү буенча инспектор» дигән зур исем йөртә башлады ул.

Яз коры һәм җилле килде. Шунлыктан борчылып калган Бондаренко агроном Сәй-

фиевне дә, председатель Гарифуллинны да ашыктыра башлады. Ниһаять, агрегатлар басуга чыкты. Ләкин беренче көннәрдән үк күңелсезлекләр башланды. Тукайлылар, гадәтләре буенча, культивация белән чәчү арасындагы аз-маз аермага игътибар итмиләр иде. Ләкин аз-маз дигәне дә көн — көн ярымга җыела иде шул аларның. Бондаренко исә ике арада аз гына аерма булдымы, культивациядәге тракторны туктата һәм баштагы участок чәчелеп беткәнче диярлек көттереп тора. Украина агрономының яхшы теләк — дымны саклау теләге белән эшләгәне һәркемгә мәгълүм иде. Ләкин басу түрендә кызынып утырганга хезмәт хакы түләмиләр лә. Җитмәсә, Кыям Низамовның чәчкечләр таккан иске тракторы ташбакадай акрын кыймылдый. Имеш, рәтләр кыл тарткандай тигез булсын, чәчкеч артына катоклар тагылсын. Рәтләре бормалы бер-ике участокны кабат чәчәргә туры килде.

Җиденче дистәне тутырып килүче Гата аганың тынычлыгы тәмам бетте. Әйтерсең лә, шушы чөгендер генә дөньяда. Таң әтәчләреннән дә иртә тора. Чәчүлек орлыкны, башка кирәк-ягракларны тикшерә, ул арада чөгендер плантациясенә барып чыга. Бондаренко өйрәткәннәрне йөз проценты белән таләп итә. Төшке ашны механизаторлар янында гына капкалый. Карчыгы янына шәфәкъ сүнгәч кенә кайта. Усал телләр «Гата бабай басуда чөгендер капчыгы кочаклап куна икән», дип тә сөйләделәр. Ләкин андыйларга игътибар итмәде инспектор. Карт бик кирәкле эш башкарды.

Әнә шундый мәшәкатьләре белән язгы чәчү үтеп тә китте. Ләкин чөгендер плантациясе үзен онытырмады. Башта «чыкмаганмы» дип көн саен басуга барып тордылар. Аннан беренче яфракларны, мәрҗән күргәндәй, исләре китеп карадылар. Ул арада чәчүлекләрне эшкәртү вакыты килеп җитте.

Агрономнар да, колхоз идарәсе дә чәчүлекләрне машиналар белән эшкәртү ягында. Әмма Гата Икътисамовның аларны ишетәсе дә килми. Көннәр буе алачыкта йөреп үзе генә белгән формада кәтмәннәр ясата, аларга коры талдан саплар әзерли. Эшләгәндә беләк талырлык булмасын!

Еш кына Гата бабай тирәсендә уралучы звено членнары да тракторга аю күргәндәй карый башладылар. Шундый тимер тавын чәчелгән җир өстенә кертергә ярыймы әллә, таптап-изеп бетерер!

Чәчкечен культиваторга алыштырып басуга килгән Кыямны бик ачулы каршылады Гата бабай.

— Чөгендер җиренә бара башласаң, тәгәрмәчең астына ятам, узсаң минем канлы гәүдәм аша узарсың, — дип куркытты ул Кыямны. Ничек итсә итте, тракторчыны кире авылга борды.

Сәгать тә үтмәгәндер, трактор тагын чөгендер басуына килеп туктады. Бу юлы инде Кыям янында комплекслы бригада бригадиры Әхмәдулла Гарифуллин да бар иде.

— Башкалар теләсә нишләрләр, Кыям туган, син минә минем Хәдичә звеносының участогын шәплэп кенә шаровкала әле.

Икътисамов ишетмәмешкә салышып читтә генә басып торды.

Икенче көнне Хәдичәләрнең күпереп, чистарып калган участогы янына барлык чөгендер игүчеләр җыелды.

— Булмаса, безнекен дә эшкәрт инде, Кыям,— диде Тәскирә Булатова.

— Безнекен дә, безнекен дә, — диештеләр кызлар.

— Әйдә, Рөкыя кызым, вакыт үткәрмик, — диде Гата бабай кызына. — Чебешне көз көне санарбыз.

Трактор белән шарофкалаганнан соң, плантация матурланып, үсемлекләр көрәеп китте. Тик Гата бабай кызы Рөкыя Икътисамова апа участогы гына чүп эчендә калды. Моңа эче пошкан Гата бабай берничә кат Кыям янына килде. Ләкин йомышын әйтергә горурлыгы кушмады, бригадирны очратып кына:

— Син, Әхмәдулла, ни... Кыямга әйт инде. Миңа яхшы түгел... Минем кызның да участогын шаровкалап чыксын!..

Җәйге көннәр озын. Җиң сызганып эшләргә дә, күңелле итеп ял итәргә дә вакыт җитәрлек. Чөгендер плантациясен гөл түтәледәй эшкәрттеләр. Алар белән бергә Завадовка чөгендер игүчесе Ефросинья Майко да тир түгеп эшләде. Үзе белгәнне татар кызларына өйрәтте.

Шаулатып, Украина һәм татар җырларын бергә кушып сабан туйларын үткәрделәр. Кунаклар китәргә җыена башлады. Дуслар хөрмәтенә аш-сулардан сыгылып торган өстәлләр әзерләнде, киңәшләр бирелде, теләкләр теләнде. Менә китәр көн дә җитте.

— Әйдә, Тәскирә, ярышыйк икәү,— диде Ефросинья, Булатованың иңеннән алып.— Эш турында хат язышып торырбыз, вагъдәме?!

— Нигә икәү генә, бригада белән диген, — дип сүзгә кушылды бригадир Әхмәдулла.

— Андый дәртегез бар икән, әйдәгез колхоз белән ярышыйк, — дип куйды Гаяз Гарифуллин.

Колхозчылар аның сүзен күтәреп алдылар.

— Ярый, сезнең теләкне якташларга житкерермен, — диде Бондаренко, — һәм хат язармын. Ә чөгендер уңышы турында язгыз, әлбәттә!

Ул елны чөгендер котырып уңды. Тукайлылар һәр гектардан 270 әр центнер татлы тамыр алдылар. Рөкыя Гатина, Гишкурый Гыйльманова, Тәскирә Булатова, Рөкыя Дәүләтшина, Җамал Кәлимуллиналар звеноларында 330 ар центнерга җитте.

Көзен колхоз председателе Г. Гарифуллин, бригадир В. Фәттахов, дуңгызлар ка-

раучы Х. Шәйхиева, колхозчы И. Әхмәдуллиннар составындагы делегация Украинага, башка бүләкләр белән бергә, Тукай исемендәге колхоз басуларында үскән шикәр чөгендере дә алып барды...

## II

Партком секретаре Галимҗан Хәмидуллин бүген кичке ашка кайтмады. Тәмам боламыкка әверелгән урам пычрагын ера-ера колхоз ашханәсенә барып килде дә, парткабинетның иркен бүлмәсенә кереп утырды. Бүгенге газеталарны кулында әйләндергәләде, аннан иртәгә башкарыласы эшләрне башыннан кичерергә тотынды. Бөтен фермаларны, бригадаларны йөреп чыгасы, колхозчылар белән сөйләшәсе булыр. Бер уңайдан күргәзмә агитацияне тәртипкә китерергә кирәк. Агитаторларны, клуб, китапханә мөдирләрен кичен җыярбыз: әнә ашханә, бала тудыру йорты вывескалары уңа башлаган, клубны, китапханәне җыйнаклыйсы бар.

Шуларның барысын да тәртибе белән язып чыкты. Шактый гына уйланып утырды, аннан өстәл тартмасын актарырга тотынды. Күләмле генә дәфтәр тартып чыгарды, аның яртылаш язылган битен ачып куйды. Менә дәфтәрнең зәңгәр титул бите. Моннан ун ел элек, юк вакытларын бар итеп, кәгазьгә төшерелгән хатирәләр шуннан башлана.

Гади дәфтәр битендә һәрберсе үз урынын алган хәрефләр, тамгалар. Никадәр истәлекләр сөйлиләр алар.

Менә болары Украинадан бүләк килгән көннәрне сөйли. Әйе, бик кыен кыш иде ул. Февраль керүгә, терлекләргә фураж калмады. Колхоз җитәкчеләре нишләргә белми аптырап йөргәндә, щорслылардан телеграмма килеп төште. «Кукуруз җибәрдек, кабул итегез». Дуслар бүләге фуражга да, чәчүгә дә җитте. Чын дус егылганда тотып кала шул!

1958 елның ноябрь башы. Әйе, шул елны Щорс исемендәге колхозга беренче мәртәбә барды Хәмидуллин. Дәфтәр битләре аны моннан җиде ел элеккеге сәяхәтенә кайтардылар.

«14 ноябрь 1958 ел. Украинаның изге җирен һәм андагы дусларыбызны күрү шатлыгы, юлга җыену мәшәкатьләре белән октябрь бәйрәме узганны да сизми калдык. һәркем, кулыннан килгәнчә, бүләкләр әзерләде. Гаяз белән мин читекләр тектердек, затлы күлмәклекләр, түбәтәйләр, сәгатьләр алдык. Гата бабай бүләген соңгы көнгә кадәр күрсәтмәде. Кичә идарәгә зур сандык алып килгән. Бизәге күз явын алырлык. Сандыкның ясалуы да, буявы да картның нык тырышканлыгын әйтеп тора. Капкачының эчке ягына «Кадерле иптәш Бондаренкога» дип яздырган. Анысы оныгы эшедер инде. Бу арада күзгә-башка күренмәгән иде, шул сандык белән мәшәкатьләнеп яткан, күрәсең. Башкалар да милли бүләкләр алырга тырышканнар. Колхозчыларның уртак бүләкләрен дә өстәгәч, багажыбыз бер машина булды. Ярый әле станциядә күбесен багаж вагонына урнаштырдык. Үзебез белән күтәреп йөрерлек түгел иде югыйсә.

23 ноябрь 1958 ел. Корсунь-Шевченко безнең Чистай чамасындагы җыйнак кына матур шәһәр икән. Йортлары ике-өч катлылар. Яналар, төзекләр. Шевченко исемендәге үзәк урам, андагы бакча һәм бөек кобзарь Т. Г. Шевченко бюсты, тулы бер кварталны алып, яшеллеккә чумган больница, шәһәр паркы һәм агачлар арасындагы ап-ак бина — Корсунь-Шевченко музее — барысы да онытылмаслык тәэсир калдырдылар. Ләкин озак йөри алмадык, хуҗалар безне Завадовкага ашыктырдылар.

Район үзәгеннән колхозга асфальт юл бара. Аңда да, сулда да алмагачлар. Алар инде яфракларын коярга өлгерсәләр дә, алмагачлар аркылы берни күрерлек түгел. Ихтыярсыз күзләремне йомдым һәм күз алдына майның унбишләрен китердем. Ах, алмагачлар шау чәчәктә чакны шушы юлдан бер генә үтсәң икән!

Алдыбыздагы җанлы стенага җитәрәк, «Победа» тукталып калды. Юлга аркылы тезелгән колхозчылар һәм пионерлар төркеме чәчәк түтәлен хәтерләтә. Ак, кызыл, зәңгәр, сары төстәге күлмәкләр, кофталар, косынкалар, киң балаклы кара чалбарлар, яшь кызларның иңнәренә ленталар салынган. Салават күпере диярсең! Халык төркеме өстендә рус, украин һәм татар телләрендә лозунглар. Машиналардан төштек һәм щорслыларга таба атладык. Салынкы мыегы белән Тарас Бульбаны хәтерләтүче бер колхозчы төркемнән аерылды. Кулында тегермән ташы кадәр бодай ипие, тоз. Гаяз Нургатович ипи белән тозны кабул итте. Исәнләшү, килүебез белән тәбрикләү, алкышлау башланды. Безнең хөрмәткә шигырьләр укылды, җырлар җырланды. Аларның күбесе украинча башкарылса да, дуслык теле аңлашылды безгә.

Идарә янында халык тагын да күбрәк иде. Без сабан туе мәйданындагы кебек югалып калдык. Төрле яктан «Дружба», «Палкий привіт», «Здоровенькі були!» дигән авазлар яңгырый. Безне кемнәрдер кочаклый, үбә. Баскычтан менүебез булды, каршыбызга ак күлмәкле ике егет килеп басты. Берсенең кулында арыш капчыгы. Егет барыбызга да нәрсәдер өләшә башлады. Әлегрәк безнең авылларда мичкә тәгәрәтеп пешерелә торган шешара кебек йомры камыр иде ул.

— Якшәмбе көнне безнең туебыз, — диде егетләрнең икенчесе. — Рәхим итегез!

Соңыннан аңыштык. Колхоз хисапчысы Борис Ильченко чөгендер игү звеносы башлыгы Нинага өйләнә икән. Ә туйга чакырганда, телдән әйтү белән бергә, кунакка «шишки» бирелә. Шишкины кабул иткән кеше туйга килми калмый.

Халык төркеме делегацияне авыл уртасындагы зур бинага алып китте. Җәй башыннан алып күзгә эшләр тәмамланганчы колхозчыларның балалары чыр-чу килә икән биредә. Хәзер ул бушап калган. Безне шунда урнаштырырга булганнар.

Бүлмә уртасындагы өстәлләр аш-судан сыгылып тора. Украина боршыннан чыккан тәмле ис борыннарны кытыклый. Зур-зур савытлардагы тавык, күркә түшкәләре, койка һәм башка нигъмәтләр авыздан су китерә. Өстәл артына ике колхоз вәкилләре кереп утыргач, табын тагын да ямьләнеп, матурланып китте. Беренче тостны халыклар дуслыгы хөрмәтенә тотабыз. Аннан азат Украина, «Кара алтын» иле Татарстан һәм Коммунистлар партиясе хөрмәтенә бокаллар күтәрелә.

Иртәгесен авыллары, колхоз объектлары, щорслыларның тормыш-көнкүрешләре белән танышу башланды. Завадовка — матур авыл. Ул яклар урманга ярлырак булганга, өйләр саманнан салынган. Шулай да күбесе иркен — ике-өчәр бүлмәлеләр, өйләрне һәм каралты-кураларны агач ботаклары каплаган. Җәен алар яшеллеккә чума, йорт-җир күренми дә, диләр. Аз гына буш урынга да алма, груша, слива утыртылган. Хәтта сыер абзарына да тар сукмак кына бара. Шунсы гаҗәп, җиләк-җимеш агачлары рәшәткә белән уратып алынмаган. Шулай да агачларга тиюче, сындыручы юк. Әрсез кәҗәләр дә күренми. Терлекләргә контроль көчле монда. Чәчүлекләрдә мал йөргәнен белмиләр завадовкалылар. Без моны, кем әйтмешли, мыекка чорнап куйдык. Ни әйтсәң дә, терлекләрнең сукбайлыгы көчле әле бездә.

Колхоз басулары тигез һәм чиста итеп туңга сөрелгән. Чи калган урыннар күрмәссең. Салам юл кырыйларына китереп өелгән, байтагы тапап ук куелган. Хуҗалык зур түгел, ләкин техника күп. Машиналар ремонтланган, чын хуҗаларча саклауга куелган. Кырчылык буенча өйрәнер нәрсәләр күп дусларыбызда. Ашлама җитештерү һәм басуларны ашлау системасы аеруча ошады. Ләкин щорслылар терлекчелек тармагында да калышалар икән. Терлек азыгы мул, әмма аны яхшылап эшкәртү, сак тоту җитешми. Терлекчелек продуктлары бездәгедән азрак әзерләнә. Без Щорс исемендәге колхоздагы тәэсирләребезне, хуҗалыктагы күркәм якларны һәм кимчелекләрне идарә утырышында сөйләдек. Үзебезгә кабул иткән яңалыклар өчен рәхмәт әйттек.

Шул ук кичне тугандаш ике халыкның дуслыгына багышланган кичә булды. Хуҗалык елына йомгак ясадык, киләсе елда да ярышу өчен договор төзедек. Алып килгән бүләкләребезне щорслыларга тапшырдык. Алар да җавапсыз калмады, әлбәттә.

Колхоз үзешчәннәре концертын карый-карый, Украина таңын каршыладык. Тарас Шевченко, Павло Тычина, Микола Бажан, Максим Рыльский сүзләре, Майборода, Мейтус, Данькевичларның сихри музыкалары, Украина бандурасының дәртле тавышы, украин халкының ашкынулы җырлары күңелебезгә сеңеп калды.

Якшәмбе көнне дә колхоз объектларына киттек. Товарлыклы-сөтчелек фермасы белән танышып чыгуга, Гаяз Нургатович сәгатенә карап алды.

— Туйга соңармагаек, егетләр!

Нәкъ төш вакытында делегация утырган автомобиль килен өе янына килеп туктады. Без машинадан төшүгә, капкада иптәш кызлары белән Нина күренде. Алар гөл кебек киенгәннәр. Чигелгән ак кофта өстенә дөньядагы барлык төсләрдән торган тасмалар салынган. Нина барыбызны да үбеп, исәнләшеп чыкты, өйгә керүебезне үтенде.

Өйгә кереп өстәл артына утырдык. Нина барыбызны да ашарга, эчәргә кыстый башлады. Шул вакыт ишек алдында тавыш купты.

— Кияү килә, кияү!!

Барыбыз да урамга ташландык. Кузовына кияү егетләре баскан автомашина килен йортына якынлашып килә иде. Егетләр барысы да диярлек чигүле украин күлмәгеннән, шароварларының киң балаклары кап-кара ялтыраткан күн итек балтырларына салынып тора. Шаяралар, көләләр. Борис Ильченко исә бик сабыр. Әйтерсең, бөтен гомере буе әнә шулай җитди, тыйнак булган!

Әмма кияү һәм кияү егетләре капка төбенә килеп җиту бәхетенә ирешә алмадылар. Каяндыр бер өстәл пәйда булды һәм кыз яклылар шуның белән юлга «баррикада» ясап куйдылар. Егетләр, машинадан төшеп, «баррикада»га ташландылар, ләкин атака кире кагылды. Шул чак өстәл өстенә чирекле горелка килеп утырды. «Баррикада»ны ала торган «корал» шушы икән. Инде капка бикле булып чыкты. Кияүгә сакчыларны бик шәплә сыйларга туры килде. Соңгы киртә өй ишеге иде. Ул ачык, ләкин аркылы таяк куелган. Җитмәсә, егетләрдән һәм кызлардан зур сак тора. Борис кесәсеннән конфет, акча алып таратты. Шулай да таяк алынмады. Сәләтен күрсәтсен әле кияү! Ильченко өч метрлар биеклегендәге кыектан сикереп, коры камыш йолкып алды. Ул арада ишектәге таяк та юкка чыкты.

Кияүгә ияреп без дә эчкә уздык. Нина иң түрдә, почмакта утыра иде. Өстәлгә куелган купшы гөл аның йөзен каплый, кичерешләрен яшерә. Сөйгәнен сагынып килгән Бориска кәләше янына тиз генә барып җиту насыйп түгел икән, чыралар белән коралланып алган кайниш — сигез-ун яшьләрдәге малай — җизнәсенә «һөҗүм» башлады. Ләкин бер уч шоколад яшь сакчының гайрәтен тиз кайтарды. Ниһаять, кияү гөл артыннан урын алды.

Нинаның сул ягында кызлар, каршы якта егетләр.

Яшьләр хөрмәтенә беренче рюмкалар күтәрелгәч, уен-җыр башланды. Дәртле, шатлыклы җырлар иде алар. Без аңлаган кадәресе шул: егетләр киленне, кызлар кияүне мактап җырлый.

Мәҗлес кызды. Шул чак житез егетләрнең берсе, өстәл аша кискен генә үрелеп, яшьләр алдындагы гөлне тартып алды. Кияү белән кызның йөзе ачылды. Шунда ук төрле яктан «Әче, әче» дигән авазлар яңгырый башлады.

Дусларыбызның гореф-гадәтләрен белеп бетермәсәк тә, җаен туры китереп, сүз алдык. Яңа тормыш төзүче яшьләрне тәбрикләдек, бүләкләребезне тапшырдык.

Өйдә, коридорда һәм ишек алдында башланган ашкынулы бию, дәртле уен-көлкедән файдаланып, китәргә ашыктык. Мәҗлестәгеләрнең кыстауларын көч-хәл белән җиңеп, идарәгә таба юнәлдек.

Кунакта үткәргән көннәребезнең берсен район үзәге белән танышуга багышладык. Корсунь-Шевченко шикәр заводы, чөгендерне кабул итү һәм аны эшкәртү технологиясе белән таныштык. Аннан станоклар төзү заводына юнәлдек. Без өр-яңа кыру станоклары янында бик озак уралдык.

— Менә кайда икән ул хәзинә! — дип куйды Әсгать Илалиев.

— Кыру станогыгыз юкмы әллә? — дип сорады завод хуҗаларыннан берәү.

Юк иде шул. Дөресен әйтеп бирдек.

— Нигә аны күптән әйтмәдегез,— диделәр алар.— Ярый, җае чыгу белән станок Тукайда булыр!

Төш аугач, шәһәр паркына килдек. Яшеллек арасыннан буяулы гөмбәзләре һәм ап-ак стеналары аз-маз гына күренеп торган бина сине үзенә дәшә. 1944 елда Корсунь-Шевченко шәһәре янында немецларны тар-мар итү операциясенә багышланган музей бу. Пыяла белән тышланган панораманы карауга, тетрәп киттем. Анда чын сугыш кыры иде. Полклар, танклар. Ут, корым, үлем. Украина азатлыгы өчен сугышып йөргән көннәремне уйлый-уйлый, экспонатлар карап йөрдем. Совет солдатының батырлыгына дан җырлыйлар алар.

Менә кунакчыл Украинадан китәр көн дә килеп җитте. Дусларыбыз ничек каршылаган булсалар, шулай озаттылар да. Тагын Киевка ук китереп куйдылар».

Моннан җиде ел элек язылган юллар шунда өзелгән. Әйе, язмаларга озак кына кулы тимәгән Хәмидуллинның. Көндәлек мәшәкатьләргә уралып тәүлекләр узган да узган. Алдагы битләрдәге язмалар инде 1959 елның җәен сөйлиләр.

«1 и ю л ь 1959 е л. Бүген генә Украинадан — Михаил Семенович Бондаренкодан хат килде. Уйлавымча, безнең якларның матурлыгы да, кунакчыллыгыбыз да, милли бәйрәмнәребез, гореф-гадәтләребез дә кунакларга ачыграк күренгәндер. Аларны дулкынландырган, уйландырган минутлар булгандыр. Читтән килүчеләр барын да безгә караганда күбрәк күргән, хәтердә калдырган булса кирәк. Шунлыктан Михаил Семеновичның хатын тулысы белән китерәм.

Дорогi Галимжан Қалимович,

Гаяз Нургатович!

Коллега Жәудәт Рәуфевич!

Тугандаш Татарстан җирендәге туган хисләр дөньясында бик әйбәт кайтып җиттек. Хатыным Елена Николаевнага, кечкенәм Наташага, Киевта укый торган кызым Тоняга, тирә-күршеләргә, бөтен колхозчыларга Сезнең кайнар сәламнәрне тапшырдым. Таңнан кара төнгә кадәр эш белән мавыгулы көннәр башланды. Әле бүген яңа төзелешләр янынннан үттем. Бездә күп алар. Типовой фермалар, башка объектлар төзелә. Кайсы гына төзелеш мәйданына килеп чыкма, сезнең кайгыртучан куллар әзерләп җибәргән сөян, усак такталар ходта. Ике вагон такта гаять зур ярдәм булды безгә. Төзүчеләр, зинһар, рәхмәт әйтеп яза күрегез, дип калдылар. Аларның үтенечләрен канәгатьләндерәм.

Каләм алуымның сере тагын шунда — Иске Кади урамнарында йөргәндә, шаушу, уен-көлке арасында, сездә алган тәэсирләр турында берни сөйләп булмады. Киткәндә дә көры «рәхмәт»тән узмадык. Шул хатамны төзәтергә исәп.

Беләм. «Кади ошадымы!» — дигән сорауга җавап көтәсез. Ялыктырмыйм, бик ошады Тукай колхозы. Сездә электән булсам да, эш белән мавыгып ул якларның гүзәллеген күреп бетермәгәнмен икән. Бу юлы бөтен җирне ләззәтләнеп карап йөрдем. Колхозның кунак йорты да, ашханәсе дә, клуб һәм китапханәсе, фермалары бик пөхтә, җыйнак. Ул ян бакчалы гүрничәләр! Дөрес, өйләр янында яшеллек аз сездә. Әмма бу кеше эшләмәслек нәрсә түгел. Аның каравы алты почмаклы, саламнан арынган тәзек йортлар, кем әйтмешли, чиркәү кебек. Тупас чагыштыру өчен гафу итегез, белгеле. Без гади кешеләрнең теле купшы сүзләргә бай түгел бит.

Авыл өстенә үк авып торган яшел хәзинә — урманны, андагы кошларның гүзәл симфониясен тиз генә онытып буламыни! Сөлчә буеның гөлчәчәкләргә күмелгән тугайлары, чишмә буендагы зирекләр, хәтта авыл башындагы өянкеләргә күмелгән каберлеккә кадәр күңелгә онытылмаслык хатирә булып кереп урнашты.

Шулай да хәтер түрендә — кешеләр, чиксез кунакчыл, ихтирамлы тукайлылар. Аларның дуслык хисләрен тоймасак, урман-кырларның, тугайларның, урам-тыкрыкларның гүзәллеге истә калыр идемени?! Идел кебек киң күңелле дусларыбыз тарта күңелне, алар онытылмый.

Иптәш Хәмидуллин, Сездә, Гаяз Нургатовичта, әлеге тиктормас Гата бабайда, комбайнчы Исмагыйль Әхмәдуллинда һәм башка дистәләрчә колхозчыларда кунакта булуыбызны, ул мәҗлесләрдәге ачык йөз, уен-көлке, сөлге җыеп йөргән егетләрнең

ашкындыргыч җырларын гомерем буе онытмам, ахры. Сөлге җыючы егетләр дигәннән, хәзер безнең Завадовкада олысының да, кечесенең дә телендә «сабантуй». Күбесенең өендә — сабантуй истәлеге — кижеле сөлгеләр. Сезгә барган кызыбыз — дуңгыз караучы Катя Коваль сөлгеләрне хатасының иң түренә элгән. Башкаларга тотындырмый, минем җырларымны, тавышымны ихтирам итеп бирелгән иң зур бүләклр алар, ди. Эштә аз гына буш ара булдымы, егет-җилкенчәк көрәшә — алыша башлый, бер-берсен баш аркылы томырырга чамалый.

Кайтуыбызга атнага якын вакыт үтте. Ләкин урынга ятып, күзләрем йомуга, күз алдыма шул көн, уен-көлке, шатлык балкып торган сабан туе килеп баса.

Чын-чыннан хезмәт, көч, яшьлек бәйрәме икән ул сабантуй. Күр син: ямь-яшь егетләрнең кулларында ике потлы гер уйнап тора. Дөресен әйтим, бәйрәм башланганчы тальян гармонь белән баян гына күргәч, җыр-бию ярлы булыр дип уйлаган идем. Концерт кичкә кадәр сузылгач, исем-акылым китте. Бар икән бетмәгән җыр, бар икән бии-бии аягы талмаган яшьлек. Бер семья членнарыннан торган квинтет чыгыш ясагач, баштагы уемнан оялып куйдым. Безнең иске танышлар — Икътисамовлар семьясы иде бит ул. Менә чын халык талантлары. Рус һәм украин көйләрен дә сыздырып уйнаучыларыгыз бар икән.

Колхоз производствосы турында анда ук сөйләшергә өлгергән идек. Өстәп шуны гына әйтәсе килә. Сезнең фермаларда күргән яңа алымнарны файдалануга керештек. Нәтиҗә әйбәт булырга тиеш. Ә чөгендерне һәм кишерне орлыкка үстерү турындагы планыгыз әйбәт, уңышлар телим.

Хисләр дөньясына батып сезне ялыктырдым бугай. Хушыгыз».

●

Битләр, битләр. Дәфтәрне актарган саен, йөрәк җилкенә, хисләр яңара. Менә болары нибары ике ел элек язылган.

«1 декабрь 1964 ел. Гаяз Гарифуллин, агроном Җәүдәт Сәйфиев, район газетасы редакторы Мәрди Рафиков, тракторчы Исмәгыйль Гыйлаҗев белән Зәки Морадыймов, сыерлар савучы Раушания Шакирова, бригадир Хөснулла Хәмидуллин Казан аэропортында утырабыз. Күз ачкысыз буран, самолетлар очмый. Җитмәсә, Завадовкага телеграмма биргән идек, дусларыбыз борчыла торгандыр.

Кич җитте. Аэропорт гостиницасыннан урын бирделәр. Аптырашып утырганда, Казан радиосы сөйли башлады. Соңгы хәбәрләр. «Бүген Тукай исемендәге колхоз делегациясе, дуслык визиты белән, Татарстаннан Щорс исемендәге колхозга китте...» — диде диктор.

— Китте,— диде Гарифуллин үртәлгән тавыш белән.— Барып җиттеләр инде.— һәм ул юрганын башыннан ук бәркәнде. Барыбыз да аның үрнәгенә иярдек.

...Без Корсунь-Шевченкога килеп төшкәндә, шәһәр өстендә меңләгән лампочкалар яна иде инде. Автовокзал янында аптырашып торабыз. Кинәт яныбызга бер «Волга» килеп туктады.

— Сез Татарстаннан түгелме? — диде шофер һәм, җавап биргәнне дә көтмичә, борылып китеп барды.

Бу хәлне нәрсәгә юрарга да белми аптырап торганда, автомобиль килеп чыкты. Аның артыннан икенчесе килеп туктады. Аннан спай киемле берәү чыгып барыбыз белән дә кул кысып исәнләште.

— «Ленинским шляхом» газетасы редакторы — Федосий Кузьмич Чаленко,— дип таныштырды үзен. Ул арада щорслы дусларыбыз машиналары да килеп җитте.

Туп-туры колхоз идарәсе янына килеп туктадык. Вакытның соң булуына карамастан, колхозчылар күп иде монда. Күрешү, кочаклашулар, шаян сүзләр. Шулай да озак ялыктырмадылар безне, табынга дәштеләр.

4 декабрь 1964 ел. Көн колхоз эшләре белән танышуга багышланды. Завадовкада үзгәрешләр бар. Колхозның элеккеге председателе Валентин Иванович Змунчилов моннан киткән: авыл хуҗалыгы академиясе бетергән белгечне зуррак урынга алганнар. Хәзер колхоз башлыгы (Украинада председательне шулай дип йөртәләр) — Григорий Андреевич Шевченко. Колхозда исә эшләр тагын да яхшырак. Бөртеклеләрнең уңышы һаман күтәрелә, техника арта. Күп кенә яңа объектлар үсеп чыккан.

Кичен клубка ашыктык. Залда алма төшәрлек тә урын юк. Без, көчле алкышлар астында, сәхнәгә узабыз. Григорий Андреевич дуслык кичәсен ачык дип белдерә, Татарстан делегациясен Украинага килү белән котлый, барыбыз белән дә таныштыра. Аннан соң сүзне Гарифуллинга бирә. Гаяз Нургатович, дулкынлануын яшерә алмыйча, трибуна артына баса һәм янәшәдәге бюст өстеннән җәймәне ала. Кинәт зал алкышларга күмелә:

— Тукай килде. Тукай Украинага килде!

Аңардан соң мин торып басам. Сөекле шагыйребез Габдулла Тукайның рус теленә тәрҗемә ителгән әсәрләре, Әхмәт Фәйзинең «Тукай» романы, татар совет язучыларының дисталәгән әсәрләреннән торган китапханәне һәм Казан күренешләре альбомын Щорс исемендәге колхозның партоешма секретаре иптәш Яременкога тапшырам. Алдан әзерләнгән сүзләрем кинәт кенә хәтердән чыга. Залга Габдулла Тукай сүзләре белән эндәшәм:

Рус белән тормыш кичердек сайрашып,
Тел, легать, гадәт вә әхлак алмашып...
Һич бетәрме тарихи бу бергәлек,
Без туган бер җепкә бергә теркәлеп.

Район житәкчеләреннән Анатолий Самойлович Шеленко, дистәләгән колхозчылар кайнар сүзләр сөйләделәр. Соңыннан район культура йорты һәвәскәрләре концерты булды. Ярышны дәвам итү турында договор кабул иттек.

5 декабрь 1964 ел. Иртән, Кремль курантлары сукканчы ук, торып киендек тә үзәк урам буйлап киттек. Юлыбыз 1958 елда ук туйларында булган Ильченколарга иде. Кайдарак яшәүләрен килгәч тә сорашкан идек. Икеләнә-икеләнә шунда таба барышыбыз.

Калай түбәле зур таш өй каршына туктап, керергәме-кермәскәме дип торган арада, капкадан Нина килеп чыкты. Ул безне тәрәзәдән үк танып алган икән.

— Әллә узып китәр идегезме? — диде ул, исәнләшергә дә онытып.— Рәхим итегез, безнең ничек яшәгәнне күреп китегез.

Ишек алдына уздык. Яна сарай, яхшы подвал, зур гына җиләк-җимеш бакчасы. Бөтен җир чиста, пөхтә. Борис үзе терлекчелектә эшли икән хәзер. Төнге сменадан кайтып житмәгән. Хужа булмагач, өйгә кереп тормабызмы әллә дигән идек, кая ул. Нина чын-чынлап үпкәләргә кереште.

Эчкә үттек. Зур гына өч бүлмә, кухнясы аерым. Гардероб та, комод та, радиолагыч та — барысы да зәвык белән куелган. Ләкин аларны нечкәләп карап тормадык, игътибарыбыз идәндә уйнап йөрүче балада иде. Сүз куешкандай, икебез дә кесәләребезгә тыгылдык һәм төрле-төрле уенчыклар чыгардык. Яңа танышыбыз белән уртак тел табарга ярдәм итте алар. Нина аш әзерли, үзе Татарстан турында туктаусыз сораша. Аңа җавап бирергә дә, Ванюша белән уйнарга да вакыт житәрлек.

Борис та кайтып житте. Безне күргәч, бөтен арыганнарын онытып, очынып килеп күреште. Кай арададыр өстәлгә парларын бөркеп торган самовар менеп утырды, тирәягы нигъмәт белән тулды. Ике республика яңалыкларын сөйли-сөйли, тастымалларны сыкканчы чәй эчтек.

Дуслар белән очрашу гаять күнелле булды. Шулай да артыгын утырырга ярамый. Анда инде безне әзлилэр булыр. Ерак юлга дигән автобуслар әзердер.

Шикләнүебез юкка булмаган. Без идарә янына кайтканда, һәр ике колхоз вәкилләре автобусларга төялгән иде инде. Тик берничә кеше генә ду килеп безне эзли. Барысы да җыелып беткәч, Днепр буена — Канев шәһәренә юл алдык...

Ярларына дулкыннарын кага-кага, Украина далаларын иңләп, Днепр ага. Без Тарас тавыннан шул чал елганың шавын тыңлыйбыз, Кобзарь йөргән киң кырларга, далаларга карап сокланабыз. Канев ГЭСы төзелешен күзәтәбез.

Украинаның бөек шагыйре Тарас Григорьевич Шевченко табигатьнең бу матур почмагында 1859 елның җәендә булган. Ун ел сөргендә җәфаланган, жандармнар эзәрлекләвеннән интеккән шагыйрь тормышының соңгы елларын Днепр буенда үткәрергә, бу тауда йорт салырга теләгән. Әмма халык җырчысын, ирек өчен көрәшчене тагын кулга алганнар һәм Украинадан өченче тапкыр сөргәннәр. Шагыйрь туган ягына имин әйләнеп кайта алмаган. Ул Петербургта үлгән һәм шунда күмелгән. Әмма иптәшләре аның:

«Сөекле Украинама
Күмегез үлгәч мине,
Киң даланың уртасында
Казып иң калку җирне.

Киң болыннар, текә ярлар
Шуннан күренеп торсын,
Днепро шаулап акканы
Ишетелерлек булсын!..» —

дигән «Васыять»ен искә алганнар һәм шагыйрьне Каневтан ерак булмаган, ул вакытта Чернечья дип аталган түгәрәк тау өстенә кайтарып күмгәннәр.

Совет власте елларында бу урын «Т. Г. Шевченко музей-заповедниегы» дип игълан ителде. Кабер өстендә 1939 елда бронзадан эшләнгән монумент ачылган, шагыйрьнең уйчан карашы Днепрга, киң далаларга текәлгән. Дәүләт музей-заповедниегының мәйданы 18 гектардан арта. Анда бакча үсә. Дәүләт һәм партия эшлеклеләре, космонавтлар, чит ил делегацияләре членнары күптән түгел кабер тирәсенә яшь имәннәр утырткаңнар. Тау итәгендә туристлар өчен өч катлы гостиница салынган.

Кабер күршесендә — ике катлы музей бинасы. Ул бик бай, анда ике меңгә якын экспонат саклана, зур һәм якты ун залда Т. Г. Шевченконың әдәби-поэтик мирасы, сынлы сәнгать һәм графика әсәрләренең копияләре, революциягә кадәрге һәм совет сәнгате мастерлары, гади халык осталары эшләгән экспонатлар куелган. Күргәзмәләрдә шагыйрьнең төрле телләрдә басылган күп санлы әсәрләре, документлар һәм материаллар экспозицияләре бөек Кобзарьның тормышы, күпкырлы иҗаты турында сөйлиләр. Аерым залларга куелган экспонатлар — Советлар Союзы, тугандаш һәм чит ил хезмәт ияләренең бүләкләре халыкның шагыйрьгә булган мәхәббәтен күрсәтәләр.

Музейны карау безгә зур тәэсир итте. Яңа Украина әдәбиятына нигез салучы, патша самодержавиесенә каршы аяусыз көрәшүче, кимсетелгән халыкларны яклаучы, рус революцион-демократлары шәкерте һәм бөек фикердәше Т. Г. Шевченконың үзе белән очрашкандай булдык. Аның каберенә кат-кат килдек, һәркайсыбызга сабый чактан ук таныш юлларны кара мәрмәрдән кат-кат укыдык:

«И меня в семье великой,
В семье вольной, новой,
Не забудьте, помяните
Добрым, тихим словом.»

Тагын музейга кердек һәм миллионлаган кешеләр кулы куелган журналга «Онытмыйбыз сине, бөек Кобзарь! Ерак Татарстанның бөек шагыйре Габдулла Тукай исемен йөрткән колхоздан килдек сиңа», дип язып калдырдык. Махсус автобусларда безнең делегацияне, авылларыннан 180 километрда булган шушы культура хәзинәсен карарга алып килгән дусларыбыз — щорслыларга рәхмәтебез чиксез иде.

Китәр алдыннан тагын Тарас тавында басып тордык. Әйе, Тарас тавы уйландыра, фикерләр уята. Ә шаулы Днепр дулкыннарын уйнатып ага да ага. Әнә аның өстендә акчарлактай ак теплоход күренде. Ул — «Тарас Шевченко». Теплоход Тарас тавы белән тигезләнгәч, сузып-сузып гудок бирде, бөек Кобзарьны сәламләде.

Ә безнең якларда салкындыр...

9 декабрь 1964 ел. Кунакчыл Украинада тәүлекләр кыска тоелды. Тугандаш республиканың тыныч көннәре гаять күңелле икән.

Староселье авылы Завадовкага терәлеп тора диярлек. «Коминтерн» колхозы — моннан 35 ел элек туган гүзәл хәрәкәтнең бишеге. Шушы авыл кызлары Мария Демченко белән Марина Гнатенконың даны 1935 елда бөтен илебезгә шаулады. Колхоз кызлары алар традициясен дәвам итәләр. Комсомолка Лидия Ильченко звеносы гектардан 600 әр центнер чөгендер уңышы ала. Колхозчы Галина Лысенко житәкчелек итә торган хор бөтен Черкасс өлкәсендә, Киевта, Мәскәүдә чыгышлар ясый.

Без Завадовкада кукуруз игү остасы Татьяна Кузка, чөгендерче Галина Бурлака, авыл Советы депутаты савымчы Лида Кириченко, тракторчы Виктор Плащенко һәм башка дистәләрчә колхозчылар белән таныштык, аларның эш тәҗрибәләрен өйрәндек.

Инде китәбез. Сау бул, Украина. Хушыгыз, дуслар. Татарстан жирендә янадан күрешкәнгә кадәр...»

Авыл өстен тутырып әтәчләр кычкыруы Хәмидуллинны дәфтәреннән аерылырга мәҗбүр итте. Партком секретаре, гадәтенчә, дәфтәрен саклык белән генә япты һәм өстәл тартмасына яшерде...

●

Биткә бәреп тәүге йомшак кар ява. Кечкенә ак күбәләкләрне хәтерләтүче кар бөртекләре җил ирегенә буйсынып йөриләр дә очып килеп борынга, пальто якаларына куналар. Быелгы кышның беренче карлыгачлары алар. Шуңадырмы, бу җылы буран тансык, шатлыклы. Ләкин тимер юл станциясендәгеләрнең игътибары анда түгел. Райком секретаре Сәмигулла Исхаков та, Гарифуллин белән Хәмидуллин да, Тукай исемендәге колхозның кунаклар каршыларга килгән башка вәкилләре дә — буран эченә кереп югалган тимер юлда. Әйтерсең, Мәскәү — Уфа поезды расписаниедә күрсәтелгән сәгатьтән элгәрәк килеп җитә.

Кинәт якында гына тепловоз кычкырган тавыш ишетелде, ул арада үзе дә күренде. Менә яннан гына багаж вагоны үтте, беренчесе, икенчесе күренде. Шул чак Гаяз Нургатовичның шатлыклы тавышы яңгырады.

— Михаил Семенович!

Икенче вагонның тамбурында калын гына гәүдәле бер ир басып тора иде. Барысы да шунда ташланды. Бондаренко, поезд туктамас борын ук, Гарифуллин белән Хәмидуллинның кочагына сикерде.

— Здоровенькі були!

Станциядән Чирмешәнгә кадәр байтак ара. Бу юлда шоферлар сәгатьтән артык вакытларын югалталар. Ләкин тукайлылар да, щорслылар да, колхоз хәлләре турында сөйләшә торгач, Чирмешән елгасына җиткәннәрен тоймадылар да. Кызыл комач эленгән зур күперне чыгасы да — район үзәге. Комач исә «Рәхим итегез кунакчыл Татарстан җиренә» дип чакырып тора.

Чирмешән урамы колхозчылар, пионерлар, партия-совет оешмаларында эшләүчеләр белән тулы. Машиналарга райком бинасыннан шактый еракта тукталырга туры килде.

Җыелган халыкны сәламли-сәламли кунаклар һәм хуҗалар КПСС райкомы бинасына үттеләр. Райкомның беренче секретаре Заһит Фәйрушин кунакларга Чирмешән районының хәзерге хәле, перспективалары турында сөйләде.

Татарча пешерелгән бөртек чәй эчкәч, кунаклар тагын автомобильләргә утырдылар. Алда утыз километрлы юл. Сәяхәтнең соңы — Иске Кади.

Фаралары белән төн караңгылыгын сөнгеләп барган автомашиналар авыл башына җиткәч тукталып калдылар. Юлда тукайлылар төркеме иде. Тагын күрешүләр, уенкөлке, җыр, шатлыклы авазлар. Шактый талчыккан щорслылар гостиницага кайтып ятканда шактый соң иде инде.

Щорслылар икенче иртәне дә сәяхәт белән башлап җибәрделәр. Тик бу юлы аларның юлы биш километрдагы Яңа Кади авылына гына иде.

Украина делегациясе иң элек мәктәпкә юл тотты. Завадовка пионерларының ялкынлы сәламен түкми-чәчми тапшырырга кирәк иде бит.

Яна Кади — Тукай исемендәге колхозның өчтән бере генә. Шулай да биредәге объектларны карап йөрү кара төнгә кадәр сузылды. Шулай булмый ни! Һәркайда танышлар, эштә яңалыклар. Сөйләшергә, өйрәнергә кирәк. Товарлыклы-сөтчелек фермасында бер төркем кызлар савымчы Любовь Шкляренко белән Валентина Мельникны урап алганнар. Тукайлы Раушания Шакирова да чолганышта калган. Былтыр гына Украина җирендә очрашкан кызлар гомер күрешмәгәндәй сөйләшәләр.

Трактор бригадасы бригадиры Иван Кузьменко, тракторчы Алексей Мельник, узган ел Щорс исемендәге колхозда кунак булып кайткан тракторчы Зәки Морадыймов, механизаторлар бригадиры Габделхак Гыйлаҗевлар машина-трактор паркына китеп баралар. Ике агроном — Бондаренко белән Сәйфиев борчак калибрлаучы колхозчылар янында. Төзүче-инженер Григорий Баглай исә яна каралтылар арасында йөри, нидер үлчи, нидер яза. Щорс исемендәге колхоз председателе Григорий Шевченко белән бригадир Григорий Шкляренконы барысы да кызыксындыра. Әле дуңгызчылык фермасына, әле кошчылык фермасына барып керәләр, аннан башка участокка ашыгалар. Хәтта тукайлылар пешергән бәлеш-бавырсакларны да ашык-пошык кына ашарга туры килде бу көнне.

Инде кайтырга дигәндә генә, тагын туарылырга туры килде. Авыл клубы бригада членнары белән тулган иде. Ике халыкның дуслык хисләре, уй-теләкләре, омтылышлары ташып, рус, украин, татар моңнары яңгырап торган кичә төн уртасына кадәр дәвам итте.

Иске Кади, Якты тау, Кызыл чишмә, Тукай поселогы. Алда әнә шул пунктлар. Аларның һәрберсендә — колхозның байлыгы, эшчән кешеләре. Икенче көнне дә әнә шуларны карап, танышып йөрделәр. Идарә янына кайтып төшүгә, кунакларны колхоз комсомол оешмасы секретаре Марс Камалов каршылады.

— Бүген клубта комсомол туе. Килми калсагыз, яшьләребез үпкәләр.

...Аксыл нурга чумган сәхнәдә Сәмигулла Әһлиуллин белән Әлфия Кәлимуллина утыралар. Залда аларның туганнары, колхоздашлары, кунаклар. Егет белән кыз тартыналар, уңайсызланлар. Әмма мондый хәл озакка бармый, партком секретаре Хәмидуллин залдагыларның игътибарын үзенә җәлеп итә.

— Колхоздашлар,— ди ул, дулкынланып,— без бүген ике яшьнең яңа тормыш башлаулары тантанасына җыелдык. Сәмигулланы беләсез. Өченче ел гына авыл хуҗалыгын механикалаштыру училищесын тәмамлап кайтты. Алдынгы тракторчыбыз. Килен дә пар килгән. Мәктәпне тәмамлаганнан бирле колхозда эшли. Биргә зур — меңгә якын хезмәт көне.

Колхозчылар гөр итеп кул чаба. Котлаулар, бүләкләр тапшыру башлана. Сәхнәгә бер-бер артлы кызлар, егетләр күтәрелә. Иң изге, иң садә теләкләр. Кияү белән кыз бүләкләргә күмелеп калалар. Менә алар янына Михаил Семенович килеп баса. Ин әлек егетнең дә, кызның да беләкләренә күз явын алырлык рушниклар бәйли. Яшьләрне Щорс исемендәге колхоз членнары исеменнән котлый һәм аларга украин күлмәкләре бүләк итә.

Туйның дәвамы колхоз ашханәсенә күчә. Яшьләр хөрмәтенә, украин һәм татар халкының дуслыгы хөрмәтенә бокаллар күтәрелә. Татарча җыр тынуга, украинча яисә русчасы башлана. Ул да булмый, өстәлләр бер читкә елыша, урталыкта Кади кызларының ашкынулы биюләре хакимлек итә башлый. Алар каршына Григорий Баглай сикереп чыга, аңа Люба белән Валентина, Алексей иярә. Яшьлек, уен-көлке, шатлык һәм бәхет тантана иткән төннең үткәне сизелми дә кала.

Соңгы кичне һәр ике колхоз вәкилләре традицион дуслык кичәсенә җыелдылар. Беренче оратор сүз алырга өлгерми, районнан да кунаклар килеп төшә. Щорс исемендәге колхоз вәкилләре — үзләренең уңышлары, Тукай исемендәге колхозда алган тәэсирләре турында сөйлиләр. Тукайлылар да җавапсыз калмый. Үзара ярышны киләчәктә дә дәвам итү, дуслык турында ялкынлы сүзләр яңгырый. Шуны раслап договор төзелә һәм анда ике колхоз вәкилләренең имзалары куела.

Колхоз председателе Шевченко тагын сүз ала.

— Щорс исемендәге колхоз членнары,— ди ул,— шушы бүләкләрне сезнең хезмәт алдынгыларына тапшырырга куштылар.

Сәхнәгә берсеннән-берсе зур төенчекләр, ящиклар алып керәләр. Шевченко тукайлыларны үз янына чакыра башлый. Тракторчы Зәки Шәмсетдинов, звено башлыгы Мөхтәрәмә Әһлиуллина, колхозчы Сания Сөләйманова, төзүче Кәшиф Яруллин, савымчы Флера Мотаһирова, дуңгызлар симертүче Фидания Курамшина... Исемлекнең ахыры юк диярлек. Зур хөрмәттән каушап калган колхозчылар бер-бер артлы сәхнәгә күтәреләләр.

Һәм кайсы күлмәклек, кайсы фасонлы эшләпә, шәлъяулык, туфли, сәгать, свитер, тагын әллә нәрсәләр алып урыннарына кайталар.

Колхоз председателен Михаил Бондаренко алыштыра. Ләкин ул ике-өч сүз әйтергә дә өлгерми, залдагылар гөр килеп кул чаба, нидер кычкыра башлый. Бер кулына бөек Кобзарьның ак мәрмәр бюстын, икенче кулына шагыйрьнең портретын тоткан Бондаренко нидер сөйли, ләкин аның тавышы алкышлар арасында югалып кала. Менә зал тынып кала һәм Украина вәкиленең сүзләре аермачык яңгырый.

— Кобзарь кунак бүген Тукайда!

Зал тагын алкышларга күмелә. Клубны ишәрдәй булып яңгыраган алкышлар озак дәвам итә.

# ТӨНЬЯК КҮРШЕЛӘРГӘ СӘЯХӘТ

Күптән түгел Татарстаннан бер төркем туристлар — врачлар, инженерлар, фән эшлеклеләре, укытучылар Финляндиядә булып кайттылар. Безнең Суоми иленә килүебез СССР Министрлар Советы председателе Алексей Николаевич Косыгинның визиты тәмамлану вакытына туры килде. Финляндия кешеләре хөрмәтле кунакны бик җылы һәм зур тантана белән каршыладылар. Чөнки алар Совет — Финляндия мөнәсәбәтләренең элекке кебек үк ныгый барачагына нык ышаналар. Финляндия һәм аның халкы белән очрашу дуслык рухы белән сугарылган иде.

Төньяк күршебезнең искиткеч матур шәһәрләре белән, аның гүзәл табигате белән танышуыбыз аяз, җылы көннәргә туры килде. Төннәрнең дә көн кебек якты булуы гаҗәеп матур тәэсирләр калдырды. Кешеләр белән очрашулар, сөйләшүләр исә аеруча җылы хисләр тудырды.

Башта без Хельсинки шәһәре белән таныштык. 350 яшьлек бу зур шәһәр диңгез буенда урнашкан. Анда ярты миллион чамасы кеше яши. Шәһәр эчендә бик күп урыннарда күлләр һәм диңгез култыклары ялтырап ята. Су күп булганга, биредә климат та йомшак. Шәһәрдә һәйкәлләр, төрле статуялар һәм фонтаннар күп. Тагын бер үзенчәлек — монда яр буйлары, су өсте катер һәм көймәләр белән чуарланган. Хельсинкида шулай ук бик әйбәт пляжлар да еш очрый. Шәһәр яшеллеккә күмелеп утыра. Анда 420 парк һәм ботаника бакчалары бар, урамнарның барысына да диярлек агачлар утыртылган, газоннар ясалган.

Шәһәрдә театрларның күп булуы күзгә ташлана, симфоник оркестрлар тавышы еш ишетелә.

Без олимпия стадионында да булдык һәм аның 72 метр биеклектәге башнясыннан шәһәрне күзәтеп тордык. 1934 елда төзелгән бу стадион хәзер 70 мең тамашачыны сыйдыра ала. Анда атаклы фин чабышчысы Паво Нурмигә һәйкәл куелган.

Финляндия башкаласының үзәге — Сенат мәйданы игътибарга лаеклы. Сенат бинасын ампир стилендә салынган башка җәмәгать учреждениеләре бинадары әйләндереп алган. Кауппаторий базары бик чуар. Шәһәргә диңгез ягыннан керсәң, ул бигрәк тә ачык күренә.

Суоменлинна (Свеаборг) крепосте XVIII гасырда ук төзелгән. Аның мәһабәт бастионнары сәяхәтчеләргә үткән заманнардагы зур вакыйгалар турында сөйлиләр.

Татарстаннан килгән туристлар Финляндия парламенты бинасында да булдылар. Бина алдында дәүләтнең беренче өч президентына куелган һәйкәлләр басып тора. Утырышлар залында 5 скульптура урнаштырылган. Аларда илнең килачәге, пионерлар тормышы тасвирлана, ышаныч һәм мәхәббәт сюжетлары сурәтләнә, хезмәт, аерым алганда иген уңышы җыю гәүдәләнә. Бинаның фойесында ил промышленностеның барлык тармаклары күрсәтелгән.

Шунда ук 1916 елда оештырылган Милли музейны да без зур кызыксыну белән карадык. Сәнгать музеенда фин художниклары әсәрләре белән таныштык. Фин художникларының күбесе Петербургта һәм Парижда укыганнар. Картиналар Финляндия табигатен, аның борынгы эпосын гәүдәләндерәләр. Шулай ук портретлар да күп.

Фин култыгының зур утравы Милли музейның филиалы булып санала. Монда Финляндия табигатенең бик матур күренешләре белән һәм илнең үткән тормышы белән танышырга була. Биредә илнең төрле почмакларыннан китерелгән борынгы өйләр, чиркәүләр, авыллар урнаштырылган. Финляндия президентының дачасы да шунда.

Сугыштан соң Хельсинки тирәсендәге урманнарда шәһәрнең 20 гә якын спутнигы корылган. Шуңа күрә шәһәр халкының байтак өлеше табигать кочагында яши һәм бер үк вакытта шәһәрләргә хас барлык уңайлыклардан да файдалана.

Без шундый спутник шәһәрләрнең икесендә — Тапиола һәм Отаниемида булдык. Анда политехника институтын карадык. Бу уку йортының 10 факультеты булып, аларда уку — алты еллык. Хельсинкиның алты факультетлы университетында егерме мең студент укый.

Финляндия шәһәрләренең тагы бер үзенчәлеге турында әйтергә кирәк. Анда акча түләми бер генә адым да атлап булмый дисәк, ялгышмабыз. Нинди булса да башняга күтәреләсеңме, спорт мәйданыннан файдаланырга телисеңме, музейга яки паркка керәсең киләме, бассейнда коенырга ниятең бармы — боларның һәркайсы өчен пенниләр, маркалар түләргә кирәк. Кино һәм театрларга керү, трамвайда, автобуста, таксида йөрү бәяләре чагыштырмача бик кыйммәт. Авыруларга дәвалану өчен дә шактый күп түләргә туры килә. Дарулар кыйммәт. Квартира өчен эшче айлык эш хакының өчтән берсен түләргә мәҗбүр. Илдә хәзергә әле эшсезлек тә бетерелмәгән.

Финляндиядә янгыннарның еш булуы милли афәт булып исәпләнә. Ил тарихында шәһәрләрне, күп километрлардагы урман һәм кырларны юкка чыгарган зур янгыннар күп булган. Шуңа күрә Финляндиядә янгын сүндерүче һөнәре — гаять мактаулы эш. Монда янгын сүндерүче музее бар, башка музейларда да шундый махсус бүлекләр күрергә мөмкин. Янгын сүндерүчеләргә багышланган маршлар, җырлар, шигырьләр языла. Шәһәрләрдә алар өчен махсус тантаналар оештырыла.

Безгә Финляндиянең иң борынгы шәһәрләреннән берсендә — Туркуда булырга туры килде. Бу шәһәр XII гасырда ук инде зур үзәкләр рәтендә торган. Ә моннан 150 ел элек ул илнең башкаласы булган. 1827 нче елда чыккан бер зур янгын берничә сәгать эчендә Туркуны көлгә әйләндергән. Бары тик шәһәр кырыендагы кварталлар гына, калкулык артында булганга, янмый калганнар. Без шундый кварталларның берсен — Луостаринмякины карадык. Ул, үткән заман хатирәсе буларак, шул вакытта яшәгән һөнәрчеләр тормышы турында сөйли. Анда 17 өй бар, берничә тыкрык сакланган һәм алар XVIII гасырның бер кисәге булып калганнар. 1940 елдан бирле бу урын һөнәрчеләр музее булып санала. Аны төзүдә һөнәрчеләр үзләре катнашканнар. Хәзер монда экскурсиягә килүчеләргә мастерскойларны күрсәтәләр. Һәр елны сентябрьнең икенче шимбә — якшәмбе көннәрендә «һөнәрче көне» үткәрелә. Без, совет туристлары, хезмәтне мактап торучы бу музейны карап, зур канәгатьләнү алдык.

Турку шәһәре җиде калкулыкка урнашкан. Аның тирәсендә 28 мең вак утрау сибелгән. Шәһәр аркылы Аури елгасы ага. Шәһәрдәге борынгы крепость-замок һәм чиркәү XIII нче йөздә үк салынган. Бу шәһәр университет шәһәре буларак та, сәнгать сөюче меценатлар торган җир буларак та атаклы. Андагы музейлар, парклар, китапханәләр, һәйкәлләр һәм башкалар меценатлардан бүләк икән.

Аури елгасы ярлары буйлап йөргәндә кафедраль соборны, шәһәр китапханәсен, XVIII йөздә салынган ампир стилендәге башка мәһабәт биналарны күреп сокланмаска мөмкин түгел.

Турку крепосте Скандинавия ярым атавы тарихында күренекле урын тота. Ул 1280 нче елларда төзелгән. Үзенең озак гомере эчендә күп вакыйгалар, канлы сугышлар шаһите булган. Аңа 14 король хуҗа булуын гына әйтү дә җитә. Хәзер бирәдә илдәге иң зур тарих музейларының берсе урнашкан. Анда борынгы заман аристократларының өй җиһазларын күрергә мөмкин. Музей-крепость залларында һәртөрле корал коллекцияләре, корольләргә бирелгән бүләкләр, хезмәт кораллары, орденнар һәм медальләр коллекцияләре саклана.

Кафедральный собор Финляндиянең милли изге урыны булып санала. Собор һәм ил тарихы үзара тыгыз бәйләнгән. Монда без урта гасырның төрле чорлары культурасын күз алдыбызга китерә алдык. Финляндия тарихын гәүдәләндерүче бик күп һәйкәлләр, бу кырыс архитектуралы собор, аның гаять биек түшәмнәре кешеләрдә гаҗәп көчле тәэсир калдыра.

Турку университеты 1940 елда оештырылган. Әйтүләренчә, Финляндиянең теләсә кайсы югары уку йортына укырга керү дә бик кыен икән. Бигрәк тә медицина һәм политехника институтларына керү өчен бик зур конкурс үтәргә туры килә.

Аларда укып, магистр дәрәҗәсе алу шулай ук катлаулы хәл. Студент укыган өчен гаять кыйммәт түләргә мәҗбүр. Программа катлаулы һәм лекцияләр иртәнге 8 дән 20 сәгатькә кадәр дәвам итә. Аннан соң инде үзлегеңнән бик каты укырга кирәк. Студент, билгеле бер белгечлекне үзләштерү белән бергә, чит телне — инглиз, немец һәм француз телләрен яхшы өйрәнергә тиеш.

Финляндиядә сигезьеллык белем алу — мәҗбүри. Башта һәркем дүртьеллык башлангыч мәктәпне тәмамлый. Аннары, кереш имтиханнары биргәннән соң, сигез ел лицейда укый. Кереш имтиханнарын бирә алмаган балалар кичке мәктәптә укыйлар. Уку мәктәптә дә, лицейда да түләүле. Аларда да чит телләрне өйрәнүгә зур игътибар бирелә. Ә махсус мәктәпләрдә биш чит ил теле өйрәнелә.

Тампере шәһәренә без зур дулкынлану белән килдек. Анда без бөек Ленин музеен карарга тиеш идек. Музейда без һәр адымыбызны көчле дулкынлану белән атладык. Бу музей 1946 елда «Финляндия — СССР» җәмгыяте тарафыннан оештырылган. Андагы 500 дән артык экспонат Владимир Ильичның 1901—1907 еллардагы тормышы һәм эшчәнлеге турында сөйли. Монда скульптуралар, китаплар, хатлар, бүләкләр, картиналар, Ленинның Финляндия турындагы язмалары, тарихи Таммерфорс конференциясе фоторәсемнәре һәм башка бик күп документлар куелган. Музейны карагач, без уйларыбызны, фикерләребезне язып калдырдык. Туристлар музейда сувенирлар сатып алдылар.

Тампере — илнең әһәмиятле индустрия һәм культура үзәге һәм иң яшь, шул ук вакытта зур шәһәр. Аның тирә-ягында утызлап күл бар. Күлләр шәһәр эчендә дә күп. Аны парклар, чәчәклекләр, сулыклар бизи.

Пююники паркында, нарат агачлары арасында, 1000 кеше сыйдырырлык җәйге театр урнашкан. Тамашачылар утыра торган амфитеатр 360 градуска борыла ала. «Мондый театр дөньяда бер генә әле»,— диделәр безгә.

Туристлар «Финляндия — СССР» җәмгыятенең Таммерфорс бүлекчәсе дачасында оештырылган кичәдә булдылар.

Без финнар белән волейбол уйнадык, коммунистлар белән сөйләшеп утырдык, биедек, җырладык. Дусларыбыз безне фин мунчасына да керттеләр. Бу мунчага керү безнең өчен, әлбәттә, кызык иде.

Тампере шәһәреннән Топянага киттек. Бу шәһәр бик матур, зур күл буена урнашкан. Ял вакытында үтәли күренмәле салкын суда рәхәтләнеп коендык. Аннары катерга утырып Ауланко шәһәренә юл тоттык. Бу сәяхәт өч сәгать чамасы дәвам итте. Ауланкодан автобус безне Лахти шәһәренә китерде. Бу — иң яшь, яңа заман шәһәре. Финча Лахти — су култыгы дигән сүз икән. Бу шәһәр гүзәл Весиярви күле буенда кайчандыр янып юкка чыккан авыл урынына салынган. Шәһәр һәр яктан, бүгенге Финляндияне, аның үсешен күрсәтеп торса, икенчедән, ул — көньяк Финляндиянең әһәмиятле сәүдә һәм индустрия үзәге. Монда һәр көнне яхшы һава. Яшәү өчен гаять уңайлы шәһәр архитектура төзеклеге белән дә игътибарны җәлеп итә. Ул хәзер спорт, туризм һәм төрле конгресслар үзәгенә әверелгән. Монда искиткеч трамплиннар, спорт мәйданнары һәм парклар сокландыра. «Мәңгелек чаңгычы», эшче һәм коенучы скульптуралары һ. б. шулай ук кызыклы.

Кыш көне ел саен бирегә спорт ярышлары уздырыла һәм алар чын мәгънәсендә халык бәйрәменә әвереләләр.

Шунда безнең сәяхәт тәмамланды.

Кунакчыл Финляндия белән без аз гына ямансулап саубуллаштык.

Н. РАМАЗАН.


# ЕВРОПА ТИРӘЛИ

*Үткән елның октябрь аенда Казаннан бер төркем туристлар Европа тирәли сәяхәткә катнаштылар һәм Төркия, Греция, Италия, Франция, Англия, Дания, Швеция илләрендә булдылар.*

*Бу санда без шул сәяхәткә катнашучыларның берсе — Казан финанс-экономика институты укытучысы Нияз Хәкимуллинның фото-очеркын урнаштырабыз.*

**Одесса диңгез порты. Анда «Александр Пушкин» теплоходы. Аңа ихтыярсыз сокланасың: беренчедән, ул әле Одессага яңа гына килгән, икенчедән, Советлар Союзының иң «яшь» судносы. Зурлыгы һәм уңайлылыгы белән аерылып торган бу теплоход барлык диңгез һәм океаннарда йөзә ала; аның озынлыгы 176, биеклеге 51 метр; сәгатенә 40 км тизлек белән йөри. Дистанцион һәм автоматлаштырылган идарә. Көчле томаннарда да юл күрсәтергә сәләтле локаторлар. 8 этажга күтәрүче лифт, барлыгы 600 каюта, һәммәсендә радио, телефон. Пассажирлар карамагына гаҗәеп әйбәт ресторан, бик шигъри исемле («Ак төннәр», «Русалка», «Пингвин» һ. б.) барлар, кино залы, библиотека, музыка салоны. Шулар өстенә, искиткеч уңай коену бассейны бар.**


**Менә шушы корабльдә без, бер төркем туристлар, Европа тирәли сәяхәткә чыктык.**



**Төркиядә**

**Көн яктырганда безнең теплоход тар гына бугазга — Босфорга килеп керде. Без төрек порты Истамбулга якынлашабыз. Палубадан матур панорама ачыла.**

**Зур шәһәр фонында гаҗәп тоелганы: мәчет һәм манараларның күплеге.**



Истамбулның гомуми күренеше.

Причаллар янында ук үзе кечкенә, ләкин шактый зур шау-шулы базар. Кырык тартмачылар, сәүдәгәрләр корабльдән төшкән һәркемне камап алалар; веерлар, Истамбул күренешләре төшерелгән открыткалар тәкъдим итәләр...





Теләмисезме аларын! Алайса, атаклы төрек тәмәкесе тартырга сезгә трубка кирәктер! Алыгыз!





Кырык тартмачыларның күзләрендә моң да, җылылык та бар: гүяки, товарын алып, син аның язмышын, иртәгесе көнен хәл итәсең...

— Тартмыйсызмы! Рәхим итегез, алайса, менә сезгә кулдан эшләнгән башмаклар, өйдә тукылган эскәтерлар...



Истамбул буйлап без озак йөрдек, аның бай кварталларын гына түгел, бәлки ярлы һәм пычрак урыннарын да күрергә туры килде.

10 мең кешене сыйдыра алган мәчетләрендә булдык, аларда бик тырышып гыйбадәт кылалар: 20—25 яшьләрдәге яшь мулла ак чалмадан, ләкин бик заманча киенгән, ул мөнбәрдә микрофон аша вәгазь сөйли.

Ярлылык, эшсезлек, төрек халкының иртәгесе көненә дә ышанмавы — барысы да шушы мәчетләрдә алла, дин исеменнән аклана инде!



**Грециядә**

Грециягә килгән турист башкаладан ерак түгел урындагы билгеле җирне — Акропольне күрмичә китми.

Акрополь үзе исә — борынгы храм җимерекләре саклана торган таш калкулык.

Бу храмнар безнең эрага кадәр V гасырда ук салынганнар, ләкин һаман да үзләренең мәһабәтлекләре белән сокландырып, борынгы грек осталарына карата хөрмәт уяталар: алар һичбер техника булмаганда да ташка, мәрмәргә җан өргәннәр ләбаса!

Бу храмнар, борынгы Парфенон фонында кемнең генә рәсемгә төшәсе килмәс! Без, казанлылар да, моннан тыелып кала алмадык, әлбәттә.

Ләкин хәзерге Греция ярлы ил. Миллионнарча кешеләр хәерчелектә яшиләр.





**Италиядә**

Без Неапольдә. Кояшлы киң урамнар. Октябрьда 30° эсселек.


Иң башта сине фрукталар ароматы һәм магазиннарның төрлелеге, күплеге гаҗәпләндерә: товарлар хәтта тротуарларга ук тезеп салынган.

Туристларга бөтен шартлар булдырылган: уңайлы автобуслар, такси...

Таксида тиз бару ошамаса, синең карамакка башка төрлесе — иске модалы фаэтоннар да бар. Атлар сине теләгән җиреңә илтә, исәпләргә счетчигы да бар, утыр гына...

Помпеи — трагик язмышы белән атаклы шәһәр. 79 нчы елда Везувий вулканы атылганда һәлак була.

18 гасыр үткәч кенә аны казу эшләре башлана. Хәзер шәһәрнең шул чактагы тормышын күзалларга була.





Җансыз ташлар. Ләкин һаман да кешеләр яши төсле монда. Бәлки бу шуңадыр: биредә тормыш бер мизгел эчендә туктала. Барлык нәрсә нәкъ 2000 ел элек ничек булган, шулай сакланган. Менә мәрмәр бассейн, кайчандыр су аккан каналлар; өске катка сузылган таш баскычлар һәм зиннәтле колонналар.


Помпеи музее бай: таш булып катып калган икмәк, шул заман акчалары, ә витрина астында бөтен гәүдәсе белән җыерылып, катып калган яшь хатын... Ул куркудан йөзен кулы белән каплаган...



Шаулы урамнары белән атаклы Римнән барганда, күп урында монахларны очратасың: кара киемле булулары белән алар күзгә тиз бәреләләр. Кызыл киемле кардиналлар да еш очрый. Алар автомобильләрдә, мотоциклда утырып йөриләр, музейларда, магазиннарда, кинода күренгәлиләр...

Моңа гаҗәпләнәсе юк. Римдә — Ватикан. Ул — биек диварлар белән уратып алынган бер «кала». Һәм аның халкы меңнәр белән исәпләнә.

...Бу монах нигә бик иркенләп елмая соң әле!! Күрмисезмени. Аның янында ышанычлы сакчысы — бик шәпләп киенгән, коралы швейцар армиясе гвардеецы тора иң...



Франциядә

Париж — матур шәһәр. Елисей кырлары, Сена ярлары.

Ләкин Париж — контрастлар шәһәре: берәүләр төннәр буе ресторанннарда типтерә, икенчеләр исә көн-төн эшли...

Менә Парижның урам художниклары. Алар көн озын урамда. Бөтен нәрсәне төшерәләр: маймыл, попугай, хәтта изге мадонна рәсемен. Кырыйда — эшләпә, аңа алдан ук «мерси» (рәхмәт!) дип язганнар.

— Ул кулын гына сузып торса, әйбәтрәк булмасмы!

— Һич юк. Франциядә хәер сорашу тыела. Ул эшләргә тиеш. Бу да — эш...

Ләкин эшнең авыры... Көн буе художник тротуарда: сыза, боза, рәсем ясый яки заказ көтә.

Ә яшәргә кирәк!

• • •

Революция мәйданында исә халык тагын да күбрәк. Затлы магазиннар, отельләр. Бу — Парижның үзәге.

...Менә халык төркемен ерырга тырышып, берәү ашыга; ул һәркемнең кулына кәгазь тоттыра.

Кырынмаган йөзле, карт бер кеше. Аның аркасында авыр щит.

Кем бу! Һәм нәрсә язылган ул щитта!

Укыйбыз: «Безнең ресторанга килегез, бездә иң тәмле ашлар!..»

Ә, реклама! Аянычлы реклама. Көн озын күпләр әнә шулай «эшләп» йөри. Кемнең соң ачтан үләсе килсен!!

Бу да — Париж!






...Тукта әле! Бусы нәрсә! Көнчыгыш кешеләренчә киенгән берәү үзе артыннан ишәк тартып килә. Париж урамында ишәк!!

— Каян ул!! Бәлки, берәр чит илдән килгәндер!!

Юк, ул — француз, парижлы икән. Бу да үзенә күрә реклама. Соң, ишәк нәрсәгә! — диярсез. Цивилизацияле шәһәрдә ишәккә һәркемнең күзе төшә һәм рекламага... Әйбәт уйланган! Капиталистка шул кирәк тә...



Автобустан төшәргә дә өлгермәдек, безгә монахлар очрады. Берәү:

— Болар да аяклы рекламамы! — диде, көлеп.

— Ә юк, болары инде «аяклы мракобес»лар була.

Шулай, монахлар Римдә генә түгел, Парижда да күп икән.



Пер-Лашез каберлеге — үле шәһәр — бик көчле тәэсир калдыра. Ирексездән Бальзак искә төшә: ул бу каберлек турында күп язган һәм үзе дә шунда күмелгән.

Каберлекнең юл күрсәткечендә аның иң ерак почмагы — коммунарлар һәм коммунистлар күмелгән урын күрсәтелмәгән.

Коммунарлар стенасы янында ук фашист корбаннарына символик монументаль һәйкәлләр.

«Равенсбрюк» корбаннарына — куллары бәйле кеше һәйкәле, ә икенче һәйкәл— Маутхаузенда һәлак булганнарга: анда өскә менүче баскыч, аркасында авыр таш булган тоткын. Кырыйда язу:

«Маутхаузенда 12500 тоткын булып, 10000 тоткын үтерелде». Һәм астарак:

«Бу турыда онытмагыз!»

Көтмәгәндә, очраклы рәвештә, чит илдә үз илең кешеләрен очратсаң, бу — зур бәхет.

Шундый очрашуларның берсе — Парижда илебезнең җыелма футбол командасы белән очрашу булды. «Модерн» отелендә якташыбыз, атаклы футболчы Галимҗан Хөсәенов белән очрашу бездә аеруча зур тәэсир калдырды.

Англиядә

Лондонда иң беренче эшебез, әлбәттә, Хайгет зиратында Карл Маркс каберен эзләп табу булды.

Мәрмәр пьедесталда зур бюст, ә плитага:

«Бирედә Маркс, аның хатыны, оныгы һәм гаилә дусты — асраулары күмелде» дип язылган.

Һәйкәл тирәли чәчәкләрдән палас җәелгән, алар янына без үзебез китергән венокны да куйдык.





Лондонда парклар бик күп. Кенсингтон паркында зур, түгәрәк буада үрдәкләрнең, аккош һәм казларның күплеге гаҗәпкә калдыра. Традиция буенча алар Англия королевасының милке санала. Кошларны ату тыела, шуңа да алар иркенләп йөзеп йөриләр.

Кошларга җим бирү паркка килүчеләрнең традицион зәвыгы. Үрдәкләрне, аккошларны, күгәрченнәрне, хәтта чыпчыкларны да — барысын да турыдан-туры учтан ашаталар.



Букингем сарае урнашкан районда булсаң, күңелле тамашага очрыйсың: сарайда һәркөнне иртән сак алмашына; оркестр тавышы астында кызыл мундирлы һәм аю тиресеннән биек итеп тегелгән бүрекле гвардеецлар, кызыл камзоллы, алтын каскалы җайдаклар Букингемга юнәләләр.

Сарай алдында да сакчылар. Кулларында мылтыклар. Сакчылар, музей экспонатлары шикелле, тын, хәрәкәтсез тора. Сөйләшергә ярамый.



Швециядә

Стокгольм — яшеллек белән капланган 14 кечкенә таш утраудан тора, ул утрауларны кырык күпер тоташтыра. Шәһәр урамнарының күбесе — каналлар, аларда моторлы көймәләр, катерлар йөзеп йөри. Озын урамнар гомумән юк.

Стокгольм урамнарында чәчәк сатучыларны еш күрәсең: рәхим итегез, Швеция гөлләрен иснәп карагыз, янәсе!



Санаулы көннәр. Теплоходыбыз туган ил ярларына якынлаша. Күңелдә инде күптән ташыган сагыну хисләре йөзгә бәреп чыккан, телдә туган җиргә карата җылы сүзләр:

— Сагындык сине, бик сагындык, Туган ил.

# *Низами Ганҗәвинең тууына 825 ел*



*Әзербайҗан шагыйре һәм философы бөек Низами Ганҗәвинең тууына быел 825 ел тулды. Низами — «Серләр хәзинәсе», «Хөсрәү белән Ширин», «Ләйлә белән Мәҗнүн», «Җиде гүзәл», «Искәндәрнамә» исемле зур шигъри әсәрләрнең һәм бик күп лирик шигырьләрнең авторы. Низами Көнчыгыш поэзиясенә зур йогынты ясаган шагыйрь. Аның бу биш әсәре («Хәмсә», ягъни «Бишлек») көнчыгышның күп кенә шагыйрьләре тарафыннан, аңа ияреп, шундый ук «Хәмсә»ләр иҗат итәргә сәбәп булган. Шагыйрьнең бу гүзәл әсәрләре көнчыгышта һәм көнбатышта күп тапкыр тәрҗемә ителгән. Аның «Ләйлә белән Мәҗнүн» поэмасы татарчага да тәрҗемә ителде. Журналыбызның бу санында без Низаминың «Серләр хәзинәсе» китабыннан ике тәмсилен һәм лирик шигырьләрен тәрҗемә итеп урнаштырабыз.*

## Явыз патша белән туры сүзле карт турында

Бер илдә бер явыз патша тора иде,
Усаллыкта Хәҗҗаждан уздыра иде.

Ил эчендә нинди серләр булса төнлә,
Таң пышылдый иде аңа һәммәсен дә.

Килде аңа яла ягучы бер кеше,
Тик шымчылык иде аның бөтен эше.

Бурычка ул серләр алып һәр көн төннән,
Яла итеп түли иде шуны иртән.

Патшага ул әйтте бер көн: «Бер карт сине
Үтеручe, кан эчүче дию диде!»

Ачуыннан тәмам ярсып патша шунда:
«Китерегез тизрәк палач,— диде,— монда!»

Палач сипте келәменә шундук комны.
Хәтта дию куркыр иде күрсә моны.

Шунда берәү карт янына чабып китте:
«Патша кисә башыңны», дип хәбәр итте.

Карт юынып, кәфен тотып бер кулына,
Курыкмыйча китте патша хозурына.

Явыз патша, каш җыерып, кулын уып,
Әйтте аңа, ачуыннан сабрын җуеп:

«Синме мине үтерүче дип атадың?
Явыз дию, кан эчүче дип атадың?

Беләсең бит минем гадел икәнлегем,
Бу хурлауга ничек итеп барды телең?»

«Мин, — диде карт, — явызлыкка күз йоммадым,
Барын сөйләп бирдем, куркып тыелмадым.

Олысыннан, кечесеннән оялмыйсың,
Син бит шәһәр һәм авылны гел талыйсың.

Мин куркусыз күз төшереп һәр ягына,
Күзге булдым яхшыңа һәм яманыңа.

Үзе нинди — көзгедә дә шундый кеше.
Көзге вату — түгел бит ул акыл эше.

Колагың сал минем туры сүзләремә.
Үтерим, дисәң — мин үләргә әзер менә!»

Куркусыз карт патшага нык тәэсир итте,
Дөреслек алдында патша тетрәп китте.

Оятыннан күзен аска таба иде,
Хак сүз чөнки хаксызлыкны ачып бирде.

Картның кәфенен ташлатырга биреп әмер:
«Ефәк кием кидерегез, — диде, — хәзер!»

Һәм шул көннән ил кайгысын күрә башлап,
Хөкем сөрде, законсызлык юлын ташлап.

Дөрес сүзгә юл ачты ул бөтен илдә
Һәм яклады андый сүзне бөтен җирдә.

Әй, хакыйкать, һәрвакыт нык һәм таза бул!
Һай, хакыйкать бик ачы шул, бик ачы шул!

## Кибетче һәм төлке

Йәмән илендә бер кибетче булган,
Малын сакларга ул бер төлке куйган.

Торып сакта бу төлке көн дә, төн дә,
Күзәткән як-ягын, күз йоммый бер дә.

Ничә тапкыр кире киткән бер угры,
Эшендә төлке булгач шундый тугры.

Ниһаять, күп маташкач, угры арып,
Йомып яткан күзен, бер читкә барып.

Аның йоклаганын күреп ерактан,
Тынычлап, төлке дә йокларга яткан.

Көтеп ул йоклаганны, угры торган,
Алып бар малны, бер тарафка шылган.

Шулай, йокларга ятса юлда бер кем,
Югалтыр, шиксез, ул башын я бүркен.

Йокыңнан тор, Низами, юкса, син дә
Югалтырсың, нисең бар, һәммәсен дә!

•

*(Кыскартып алынды)*

Акылы булса кеше бәйләтмәс алтын кулына,
Алла алдында, — шуны бел, — патша да бер кол гына.

Тиз чыгу юлын кара, җәннәткә ләксәң син әгәр;
Нишләсен анда синең шикелле гади бәндәләр?

Коткара алмады хәсрәттән Гыйса да дөньяны,
Күккә ашты, калдырып табаны астында аны.

Бу җиһанда бар да бер-берсен ашый, җендәй явыз.
Җен белән кем дуслашыр соң? Яннарыннан тизрәк уз!

Чын кешелекле кешене эзләмә, ул монда юк.
Тугрылык, игелек, өмет үлгән яралган чорда ук.

Читләтелгән җирдә халык бар әшеннән дөньяның,
Сәмруг үлгән. Безгә калган тик матур исеме аның.

Алланы телгә алалар тик сораганда хәер.
Шул хәерчелек белән алла да дуслашкан хәзер.

Язмышын улларының торса Адәм алдан белеп,
Йокламый Хәва белән, яшәр иде буйдак булып.

Җирне каплады тизәк, ә күк — югары һәм ерак.
Тик тора, җыеп итәкләрен, сасы җиргә карап.

Кайгы-хәсрәт ялвара юкка гына ярдәм сорап.
Без — саран, ә дөнья — чукрак. Кем аңа бирсен җавап?

Сокланабыз без бабайларга, ләкин эше харап,
Булса сокланмак берәү, безнең бозык чорга карап!

Дөньяны чүп басты. Үлем, кил, себеркеңне алып,
Себереп ат юклыкка! Бер калсын күз алды чистарып!

Корыды дөнья бакчасы. Нәфрәт, нигә бәрдең атып
Пычкыны? Корган агачларны кисәргә бик вакыт!

Тырпаябыз без заман авызында, артык теш сыман.
Ал да, күк, кыскыч, суыр, бездән арынсын бу заман!

Күк! Җәберләр яудырып, күпме табарсың син кызык,
Безнең өмет тактасындагы хәрефләрне бозып?

Каплыйсың ахмакның артын, ник ефәк, атлас асып?
Ә акыллы — шыр-ялангач. Ник аның арты ачык?

Бирмисең кирпеч тә ник минем хыялым йортына?
Мин аны күңлемдә төздем — тик һаман ул буш тора.

Бушбугаз булдым бу әчке мәҗлесенә мин тарып.
Тонды шунда акылым, буп-буш хыялга алданып.

•

Чигенә җиттем җиһанның, очрашу өмет итеп,
Чапты аерылу кылычы тән аша җанны тетеп.

Бу йөрәк өмет юлында булды бер кәрван-сарай,
Күпме хәсрәт кәрваны шуның аша китте үтеп!

Сөрде тормышның корабын гел заманның дулкыны,
Туктады бер көн корабым, буш килеш ярга җитеп.

Очса кош ауны өзеп, мәңге аңа кайтмас кире,
Нәкъ шулай кайтмас гомер дә, чигенә калса житеп.

Очрашуның белмәдек вактында кадрен, чөнки без
Очрашып килдек, карак күк, һәрвакыт яшрен итеп.

## Дүртьюллыклар

Сиңа булган гыйшкым күгеп иңләп булмас,
Күңелемнең сиңа һич тә хәтере калмас.
Сиңа гашыйк кеше жанын үзе бирер,
Газраил һич аның жанын ала алмас.

●

Кая киттең? Сине эзләп гизәм, нишлим?
Сөйләмим һичкемгә хәлем, түзәм, нишлим?
Канлы яшьләр белән юам күзләремне,
Инде кабат күрә алмам, сизәм, нишлим?

●

Күрми калдың, күзем, ул бит югалды,
Көлде, елавымны уенга санды.
Йөрәк жанга ябышты, жан — йөрәккә,
Ә ул, селтәп кулын, китте дә барды.

●

Ни эчсәм дә, шәрап миңа барыннан артык,
Сусыны саф аның, шуңа барыннан артык.
Дөнья бит ул — жимерек бина. Шунда исереп,
Чумып яту хыялыңа — барыннан артык.

●

Янында дуслык булмаса, киләчәк — кара.
Дуссызлык сала йөрәккә хәсрәтле яра.
Күк биргән өч-дүрт сулышлык кыска гомерне,
Аямыйча, бер ялгызың үткәреп кара!

Әхмәт Исхак тәрҗемәләре.

——◆——

*Хатип Госман*

# ТАТАР ПОЭЗИЯСЕ ТАРИХЫНДА ТУКАЙНЫҢ УРЫНЫ

*Мәгъмүр Болгар шәһәрләре, болгар авыллары, бер дә булмаган төсле, кырылдылар да беттеләр, эзләре дә калмады. Әмма менә бу кыйммәтле мирас дидекемез халык шигырьләрен туплар да ватмады, уклар да кадамады. Алар һаман да халык күңелендә һәртөрле бәлая вә казаядан, муллалар әйтмешли, мәсун вә мәхфуз уларак калдылар; алар сәламәт әле, алар яңгырый әле.*

**Г. Тукай. Халык әдәбияты.**

## I

Татар әдәбиятының тарихы зурмы? Моңа, гадәттә, уйланып тормастан, «җиде-сигез гасыр» дип кенә җавап бирәләр. Ләкин башкача уйлаучылар да юк түгел. Татарның чын үз поэзиясе тик 1905 елдан соң гына барлыкка килде, аңа кадәргесе территориягә, халыкка бәйләнмәгән, дини хорафатлар белән сугарылган космополитик әдәбият, теле дә аның татарга бәйләнеше булмаган «төрки» иде, дип расларга әзер торучылар да бар.

Мондый, төрлечә фикер йөртүләрнең сәбәбе — әдәбият тарихының ныклы эшләнмәгән булуында. Бигрәк тә бу тарихның методологик проблемалары җитәрлек тирән яктыртылмаган. Әгәр чыннан да күп гасырлык язма әдәбият булган икән, аның шулай иртә тууын нинди тарихи шартлар мәҗбүр иткән — болар билгеләнмәгән. Сүзне әнә шуннан — татар әдәбиятын китереп чыгарган тарихи шартлар мәсьәләсеннән башлап китәсе килә.

Иделнең түбән һәм урта агымында төрки телле халыклар безнең эраның беренче мең елында ук инде яшәгәннәр. Хәзерге Казан татарларының тамырлары әнә шуннан ук килсә кирәк. Совет фәне шул фикерне куәтләүгә таба бара.

Идел буйларында яшәгән төрки кабиләләрнең сөйләм поэзиясе күптән туган, әлбәттә. Ә язма поэзияләре кайчан килеп чыккан соң? — Менә бу бик мөһим мәсьәлә.

Борынгы чорда теге яки бу халыкның цивилизация юлына басуы һәм моны нинди объектив тарихи шартлар мәҗбүр итүе марксизм классиклары тарафыннан ачык аңлатылган. Алар бу мәсьәләдә хәлиткеч шарт итеп *игенчелек белән һөнәрчелек арасында хезмәт бүленеше* барлыкка килүне күрсәтәләр. Әлбәттә, бу төп шартның алгы шартлары да бар. Мәсәлән, халыкның утрак тормышка күчкән булуы. Халык күчмә тормыш белән яшәсә, күчмә рәвешле мал асраучылык белән шөгыльләнсә, әлбәттә, мондый шартларда мал асраучылыктан һөнәрчелек аерылып чыга алмый. Алай гына да түгел, халыкның утрак тормышка күчеп, игенчелек белән шөгыльләнә башлавы әле шунда ук һөнәрчелек аерылып чыгуын мәҗбүр итми. Без тарихта утрак игенчелеккә күчеп тә, озак заманнар буе цивилизациясез, язусыз-нисез яшәгән халыкларны да беләбез. Ни өчен шулай булган соң? Чөнки алар, игенчелеккә керешсәләр дә, натураль хуҗалыкта йомылып калганнар, аларда игенчелек белән һөнәрчелекне аерып җибәрүче шарт яралмаган. Алмаш тумаган. Сәүдә мөнәсәбәтләре килеп чыкмаган.

Идел буеның төрки телле халыкларына күз салсак, без үзгәрәк картинаны күрәбез. Безнең эраның беренче мең еллы ахырларына таба монда инде нык урнашкан игенчелек бар. Ул гына да түгел, Болгар иленлә игенчелектән һөнәрчелек аерылып чыккан һәм мөстәкыйль эшчәнлек өлкәсе буларак формалашкан. Һөнәрчеләр, авыллардан аерылып чыгып, зур юл чатларында, зур су ярларында һөнәрчелек-сәүдә бистәләрен төзегәннәр. Бу соңгылар тора-бара һөнәрчелек-сәүдә шәһәрләренә әверелгәннәр. Бу вакытта ук инде без Идел тамагында Итил шәһәрен күрәбез. Урта Иделдә исә Болгар, Биләр, Юкәтау, Тубылгытау, Мокша, Кашан кебек шәһәрләре белән мәгълүм Болгар иле җәелеп ята...

Шунысын онытырга ярамый: бу чорда сыйныфлар, дәүләт һәм аның органнары инде формалашып җиткән. Иҗтимагый тормыш, төрле социаль катлаулар арасында мөнәсәбәтләр, күрше илләр белән бәйләнешләр шулай ук катлаулы төс алган. Бу дәрәҗәгә җиткән җәмгыять язусыз булдыра алмый. Тормышның барышы язуны кирәксенә генә түгел, таләп итә. Язу-сызу, укымышлылык объектив ихтыяҗ буларак барлыкка килә, хезмәт кәгазьләре хәрәкәткә керә, китаплар языла.

Дөнья тарихыннан бернәрсә ачык күренә: *борынгылыкта үз кулы белән шәһәр салмаган халык китап та язмаган.* Идел буенда да төрки шәһәрләр кайвакытта барлыкка килгән булсалар, төрки телендә китаплар да бирелә шул вакытта языла башлаганнар.

Әмма язу куллана башлау белән үк матур әдәбият әсәрләре туа башлый икән дип уйлау дөрес үк булмас иде. Сәнгать әсәрләре иҗат итү хезмәт бүленеше шактый үскәч, билгеле бер югарылыкка ирешкәч кенә башланган. К. Маркс һәм Ф. Энгельс болай язалар: «Материаль хезмәт белән рухи хезмәт арасында бүленеш барлыкка килгән моменттан гына хезмәт бүленеше чын-чыннан бүленеш булып әйләнә» [1].

Тарих фәнендә Болгар дәүләтенең формалашуы X гасырда ук бик җанлы төстә барганлыгы раслана. Ә безгә Болгар чорыннан Колгалинең «Кыйссаи Юсуф» поэмасы гына килеп җиткән. Бу инде XIII гасыр башында язылган әсәр. Күрәсең, Болгар дәүләтендә материаль хезмәт белән рухи хезмәт арасында бүленеш шул заманнарда югары дәрәҗәгә үскән.

Колгалинең чибәр Юсуф турындагы мәгълүм легенда сюжеты буенча язылган һәм билгеле гуманистик идеяләр белән сугарылган бу поэмасы композицион төзеклеге, сурәтләү чараларының җанлы булуы белән аерылып тора һәм ул бөтен татар поэзиясенең үсешенә тирән йогынты ясаган. Мондый камиллеккә ирешүнең чыганаклары кайда? Бик ерак заманнарда Идел буеның төрки телле әдәбияты ничек шундый югары дәрәҗәгә күтәрелә алган соң? Бу уңай белән дә без тагын Маркс һәм Энгельс сүзләрен тыңлыйк әле. Алар, Яңарыш чорында Италиядә чәчәк аткан сәнгать тәҗрибәсенә таянып, болай диләр: «Рафаэльнең килеп чыгуы, теләсә нинди бүтән художникның килеп чыгуы шикелле үк, сәнгатьтә аңа кадәр ирешелгән техник казанышлар, ул яшәгән якларда җәмгыятьнең оешу рәвеше һәм хезмәт бүленеше, шулай ук, ниһаять, ул яшәгән яклар бәйләнеш тоткан барлык илләрдәге хезмәт бүленеше тудырган шартлар белән бәйләнгән» [1].

Бу яктан да Болгарның мөмкинлекләре җайлы булган. Идел Европа белән Азиянең уртасыннан — югарыдан алып түбәнгә кадәр — юл ярып биргән. Урта диңгездән Азовка кадәр су юлы, аннан, Түбән Идел, Болгар җирләрен үтеп, Кытайга кадәр кәрван юлы салынган, — бу юл Европа белән Азияне тоташтырган. Болгар шушы ике бөек юлның очрашып узган үзәгендә торган. Ул үз заманында бөтен дөньяны — «җиде иклимне» — тәшкил итә дип исәпләнгән барлык тарафлар, барлык илләр белән бәйләнешкә керә алган. Әмма фикер, мәгърифәт, әдәбият һәм сәнгать мәсьәләләрендә Болгар Хорәземгә, аннан арырак торган Иранга, гарәп илләренә өстенлек күрсәткән, аларның рухи культурасына тиңләшергә омтылган. Ул заманда Болгар өчен бу иң прогрессив ориентация булган. Ни өчен? Чөнки ул вакыт әле Европа христиан дине караңгылыгы астында ята, Яңарыш таңы атар-атмас халдә аз-аз гына төсмерләнә башлаган. Болгар янәшәсендәге күрше илләрдә дә эш шул чамадарак. Гарәп, фарсы дөньясында исә бөтенләй башка хәл: монда антик, бигрәк тә грек сәнгатенә игътибар үсә, көчәя. Гарәп, иран галимнәре грек телен ныклап өйрәнергә керешәләр. Аристотель, Эвклид кебек

---

[1] К. Маркс и Ф. Энгельс об искусстве. Мәскәү. 1957 ел. Рус телендә. Ике томда. I том, 146 бит.

[1] Шунда ук, II том, 250 бит.

галимнәрнең хезмәтләре гарәп теленә күчерелә. Мәгълүм ки, борынгы грек фәнендә, грек сәнгатендә *кеше проблемасы,* аның тирә-юньгә мөнәсәбәте мәсьәләсе аеруча калку, аеруча кабарынкы төстә куелган. Бу унайда греклар күтәреп чыккан фикер һәм идеяләр фарси әдәбиятына һәм сәнгатенә дә тәэсирсез калмыйлар, билгеле. Нәтиҗәдә, Рудәки, Фирдәуси, Гомәр Хәйям, Насыйр Хөсрәү, Әбүгалисина, Низами, Сәгъди кебек даһи шагыйрьләр мәйданга чыга.

Алар иҗат кешесенең матурлыгын җырлаганнар, тирән гуманизм хисләре белән сугарылган әсәрләр язганнар. Бу сыйфатлар Хорәземдәге һәм Идел буендагы төрки халыклар культурасына да үткән; монда да фән һәм сәнгать, шул заман дәрәҗәсе белән чагыштырганда, зур югарылыкка күтәрелгән. Фәнни фикердә, әдәбият, сәнгать өлкәсендә Болгарның Хорәземгә, аннан ары гарәп һәм фарси дөньясына ориентация алуын әнә шуның өчен дә без прогрессив күренеш булган дип саныйбыз. Ул яклардан безгә гарәп һәм фарси культурасы традицияләре генә түгел, алар аркылы антик культура, аерата грек культурасы традицияләре дә, килгән дияргә мөмкин.

Идел буенда шул ерак заманда ук, «Кыйссаи Юсуф» кебек, сәнгать ягыннан югары дәрәҗәгә күтәреп иҗат ителгән әсәрләрнең килеп чыгуы да әнә шул шартларга бәйләнгән.

## II

Коточкыч хәлләр килеп чыкмаганда, Болгар әдәбияты, фарси һәм гарәп культураларының бәрәкәтле йогынтысы тәэсирендә, шулай җайлы гына күтәрелеп тә киткән булыр иде. Ләкин XIII гасыр урталарында Батый хан яулары Болгар халкын кырып, шәһәрләрне талап, яндырып, көлгә әйләндереп үтәләр. Тик йөз елга якын вакыт узгач кына Идел буе төрки дөньясы яңадан күтәрелә, Болгар аякка баса, Түбән Иделдә Сарай-Бату, Сарай-Бәркә, Увек, Хаҗи Тархан (Әстерхан), Сарайчык һәм башка яңа шәһәрләр төзелә. Болар баскынчы татар-монгол ханнарының әмере буенча барлыкка килгән калалар. Ләкин бу калаларны җирле халык осталары төзи һәм аларның төп халкын да алар тәшкил итә.

Басып алу сугышлары вакытында әлеге зур сәүдә юлы бераз өзелеп торса да, соңрак, элеккедән дә җанлырак булып, яңадан хәрәкәткә килә. Урта һәм бигрәк тә Түбән Идел кабат халыкара сәүдә багланышлары үзәгенә әйләнә. Бу чорда төньяк Хорәзем, Болгар, Кырым, Кавказ төрки дөньялары үзара шактый якыная төшкән булсалар кирәк. Кыпчак теле боларның барысы өчен дә уртак әдәби телгә әйләнә баруы күренә. Шулай да һәр аерым әсәрдә теге яки бу әдипнең кай яктан, мәсәлән, Болгарданмы яисә Кавказданмы чыкканына карап, телендәге аермалы элементларны да шактый ачык билгеләргә була.

Мәгълүм ки, XIV гасыр урталарына кадәр булган чор Алтын Урда дәүләтенең, Алтын Урда ханнарының күтәрелү, көчәю чоры санала. Идел буе төрки әдәбиятында нәкъ шушы чор буш тора: безнең кулда шул чорда язылган нинди дә булса дөньяви, гуманистик рухлы әсәр хәзергә юк, бәлки, андый әсәрләр ул чорда язылмагандыр да. XIV гасыр урталарыннан Алтын Урданың җимерелү чоры башлана һәм ерткыч ханнар дәүләте бик тиз, ярты гасыр эчендә тәмам ишелеп төшә, һәлак була, юкка чыга. Нәкъ менә ханнар дәүләте җимерелә башлау белән гуманистик рухлы әдәбият терелеп китә: 1342 елда Котби «Хөсрәү вә Ширин»не яза, 1354 елда Хорәзми «Мәхәббәтнамә»не, 1370 елда Хисам Катип «Җәмҗөмә Солтан»ны иҗат итә, ниһаять, ханнар хакимлеге гөрселдәп тәмам авып барган елларда бу чор прогрессив әдәбиятының иң югары казанышы — Сәйфи Сараи әсәрләре дөньяга чыга. Саналганнардан «Хөсрәү вә Ширин», Сараиның «Гөлстан» кебек әсәрләре ачыктан-ачык халыкка хөрмәт, хезмәтне олы күрү, иҗат кешесенең матурлыгын җырлау рухы белән сугарылган. Бу әсәрләрнең икесенә дә оптимизм хас. Аларны иҗат итүчеләрнең рухи хәлләре ханнарга бәйләнмәгән. Алар сарай язучылары булмаган. Аларга хәтта хан башбаштаклыгы аеруча котырынган Идел буе шәһәрләрендә яшәп иҗат итү дә кыен булган булса кирәк: аларның байтагысы моннан Мисыр төркиләре — мәмлүкләр арасына китеп, үз әсәрләрен шунда язган.

Борынгы заманда Идел буендагы төрки әдәбиятны шушындагы, Идел буендагы тарихи шартлар тудырган. Ләкин без югарыда Маркс белән Энгельсның Рафаэль турындагы сүзләреннән күреп үттек, әдәбият һәм сәнгать шундый иҗтимагый күренешләр ки, аларны һәрбер халыкның үз эчке көче тудырса да, бер тугач, бер дөньяга килгәч, гөрләп үсеп китәр өчен аларга шул халыкның үзе әзерләгән әдәбият һәм сәнгать тәҗрибәсе генә аз булып кала. Яңа

туган әдәбият һәм сәнгатьне алга киткән халыкларның әдәбиятлары һәм сәнгатьләре тәҗрибәсе белән баету бурычы котылгысыз булып әверелә. Талант ияләре бу баету эшенә керешәләр дә. Идел буе әдипләре, югарыда әйтелгәнчә, шушы максат белән гарәп һәм фарсиның бөек классик әдәбиятына мөрәҗәгать иткәннәр. Тәҗрибә күчереп алуның юллары бик күп. Ул алга киткән әдәбиятның телен өйрәнүдән башланырга мөмкин. Һәм чыннан да Идел буеның борынгы төрки язучылары үз телләре өстенә гарәп һәм фарси телләрен камил белгәннәр, теләсәләр, ул телләрдә китаплар, хәтта шигырьләр дә яза алганнар. Алар гарәп телендәге, бигрәк тә фарси телендәге, әдәбиятны Идел буеның төркисенә тәрҗемә итү эшен җәелдереп җибәргәннәр. Бу эш үзе генә дә зур иҗат мәктәбе тудыруга сәбәпче булган. Гарәп һәм фарси дөньясында әдәби иҗат тәҗрибәсен күчереп алуның үзенә махсус бер алымы эшләнгән. Бу назыйрә дип аталган.

Назыйрә — ияреп, күчергеч алып язу. Бер шагыйрь икенче шагыйрь әсәренең темасын, сюжетын күчереп ала да, аны үзенчә яңартып кора, язганда әлеге шагыйрьнең үлчәмен, ритмнар системасын һәм башка үзенчәлекләрен үзгәртмичә саклый яки нәкъ шуларга охшаш итеп ала. Ләкин назыйрә механик иярү түгел. Киресенчә, ул шагыйрьләр арасында бер үк вакытта тәҗрибә уртаклашу да һәм иҗат ярышы да[1]. Рим шагыйре Горацийның «Һәйкәл» дип исемләнгән бер шигыре бар. Без француз шагыйре Ронсарның, рус шагыйрьләре Державин һәм Пушкинның Горацийга ияреп язылган, шул ук исемдәге әсәрләрен беләбез. Беренче карашка, алар арасында уртак мотивлар, охшаш яклар да күп шикелле. Әмма бер үк исемдәге бу шигырьләрнең һәркайсы үзенә мөстәкыйль, һәркайсы кабатланмас сәнгать әсәре. Менә бу да назыйрәнең бер күренеше. Бу алым белән язылган әсәрләрдә традиция һәм новаторлык бер бөтен булып оеша.

Идел буе төрки шагыйрьләренең гарәп һәм иран поэзиясе традицияләрен үзләштерүендә назыйрә гаять зур роль уйнаган. Көнчыгыш поэзиясе традицияләрен Идел буе төрки туфрагына күчерү баштарак әсәрләрне турыдан-туры тәрҗемә итү юлы белән барса, соңга таба тәрҗемәгә назыйрә элементларын катнаштырып җибәрү көчәя. Ленинград университетының иран теле һәм әдәбияты белгече доцент Габдрахман Таһирҗанов Колгалинең «Кыйссаи Юсуф» поэмасын Фирдәүсинең «Иосыф һәм Зөләйха» әсәре белән чагыштырып караган һәм Колгали әсәренең Фирдәүсигә ияреп язылган булуын ачкан.

Борынгы Идел буе төрки әдәбиятында бу алым Сәйфи Сараи иҗатында иң биек ноктага күтәрелә. Котби үзен Низами шәкерте санаса, Сәйфи Сараи үзенә бөек иран шагыйре Сәгъдине остаз иткән. Сәгъди 1258 елда «Гөлстан» әсәрен язган.

Әсәр аерым-аерым хикәяләрдән тора. Хикәяләү барышында Сәгъди шигырьгә күчеп-күчеп ала. Нәтиҗәдә, «Гөлстан» бик күп шигырьләр катнаштырылган проза әсәре булып әверелә. Идея эчтәлеге ягыннан бу әсәр халык массаларының феодализмга каршы протестын чагылдыра. Сәйфи Сараиның да бу әсәргә мөрәҗәгать итүе тикмәгә түгелдер, безнең шагыйрь дә, бәлки, аның феодаллар, ханнар ерткычлыгына каршы идеяләрен үз күргәндер. Шул кадәресен дә әйтергә кирәк, әсәрнең проза өлешен Сараи беренчеләргә үзгәрешсез диярлек тәрҗемә иткән, әмма шигъри өлешендә өч нәрсә күзгә ташлана: шигырьләрнең бер өлешен ул төгәл тәрҗемәдә биргән, икенчеләрен назыйрә алымы белән эшләгән, өченчеләрен исә бөтенләе белән үзеннән язган.

«Гөлстан»ны тәрҗемә иткәннән соң Сәйфи Сараи назыйрәләрдән торган лирик шигырьләр җыентыгын язган. Биредә инде ул үз чорының төрки шагыйрьләре Мәүлә Казый-Мөхсин, Мәүлә Исхак, Мәүлә Гыймад, Хорәзми, Габделмәҗит, Әхмәт Хуҗа әс-Сараи, Туглы хуҗа һәм Хәсән углы әсәрләреннән күчергеч ала. Әдәби ярышта Сәйфи Сараи үзе чын виртуоз булып күз алга баса.

Ул замандагы төрки телендәге әдәбият, әгәр Идел буе дөньясын үзен генә аерып карасаң, Хаҗи Тархан (Әстерхан) нан алып Казанга кадәр җәелеп яткан мәйданда язылган һәм укылган. Ул заман таләпләре ноктасыннан караганда сәнгать ягыннан камил өлгергән, җитлеккән әсәрләр барлыкка килгән. Аеруча шигырь зур югарылыкка ирешкән. Әдәби тел дә яхшы эшләнгән. Сәйфи Сараи һәм Мөхәммәдъяр (Казанлы) әсәрләрендәге тел төзеклегенә игътибарсыз калып булмый. Бигрәк тә Сараи теле аерылып тора. Ул безгә хәзер дә җиңел аңлашыла.

Алтын Урда дәүләте ничек тиз бар-

---

[1] Н. Ханзафаровның «Казан утлары» журналының быелгы 4 санында басылган мәкаләсен карагыз.

лыкка килсә, шулай ук тиз җимерелеп төшә дә. Бер заманнарны аның кул астына эләккән төрки илләр дә, һәркайсы үзенчә аерылып, моннан соң һәркайсы мөстәкыйль юл белән үсә башлый. Болгар, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы заманнарында барлыкка килгән культура казанышларын хәзерге замандагы татар халкы үзенә мирас итте. Безнең әдәбият тарихыбыз да әнә шул ерак заманнардан килә. Моның шулай икәне совет тарих фәнендә инде расланган [1].

III

Җәмгыятьнең борынгы заманнан социалистик революция ягына таба хәрәкәт итүе өчен феодаль таркаулык бетерелергә, үзәкләшкән зур дәүләт барлыкка килергә тиеш булган. Тик шундый дәүләт булганда гына капитализм барлыкка килә ала, ә инде капитализм чоры социалистик революция өчен объектив шартлар әзерли.

Казан ханлыгын тар-мар итү һәм аның җирләрен Мәскәү дәүләте составына кушу әнә шул үзәкләшкән дәүләт төзелә баруның бер күренеше булган. Ләкин, мәсьәләнең катлаулылыгын аңлар өчен, биредә зур вакыйгаларның *объектив* тарихи мәгънәсе белән бу вакыйгаларда катнашучы сыйныфларның *субъектив* максатлары дигән нәрсәне истән чыгармаска кирәк. Казан ханлыгын тар-мар итү, аның җирләрен Мәскәү дәүләтенә кушу эшен рус князьләре, рус патшалары, ягъни рус феодаллары башкарган. Бу очракта алар үз субъектив максатларын күзәткәннәр: аларга эксплуатацияләү өчен кинрәк мәйданнар ачылсын, алар кул астына күбрәк халык керсен, алар сыйныфы баерак, көчлерәк булып әверелсен, дәүләт власте ныгысын, алга киткән башка илләрдән куркып тормаслык кына түгел, хәтта, әгәр кирәк икән, өсләренә барып басарлык булсын. Субъектив максатларның шундыйлыгы аңа ирешү чараларының рәхимсез характерын да билгеләгән.

Әлбәттә, субъектив максатлар белән объектив зарурият шунда ук, һич кичегүсез, икесе берьюлы нәтиҗә бирә дип уйлау бик үк төгәл булмас иде. Субъектив максатлар шунда ук нәтиҗә бирә башлый һәм алар кыска гомерле, әмма объектив зарурият озын гомерле, чөнки ул ерак киләчәккә караган, аның барып ирешәчәге зуррак, бөегрәк.

[1] Карагыз: Б. Д. Греков, А. Ю. Якубовский. Золотая Орда и ее падение. Рус телендә. Мәскәү, 1950 ел, 10 бит.

Һәркемгә мәгълүм бу хакыйкатьне болай кабат сөйләп чыгу безгә татар халкы рус дәүләте составына кергәннән соң аның әдәбияты ничек үсүен аңлатыр өчен кирәк. Казан алынганчы ук татар феодаллары арасында рус дәүләтенә мөнәсәбәттә ике агым булган: бер әүләр карышмый-нитми Мәскәүгә буйсынырга кирәк дигәннәр, икенчеләр— каршы тору юлын тотканнар. Казан җиңелгәч тә феодалларның байтагысы динен алмаштырган һәм шуның белән үз биләмәләрен, үз хокукларын саклап калган, ә бераздан бөтенләй руслашкан. Соңыннан болар населениедән күп кенә җәмәгать һәм дәүләт эшлеклеләре, рус культурасын үстерүгә житди өлеш керткән фикер ияләре, художниклар чыккан. Феодалларның бер ишесе, чукынмаса да, рус патшалары каршында ышаныч казанган.

Рус патшаларының татарларны дәүләт хезмәтенә тартуы «йомышлы татарлар» дигән яңа катламны китереп чыгара. Болар үз эчләрендә шулай ук түбән һәм югары катламнарга аерылганнар. Югарылар, хезмәтләре өчен рус патшаларыннан зур бүләкләр алып, эре алпавытларга, дәрәҗәле кешеләргә әйләнәләр, үзләренә бер иҗтимагый мөхит тудыралар. Алар патшага Урта Азияне, Казагыстанны һәм башка көнчыгыш илләрен кулга төшерүдә ярдәм итәләр. Шундыйлардан берсе — Котлу Мөхәммәт Тәвкилев, мәсәлән, зур алпавытка әйләнгән.

«Йомышлы татарлар»ның мөлкәтле катлаулары арасында, әлбәттә, дөньяви максатлар, дөньяви идеяләр өстенлек иткән. Әдәбият өлкәсендә дә алар татарлар арасында элекке чорда туган һәм үскән дөньяви традицияләрне көчәйтеп алганнар, ул традицияләрне яңа тарихи шартларга яраштырганнар. Ә яңа шартларда үзәкләшкән дәүләткә мөнәсәбәт, аңа нинди караштা булу мәсьәләсе беренче булып торган. Бу җәһәттән Кадир Гали бәк Җалаерлының Борис Годуновка багышланган одасы кызыклы. Рус патшасын күкләргә күтәреп мактап, ул болай ди: «Ай кеби, көн кеби халыкка яругълыгың (нур сибеп торуың — Х. Г.) бар. Барча рус вә татар, немец вә липкәнең (полякның — Х. Г.) Борис атлыйгъ ханы бар». XVI гасыр ахырында һәм XVII гасыр башында Кадир Гали бәк Җалаерлының Борис патша һәм аның власте йөзендә үзәкләшкән бер бөтен дәүләтне яклап чыгуы, һичшиксез, уңай сыйфат. Бу очракта без татар әдәбиятында *Россияне бер бөтен уртак ватан итеп* тануны — бу

яңа тойгы, бу яңа идеянең беренче гәүдәләнешен күрәбез.

Шунысы кызыклы, мондый «мәдех» (ода) жанры татар әдәбиятында Алтын Урда һәм Казан ханлыгы вакытында ук популяр төс алган була. Жанрда гәүдәләнергә тиешле идеяләр даирәсе, композициянең үзенчәлекләре, хәтта төп тасвир чаралары шул чакта ук бик анык итеп эшләнгән, традициягә әверелгән. Тик хәзер адресат кына алмашына: тегендә татар ханнары һәм аларга хезмәт итүче дәрәҗәле кешеләр, бирегә исә рус патшасы, аңа хезмәт итүче дәрәҗәле татарлар. Монда борынгы мәдхия жанры эчтәлеген алмаштыра, аның яңа тарихи функциясе ачыла. Татар әдәбиятындагы борынгы жанр хәзерге заманныкы булып яңара, аңа яңа дәвернең киләчәгенә үтәр өчен юл ачыла. Чыннан да XVIII гасырда, бигрәк тә аның икенче яртысында, бу жанр шактый канат җәя, үзенең төсмерләрен ачыклый. Аны инде, исән кешегә багышланса «мәдхия» дип, вафат булган кешегә багышланса, «мәрсия» дип икегә аерып исемләү гамәлгә керә.

XVIII гасыр ахырларына таба «мәдхия» һәм «мәрсия»ләр күп языла. Котлу Мөхәммәт Тәвкилевкә багышланган мәрсия, мөфти Мөхәммәдҗанга, Казан ахунына, Пугачев күтәрелешен бастыруда генерал Михельсонның уң кулы ролен үтәгән йомышлы татарлардан Габделмәннән Мөслимовка багышланган мәдхияләр әнә шуны раслыйлар. Аларның һәрберсендә диярлек макталган затның рус патшаларына күрсәткән хезмәтләре, моның өчен мактаулы бүләкләр алуы аерым билгеләп үтелә. Мәдхия һәм мәрсияләрнең тантаналы стильләре, шигъри төзелешләре XVIII гасырда ук тәмам эшләнеп җитә. XIX гасыр дәвамында бу жанр үз адресатында акрын-акрын эволюция кичерә. Ниһаять, Тукай аның яңа функциясен ача: ул Заһир Бигиев, Шиһап Мәрҗани, Хөсәен Ямашев хезмәтләрен җырлаган мәрсияләр яза. Бу очракта без татар поэзиясендә күп гасырлар буе хәрәкәт итеп килгән традицияләрдән берсенең Тукай иҗатында яңа куәт алуын, яңаруын һәм инде эксплуататор сыйныфларның аерым вәкилләрен мактауга түгел, бәлки аларга каршы, прогрессны, халык азатлыгы идеяләрен алга сөргән геройларны мактауга хезмәт итүен күрәбез.

Шул ук XVII—XVIII гасырларда татар әдәбиятында дөньявилыкка каршы, дини хорафат белән сугарылган әдәбият та киң җәелеп бара. Ул әдәбиятны дәвам иттерүчеләр, әлбәттә, руханилардан гыйбарәт. Алар үзәкләшкән зур дәүләт булуга каршы. Шулай да аларда тарихның бу чынлыгына ачыктан-ачык көрәшерлек реаль көч юк. Алар идеологик сугыш юлын тоталар, татарлар аңына ислам динен тирәнрәк сеңдерергә, «каферләр»гә карата дошманлык тойгысын кабартырга омтылалар. Шул идеяләр нигезендә алар дини легендаларны әдәби формаларга салып, ислам «изгеләр»енең «каферләр»гә каршы сугышларын тасвир итәргә тырышалар. Бу юлда тезмә белән дә, чәчмә белән дә күп санлы калын-калын китаплар языла. Бу әдәбият, билгеле, суфичылык белән тоташа. Ләкин суфилар үзләре бертөрле генә булмаганнар, күрәсең. Алар арасында руханиларның түбән катламы вәкилләре, аннан да бигрәк ярлы хәлфәләр булган булса кирәк. Соңгылары арасында изелгән халыкка теге яки бу формада теләктәшлек иткән аерым суфилар да очрый. Мәүлә Колыйның шундыйлардан булуы мөмкин. Ул — зур талант. Шуңа күрә хәл аны бик каршылыклы итә. Берьяктан, суфичылык өйрәтмәсе аның дөньядан бизүен, бу дөньяны каргавын, алдындагы тормыш күренешләренә күз йомып, үз эченә бикләнүен таләп итә. Ләкин, икенче яктан, аңарда тормышның җанлы күренешләренә тиенү белән уянып китә торган сизгер йөрәк бар. Иҗтимагый тормышта хөкем сөргән ерткычлык, ачкүзлелек, көчленең көчсезне өзгәләп ташларга әзер торуы — болар аңарда нәфрәт уята, нәфрәте ачу тудыра. Ул хәтта суфилыкны үзенә битлек итеп кенә алган ерткычларны аерып күрсәтә. «Суфи мән тир... мал өчен каның суча эчәр... Фәкыйрь мискин мөэминнәргә зарар кыйлыр, рәхим кыйлмаз, башын куйса — печәр ирде», — ди. Ул тарихи прогресс юлы белән алга таба барып, иҗтимагый явызлыкны җиңәргә мөмкин булачагын, әлбәттә, күрми, киресенчә, тарихи үткәннәргә, патриархаль борынгылыкка йөз бирә, иҗтимагый тормышның катлаулы каршылыкларыннан котылып, борынгы гади игенче тормышына кайту турында хыяллана. Шуннан ул табигать белән татулыкка, иң гади тормыш шартларына риза булып, үзенең тыныч хезмәтеннән туды канәгатьлек тапкан игенчене идеал итә, аның хезмәтен җырлый. Прогрессив белән реакцион тенденцияләрнең бер шәхес аңында, бер шәхес рухи дөньясындагы мондый үрелмәләре ул шәхеснең үз индивидуаль сыйфатларына гына бәйләнмәгән, әлбәттә. Аларның чыганагы — иҗтимагый тормышта

Тормыш үзе шундый үрелмәләр белән чәбәләнеп беткән. Шәхес аңындагы каршылыклар чишелсен өчен, башлап иҗтимагый тормыштагы чәбәләнешләрнең сүтелә башлавы кирәк. Бусы инде халык хәрәкәтләренә бәйләнгән.

XVII гасыр башында Иван Болотников житәкчелегендәге рус крестьяннары сугышы илнең көнбатыш өлешеннән тиз арада көнчыгышка таба җәелде. Идел буенда бу хәрәкәткә, рус крестьяннары белән берлектә, татар, мордва, чуваш һәм башка халыклар да кушылды. Феодаль таркаулык бетеп, үзәкләшкән эре дәүләт барлыкка килү төрле халыкларның хезмәт ияләрен үзара якынаюга китерде, аларның изүчеләргә каршы көрәштә берләшүләренә мөмкинлек тудырды, көрәшнең күрелмәгәнчә колач алуы өчен киң мәйдан ачты. Бу үзәкләшкән дәүләт оешуның уңай тарихи нәтиҗәләреннән берсе иде.

Болотников хәрәкәте тудырган яңалыклардан халыкка ачык хат — өндәмәләр белән мөрәҗәгать итүне әйтергә кирәк. Хәрәкәт башлыгы «Листы» исемле хатлар тараттырды. Руслар ачкан бу яңалыкны соңрак башка халыклар да элеп алдылар. Степан Разин житәкчелегендәге крестьян сугышлары вакытында да «Прелестные письма» исемле хат-өндәмәләр татар һәм башка телләрдә дә языла башлады. Степан Разинга кушылган Хәсән Айбулатов крестьян сугышлары җитәкчесе исеменнән дә, үз исеменнән дә Казан татарларына хатлар язды. Азатлык көрәшенә чакырып, халыкка үз телендә ачык хат белән мөрәҗәгать итү — рус халкыннан күчереп алынган бу яңалык — Пугачев җитәкчелегендәге крестьян сугышлары вакытында татар халкында бик үзләшеп, үз булып әверелде. Татар язма культурасы халыкның азатлык хәрәкәтләренә, алай гына да түгел, илдәге башка халыклар белән бергәлек көрәшенә хезмәт күрсәтә башлады. Укымышлылык, язу-сызу дөньясында яңалык бәбчеге шытып чыкты. Шушы уңай белән бер фактны атап әйтеп китәсе килә. Бу — крестьян сугышларында шул чорның укымышлылары катнашуы мәсьәләсе. Татар әдәбияты тарихына багышланган хезмәтләрдә бу мәсьәлә гадәттә шыпырт аваз белән генә телгә алып үтелә. Соңгы вакытларда архивларда Пугачев хәрәкәтенә бәйләнешле татарча күп кенә документлар ачылды (Пугачевның татарлардан торган гаскәрләренә биргән приказлары, командирларның рапортлары, һәртөрле билет (пропуск) лар, хатлар, татар отрядларының исемлекләре һ. б.). Беренче күз ташлау белән үк бу кәгазьләрнең гаять грамоталы, нәфис каллиграфия белән язылулары игътибарны җәлеп итә. Бу факт крестьян сугышларына Пугачев ягыннан да үз заманасының шактый укымышлы татарлары катнашуын күрсәтә. Арада, әлбәттә, мәдрәсә шәкертләре дә булган. Бер дәлил китерик. Бөгелмә тирәсендәге Акбаш авылына Пугачев гаскәрләре туктала. Хәрби әзерлек бара. Читтәрәк бер төркем кешеләр арасында басып торган Йосыф мулла, бу бунтчыларның кулларында ныклы эш юк, дип сөйләнә. Моны ишетеп торган берәү командирга җиткерә. Котны таратучыны шунда ук кулга алалар: «Мулланы урамга ултыртып, мылтык илән атыплардыр вә нәкылдер: атучы талибелгыйлемләр җөмләсендән багыйлар гаскәренә табгъ улмыш кемсә имеш»[1].

Укымышлы татарларның Пугачевка кушылуы тарихта тикшерелмәгән, бәяләнмәгән, бу кушылуның мотивлары ачылмаган. Әдәбият үсеше ноктасыннан караганда бу факт җитди әһәмияткә ия: пугачевчы укымышлылар баш күтәргән халык белән уртак тойгыларын, кичереш һәм уйларын язу ярдәмендә культура сферасына алып керәләр, татар халкы культурасында яңа элемент туа. Пугачевка, Салават Юлаевка багышланган бәетләрне, җырларны чыгаруда да нәк шул укымышлыларның, мәдрәсә шәкертләренең роле булмый калмагандыр. Ә бу әсәрләр үзләре татар халкының поэзиясендә бөтенләй яңа күренеш. Боларда Ватан итеп тулаем Россия күздә тотыла. «Пугачев патшаны күрсә идең, алларыннан буй бөгеп үтсә идең, аргамак менеп, дан тотып, Җаек яуларында йөрсә идең», диелә бәетләрнең берсендә. Бу юлларны әйтүче лирик герой үз Ватаны Россиянең иркле булуы өчен үзен җаваплы тоя, Пугачевка тирән хөрмәтен белдерә, аның җитәкчелегендә сугышырга әзер торуын раслый. Бу инде иҗтимагый явызлыктан табигать кочагына китеп котылырга омтылу түгел, киресенчә, явызлыкны җәзалау, бетерү теләге. *Россия* дә, Гали Кадир бәк Җалаерлы одасындагыча, патша милке итеп түгел, *халыкның үзе хуҗа булырга тиешле* иле итеп аңлатылган. Бу бәетләр татар поэзиясендә гражданлык

[1] «Мәгариф» журналы. 1927 ел, 12 сан, 91—92 битләр. Сүзлек: нәкыл — мәгълүм. Талибелгыйлем — укучы. Багый — бунтчы. Табгъ — кушылган.

мотивларын үстерү буенча яңа традицияләргә нигез салалар.

Рус патшалары Казан ханлыгы җирләрен үзләштерүнең беренче чорларында татар халкын шәһәрләрдән чыгаралар, зур елга буйларыннан эчкәре кысрыклыйлар. Культура хәрәкәтен үзәкләштерү кыенлаша. Мәдрәсәләрнең Тирсә, Буби, Кышкар, Түнтәр кебек эчкәрге почмакларда барлыкка килүе дә, бәлки, шуңар бәйләнгәндер. Мөлкәтле татарлар исә балаларын, күбесенчә, өйгә чакыртылган мөгаллимнәрдән укыттырган булсалар кирәк. XVIII гасырга килгәч хәл шактый үзгәрә. Петр Беренче Казанда корабльләр төзү буенча адмиралтейство ачтыра, монда мәҗбүри эшкә күп санлы татар крестьяннары да беркетелә. Шәһәрләрдә татар халкы да күренә һәм акрынлап ишәя башлый. Бу хәл үзе татар культурасы һәм әдәбияты үсешенә уңай тәэсир ясый. Бу шартларда крестьян сугышларының татар әдәбияты өчен уңай әһәмияте тагын да ачыграк күренә. Монда дөньяви рухлы шигырь чыгару, кичергән вакыйга турындагы риваятьләрне язып алу, әдәби очерк иҗат итү башлана. Халык кузгалышы азатлык рухын үстереп калдыра. Схоластик мәктәпләрнең укучылары арасында бунтарь элементлар күбәя башлый. Әдәбиятта суфичылык өйрәтмәләренә капма-каршы идеяләр үсә, гуманистик традицияләр яңара башлый. Россияне уртак Ватан итеп тану тойгысы һаман үсә, көчәя бара. 1812 елгы Ватан сугышы уңае белән язылган әсәрләр моның ачык мисалы. Шул шартларда шәкерт шагыйрьләр арасыннан Габделҗаббар Кандалый (1797—1860) килеп чыга. Кайнар дәрт белән зур белемгә омтылган хөр фикерле бу егет схоластик мәдрәсәләрдән куып чыгарыла, ләкин аның исе китми:

**Китәрмен:**
**Җен-иблистән дә битәрмен,**
**Үз белгәнемне итәрмен,**
**Ки әгълә-гаршә ашкындым...**
**Кусагыз да һич уфтанмам,**
**Язуымнан да тукталмам,**
**Котылмассыз барыбер сез,**
**Әле болай гына калмам...**

Кандалый татар язма поэзиясендә аңа кадәр күрелмәгән бөтенләй яңа лирик герой образын тудырды. Аның лирик герое мәхәббәттә бәхеткә ирешүне ходайдан сорамый, бәлки гыйшкы төшкән кешесеннән сорый, кызның җанлы, табигый матурлыгына, сәламәтлегенә соклана. Шагыйрь гарәп һәм фарси телләрен, көнчыгыш классик әдәбияты традицияләрен тирән һәм камил үзләштергән, шулай ук ул русча да белгән. Менә шуңа да аның иҗатында үткәннең иң яхшы традицияләре кабат яңартыла, язма поэзиянең матур традицияләре белән татар халык поэзиясе казанышлары бергә кушыла. Аның иҗаты татар поэзиясенең тарихи үсешендә бөтен бер баскыч дип каралырга хаклы.

Кандалыйдан соң татар поэзиясен яңа биек баскычка күтәргән шагыйребез Тукай булды.

## IV

XVIII гасыр урталарыннан рус культурасы тизлек белән үсәргә керешә һәм XIX гасырда инде ул бөтен дөнья күләмендә танылган бөек кешеләрне бирде. Без К. Маркс белән Ф. Энгельсның югарыда китерелгән өйрәтмәләренә таянып, бу хәлне — рус культурасының 100—150 ел эчендә шулай тиз күтәрелеп китүен — материаль хезмәт белән рухи хезмәт арасындагы бүленешнең югары дәрәҗәгә җитүе белән аңлатырга тиешбез. Әгәр рус культурасының үсүен материаль яктан тәэмин итә торган нигез һаман шул бер үк рус крепостной крестьянының колларча хезмәте белән генә чикләнеп калса, эш, әлбәттә, кыен булыр иде. Рус дворяннарының көне крепостной крестьянга, аның да житештерүчәнлеге бик түбән һәм күтәрелү ихтималы да бик аз булган хезмәтенә генә калганда, бу дворяннар үз эшчәнлекләрендә милли чикләрдән, бәлки, чыга да алмаслар иде. Ләкин тарих барышы мәсьәләне башкача хәл итте: крепостной крестьян хезмәте җитештерүчәнлегенең түбән булуы тудырган кимчелек — бу сыйфат кимчелеге — сан көче белән тутырылды, Россия империягә әверелделәр, аның кул астына күп җирләр, күп халыклар кертелде; рус дворяннары сан ягыннан шул ук күләмдә калса да, алар эксплуатацияли торган халык массалары гаять дәрәҗәдә артты. Рус крепостной крестьяннары һәм буйсындырылган халыкларның хезмәт нәләре бергәләп дворяннар өчен гаять зур байлык өлгерттеләр. Нәтиҗәдә, рус дәүләте ныгыды, армиясе үсте. Халыкара дипломатиядә аның тавышы көчәйде. Рус дворяннары көнбатыш Европаның алга киткән илләрендәге хаким сыйныфлар белән тиңлеккә ирештеләр, алар өчен милли чикләр җимерелде. Рус дворяннарының талантлы вәкилләренә кешелек-

нең алдынгы Европа культурасында йомгакланган һәм баетылган фән һәм сәнгать үсеше нәтиҗәләрен үзләштерергә һәм болар белән рус милли культурасын ашландырырга мөмкинлек ачылды. Рус культурасы югарыга сикереш ясады, аның үсешендә бөтен дөнья культурасы яңа югарылыкларга ирешә. Бу үсеш бер яктан, рус крепостной крестьяннары һәм империягә кертелгән халыклар, икенче яктан, рус дворяннары арасында материаль хезмәт белән рухи хезмәт бүленеше нәтиҗәсендә мөмкин булды. Бер якта коточкыч эксплуатациягә дучар ителгән рус крепостной крестьяннары һәм империянең изелгән халыклары, икенче якта — рус дворяннары. Нәкъ менә шуның өчен дә Россиядә әдәбиятның, сәнгатьнең искиткеч балкулы биеклекләргә күтәрелүе халык массаларының коточкыч бөлгенлеге, наданлыгы һәм кыргыйлыгы шартларында барды. Ләкин үзенең билгеле драматизмына да карамастан, Россиядә шундый юл белән үскән культура илнең революциягә таба хәрәкәтен тизләтүче факторлардан булды: ул өлгерткән интеллектуаль дәрәҗәдән башка илнең алдынгы фикер ияләренә марксизм тәгълиматын үзләштерергә һәм аны яңа гына формалашып җиткән яшь эшче сыйныфының хәрәкәте белән кушарга мөмкин булмас иде. Чынлыкта бу мөмкин булды һәм ленинизм туды.

1861 елгы реформадан соң Россиядә капитализм үсеше тизәйде, ул авылга, шул исәптән татар авылына да, басып керде. Бу хәл татар халкы тормышында да тирән үзгәрешләр китереп чыгарды. Татар авыл буржуазиясе куәт ала башлады, җир җитмәүдән болай да интеккән хезмәт иясе крестьяннар бөлделәр. Алар, эш эзләп, шәһәрләргә, Үзәк Россиядәге, Уралдагы промышленность учакларына агылалар. Крестьян хәрәкәтләре көчәя. Татар буржуазиясе үсә башлый, мәгърифәтчеләр туа, алар халыкны искелек калдыкларыннан арынырга, алдынгы рус культурасы казанышларын үзләштерергә чакыралар. Схоластик мәдрәсәләр урынына җәдит мәктәпләре ачыла, аларда дөньяви фәннәргә урын бирелә. Гасыр ахырында татар яшьләренең иң алдынгы өлеше Казанда һәм башка шәһәрләрдә барлыкка килгән революцион оешмалар белән бәйләнешкә керә. Бөтен Россиядә, шул исәптән Татарстанның үзендә дә, бөтен илне, самодержавие строен тетрәтерлек көчләр өлгерә.

Ниһаять — беренче демократик революция башланды. Гомумроссия күләмендәге капиталистик үсеш юлына баскан татар халкы өчен буржуаз-демократик характердагы бу революциядә катнашу объектив тарихи зарурият иде, һәм ул гомум рус революция ташкынына кереп китте.

Патша Россиясе — халыклар төрмәсе иде. Татар халкы күп гасырлар буе аның тоткыннарыннан берсе булды, татар җәмгыятенең тарихи үсешенә самодержавие күптөрле киртәләр корып килде. Нәтиҗәдә, татар җәмгыяте 1905 елгы революция бусагасына үз эчендәге күптөрле каршылыклар, чишелмәгән мәсьәләләр белән килеп керде: аңарда иң борынгы патриархаль тормыш калдыклары да, урта гасырчылык та, көнкүрештә һәм аңда, гореф-гадәтләрдә ислам дине урнаштырган шәригать тә, милли изү тудырган мескенлек һәм аңа каршы милли азатлык идеяләре дә, капиталистик мөнәсәбәтләр үсеп баруы нәтиҗәсендә туган актив революцион демократик протест тойгысы да, ниһаять, бер өлешенең рус индустриаль пролетариаты сафына кереп, аның белән уртак язмышка ээлгүе сәбәпле социалистик хәрәкәткә тартылуы да күз алдында иде. Көнбатыш Европа халыклары мондый күренешләрне күп гасырлар дәвамында баскыч-баскыч үтеп килгәннәр: урта гасырчылык һәм Яңарыш чоры, мәгърифәтчелек һәм XVIII гасырның бөек буржуаз революциясе, капитализм үсеше һәм эшчеләр сыйныфы, фәнни социализм хәрәкәте — анда боларның һәркайсы үзенә аерым-аерым чорларны биләгән. Россия исә боларның һәммәсен бергә җыеп, хезмәт җитештерүчәнлеге чагыштырмача түбән булса да, барлык милләт хезмәт ияләре өлгерткән материаль нигезгә таянып, кыска тарихи чор дәвамында берьюлы үтә. Күп эпохаларны бергә җыеп үтү ул эпохалар өчен хас каршылыкларны да бергә җыйды. Шуның өчен дә Россия демократик революциягә тарихи хәрәкәтендә гаять катлаулы, гаять каршылыклы процесс белән килеп керде. Әнә шул үзенчәлек Көнбатыш Европада бер-берсеннән йөз еллар аерып торган икә зур бурычны Россиядә бер-бер артлы икесен бер уңайда чишеп ташлау ихтималын китереп чыгарды: башта *демократик* революция, шуннан ук, тукталып тормастан, *социалистик* революциягә күчеп китү.

Шушы шартларда татар әдәбиятында яңа хәрәкәт туды. Мәйданга яңа талантлар чыкты. Арада Тукай аеруча зур роль уйнады.

Татар әдәбиятының бу чордагы күтәрелеше дә К. Маркс ачкан һәм без борынгы әдәбият турында сөйләгәндә инде әйтеп үткән объектив тарихи закон буенча бара: татар халкы капиталистик шартлардагы хезмәт бүленешенә кереп киткән, буржуаз экономик бәйләнешләр ярдәмендә ил күләмендәге һәм дөнья күләмендәге мөнәсәбәтләр хәрәкәтенә эләккән. Бу үзе культура үсешендә милли чикләрне ерып чыгарга шартлар тудыра, революция башлану белән халыкның алдынгы вәкилләре милли йомыклыкны зур гайрәт белән җимереп ташлыйлар да. Бу бигрәк тә әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә аерата ачык күренә. Нәтиҗәдә татар халкының бөтен тарихи гомере буенча хәзерләп, туплап килгән әдәбият һәм сәнгать иҗаты тәҗрибәсенә яңа заманда алга киткән халыкларның — русның һәм Европа халыкларының — иҗат тәҗрибәсен кушарга, боларның һәммәсен татар халкының революция практикасы тудырган яңалыклар белән баетырга мөмкинлек ачыла. Моны, мәсәлән, Тукай шулай эшләде. Ул татар халкыныкын гына түгел, бөтен төрки халыкларның борынгы заманнардан ук язма поэзияләре иҗат итеп килгән хәзинәне, язма поэзия туплаган иҗат тәҗрибәсен үзләштерде. Ләкин бу үзе генә аз, үзен генә алганда эшнең яртысы гына иде. Шагыйрь калган ягын тутырыр өчен рус һәм көнбатыш халыклары поэзиясе тәҗрибәсенә мөрәҗәгать итте. Бу соңгыларны үзләштерер өчен капиталистик чорда халыклар, илләр арасында үсеп киткән экономик һәм культура мөнәсәбәтләре зәмин, туфрак әзерләгән, ә инде башланып киткән революция исә халык массаларын үзара якынайткан, азатлык идеаллары нигезендә аларны *рухи яктан берләштерә* килә иде. Менә шушы тарихи объектив шарт Тукайның һәм аның замандашларының хәлен җиңеләйтте. Бу асылда революциянең кешеләр рухындагы, сәнгать өлкәсендәге хәрәкәте иде.

Бөтен кешелекнең тарихи язмышын хәл итүдә актив катнашкан халык кына бөтен дөнья культурасы хәзинәсенә өлеш булып керерлек кыйммәтләр тудыра. Татар халкы 1905 елгы революциягә актив катнашуы белән бөтен кешелекнең язмышына тирән тәэсир ясаган вакыйганың бер героена әйләнде. Шуңар күрә аның алдынгы вәкилләре, милли йомыклыктан чыгып, дәвернең иң алдынгы идеяләрен үзләштерделәр, шул идеяләрне тормышка ашыру көрәшендә зур гайрәт белән катнаштылар. Әдәбият та шулай булды. Тукай иҗаты белән татар поэзиясе XX гасыр дөнья әдәбияты дәрәҗәсенә күтәрелә алды.

Тукай төрки поэзиянең күп гасырлар дәвамында хәрәкәт итеп килгән һәм җитлеккән сыйфатларын тулысынча үзләштерде: кешенең кичерешен, хисен һәм уйлануларын хикмәт рәвешенә кертү, афоризмга әверелдерү, шул уңайда мәкальгә хас антитеза куллану. Лирикада газәл өлгесен үстерү, шигырьнең ритмик төзелешендә инде камил эшләнеп җиткән өлгеләрдән файдалану — болар барысы да Тукайда төрки поэзиясенең аксакалларыннан мирас итеп алган байлык. Әмма ул боларны күчереп алу белән генә калмый, алга таба үстерә, тагын да камилләштерә, функцияләрен революционлаштыра. Мәсәлән, назыйрә. Бу аның назыйрәне куллануында аерата ачык күренә. Элек иҗаттагы бу алым гел гарәп һәм фарси, гел төрки дөнья белән генә чикләнә иде. Тукай назыйрәне көнчыгыштан көнбатышка — рус һәм Европа поэзиясенә каратып борды. Бу искиткеч зур нәтиҗә бирде, назыйрә аркасында Тукай рус һәм Европа поэзиясенең байлыгын татарга, татардан башка төрки халыкларга күчерүнең иң кыска һәм иң уңышлы юлын ачты. Хәзер кайбер кешеләр Тукайның оригиналь әсәрләрендә Пушкинны яки Лермонтовны хәтерләткән юллар очраса, сәерсенәләр. Монда сәерсенерлек нәрсә юк. Бу назыйрә күренеше. «Бер татар шагыйренең сүзләре»ндә мондый юллар бар:

**Шикләнмибез дошманнарның көченнән без,**
**Бүгенге көн Гали, Рөстәмнәргә тиң без;**
**Шагыйрь гомере хәсрәт, кайгы күрсә күрер,**
**Дулкынланмый тормый ич соң өлкән**
**дингез.**

Лермонтов шигырендәге түбәндәге юллар белән никадәр аваздаш алар!

**Пора, пора насмешкам света,**
**Прогнать спокойствия туман;**
**Что без страданий жизнь поэта?**
**И что без бури океан?**

Бу назыйрә күренеше. Тукай Лермонтовтан алынган юлларга бөтенләй яңа мәгънә салган. Тукай үз героен Фирдәусинең Рөстәменә тиңли. Шушы дүрт юлда мең ел эченә килеп киткән өч заманның өч шагыйре авазы берләшә. Үз иҗатында киң гомумиләштерүләр ясаган Тукай өчен бу бик хас.

Тукай иҗаты — революция көзгесе. Ләкин менә нинди яктан «революция көзгесе»? М. Горькийның «Ана» романы да

революция көзгесе. Бу көзгедән эшчеләр сыйныфының ничек фәнни социализм идеяләрен үзләштерә һәм аны революцион практикада кулланышка кертә баруы, эшчеләр сыйныфының революция авангарды булып үсә килүе чагыла. Бу — революциянең көчен чагылдырган көзге. Әмма Лев Толстой иҗаты да революция көзгесе. Бусы нинди мәгънәдә?

В. И. Ленин болай ди: «Россиядә буржуаз революция башлану заманына миллионнарча крестьяннарда туган идеяләрне һәм настроениеләрне чагылдыручы булуы ягыннан Толстой бөек. Толстой ул — оригиналь, чөнки бөтенләе белән алганда аның карашларының җыелмасы нәкъ шул безнең революциябезнең *крестьян* буржуаз революциясе булу үзенчәлекләрен чагылдыра. Шушы күзлектән, Толстойның карашларындагы каршылыклар — безнең революциябездә крестьяннарның тарихи эшчәнлеге куелган каршылыклы шартларның чын көзгесе булалар» [1].

Бу фикерләргә В. И. Ленин басым ясап кабатлап әйтә: «Толстой идеяләре алар — бездәге крестьян восстаниесенең йомшак якларының һәм кимчелекләренең көзгесе, патриархаль авылның мәлҗегәнлегенең һәм «хуҗалыкчыл мужикның» тупас куркаклыгының чагылышы» [2]. Күренә ки, Толстой иҗаты — революция көзгесе һәм аңарда революциянең йомшак яклары чагыла. Шул ук вакытта Толстой — даһи художник. Самодержавиегә, капитализмга, җәмгыятьтәге ялганга һәм фальшка Толстойда нәфрәт кайный, протест дөрләп тора. Асылда бу патриархаль крестьяннарның Толстой йөрәге аша бәреп чыккан нәфрәте, алар протесты, даһи художник искиткеч җанлы картиналарда «капиталистик эксплуатацияне аяусыз тәнкыйть итә, хөкүмәтнең көчләүләрен, суд һәм дәүләт идарәсе комедиясен фаш итә, байлыкның үсүе һәм цивилизациянең казанышлары белән эшчеләр массасындагы хәерчелекнең, кыргыйлануның һәм михнәт чигүләрнең үсүе арасындагы каршылыкларның бөтен тирәнлеген ачып сала», аңарда — «иң аек реализм, барлык һәм һәртөрле маскаларны ачып ташлау» [3].

Толстойдай гигантның искиткеч каршылыкларын һәм бөеклеген Ленинның даһилыгы безнең каршыда әнә шулай төбенә хәтле ачып сала, аңлатып бирә.

Тукайга килгәндә, аны Толстой белән бермә-бер китереп чагыштыру, әлбәттә, саксызлык булыр. Әмма В. И. Ленинның Толстой иҗатын анализлавы безгә Тукай кебек даһи иҗатын өйрәнер өчен дә методологик нигез бирә.

Без югарыда тарих татар халкын революциягә патриархаль крестьяннар өчен хас үзенчәлекләрдән алып фәнни социализм хәрәкәтенә кадәр аралыкта булган күптөрле иҗтимагый тормыш формалары белән чәбәләнеп беткән хәлдә китереп кертүен әйткән идек. Революция татар халкын күп гасырлык торгынлыктан кузгатып, бөтен дөньяны тетрәтәчәк бөек революцион вакыйгалар эченә, ул вакыйгаларны ясаучы көчләр рәтенә кертеп куйды. Халык торгынлыктан революционлыкка таба борылырга тиеш булды. Борылышның үзе өчен вакыт кыска иде. Шуңа күрә халык искелектән әле генә кузгалып, аңардан бөтенләй үк аерылырга да өлгермәстән яңалыкка кушылды. Бу хәл аның кичерешләр, хис һәм фикер, гомумән рухи халәтендә гаять катлаулы каршылыклы процессларны китереп чыгарды. Әлбәттә, аңардагы бу процесс аның хисен, уен һәм идеалларын гәүдәләндерүче художниклары өчен рухи азык, аларны иҗатка дәртләндергән чыганак булды, сәнгатьтә халык рухи хәленең чынлыгын ачкан әсәрләр тудыруга китерде. Художникләр халыкның бер тамчысы булганга үзләре дә халыкка хас каршылыклардан хали түгел иделәр, бу шулай булмыйча мөмкин дә түгел иде. Без Тукай иҗатында да каршылыклар бар дип таныйбыз икән, бу аның гына каршылыгы түгел, бәлки халыкның үзеннән килгән каршылыклар дип әйтергә тиеш булырбыз. Ул гына да түгел. Бу каршылыклы хәлдә халык кичергән тарихның үзенчәлекле нәтиҗәсе, аның революциягә нинди чәбәләнешләр белән килеп керүе һәм аларның нинди кыенлыклар, нинди сикерешле-чигенешле, ярсулы-сүрелүле хәрәкәтләр белән чишелә баруы гәүдәләнә, халыкның озын тарихи юлны шушындый кыенлык аркасында ничек кыскартып үтүе күренә дияргә мөмкин. В. И. Ленин: «...Толстойның карашларындагы һәм тәгълиматларындагы каршылыклар очраклы күренеш түгел, бәлки XIX йөзнең соңгы 30 елында рус тормышындагы каршылыклы шартларның чагылышы» [1],—дип аңлата. Ту-

[1] Ленин әдәбият турында. Казан, 1960, 13 бит.
[2] Шунда ук, 15 бит.
[3] Шунда ук, 12 бит.

[1] Шунда ук, 13 бит.

кайның каршылыклары да шулай. Ул каршылыкларның эчтәлегендә тарихи чынлык чагыла. Хәзер шагыйрьнең иҗатын ул каршылыклардан арындырып чыксаң, бу аңа кимлек китерер, ул иҗатны коры схемаларга әйләндереп калдырыр иде. Шуңар күрә безнең бурыч шагыйрь иҗатындагы каршылыкларга күз йому түгел, бәлки аларның тарихи сәбәпләрен аңлату. Толстой турында язганда В. И. Ленин: «Тарихи-экономик шартлар массаның революцион көрәше тууының котылгысызлыгын да, аның көрәшкә хәзерлексез булуын да, беренче революция кампаниясенең җиңелүенә бик житди сәбәп булган нәрсәне — Толстойча, явызлыкка каршылык күрсәтмәүне дә аңлатып бирәләр»[1],— ди. Бу — безгә Тукай иҗатын өйрәнүдә житәкче өйрәтмә.

Бездә Тукай турында язганда күбрәк аны фикер иясе булуы ягыннан яктыртырга омтылалар. Хәлбуки, *Тукай барыннан да элек художник.* Аның бөтен мәһабәт көче, мәһабәт таланты художниклыгында ачыла. Фикер иясе тарихи хакыйкатьне фактларга анализ ясау, логик нәтиҗәләр чыгару, дәлилләү белән ачарга омтыла. Художник исә шул ук хакыйкатьне, аның да җанлы буенсынын, төсен-битен кеше күңеленең кичерешләре, тойгысы, хисе белән эзли, ул тарихи хакыйкатьне сәнгать сурәтендә ача, аның иҗаты процессында хис һәм хакыйкать бер-берсен табышып, бергә берләшә. Ә уй? Ә фикер читтә каламы? Юк, читтә калмый: иҗат процессында художникның уе, фикере хисләренә кушылып эшли, хис сукыр тойгы булып түгел, әчтән фикер нуры белән яктыртылган, максатын ачык үзләштергән акыллы хис буларак юл яра, монда «интуицио белән рацио, хис белән фикер гармониясе» хөкем сөрә. Һәрбер шигырь хиснең кузгалуы, аннан ташып китүе һәм ахырда үзенең билгеле бер инкеленә төшеп, үз урынын табып, җыйнакланып калуыннан тора түгелме? Әмма бездә кайберәүләр еш кына әсәрне бөтен бер картина, рухи хәлнең фәлән торыштан фәлән торышка хәрәкәте итеп карамыйча, арадан берәр юлны зерып алалар да, үз хөкемнәрен шуңа коралар. Нәтиҗәдә, сәнгать әсәренә анализ түгел, берәр мәкаләгә анализ ясау кебек нәрсә килеп чыга. Мондый юл белән барганда Тукайның табигать, интим дөнья, әдәп-әхлак, кешенең шәхес буларак сөенечләре, кайгылары, тормыш ыгызыгысы, уен-көлкесе, шаярулары — кыскасы, кеше тормышына тулылык биреп тора торган бик күп нәрсәләре игътибардан төшеп кала. Тукайның замандаш кешесен, аның героен җанлы бөтенлегендә күрү мөмкинлеге кими.

Тукайны художник буларак өйрәнергә, аның барлык нәрсәсенә художниклыгы ягыннан килеп бәя бирергә вакыт җитмәдеме икән?

Без мәсьәләгә татар язма поэзиясенең үсеш баскычлары ноктасыннан күз ташларга теләдек. Беренче чор борынгы Болгар, Алтын Урда, Казан ханлыгы заманнарын күздә тотса, икенче чор татар халкының феодаль таркаулыктан чыгып, үзәкләшкән зур рус дәүләте составына керүеннән башлана. Бу икенче чор беренчесеннән югарырак та, тарихи мәйданы ягыннан киңрәк тә, идеяләр байлыгы, сәнгать матурлыгы ягыннан чагыштыргысыз югары да. Бу чорны Тукай иң югары биеклеккә күтәреп тәгалләде.

Бөек Октябрь революциясе белән поэзиябез үсешендә өченче чор башланды.

---

[1] Шунда ук, 15 бит.

# РЕДАКЦИЯДӘН

Ибраһим Нуруллинның «Шагыйрьне өйрәнү юлында» («Казан утлары» журналы, 1966 ел, 3 сан) исемле мәкаләсе уңае белән кузгалып киткән бәхәсне тәмамлыйбыз.

Дөресен әйтергә кирәк: 7—8 ай дәвам иткән бәхәс, кызганычка каршы, теләгәнчә файдалы, көткәнчә нәтиҗәле булмады. Әдәбиятыбыз тарихында җитәрлек өйрәнелмәгән яисә ялгыш яктыртылган мәсьәләләр, сөекле шагыйребез Габдулла Тукайның тормыш юлын, аның бай иҗат мирасын өйрәнү өлкәсендәге бурычлар турында иҗади сөйләшү нияте белән башланган сүз берьяклырак юнәлеш алды һәм шактый киеренке, шау-шулы атмосферада узды.

Фикер алышу уңае белән басылган аерым мәкаләләрдә фәндә күптән инде ачыкланган, һәркемгә билгеле әйберләр турында урынсыз сүз куерту шактый күп булса да, әдәбият фәненең бүгенге көн өчен үтә мөһим һәм җитди, өйрәнүне һәм фәнни хәл итүне көтеп ятучы зуррак мәсьәләләре игътибардан читтәрәк калды.

Фикер алышуларның, таррак сукмактан китеп, болай берьяклырак узуына билгеле бер дәрәҗәдә «Шагыйрьне өйрәнү юлында» исемле мәкалә үзе дә сәбәпче булды. Габдулла Тукай иҗатын фәнни өйрәнү өлкәсендәге төгәлсезлекләрне ачуга багышланган һәм әдәбият тарихын, шулай ук, аерым язучылар иҗатын яктыртканда, чын мәгънәсендәге фәннилек принципларыннан чыгып эш итәргә чакыру максаты белән язылган ул мәкаләдә, дөрес һәм кирәкле фикерләр күтәрелүе белән бергә, үзе яклаган, үзе раслаган тезисларга каршы килерлек нәтиҗәләр дә, ахыргача аңлатып бетерелмәгән, төрлечә аңларга урын калдырырлык аерым формулировкалар да һәм фәнни яктан бик үк төгәл булмаган аерым җөмләләр дә очрый.

«Бер бәхәс уңае белән» («Казан утлары» журналы, 1966 ел, 9 сан) исемле мәкаләсендә Гали Халит дөрес яза: «Нуруллин мәкаләсендә аеруча кискен булып яңгыраган һәм күпертеп куелган кайбер тезислар башка кирәк һәм әһәмиятлерәк мәсьәләләрне читкәрәк этәрде, күптән билгеле хакыйкатьләрне кабатларга мәҗбүр итте».

Тагын шул кадәресе дә бар. Тукай — күптән инде халкыбыз күңелендә урнашкан гаять кадерле һәм газиз шәхесләрнең берсе. Аның турында язганда, уйлап бетермичәрәк, җайсызрак сүз әйтеп ташладыңмы, кешеләрнең күңелләрен рәнҗетү дә бик мөмкин. Өстәвенә мәкалә журналда ашыгыбрак басылды: аның дөньяга чыгуы юбилей тантанасы якынлашып килгән көннәргә туры килде.

Әмма бәхәс күптән билгеле хакыйкатьләрне тагын бер тапкыр кабатлап чыгудан узмады, бернинди файда бирмәде дип нәтиҗә ясау яки шундый нәтиҗә ясарга тырышу да гаделсезлек булыр иде. Ибраһим Нуруллин кузгаткан бәхәскә турыдан-туры катнашкан иптәшләрдән филология фәннәре докторы М. Гайнуллин («Дөреслекне төгәл яктыртыйк», «Казан утлары» журналы, 1966 ел, 7 сан), философия фәннәре докторы М. Абдрахманов, философия фәннәре кандидаты К. Фасеевлар («Гүзәл хәзинәне яклап», «Социалистик Татарстан» газетасы, 1966 ел, 24 май саны) һәм бигрәк тә тарих фәннәре докторы Р. Нафигов («Габдулла Тукай биографиясен өйрәнүнең кайбер мәсьәләләре», «Казан утлары» журналы, 1966 ел, 8 сан) мәкаләләрендә халык шагыйре иҗатын тагын да тулырак, тагын да тирәнрәк аңларга ярдәм итәрлек моментлар булуын инкарь итү мөмкин түгел.

Шагыйрь иҗатын өйрәнү методологиясе турында барган фикер алышуда бер «Казан утлары» журналы битләрендә генә дә Габдулла Тукайга багышланган дистәләрчә материаллар басылды. Алар арасында шагыйребезнең моңарчы чыккан җыен-

тыкларына кермәгән һәм киң катлау укучыларга билгесез булган шигырьләре, хатлары [1], аның тормыш юлы, иҗаты турында язылган кызыклы яңа истәлекләр, фәнни мәкаләләр бар. Рәис Сафаров («Тукайга — яхшы тылмач», «Казан утлары» журналы, 1966 ел, 7 сан), Шәриф Байчура («Инәсеннән җебенә кадәр», шунда ук) мәкаләләрендә Габдулла Тукайны рус теленә тәрҗемә итүдәге, аның әсәрләрен матбугатта чыгару һәм фәнни бәяләү эшендәге җитди кимчелекләр турында сүз бара. Филология фәннәре кандидаты Р. Ганиеваның «Уртак кояшыбыз» («Казан утлары» журналы, 1966 ел, 4 сан), уйгур әдәбияты белгече, филология фәннәре кандидаты Г. Сәгъдеваккасовның «Уйгур әдәбиятына Габдулла Тукайның тәэсире» («Казан утлары» журналы, 4 сан), Н. Ханзафаровның «Печән базары яхут яңа Кисекбаш» һәм хәмсә, назыйрә традициясе» (шунда ук) исемле мәкаләләрендә бөек шагыйребезнең иҗатына кагылышлы кызыклы фикерләр әйтелә, яңа мәгълүматлар китерелә. Бу җәһәттән филология фәннәре докторы, профессор Хатип Госманның «Татар поэзиясе тарихында Тукайның урыны» («Казан утлары» журналы, 10 сан) һәм күренекле тәнкыйтьче, әдәбият белгече Гали Халитның «Бәхәссез һәм бәхәсле хакыйкатьләр» («Казан утлары» журналы, 4 сан) исемле зур күләмле мәкаләләре аерым игътибарга лаек. Һәр ике мәкаләдә Габдулла Тукай иҗатын фәнни өйрәнү һәм бәяләүгә кагылышлы күп яңа проблемалар кузгатыла, моңарчы күтәрелеп тә тиешенчә яктыртылмаган яки ялгыш яктыртылган мәсьәләләр яңача куела.

Габдулла Тукай — «күптән инде үз заманының тарихи чикләрен үтеп, яңа чорларга күчә барган» үлемсез әдип, безнең белән бергә, безнең арада яшәүче замандашыбыз. «Тукай традицияләре үзләренең барлык тере тамырлары белән безнең аңыбызда, хисебездә, әдәбиятыбызда, сәнгатебездә һәм, ниһаять, тормышыбызда» [2] яшиләр, дәвам һәм тәрәкъкый итәләр. Бәхәс барышында бер мөһим нәрсә ачыкланды: әнә шул иң зур шагыйребезнең иҗатын тиешенчә бәяләргә өлгермәгәнбез, аның гаять бай иҗади мирасын һәм тормышын өйрәнү методологиясендә карашлар бердәмлеге җитенкерәми икән. Габдулла Тукайның тормыш юлын һәм иҗат диалектикасын фәнни өйрәнү, бәяләү юлында башкарасы эшләребез моңарчы без уйлаганнан күп мәртәбәләр зуррак булып чыкты. Мәкаләләрдә инде хәл ителгән, фәнни исбатланган дип санап йөртелгән мәсьәләләр буенча да капма-каршы фикерләр әйтелде. Димәк, уртага куеп сөйләшәсе, бергәләп хәл итәсе фәнни проблемаларыбыз күп, бик күп икән. Һичшиксез, Габдулла Тукай иҗатын бәяләү буенча фәнни бәхәсләр киләчәктә дә булыр. Алар иҗади дуслык шартларында узсыннар, җәмәгатьчелек фикерен әдәбият фәне алдында торган зур, җитди мәсьәләләр тирәсенә тупласыннар иде.

---

[1] Нәкый Исәнбәтнең, Сәгыйть Исәнбаевның, Гали Халитның дүртенче санда урнаштырылган материалларын карагыз.

[2] «Казан утлары» журналы, 9 сан, 133 бит.

# Истәлекләр

*Фатих Бәкер*

## „СӘЙЯР“ ТРУППАСЫ СОСТАВЫНДА

1914 елның октябрь аенда мин Оренбургтан Казанга килдем. Килүемнең максаты: Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсеннән киткәч, башланган русча укуымны Казанда дәвам иттерү иде. Казан университетлы шәһәр булгач, русча укуым өчен күбрәк мөмкинлек булыр, дип уйладым. Өлгергәнлек аттестатына имтихан тапшыру нияте дә юк түгел иде.

Казанга килгәч, учитель яллап, русча укый башладым. Уку белән бергә татар театрына йөрергә бик һәвәсләнеп киттем. «Сәйяр» труппасының һәр спектаклен бик яратып карый идем. Рус театрына да йөри башладым. Беренче мәртәбә рус операсын мин Казанда күрдем. Һәр караган спектакль минем өчен зур мәктәп иде.

«Сәйяр» труппасында минем бар дикъкатемне беренче нәүбәттә Габдулла Кариев үзенә тарта иде. Габдулла Кариевны миңа төрле рольләрдә күрергә туры килде. Ул уйнаган спектакльләрне карап кайткач, икенче көнне дә аның сүзләрен эчемнән тәкрарлап йөри идем. Социаль мохите, заманы, табигате һәм эчке сыйфатлары белән бер-берләренә һич охшамаган рольләрне Г. Кариев индивидуаль характерлы образ итеп сурәтли иде.

Г. Камалның «Банкрот» пьесасында Сиражетдин бай, Н. В. Гогольнең «Ревизор»ында Городничий, Шәриф Камалның «Хажи әфәнде өйләнә» комедиясендә Хажи, Шиллерның «Мәкер һәм мәхәббәт» әсәрендә Миллер — аларның милләтләре, характерлары бер-берсеннән бик нык аерылып торуга карамастан — Г. Кариев уйнавында чын образлар булып күз алдына килеп баса иде.

Г. Кариев башка артистларга зур рольләрдә чыгарга мөмкинлек бирер өчен еш кына үзе кечкенә рольләрдә уйный иде. Кечкенә дигән роль дә аның башкаруында онытылмас тәэсир калдыра иде. Г. Кариев комедияләрдә генә түгел, драмаларда да, трагедияләрдә дә үзен зур сәнгать остасы итеп күрсәтә иде.

Ул чорда «Сәйяр» труппасы составында талантлы артистлар шактый иде. Гөлсем ханым Болгарская, Кәрим Тинчурин, Нури Сакаев, Г. Мангушев, Н. Таждарова, Камал I, Камал II тамашачыларның тирән мәхәббәтен казаналар иде. Соңрак аларга зур талантка ия булган Фатыйма Ильская да өстәлде.

Тора-бара мин дә «Сәйяр» труппасы артистлары түгәрәгенә кереп киттем. Моның сәбәбе Кәрим Тинчуринның мин торган гостиницага (Панаевское подворье) күчеп килүе булды. Г. Кариев белән дә еш кына очраша башладык — ул Кәрим Тинчурин номерына килгәли иде.

Шунда яшь торгач, артистлар белән генә түгел, күп кенә язучылар һәм шагыйрьләр белән дә танышып киттем. Г. Сөнгати, Г. Харис, Каюм Юлдаш, Нәкый Исәнбәт, Фәтхи Бурнашлар белән якыннан таныштым. Шулар тәэсирендә үзем дә язгалый башладым. Жуковскийның «Лесной царь» дигән шигырен татарчага тәрҗемә иттем. Бу тәрҗемә басылып чыкмаса да, берничә мәртәбә сәхнәдә укылды. Соңрак «Сөембикә» журналында «Мөгаллимә», «Карс фаҗигасе» исемле хикәяләрем, «Аң» журналында «Язмыш» дигән нәсерем басылды. «Ялт-йолт» журналында бераз катнашкаладым.

Әлбәттә, аларның художество кыйммәте әллә нәрсә булмагандыр, 16—17 яшьлек бала гына идем ул вакытта. Шулай да, алар басылып чыккач, түбәм түшәмгә тия иде.

1915 елның көзендә мин Казан музыка мәктәбенең драма бүлегенә укырга кердем. Мәктәпкә керер өчен имтихан тотарга туры килде. Имтихан алучы миңа Габдулла Тукай шигырьләреннән берсен ана телемдә

яттан укып бирүемне сорады. Мин: «Баш өсте», дидем дә «Җиктереп пар ат Казанга...» дип укып киттем.

Бу шигырьне бик яхшы ятлап алган һәм берничә мәртәбә сәхнәдә укыган булсам да, дулкынланудан ялгышып киттем. Шигырьнең сүзләре буталды. Мин ялгышканымны сиздермәс өчен белгән шигырьләремнән нәрсә исемә төшсә, шуны тезә башладым. Сәгыйт Рәмиевнең «Сызла күңелем»ен дә кыстырып җибәрдем. Декламацияне артыграк сузып җибәрдем булса кирәк, мине «яхшы» дип туктаттылар. Шулай итеп имтиханнардан үтеп, мәктәпкә кабул ителдем.

Минем театр студиясенә керүемне «Сәйяр» труппасы артистлары, беренче нәүбәттә, Габдулла Кариев бик хуп күрде. Чөнки бу вакытка кадәр әле татарлардан студиядә укучылар юк иде. Г. Кариев һәрвакыт минем ничек укуым турында хәбәрләшеп тора иде.

Ул елны «Сәйяр» труппасы Габдулла Кариевның антрепрезациясенә әверелде һәм барлык артистлар да договор белән эшли башладылар.

Беркөнне Г. Кариев мине үз труппасына штатлы артист сыйфатында керергә тәкъдим итте. Мин, дөрес, аңарчы да спектакльләрдә катнашкаладым, ләкин штатта түгел идем. Бу тәкъдим минем өчен гаять зур шатлык булды. Мин, театрга булган мәхәббәтемне һәм «Сәйяр» труппасына булган хөрмәтемне әйтеп, труппада бушка хезмәт итәргә дә риза икәнлегемне белдердем. Чөнки ул вакытларда өйдән дә яхшы гына ярдәм алып тора идем. Г. Кариев жалованиесез эшләвемә риза булмады. «Сборларда һәммә артистның өлеше бар, синеке дә бар. Мин фәкать бу эшне оештыручы гына», диде.

Труппада әһәмияткә ия булган барлык мәсьәләләр артистлар белән киңәшләшеп хәл ителә иде. Әгәр труппада берәр аңлашылмаучылык булса, моны да Г. Кариев, ялгыз үзе хәл итмәстән, коллективка куя иде.

Г. Кариев, беренче карашка, бик вәкарле, кырыс кешегә охшап күренә иде. Әммә аның белән якыннан танышсаң, бу карашны үзгәртергә туры килә, чөнки чынлыкта ул кешеләргә яхшы мөгамәләле, кече күңелле, олы җанлы кеше иде. Хәтта ул үзенә яманлык кылган кешеләрдән үч алу, аңа яманлык белән кайтару кебек нәрсәләрдән дә ерак тора иде.

Г. Кариев үзе бик югары әхлак сыйфатларына ия булган хәлендә, труппа коллективының да үз-үзләрен тотышына нык игътибар бирә иде. Бервакыт аның Нури Сакаевның шаяртуына бик каты ачуланганы хәтердә.

Вакыйга шулай булды. Беркөнне Галиәсгар Камал, Кәрим Тинчурин, «Йолдыз» һәм «Кояш» газеталары редакцияләреннән тагын берничә кеше ял итеп алу өчен карта уйнап утыра идек, ишек шакыдылар. Номерга өстенә солдат киеме кигән берәү белән Нури Сакаев килеп керде. Кулына скрипка тоткан. Барыбыз белән исәнләште дә бу, миңа мөрәҗәгать итеп:

— Туганкай, мин патшага солдат булып хезмәт итү өчен иртәгә китә торган кеше. Юлга акча кирәк. Менә шул скрипканы сатып ал инде, — дип ялына башлады.

Миңа гәрчә скрипка кирәкмәсә дә (скрипкада уйный белми идем), бик ялынгач, күпмедер акча биреп, скрипкасын алып калдым. Акчаны алып чыгып киттеләр. Күп тә үтмәде, солдат иптәше белән Сакаев аракы һәм закускалар күтәреп килеп керде.

Түгәрәк өстәл әйләнәсенә утырып алдык. Алар алып килгән шешә бушады, закускалар да ашалып бетте. Шуннан соң Сакаев саубуллашып китәргә җыенды. Миңа саткан скрипкасын да урап култыгына кыстырып алды.

— Саттың түгелме соң скрипкаңны? — дигән идем, ул:

— Кичер инде, туганкай, мин солдатка китүче кеше. Турыдан-туры килеп, мине сыйла дисәм, риза булмас идең. Шуның өчен мин бу хәйләне уйлап таптым. Скрипка да үземнеке түгел бит. Мин аны башка берәүдән алып кына торган идем. Хуҗасына кайтарырга кирәк. Сиең өчен рәхмәт, гаепләштән булмасын, — дип, солдат иптәше белән чыгып китте.

Без һәммәбез дә көлешеп калдык. Бу вакыйга икенче көнне Г. Кариевка ишетелгән. Кариев бу алдавы өчен Нури Сакаевны: «Бу труппабыз авторитетына, артистлар исеменә тап төшерә», — дип бик каты орышкан.

Г. Кариевның труппа һәм артистлар абруе өчен нык кайгыртуын шушы кечкенә вакыйга да ачык күрсәтә.

Г. Кариевның труппадагы артистлар белән мөгамәләсе шундый гади, шундый эчкерсез иде ки, аны җитәкче кеше дип әйтүе дә бик кыен иде. Ул һәркемгә дусты итеп, якын кешесе итеп карый иде. Бигрәк тә ул артисткаларыбызны хөрмәтли һәм башкалардан да аларга шундый хөрмәт таләп итә иде. Гөлсем Болгарская, Нәгыймә Таҗдарова, Нәфига Арапова, Фатыйма Гомәрова һәм башкаларның барлык сорауларын да гамәлгә ашырырга тырыша иде.

Ул татар сәхнәсенә яңа чыккан һәр артист һәм артистканы зур өметләр белән каршы ала, аның үсеше өчен бөтен мөмкинлекләрне тудырырга тырыша иде. Арапованың беренче уңышларын күреп бик куанганы хәтердә.

Оренбург шәһәренең татар труппасында Фатыйма Ахмерова исемле яшь, талантлы артистка хакында «Вакыт» газетасыннан рецензияләр укыгач, Г. Кариев аны «Сәйяр» труппасына алдыру турында уйлана башлады. Минем Фатыйма Ахмерова белән яхшы таныш булганлыгымны белгәч, аңа Казанга чакырып хат язуымны сорады. Мин артист Мортазин җитәкчелегендәге труппа адресына Фатыйма Ахмерова исеменә бер хат яздым. Ләкин җавап килмәде. Г. Кариев, ярым шаяртып: «Менә Фатыйма Ахмерова синең хатыңны бөтенләй игътибарсыз калдырды, хәтта җавап бирергә дә кирәксез тапты», — дип еш кына искә төшерә иде. Мин бераздан башка бер кеше аша Фатыйма Ахмероварга тагын хат

яздым. Озак та үтмәде, шул хат буенча Фатыйма Ахмерова Казанга килде. (Труппа адресына язылган беренче хатның Ахмеровага тапшырылмаганлыгы мәгълүм булды.)

Г. Кариев, К. Тинчурин һәм мин, өчәүләп утырып, Ахмерова фамилиясен башка, яңгыравыклырак фамилия белән алмаштыру турысында киңәштек. Нәтиҗәдә «Ильская» дигән фамилиягә тукталдык. Фатыйма Ильская, Казан тамашачылары алдында берничә мәртәбә уйнап, театр сөючеләр алдында дан казангач, Г. Кариев аны монда чакырып килүдәге тырышлыгым өчен кат-кат рәхмәт белдергәне исемдә.

Г. Кариев труппага һәвәскәрләрне дә тарта һәм аларның өметлеләрен үстерергә тырыша иде. Айдаров, Колмәмәт, Искәндәров, Шахбаз һ. б. лар аның турыдан-туры ярдәмендә артист булып җитештеләр. Г. Кариев труппаның режиссеры сыйфатында яшьләрне үстерү буенча армый-талмый эшли иде. Минем сәхнәгә беренче чыккан көннәремдә каушап, тотлыгып кала торган кимчелегем бар иде. Г. Кариев һәм К. Тинчурин бу кимчелегемне бетерүдә миңа зур ярдәм күрсәттеләр.

Тагын бер эпизод хәтердә калган. Фәтхи Бурнаш 1916—1917 нче елларда артистлар өчен рольләрне кулдан күчереп язучы сыйфатында труппада эшләде. Бер пьесада кечкенә генә бер рольне башкару өчен кеше җитми калгач, Г. Кариев Ф. Бурнашны тәкъдим итте. Ул сәхнәдә нинди дер уңай белән бары бер генә сүз әйтергә тиеш иде. Фәтхи репетициядә оялып, каушап шул сүзне дә әйтә алмады. Г. Кариев бу сүзне берничә мәртәбә үзе тәкрарлады һәм нәтиҗәдә Бурнаш та рольне ярыйсы гына башкарып чыкты.

Г. Кариев шул вакытларда Казан университетында укый торган студентлардан бер төркем һәвәскәрләрне труппага тартты. Алар арасында Газҗетдин Сәйфелмөлеков (Гакс) Хансәрвәров, Иделбаев, Мөстәкыймов, Габәши һ. б. лар бар иде. Аларның кайберләре хәтта зур рольләрне дә башкаралар иде. Мәсәлән, Г. Сәйфелмөлеков Островскийның «Урман» пьесасындагы Шмага ролен уңышлы гына башкарды.

Г. Кариев, әйтеп үткәнемчә, артистларның тату яшәүләрен, алар арасында төрле тавыш-гауганың, аңлашылмаучылыкның булмавы өчен нык кайгырта иде. Бер вакыйга исемдә калган. Труппада эшләвемнең беренче елында мин, Г. Кариев кушуы буенча, администраторлык эшләрен алып бара идем. Афиша әзерләү, аны бастырып тарату минем өстемдә иде. Ниндидер сәбәп белән бер афишада Габдулла Камал белән Габдрахман Камалның исемнәре тулы язылмаган, һәр икесе дә «Г. Камал» дип куелган иде. Аерылып торсыннар өчен мин аларның исемнәрен Г. Камал I, Г. Камал II дип төзәтеп яздым.

Афиша чыккач, бу яңалык бераз шау-шу чыгуга сәбәп булды. Бигрәк тә Габдрахман Камал тавышланды: «Безне беренче, икенче дип атап йөртергә әллә без патшамы». — дип ризасызлык белдерде. Бу нәрсәне мин үз башымнан эшләгән булсам да, Г. Кариев, тавышны туктату өчен, гаепне үз өстенә алды. Шулай итеп, Камаллар «I» һәм «II» булып киттеләр.

Шул елларда труппаның үсешендә, аның яңа пьесалар, рус классиклары әсәрләрен уңышлы куя башлавында Г. Кариевның роле зур булды. Труппада көчле режиссер булсын дигән максат белән, ул рус театрыннан Михаленко дигән тәҗрибәле иптәшне чакырды. Михаленко, кулдан килгәнчә, труппа постановкаларын яхшыртырга тырышты. Фатыйма Ильская бенифисына куелган «Трильби» һ. б. күп кенә спектакльләрне сәхнәгә Михаленко куйды.

«Сәйяр» труппасының шул еллардагы үсешендә, татар тормышыннан алып язылган яңа пьесаларны күбрәк куя башлауда Кәрим Тинчурин да зур роль уйнады. Кәрим Тинчурин, Г. Кариевның якын дусты булу белән бергә, көндәлек эшләрендә аңа менә дигән ярдәмче иде. Ул елларда Кәрим Тинчурин үзенең берничә пьесасын язды, аның иҗаты торган саен киңрәк колач ала барды.

Кәрим Тинчурин зур культуралы артист-режиссер гына түгел, бәлки кеше буларак та олы җанлы, киң күңелле иптәш иде. Миңа да аның зур ярдәме тиде.

1916 елда «Язмыш» дигән әсәремнең «Аң» журналында басылып чыгуы турыдан-туры аның ярдәмендә булды.

1916—1917 елларда «Сәйяр» труппасы минем ике пьесамны сәхнәгә куярга әзерләде. Аларның эчтәлеге икесенең дә русчадан алынган булып, беренчесе — «Мәңгелек сәяхәтчеләр», икенчесе — «Үз кайгысын көйләүчеләр» исемле пьесалар иде (соңгысы сәхнәдә «Ялланган кияү» дигән исем белән куелды).

«Мәңгелек сәяхәтчеләр» исемле пьесага патша цензурасы рөхсәт бирмәде. Бу пьеса хәзерге көндә Ленинград театр музеенда саклана.

Г. Кариев сәхнәгә мәгънәсез, фарс пьесаларны куюга һәрвакыт каршы булды. Бервакыт Казан рус театрларында (1916 елда булса кирәк) Арцебашевның «Дошманнар» дигән натуралистик, фарс пьесасы белән кызыксыну башланган иде. Труппада кайберәүләр ул пьесаны татар тамашачыларына да күрсәтүне тәкъдим иттеләр. Мин аны тәрҗемә итәргә алындым. Ләкин Г. Кариев бу түбән әхлакны алга сөргән пьесаны татар сәхнәсенә меңгерүдән баш тартты.

1917 елның май аенда «Сәйяр» труппасы Мөселманнар съездында спектакльләр кую өчен Мәскәүгә китте. Мин, Казан укучы яшьләренең соравы буенча, «Новый клуб» бинасында бер кичә оештырдым. Анда революциягә багышланган «Нурлы таң» исемле бер пәрдәлек мажаралы пьесам куелды. Андагы рольләрне Казанда калган артистлардан Н. Таждарова белән Г. Камал I уйнадылар. Бу кичәгә мин беренче мәртәбә режиссер сыйфатында катнаштым. Бу 18 яшьлек егет өчен әйтеп бетергесез зур шатлык һәм горурлык булды.

Бу кичәне үткәргәннән соң, мин Казаннан киттем.

# Г. Ибраһимовның тууына 80 ел

*И. Рәми*

# Якташым

1912 ел иде шикелле. Якташым Гыйбад Алпаров мине үзенең дачасына чакырды. Ул Казанда учительская школада укый иде. Җәен газета-журналларда язышa, тәрҗемә итә, бераз акча эшли. Баеган күрәсең, дачага чыккан!

— Дачаң кайда?

— Суконный башында, — диде.

Бу сүз колагыма ят тоелмады. Ул елларда Суконный башына дачага чыгу гадәте бар иде. Ул якка, билгеле, хәлле кешеләр чыкмый. Алар Идел буендагы авылларга, урманнарга, табигатьнең матур урыннарына чыгалар. Суконный бистәсе исә, ярлы татар шәкерте уйлап тапкан «дача».

Якшәмбе көнне иртән пароход белән бармакчы булдым. Сәяхәт тә булыр, дидем.

— Батан (ботаник) бакчасына төшмә, шуннан аргы пристаньга төш, каршыларм-ын, — диде Алпар.

Кабан күлендә буксир сыман ике кечкенә пароход йөри. Берсе «Нептун», икенчесенең исемен хәтерләмим. Алар хәзерге Татарстан урамы башындагы Болак күпере янынңан кузгалып китәләр. Ул чагында анда чырайсыз агач күпер иде. Күпере шикелле үк исеме дә ямьсез иде — «Хәерчеләр биржасы». Күпернең ике ягы буйлап төрле калибрдагы хәерчеләр тезелешеп утырганга шулай атала иде ул. Балык базары белән Печән базары арасында булганга, алар аны төшемле урын итеп саныйлар.

Пароход, шуннан кузгалып китеп, Кабанның аргы очына хәтле йөри. Берсе бара, берсе кайта. Очрашканда сәламләшеп үтәләр, сузып кычкырткан тавышларыннан күл өсте яңгырап китә. Туктаганда да, киткәндә дә, йоласына туры китереп, сызгырткан булалар. Чын пароход диярсең, моржасы бар, төтене чыга... Бәйрәм көннәрне юлаучы күп була. Кабанның аргы башындагы дачаларга, ресторанлы «Аркадия» фермасына, казармаларга, Борисково авылына һәм башка шуның кебек урыннарга баручы-кайтучы, минем ише «сәяхәт» һәм истирахәт итүчеләр өзелеп тормый.

Утырдым. Киттем. Күп тә үтмәде, барып та җиттем.

Алпар чыннан да килүемне көтеп торган икән. Каршыларга чыккан. Мин аның башкалардан аерылып торган озын гәүдәсен, башындагы ак эшләпәсен ерактан ук күреп алдым, кулымны болгадым. Ул да, эшләпәсен күтәреп, аны һавада бер-ике тапкыр селкеп алды.

Алпарның пристань дигәне аяк басу белән үк «үләм, җимереләм, ләкин үзем белән бергә сезне дә су төбенә алып китәм», дип калтырап, дерелдәп торган тар басма булып чыкты. Әгәр сакланып төшмәсәң, өс-башыңны салмыйча, су коенып чыгарга мөмкин.

Алпар, мине бик ачык каршылап, үзенең дачасына алып китте.

Суконный бистәсендәге йортларның дачалыгы нәрсәдә соң? Тузан аз, шау-шу ким, авылчарак. Күл буена салынган йортларның бакчалары күлгә барып тоташа. Анда миләш, эт шомырты, зелпе һәм башка шуның ише «затлы» агачлар үсә. Күл буе исә тоташ өянкелек. Өянке башларында

карга оялары. Аларның өзлексез кычкырып, карылдап торуларына бака симфониясе кушыла. Табигать сулышы колагыңны тирбәтә, күңелне рәхәтләндерә.

Дача кешеләренең көне әнә шунда, табигать кочагында үтә. Агач күләгәсендә дача өстәле; остасы аптырап тормаган, дүрт казык каккан да такта белән япкан. Шунда ашап-эчәләр, укыйлар, язалар.

Ае дүрт-биш сум торган «дача» өчен шул комфорт житкән. Сәдакасына күрә савабы.

Галимҗан Ибраһимов та шунда, Алпарның күршесендә тора икән. Шәһит Әхмәдиев, Заһит Нуркин һәм башка шуның кебек танышларым да бу тирәгә урнашканнар.

Алпар мине Галимҗан белән таныштырырга булды:

— Безнең якныкы ул. Бер өяздән, — диде.

Аның Алпар белән дә, минем белән дә бер өяздән икәнен белә идем, тик үзе белән генә таныш түгел идем. Мин аның исемен 1907—1908 елларда Стәрлетамак мәдрәсәсендә укыган чагымда ук ишеткән идем. Ул чакта, бердән, мин аны «Әльислах» газетасында басылган «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» исемле хикәясен укып белгән булсам, икенчедән, 1908 елда «Вакыт» газетасында басылып чыккан бер хәбәр аркылы да белә идем. Бу хәбәр безнең барыбызның да дикъкатен җәлеп иткән һәм Г. Ибраһимов турында күп кенә сүзләргә, имеш-мимешләргә сәбәпче булган иде.

Хәбәр түбәндәгедән гыйбарәт иде:

«Стәрлетамактагы «Каләм» китап ширкәте нәшере «Татар шәкертләре ни өчен ислах сорыйлар?» исемендәге улан бер китап, Казанда Шәрәфләр типографиясендә басылып чыкканнан соң, полиция тарафыннан җыеп алынган. Рисаләнең мөхәррире Өфе «Галия» шәкертләреннән Галимҗан Ибраһимовтыр».

Бу хәбәрне без үз вакытында бик кызыксынып укыган идек. Бүген менә шул хәбәрдә телгә алынган, хәзер танылган язучы булып киткән Г. Ибраһимов белән танышырга мөмкинлек туды.

Алпар таныштырды. Исемемне, кайдан килгәнемне әйткәннән соң:

— «Амур» мөсафирханәсенең конторщигы,— дип өстәп тә куйды. Бусы инде минем эш урыным иде.

Шуннан соң мин Галимҗанны бу «дача»да берничә мәртәбә күрергә, яхшы булганга, бигрәк тә инде танылган язучы булганга, аны читтән торып булса да, күзәтергә туры килгәләде. Аның «дачада» көнне ничек үткәрүе, кыяфәте, төсе-бите әле дә күз алдымда.

Ул көннәрен әрәм итми, иртәнге сәгатьләрдә басылып утыра, эшли. Эшләгән чагында аның бакчасына кереп комачауламыйлар. Ул моны үзе шулай куйган булса кирәк. Эшеннән туктагач, төркем янына үзе килә. «Суконный бистәсендәге дачада язылды» дип куелмаса да, кайбер әсәрләре шунда язылгандыр дип уйлыйм.

Галимҗан монда да гадәттәге кыяфәтендә. Дача кешесе булып киенеп-ясанмаган. Артка кайтарып салган озын чәче, бөркекле күгәрчен таҗына охшап, кабарып тора. Кара сатин күлмәк, билендә ефәк шнур. Сахрача булсын өчен күлмәк изүен чишкән. Чалбар балагы итек кунычында. Кыяфәте Горькийны хәтерләтә.

Ял көннәрендә күрешергә, көнне бергәләп үткәрергә килүчеләр дә шактый җыела икән. Шунда бакчада, күл буенда әңгәмәсе, уены-көлкесе — барысы бергә.

Бу елларда Галимҗан танылган язучы, татар әдәбиятының үзәк фигураларыннан берсе иде инде. Шулай булуга карамастан, ул үзен садә тота, олысы-кечесе белән уртак тел таба, масаймый иде.

Мондагылар үзләрен тулысынча дача кешесе итеп тоялар. Кайберәүләр, модагаияреп, челтәр күлмәк кигән. Ак чалбар, ак эшләпәләр дә күренә. Кояшта кызыналар. Иңбашына сөлге салып, иртәсен-кичен күлгә коенырга төшәләр. Һәр рәхәтнең бер михнәте була дигәндәй, күл читенә бака тизәге бик җыелучан. Ләкин аның әмәлен тапканнар. Коеныр алдыннан чыбык алып, суны тегеләй-болай ишкәлиләр дә, бака тизәге тарала, юл ачыла.

Иртәсен язу-сызуга утырмаганы балык тота. Әбер-чебер каба, бер карышлысы да эләккәли. Ә эләкмәгәне, кармактан ычкынганы гел эре була. Шулай да кайберләре шулпалык тоталар. Әмәлен китерергә тырышып, күл буенда пешерәләр, дусларын, иптәшләрен чакыралар.

Галимҗан балык тоту белән мавыкмаса да, шулпасын кире какмый. Күл буендагы таганда шулпа пешерү үзе бер кызык, аннары беләсезме, вак балыкның шулпасы, тозы, борычы, лавр яфрагы үткенрәк булса, гаҗәп тәмле була, телеңне йотарсың! Ипи үткәрергә шәп булды дип, мактый-мактый ашыйлар.

Кайчакларда күмәк уеннар була. Шундыйларның берсе — домино. Бирелеп, ярышып уйныйлар. Галимҗан чәмле уенчы, отылырга яратмый, отса, шатлана, кәефе килә.

Шәһит Әхмәдиев, малайлар шикелле, хәрәмләшеп уйный. Заһит Нуркин педант кеше, кагыйдәсенә туры китереп уйнаганны ярата. Алпар, гадел уйнап, сабыр гына отыла да уеннан чыга. Урын бушаганны көтеп торучы һәвәскәрләр житәрлек.

Әйтегезче, бу «дача» курорттан кай төше белән ким? Дингез житми, һавасы ул түгел, сәрви, магнолий агачлары юк, диярсез. Аның каравы, «ботагы дөнья каплаган, яфрагын да какмаган» өянкеләре бар, өянке саен дистәләрчә каргалары...

Боларны хәзер, бүгенге күзлектән карап, бераз чеметеп язган булам. Әмма ул чагында: «Их, шулар шикелле дачада торсаң иде»,— дип кызыгып кайта идем.

* * *

Әдип Казанда һәм башка урыннарда торган чагында, җәен, кыска гына вакытка булса да, Уфага кайта иде. Революциядән элек тә, соңыннан да шулай дәвам итте.

— Әни карчыкны күрим дип кайттым әле, — ди торган иде ул.

Әнисе исән чакта ул үзенең уллык бурычын мөмкин чаклы төгәл үтәп килде шикелле. Кайтмый калган елы сирәк булгандыр.

Уфада озак тукталмый. Якын күргән кешеләре белән күрешкәләгәч, авылына кайту хәстәрен күрә.

Миңа аны, Уфада ике-өч тапкыр авылына озатышырга туры килде. Гомумиләштереп әйткәндә, озатышу болай була торган иде.

Беренче эш — ямщик эзләү, безнең яктагыча әйткәндә, ямчы эзләү. Галимҗанның эзләгән ямчысы пар атлы, җиңел тарантаслы, кыңгыраулы булсын һәм арзан алсын.

Уфадан Бөрегә, Минзәлә, Бәләбәй, Златоуст өязләренә барасың булса, ул якка су яки тимер юлы бар. Стәрлетамак ягына андый транспорт юк. Ул якка бары ямчылар гына йөри.

Ямчы агайларны двор өендә яки гостинный базарында очратасың. Аларны килешкилбәтләреннән танып була. Ак киез эшләпәле, бишмәт яки җиңсез камзул өстеннән күкрәкчәле киндер алъяпкыч япкан, билбавына чыбыркы кыстырган чабаталы агайны очратсаң, шул безнең якның ямчысы инде. Төп билгесе әнә шул — билендәге чыбыркы. Чәчү бетеп, арыш урагы кергәнче ям чабалар.

Уфадан Бозаязга олы юл (Уфа — Стәрле — Оренбург юлы) белән илле чакрым, аннан Солтанморатка ун чакрым чамасы кыр юлы белән борылып керәсең. Шул арага элекке бәя белән чакрымына 8—10 тиен сорыйлар. Кыңгыраулы булса, шуннан ким алмыйлар.

Бервакыт мин шулай, Галимҗанның үтенүе буенча, аңа пар атлы, җиңел тарантаслы ямчы эзләдем. Күңелемә ошаганнары янына туктап, атларын, тарантасларын, кыңгырауларын караштыргаладым, бәяләрен дә белештем. Тик шуннан соң гына Галимҗанга кайтып әйттем.

Ямчымның атлары дворда иде. Әдип минем белән барды, атларны бик җентекләп карады, ялларын аралаштырып, муеннарын сөйде. Уртача көрлектәге атлар иде. Тарантас көпчәкләрен сынап, аягы белән типкәләде, читәнен селкетеп карады, ягъни Солтанморатка кайтып җиткәнче ишелеп төшәрлек түгелме? Камыт-дуга, кыңгыравына да күз салды.

— Калакул чырлы, Кырмыскалы эше,— диде ямчы, мактана төшеп.

Кырмыскалы булгач, аңлашылды инде,— яхшы кыңгырау. Уфа ягында Кырмыскалы белән Сәмән авыллары дуга кыңгыравы, терлек муенына аса торган кечкенә җиз кыңгырау кою эше белән атаклы иде. Уфа яны Кырмыскалысы эше булса, аеруча мактаулы иде.

Ямчы, хакны күтәрергә теләп, атларын, сбруен, тарантасын мактады һәм, бик тантаналы итеп, шуның белән безне кызыктырырга теләп:

— Тарантас читәне артына палас җәярмен. Бик шәп палас. Бохар паласы, — диде.

Паласын да карарга теләгән идек. Анысы двор өендә булып чыкты. Кереп тормадык, ышандык. Тик иртәгесен генә паласын күрергә насыйп булды. Палас бик начарлардан булмаса да, Бохар паласы түгел, хәтта аның янында кич тә кунмаган иде.

Таң белән юлга чыгарга булдылар. Пушкин урамындагы «Сарай» номерына килергә кушты әдип. Тарантас төбенә печән салырга онытма, диде. Агайның кайсы якныкы икәнен сорашкач, «җиңел кулдан» дип, задаткасын да бирде. Авылда үскәнгә ат тирәсен, эшнең рәтен-тәртибен белә иде Галимҗан.

«Сарай»га кайтышлый гостинный базарга сугылдык. Күчтәнәчкә дип аны-моны алды. Әллә ни кыйбатлылардан түгел, бәлки авыл зәвыкына туры килә торган арзан-

лы тәмле-төмлеләр үлчәтте. Авылларны үткәндә кыр капкасын ачкан бала-чагага ташлар өчен камыр канфит, клиндер алырга да онытмады.

Магазинга кереп, бер кара кәләпүш алдык. Бусы, табын янында яланбаш утырып, әни карчыкның өендәге «фәрештәләрен» качырмас өчен, ягъни карчыкның күңелен рәнҗетмәс өчен кирәкле атрибут иде. Билгеле, ул кәләпүш кире кайтмый, авылда кала.

Юл кирәк-ярагы булды, бары тик китәсе калды.

Туган якларга китә торган Уфа—Стәрле юлын күрәсем килдеме, белмим, Агыйдел күперен чыкканчы озата бармакчы булдым һәм, иртән килергә булып, кайтып киттем.

Иртә белән мин килгәндә, ямчы агайның атлары «Сарай» мосафирханәсе алдында тора иде инде. Чәй эчеп-нитеп тормадылар. Гадәттәгечә:

— Юл кешесенең юлда булганы яхшы,— дип, агай да ашыктырды, иртәнге салкында юл аласы килде.

Көтү чыккан чакта кузгалып киттек. Болай да тын каланың урамнары иртә белән бөтенләй хәрәкәтсез иде. Чуер таш түшәлгән урам тарантасны селкетә, чайкалдыра. Зарар юк, тарантас төбенә күп итеп яшел печән салынган, әллә ни каты түгел. Аннан хуш ис аңкып тора.

Агыйдел күперен чыккач, ямчы атларны туктатты, камыт-эшлияләрне рәтләде, калакулны чиште (кала эчендә калакул чишеп йөрү пожарникларга гына рөхсәт ителә).

— Ярый, аллага тапшырдык, — дип, атларын әйдәп җибәрде.

Башта көйләнеп китә алмыйча, өзек-өзек тавыш биреп барган кыңгыраулар, ат йөрешенә тигезләнеп алгач, ритмлы рәвештә теллин-беллин, теллин-беллин итеп, моң гына чыңлый башладылар.

Бу хозур минем өчен озакка сузылмады. Чегән даласын үтеп, олы юлга кергәч, төштем, хәерле юл теләп калдым. Юлчылар әле генә башак атып утырган арыш басуы диңгезе эченә кереп киттеләр...

* * *

Февраль революциясеннән соң Уфада татарча революцион газета чыгару хәстәренә керешүчеләрнең беренчесе Галимҗан булды. Эшлим дигән эшенә кыю, батыр һәм үз-үзенә ышанып керешә торган гадәте бар иде аның. Тиенсез-тәңкәсез килеш «Ирек» исемле газета чыгарырга кереште. Беренче саны мартта чыкты.

Электән чыгып килгән «Вакыт», «Йолдыз», «Тормыш»лар һәм февраль революциясеннән соң борынлаган башка милли-буржуаз газеталар һәммәсе бертавыштан: «Мөселманнар бер җан, бер тән. Милләт бер, бай белән ярлыга аерылу юк», — дип кычкырганда, «Ирек» газетасы: «Бай белән ярлы, хуҗа белән эшче, алпавыт белән җирсез яки аз җирле крестьяннарның теләк вә мәнфәгатьләре бер булмавы хак икәнен тормыш үзе үк күрсәтә һәм күрсәтәчәк», — дип язып чыкты.

Каләме үткен, телгә бай, акчага ярлы бу газета революциягә теләктәш булган һәм сыйнфый аерымлыкны аңлый белгән, яшь журналистларның каләм көченә таянып барды. Язышучыларга гонорар түләү түгел, редакциядә эшләүчеләргә дә хезмәт хакы бирә алмый иде ул. Кайдан акча килсен аңа? «Җир крестьянга», «Завод-фабрик эшчегә» дип өндәгәне өчен алпавытлар белән сәүдәгәрләр бирсенме? Бәлки, подпискадан җыелган санаулы акчалары кәгазь алырга (әйбер төрә торган сары кәгазь иде) һәм басмаханәгә түләргә дә җитмәгәндер. Шулай да газета чыкты, таралды, укучыларын тапты.

Газетаның редакциясе Пушкин урамында, әлеге «Сарай» мосафирханәсенең бер бүлмәсендә иде. Арзанлы мосафирханә булуына карамастан, урыны каланың үзәгендә, җиде юл чатында.

Бәләкәй һәм бик гади бер бүлмә иде ул. Ике өстәл, биш-алты урындык. Барлык җиһазы шул. Бер өстәлдә редактор Г. Ибраһимов, икенчесендә секретарь Фатих Сәйфи-Казанлы утыра. Редакциянең штаты да шул. Басмаханәгә түләр акчасы булса, газета атнасына өч сан чыга, булмаса, ике белән дә кала.

Галимҗан шул тар бүлмәдә дә киң колач белән эшләде. Оештыру сәләте бик көчле иде аның. Һәркемнең көченә, сәләтенә, белеменә күрә эшен тапшыра иде ул.

Бай-байгура койрыгына тагылмаган яшьләрнең каладагысы, авылдан килгәне «Ирек» редакциясе белән бәйләнештә иделәр. Монда язучы-журналистлар гына түгел, солдатлар, крестьяннар, мөгаллимнәр, шәкертләр, приказчиклар һәм артистлар да очрый. Көчләреннән килгәнчә язып, материал алып килләләр, яза алмасалар, телдән генә сөйлиләр. Бу кешеләр — газетаның хәбәрчеләре һәм «штаты» иде.

Бу редакция ул чагындагы Уфа язучылары галереясе иде. Матбугатта исемнәре билгеле булган язучыларның барысын да күреп була иде анда.

Монда инде төп фигура Галимҗан. Иртәнге сәгатьләрдә шунда була. Аннан җәмәгать эше белән башка урыннарга китә. Татар хәятында ул катнашмаган мәсьәлә яисә берәр зур җыелыш булмагандыр.

Аның чәче һаман шулай озын, артка кайтарып таралган. Тик кием-салымында гына үзгәреш бар. Өстендә костюм, кайтарма якалы, галстуклы күлмәк, аягында ботинка яисә күн итек. Аның күпләргә таныш күн итеге Казан, Киев, Кавказда булган, Оренбургны да күргән, ничәмә кат Солтанморатка кайткан. Галимҗан спай киенүчеләрдән түгел. Кием-салым белән әллә ни мавыкмый. Итеге рәтле булса, эшләпәсе бик шәпләрдән түгел яки шуның киресе. Килешле булса, булмаса да, әйберне тузганчы сөйри. Ишле семьяда тәрбияләнүе, исрафны аңлавы сизелеп тора.

Ул гаять сизгер, нечкә күзәтүче. Табигать аңардан хәйләкәрлекне дә кызганмаган. Шуннан маневр ясау осталыгы килеп туа. Әле генә танышкан кешесенең берничә сүзеннән үк, аның рухи хәлен, тел төбен чамалап ала. Шуннан чыгып, ул һәркемне үз шүрлегенә утыртып, мөнәсәбәтен билгели. Кирәк булса, йомшак җәеп, каты утырта да белә. Уйдаш-көрәштәш булырдайны үз ягына тарта, җитәкли. Характеры белән күпкырлы кеше иде ул.

Фатих Сәйфи-Казанлы өлгер эшли, тиз яза. Эш арасында бәхәсләшергә дә вакыт таба. Маневр ясап, кинаялап тормый, турысын әйтеп сала. Шунысы кызык, табигатьләре төрлечә булган бу икәү гаҗәп тату яшиләр иде.

Фатих гаҗәп хәрәкәтчән кеше. «Бер генә минут тик тормый бу Фатих, орчыктай бөтерелә, астындагы утыргычка ходай үзе түземлек бирсен», — ди торган идек без.

Йөреше-торышы, кием-салымы белән гади, садә булган Мәҗит Гафури да редакциядә еш кына күренә. Аз сөйләп, күбрәк тыңлый. Бу төркемдә яше белән иң өлкәне ул иде.

Мөмкинлеге ирек биргән чаклы килешле, пөхтә киенгәне шагыйрь Сәгыйть Рәмиев булыр. Ул песи кебек сак кына, йомшак кына басып керә. Ачык чырайлы, көләч табигатьле, яхшы әңгәмәче. Кешеләр белән культуралы мөгамәлә аңарда гадәт булып әверелгән, ясалма булып чыкмый, табигый үзенчәлекләреннән берсе.

Тыйнаклык һәм тынлык белән мөмтаз Сәйфи Кудаш та редакциягә килеп-китеп йөри. Йөзе-күзе белән шым гына көлә-көлә тәмләп, җөпләп сөйли — бирелеп тыңлыйсың. Аның тагын бер әйбәт сыйфаты бар: берәрсенең авызыннан үткен сүз яисә афоризм чыкса, кайтарып сорый да хәтеренә беркетеп куя. Ил теленнән сүз җыя.

Фырт табигатьле шагыйрь Сәгыйт Сүнчәләй берәүгә дә башлап эндәшмәс. Манара югарылыгыннан карый да, сүзен мыскаллап кына чыгара. Кайбер сүзләрен күп нокталар аша аңларга куша. Көлми, елмаймый.

Җәй урталарында бугай, каяндыр кайтып, редакциядә шаян табигатьле, тапкыр сүзле, инәсе белән кинәсе тел очында булган бер егет күренә башлады. Ул рәхәт итеп, йогышлы итеп көлә, көлдерә, ә кайчакны үзе бер дә көлми, шулай да көлдерә. «Кем?» дисез? — Шәехзадә Бабич.

Тагын... матур каләме белән ялтырап күренеп киткән Әхнәф Таңгатар бар иде. Язышты, йөрде. Йөри торгач, «мин битараф булам» дигән уйга төште. Галимҗан аңа:

— Ахмак сүз сөйлисең, Әхнәф. Каты сыйнфый көрәш барган чакта ике генә юл бар, я революция сафында, я каршы якта буласың, уртасы юк, — дигән кисәтү ясады.

Егетебез, «битараф газета чыгарам», дигән уй белән Бәләбәй ягына китте. Шул уй белән земство тирәсендә буталып йөрде. Аклар кергәч, ашар ризыгы булган, күрәсең, алар камчысының тәмен татыды. Бу аңа битарафлыкның юклыгын аңлау өчен яхшы сабак булды. Ул елларда я ялгышып, я арт уй белән «битараф» булучылар аз түгел иде.

* * *

Милләт мәҗлесе. 1917 елның 20 ноябрендә Уфада ачылды бу мәҗлес. Татар халкы яшәгән урыннардан — мәхәллә һәм милли оешмалардан сайланып килгән вәкилләр җыены. Килгән вәкилләр арасында эшче-крестьяннардан берәү дә юк. Солдатлар бернichә генә. Күпчелек буржуаз милләтче интеллигентлар, үзләрен «төрекчеләр» дип атап йөрүчеләр. Бу төркемнең башында Гаяз Исхакый торды. Бу агымга каршы торган «тупракчылар» (яки федералистлар) төркеме Галимҗан Ибраһимов җитәкчелегендә барды. Болар азчылык иде.

Милләтчеләр уйлаганча мәҗлес «милләт бер бөтен, байга, ярлыга аерылу юк» дигән

лозунг астында барырга тиеш һәм мәҗлесне ачкан Садрый Максудиның кереш сүзе шуңа нигезләнгән иде. Мәҗлес ачылыр алдыннан коръән укыган мөфти Г. Баруди дә, мөселманнарны берлеккә өндәп, фатиха бирде.

Шул рәвештә мәҗлес тәмам милли һәм дини юнәлеш алып барган чакта яшьләр милли симфонияне боздылар. Тупракчылар төркеме исеменнән сүз алган Шәһит Әхмәдиев:

— Мәҗлес исеменнән Советлар хакимиятен тану турында Халык Комиссарлары Советы рәисенә — В. И. Ленинга котлау телеграммасы җибәрергә тәкъдим итәм, — диде.

Бу тәкъдим милләтчеләр өчен аяз көнне яшен суккандай булды. Аптырашып калдылар. Мәҗлес тынды. Председатель бер утырды, бер торды. Мәҗлесне ачу тантанасы пар-бу булып очты.

Шунда Г. Ибраһимов, мәҗлеснең тынлыгын бозып:

— Мондый телеграмма мәҗлеснең сәяси йөзен ачыклау өчен дә кирәк, — дип Шәһит Әхмәдиев тәкъдимен яклады.

Бер мәлгә исен-акылын югалтып утырган Г. Исхакый кинәт урыныннан сикереп торып, рөхсәт сорап-нитеп тормыйча, трибунага ташланды. Төкерекләрен чәчеп, куллары бутый-бутый, бу тәкъдимгә каршы сөйли башлады. Имеш, гомере «ике-өч көнлек» большевик хөкүмәтенә котлау җибәрү тарихи хата булачак. Моны күреп, аның иярченнәренә дә җан керде, алар да шауларга, гөрләргә керештеләр.

Милләтчеләр көтмәгән һәм көн тәртибе белән билгеләнмәгән бу мәсьәлә шактый озакка сузылды. Мәҗлес сикәлтәле юлга кереп китте. Күп тартыштан соң тәкъдимне тавышка куйдылар. Шуның белән мәҗлеснең политик йөзе ачыкланды. Тәкъдимне яклап — 17, каршы — 27 тавыш бирелде. 17 кеше, тавышка катнашмыйча, куак артына посты.

Көн тәртибе белән күрелмәгән тагын бер мәсьәлә күтәрелде, тагын көрәш башланды. Г. Ибраһимов:

— Монда «төрек-татар халкы», «төрек-татар теле» дигән атама кулланып маташучылар күренә. Һәр әйберне үз исеме белән атап йөртергә кирәк: төрек телеме, әллә татар телеме? дигән мәсьәлә куйды һәм моңа ачыклык кертүне таләп итте.

Урыннан берәү, Г. Ибраһимовның фикерен яклап:

— Гөнаһ шомлыгына каршы, халкыбызның әле булса исеме юк икән, — дигән реплика ташлады. — Әллә, азан әйтеп, исем кушыйкмы?!

Татар матбугатында күптән күтәрелгән, 1911—13 елларда кызу дискуссия төсенә кергән бу мәсьәлә тагын кызып китте. Буржуаз милләтчеләр тагын «төрек-татар байрагын» күтәреп чыктылар.

Шул рәвешчә көннәр үтте, мәҗлес үзенең мәсьәләсе булган милли мөхтәрият (автономия) һәм шуның нигез канунын раслау эшенә килеп җитә алмый йөдәде.

Милли мөхтәрияткә каршы булган тупракчылар, тупраклы автономия, аннан ары китеп, советлар платформасында автономияле республиканы якладылар. Милләтчеләр күпчелек булу сәбәпле үз проектларын үткәрделәр.

Мәҗлестә һәр мәсьәлә буенча фикер бәрелешендә күзгә ык ташланган ике кеше булды. Берсе — милләтчеләрнең удаманы Гаяз Исхакый иде. Ул, танылган язучы булуына карамастан, гаять логикасыз, алама оратор, тупас бәхәсче, интриган кеше иде. Хәтта үз иярченнәре дә аны, мыскыллап, «тәмизсез» диләр, ягъни фикердә, бәхәстә, сүздә шапшак дигән сүз.

Һәр мәсьәлә тикшерелгәндә аңа каршы речь белән чыгучы Г. Ибраһимов булды. Ул сүзгә оста, дәлилле, логикалы һәм саф татарча сөйли. Әйтәсе фикерен калыпка салып, ачык итеп әйтеп бирә, җеп очын югалтмый. Әдәби мисалларга бай. Тупас сүз кулланмыйча, йомшак җәеп, каты утырта белә иде. Тик аның бер кимчелеге бар: ораторлык интонациясе җитеп бетми. Ул елларда, ягъни каты сыйнфый көрәш елларында, ораторлардан дөрес политикалы, логикалы речь белән бергә ялкынлы пафос та таләп ителә иде. Галимҗан исә, ялкынлы пафос белән түгел, үзенең сабыр, тыныч һәм кешеләрнең күңелләренә керә, аларны ышандыра ала торган рече белән җиңә иде.

Шул ук елның декабрь азагында Галимҗан, Оренбургта җыелган башкорт корылтаена барып, милләтче Зәки Вәлиди белән дә кыешып кайтты. Уфага кайткач, Милләт мәҗлесенең ябылганын көтмәде, утырышларына да йөрмәде. 1918 ел январь башында Петроградка учредительный собраниегә китте. Шул китүдән Уфага кайтмады, башта Петроградта, аннары Мәскәүдә Милләтләр комиссариаты янында төзелгән Үзәк мөселман комиссариатында эшләде.

* * *

1918 елның уртасы иде. Мин Уфа мөселман комиссариатының эше белән Мәскәүгә Үзәк мөселман комиссариатына бардым. Йомышымны үтәдем. Әмма Уфаны акгвардеецлар алганлыктан, вакытлыча бүленеп калдым. Шулай итеп, мин дә Мәскәүдәге иптәшләр белән бергә яши башладым.

Үзәк мөселман комиссариаты Мәскәү елгасы буенда миллионер Солодовников йортына урнашкан иде. Сүз юк, йорт бик яхшы, сарай шикелле. Флигелендә сотрудниклар өчен гомуми торак. Аерым бүлмәләрнең берсендә Г. Ибраһимов тора. Минем иште эш белән килгәннәр дә шул флигельдә туктала икән. Безнең таләпләр зурдан түгел. Аркылысы буена тигез итеп эшләнгән бер зур агач кроватьта дүртәүләшеп, шинельләребезне ябынып, тезелеп ятабыз. Баш астында китаплар, газеталар. «Иркен» дә, «йомшак» та.

Монда торучылар иртән торып эшкә киталәр дә, кич белән арып-талып кайтып, урыннарына егылалар. Ашау-эчү белән шөгыльләнгән кеше күренми. Чөнки көнлек паек булган ипи эшкә баргач, көндез бирелә. Ул ипине кичке яки иртәнге чәйгә дип сакларга түземлек житми. Чәешикәре булмагач, кайнар суның ни тәме бар. Шулай булгач, кайталар да яталар, торалар да эшкә китәләр.

Мәскәүдә азык-төлек мәсьәләсе начарланганнан начарлана бара. Көнчыгыш өлкәләре аклар кулында булганлыктан, ул яктан икмәк эшелоннары бөтенләй килми. Хезмәт ияләренә бирелә торган икмәк паегы болай да бик кечкенә. Кайбер көннәрне хәтта ул да бирелми. Базардан сатып алу турында уйларга да мөмкин түгел. Юк. Булса да яшереп саталар. Һәм чамасыз кыйммәт.

Г. Ибраһимов минем ашау-эчү мәсьәләсен рәтләгәндәй итте. Үзләре йөри торган «Метрополь» ашханәсенә беркетте. Монда хөкүмәтнең җаваплы эшчеләре беркетелгән. Көненә бер тапкыр кайнар аш, ипи бирәләр.

Зур өметләр, капканны көтми торган аппетитлар белән бардым. Ашханә залы гаҗәп зур, матур. Ап-ак ашъяулык җәелгән өстәлләр, кызыл хәтфәле урындыклар. Кеше саен кашыгы, чәнечкесе, пычагы куелган. Затлы, кыйммәтле приборлар. Аш ташучылар да җитез йөриләр. Башта борын башына чирек кадак (100 грамм) ипи өләштеләр. Саламлы-кибәкле ипи. Күзне кыздырып, карынны үртәп тормасын өчен аны кәгазьгә төреп кесәгә салабыз. Кичке чәйгә булыр, дибез. Якшәмбе көнне көчәйтелгән паек алабыз. Чирек кадак ипи өстенә яртышар клиндер яки әчмуха кадак (50 грамм) борчак бирәләр.

Беренчегә — тозлы балык шулпасы. Ите кайдадыр, әмма кылчыгы житәрлек. Шулай да кайнар аш. Икенчегә — борчак буткасы яки бәрәңге измәсе. Ач песи берике кабуда рәхәтләнеп йотып җибәрерлек. Җитмәсә, еш кына майсыз була, алай да тәмле. Күбрәк аударсалар, зарар итмәс иде, дибез. Өченчегә — әлеге пычак белән чәнечкe. Аны куялар да алалар, бер эшсез урын били, буялырга да өлгерми. Ләкин күңелләребез күтәренке, ак бандаларны җиңәчәгебезгә һәм бөтен дөньяда пролетариат революциясе булачагына ышанабыз.

Көзгә табан, көннәрдән бер көнне Галимҗан:

— Егетләр, туйганчы ипи ашап, тәмләп бер чәй эчәсе иде, — диде.

Бу тәкъдим барыбызга да ошады.

Мәскәү кешеләре, тирә-як авылларга барып, кием-салымга ипи алып кайталар, имеш. Без дә шул чараны эшләп карыйсы иттек. Ләкин бездә кием-салым юк. Без барлык акчабызны бергә җыйдык.

Штатта булмагач, эштән бушрак кеше мин. «Бәхет эзләү» эше миңа тапшырылды. Башым да кузем — шинелем дә үзем. Вокзалга киттем. Поезд 50—60 чакрым киткәч, ипи эзләүче кешеләр станцияләрдә төшә башладылар. Берсендә мин дә төштем. Авыл ерак түгел. Күрер күзгә хәлле бер өйне сайлап кердем. Юлым уңды. Хуҗа хатын акчага ике бөтен ипи сатарга риза булды. Бик кыйбат сораса да, акчамны кызганмадым, алдым.

— Болай, күрше-күләнгә күрсәтеп алып чыгарга ярамый, — диде хатын.

Сүзен тыңладым, берәүгә дә күрсәтми алып чыгып киттем.

Кызарып пешкән, чите кетердәп торган ике бөтен арыш ипие аркамдагы капчыкта ята. Әллә үз җылысы, әллә күңелемдәге җылы белән җанымны рәхәтләндереп тора. Яшермим, шайтан котырта: «Аша, читен генә булса да, сындырып кабып кара», — ди. Ләкин мин иптәшләр өлешенә керергә теләмим. Бары билемдәге каешны кысыбрак бәйләү белән генә чикләнәм.

Юл уңгач, эш гел уңайга барып тора. Поездны да озак көтмәдем. Вагонга да урнаштым. Әңгер-меңгер төшәр алдыннан кайтып та җиттем.

Иптәшләр эштән кайттылар. Чәйгә җыелдык. Күз явын алырлык булып кетердәп пешкән ипиләрне өстәлгә чыгарып куйдым. Иптәшләр шатлыкларыннан:

— Ах, ипие! — дип кычкырып җибәрделәр.

Өстәл башында — иң хөрмәтле урында Галимҗан утыра иде.

Ипинең барысын да турарга, җан теләгән чаклы ашарга карар бирдек. Тантаналы төс белән ипине урталай кистем... Ләкин ни күрик, ипи эченнән бәрәңге кабыклары коелды. Иптәшләрем яңадан «Ах!» дип кычкырып җибәрделәр. Бу юлы инде шатлыклы «ах» түгел, ә хәсрәтле, кайгылы «ах» иде. Мин исә, пычагымны кулыма тоткан килеш катып калдым. Шундый авыр елларда, бөтен илдә ачлык хөкем сөргәндә һәм ач үлем үзенең шыр сөякле куллары белән революцияне, азатлыкны, халыклар бәхетен буарга маташканда, мондый эшкә кемнең кулы барыр?

— Нинди кешедән алдың? — диделәр.

Сөйләп бирдем.

— Кулактан алгансың, — дигән фикергә килделәр.

Бәхәсләшеп тормадым. Чыннан да, бай йорт иде.

Мин әле аптырап басып тора идем, иптәшләр дә ипигә сузылмыйлар. Галимҗанга рәхмәт, аптырашлы хәлдән мине дә, башкаларны да чыгарды. Ул, бәрәңге кабыкларын кулына алып, әйләндергәләп карап торды да:

— Туктагыз әле, егетләр, юып тутырган бит бу моны,— диде һәм берничәсен кабып карады. — Ашарлык. Хәтта тәмле дә.

Без, ипине турап, бәрәңге кабыкларын өстәл өстенә өеп куйдык һәм аларны берәмләп ала-ала, бик тәмләп ашарга керештек. Кружкаларыбызга чәй агыздык. Кайсысыныңдыр ике-өч шакмак шикәре дә бар икән. Ул да чыкты. Күңелләребез кинәт күтәрелеп китте.

Әйе, ачлык елны барысы да ашлык, җир алмасының кабыгы да тәмле була икән!

Бу чәй мәҗлесен Галимҗан безгә кәефхозур булсын өчен уйлап чыгарган иде. Шулай булды да, «банкет» күңелле узды.

*Фазыл Фәсиев*

# Исемнәр дөньясына сәяхәт

**«Бер кешенең исеме Я к о в икәнен белү белән генә әле, мин аның турында катгый берни дә әйтә алмыйм»**

*(К. Маркс.)*

**Гаҗәп түгелмени?** Без, гадәттә, сүзләрнең чыгышы, асыл мәгънәсе турында уйланып тормыйбыз, күнеккәнчә сөйли бирәбез. Ә уйлап карасаң, гади генә сүзләрдә дә кызык һәм шактый катлаулы нәрсәләр ачыла.

Кеше исемнәрен искә алыйк. Әхмәт, Гали, Сания, Рабига, Зөһрә һ. б. Болар ни аңлата? Әйтик, маңгаенда ак таплы колынга «Йолдыз Кашка» диләр икән, моның әле реаль нигезе бар. Ә мин үземнең нигә Вәли булуымны аңламыйм. Минем Вәлилегем нәрсәдә соң?

Аннан соң, башка «Вәли»ләр дә бар бит әле... Бәлки, исем ясалма рәвештә төзелгән (В+ә+л+и) авазлар тезмәседер? Алай дисәң, телдәге авазлардан беркем дә шулай исем төзегәне юк. Әллә исем, икенчедән аеру өчен, «тамга салу» кебегрәк бер нәрсәме?

Әйе, исемнәр, төбендә, кешеләрне бер-берсеннән аеру-тану өчен хезмәт итәләр. Ләкин бу бик үзенчәлекле тамга...

Кайберәүләр: «Ничек булса да барыбер түгелмени?! Асия белән Нурияне, Мәҗит белән Хәмитне аера алгач, шул җиткән», диярләр. Әмма һәрнәрсәнең төбенә төшенергә, сәбәбен эзләргә тырышучы кеше өчен, бу аңлату гына җитми, билгеле.

**Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр.** Мәгълүм булганча, географик исемнәр, кеше исемнәре, отчество һәм фамилияләр, кушамат һәм псевдонимнар **ялгызлык исемнәр** дип аталган категориягә керә. Алар баш хәреф белән язылалар. Аларның каршыдашы булган уртаклык исемнәр юл хәрефеннән язылалар. Грамматикада без шушы хакыйкатьне үзләштерү белән чикләнәбез...

Төп аерма исә шунда: **уртаклык исемнәр** — төрле дәрәҗәдәге гомумиләштерү функциясен, ә ялгызлык исемнәр — берәмлеккә кадәр конкретлаштыру функциясен үтиләр. Башкачарак әйткәндә, ялгызлык исемнәр — берәмле объектларның тамгасы, ә уртаклык исемнәр күпләгән төрдәш объектларның уртак, җыйма, гомуми тамгасы. Мәсәлән, **яшәеш, галәм, су, авыл, бала** уртаклык исемнәр булсалар, Юпитер, Европа, Татарстан, Мансур, Мәрзия — ялгызлык исемнәр.

Уртаклык исемнәр — телнең төп материалы, алардан башка тел булмас иде. **Ялгызлык исемнәр** исә телнең төп сүзлек байлыгыннан бераз читтәрәк торалар кебек. Ләкин алар да асыл чыгышлары белән шул ук уртаклык исемнәргә барып тоташалар: Йолдыз, Сылу, Арслан, Тимер һ. б. Әмма күпчелек очракларда, бигрәк тә чит телләрдән алынма исемнәрдә бу хәл ачык күренеп тормый.

Ялгызлык исемнәрне өйрәнә торган махсус фәннәр — ономастика һәм топонимика

(топонимия [1]) бар дисәк, сез бәлки, гаҗәпләнерсез, алар нигә кирәк диярсез. Әмма аларның, тел белеме белән тарих һәм география арасындагы фәннәр буларак, теоретик һәм практик әһәмияте зур. Без биредә тел гыйлеменең ономастика, ягъни кеше исемнәре турындагы бүлегенең кайбер төшенчәләрен популяр рәвештә бәян итмәкче булабыз.

**Исемнәрнең функциясе.** Исемнәрнең җәмгыятьтәге хезмәте шактый күп төрле һәм катлаулы. Мәсәлән, идарә, оешмаларда эш йөртү бик күп кешеләр белән бәйләнгән. Шуңа күрә исем-фамилиясез бер генә документ та булмый. Исем-фамилия һәм имза документта реаль кешенең урынбасары булып хезмәт итә: кеше үзенең хокукларыннан да файдалана, үз өстенә иҗтимагый җаваплылык та ала. Финанс эшендә исем-фамилияләрнең төгәллеге аеруча әһәмияткә ия. Менә — исемнең бер функциясе.

Исем — кешенең гомерлек юлдашы һәм тарихи истәлеге дә. Әйтик, кеше үзе инде күптән юк (хәтта сөякләре җир туфрагына әйләнгән), ә аның иң «очкын» билгесе — исеме әле һаман да халык телендә яши, үз заманына караганда да мәгълүмрәк, киңрәк тарала...

Тормыш агымы туктамый. Үткәнгә алмашка яңа буыннар туа... Әйтик, тагын бер кеше дөньяга киләсе, ди. Ата-ана аңа, тиешле кирәк-яраклар әзерләү белән бергә, исем дә эзли. **Кешегә исем зарур!** Аның белән (зурмы, кечкенәме — барыбер) «Әй, син!», «Әй, кызый!» дип, яки «ул», «аңарга», «аңардан»... дип кенә мөгамәлә итеп булмый бит! Сәяхәтчеләр иң артта калган кыргый кабиләләрдә дә кешенең исеме булуы турында язалар. Шулай булмый мөмкин дә түгел. Чөнки кешенең исем-фамилиясе аның чыгышын, җирлеген, нәсел-кабиләсен дә күрсәтә.

Исемнәр халыкның тарихи һәм культура элемтәләре белән дә тыгыз бәйле. «Тел, лөгать вә әхлак алмаштыру» белән бергә, халыклар арасында исем алмашулар да була.

**Борынгы исемнәр.** Безнең ерак бабаларыбыз — болгарлар — төрле халыклар белән политик һәм культура бәйләнешләре урнаштыралар. Шулчак ул телләрдән бик күп төшенчәләр һәм исемнәр дә килеп керә. Мәсәлән, бездәге **Әхмәт** исеме — гарәпчә мактаулы дигән сүз; Гали — бөек, югары; Хатип — сүз остасы, оратор; Гомәр — коручы, төзүче; **Шәмсия** — кояш, **Камәр** — ай дигән сүзләр. Кайбер исемнәр фарсыча: **Гөлчәһрә (Гөлчирә)** — гөл йөзле; **Маһруй** — ай йөзле, **Бәхтияр** — бәхет дусты һ. б. Мисаллардан күренә ки, кешенең үзе белән **исеменең мәгънәсе** арасында зарури бәйләнеш юк, бары тик ата-ананың шәхси теләкләре һ. б. ш. кебек очраклы моментлар гына чагыла. **Шәмсиянең** чынлыкта кояш кебек көләч булмавы да мөмкин бит...

Гарәпләр белән бәйләнешкә кадәр безнең бабайларның үз исемнәре булганмы соң? Әйе, булган. Мәсәлән, Айдар, Айтуган, Айрат, Илбилге, Илтуган, Илбарыс, Илтөзәр, Илбатыр, Тимеркәй, Миңлекәй, Биктимер, Бикбулат кебек исемнәр — ир балаларга, Айсылу, Гөлбикә, Туйбикә, Сөембикә кебек исемнәр кызларга кушыла торган булган. Мондый исемнәр хәзер күбрәк тарихи истәлек, легенда, җыр һәм әкиятләрдә генә сакланып калганнар.

Әүвәлге заманнарда кешенең хәтта берничә исеме булган. Башта **балалык исеме** белән йөрсә, үсеп буйга җиткәч (махсус сынау, ярыш һәм бәйгеләр үткәч), аңа икенче, яңа исем — **егетлек, батырлык** символы буларак «ир аты» бирелә торган булган. Мәсәлән, күренекле тюрколог С. Е. Малов игълан иткән кабер таш язмаларында: «Эр эрдәм атым бар өчүн, бәңкү таш тикә бәртим» (ир ирлек исемем булган өчен, мәңге таш куя бирдем), диелә. Кайберләрендә исемнәре атап та язылган: «Ир атым — Удун»; «Ир атым — яшь Аңбаш»; «Ир атым — ярук Тигин»; «Ир атым — Ирән Улуг, ирдәмле батырмын»; «Бу улуг ир атым — Үгдәм алып»; «Ир атым — Акбаш атак». «Ир атым — Буга» һ. б. Хәзерге татар телендә сакланып калган «ир-ат», «ир-ат булды» тәгъбире шул заманнан ук калган булса кирәк. Моны орхун язмасындагы: «он йашда иним Күл-тигин эр ат булты» (ун яшьтә энем Күл-тигин ир исеме казанды [2]) дигән сүзләр раслый.

---

[1] **Т о п о н и м и я** — топонимнар (топонимика) турындагы фән, ягъни ул җир өстендәге физик-географик объектларның (урман, җир-су, тау-чокыр һ. б.) һәм тарихи-административ объектларның (ил, шәһәр, авыл һ. б.) исемнәрен өйрәнә.

[2] Монда булты — тапты, казанды дигән сүз һәм принц Күл-тигиннең 10 яшендә үк «ир аты» алуына гаҗәпләнерлек түгел, чөнки 16 яшьтә үк инде ул танылган гаскәр башлыгы була.

Югарыда әйтелгән йола Себердәге кайбер халыкларда хәзергә кадәр сакланып килгән. Мәсәлән, кеше тормышында бер вакыйга була: ул бер батырлык күрсәтә — һәм аңа инде яңа исем бирелә. Боларның элеккесе — төп исем, яңасы — кушамат [1] булып кулланыла. Тора-бара төп исем бөтенләй онытылырга да мөмкин. Мәсәлән, «Алтынчәч» легендасындагы Тугзак ананың шәхси исеме дә булгандыр, билгеле. Ләкин һәркем аны ил арасындагы мәшһүр **кушаматы**, данлы «тугыз улы» буенча атый. Җикмәргәннең дә төп үз исеме билгесез («җик мәргән» — яхшы, тәз атучы дигән сүз).

Төрле халыкларның исем кушу йоласы бик сәер тоелырга мөмкин. Мәсәлән, «Ташбай» (Ә. Айдар) повестенда казакъ-кыргыз гадәте болаерак сурәтләнә: «Бала тугач, кендек әбисеме, башка бер өлкән хатынмы, тирмәдән чыга да тирә-якка бага һәм күзенә иң элек ни чалынса, шуның белән баланың исемен билгели. Ташбайның өлешенә төшкән көмеше — **таш өеме** булган!.. Димәк, ташка бай — Ташбай... Казакъ мәгърифәтчесе Ибраһим Алтынсарин язмаларында берәүнең Кул, Камыш, Каскыр (Бүре), Куй һәм Пычак исемле уллары булуы (һәм шуның белән бәйле бер мәзәк) теркәлгән [2].

Әгәр бер гаиләдә балалар булмый, я авырып үлә икән: Тансык, Үлмәс, Җанбул [3], Сөембикә, Виталий (яшәүчән), Ждан, Любим, Надежда, Любовь кебек исемнәр кушылган. Киресенчә, күп балалылар: Туктамыш, Артыкбикә (М. Әмирнең «Агыйдел»ендәге Артыкбикә образын искә төшерегез), Нежданн дибрәк тә куша торган булганнар. Алтынбай, Хангильде (хан килде), Байгильде, Дәүләтгильде, Солтанбикә, Асылбикә, Геннадий (асыл, яхшы нәселле), Виктор (җиңүче) шикелле исемнәр күбрәк югары катлауларда очрый (тарихи документларда бу бик ачык күренә). Колчура (кол+чура [4]), Янчура, Карабаш (кол д. с.), Карабай, Ходайбирде, Гаптери, Биби; Рябой; Ярмалай, Акулина, Филька, Мавра кебек гадиерәк исемнәр түбән катлауларда ешрак очрый (бу үзенчәлекне әдипләр тарихи романнар язганда бик оста кулланалар).

Кайбер исемнәрдә баланың ничәнче булуы чагыла. Әхәт (1), Сания (2), Рабига (4), Первуша, Третьяк, Шестак (шуннан Третьяков кебек фамилияләр барлыкка килгән).

Диннәрнең (христианы, мөселманы һ. б. да) идеологик нигезе бер үк булганлыктан, төрле телләрдә бер үк мәгънәле Богдан — Теодор — Тодор — Феодор — Федор — Аллабирде — Тәңребирде [5] кебек адаш исемнәр барлыкка килгән. Дин гадәттә, халыкның үз исемнәренә каршы торган, ләкин шулай да, аларны тиз генә кысрыклап чыгара алмаган. Кешенең халык арасындагы исеме — саф татарча, ә рәсми, дини исеме — гарәпчә йөртелгән. Мәсәлән, X гасыр башындагы болгар ханы Алмушның гарәпчә исеме Габдулла булган. Мондый ике исемлелек гади халыкта 16—17 гасырларга кадәр очрый. Исемнәрнең тулы һәм кыска вариантлары да (Гали, Галикәй, Уразмөхәммәт — Уразай һ. б.) шул ук ике исемлелекнең яңача дәвам итүе булса кирәк. Тарихи истәлекләрдә, шәҗәрәләрдә 19—18 йөздән әүвәлгә киткән саен, борынгы татарча исемнәр ешрак очрый бара: Балтач, Бигиш, Явиш, Гуиш һ. б. (Моны чагыштырмача хронологияне билгеләгәндә дә исәпкә алырга мөмкин.)

---

[1] К у ш а м а т — «кушам-ат» — төп исемгә кушыла торган өстәмә исем. Хәзер дә кайбер авылларда картлар телендә «Кушама ат» — «кушам ат» дип сөйләүләр ишетелгәли. Мондагы «ат» — шул ук «исем» мәгънәсендәге әүвәлге үз сүзебез. Мәсәлән, ни атлы? а т а у, а т а м а... сүзләренең нигезендә шул тамыр ята. Исем сүзе исә гарәп теленнән үзләштерелгән. Хәзер а т — күбрәк «дан», «шөһрәт» мәгънәсендә йөртелә: атказанган, атаклы һ. б.

[2] И. А л т ы н с а р и н. Избранные произведения. Алма-Ата. Рус телендә. 1957 ел, 297 бит.

[3] Бездәге Терегул-ов, Теркул-ов кебек фамилияләрнең дә этимологиясе: Терегул — терек ул — тирик ол — «тириг ол», ягъни тере бул, дигән яхшы теләкле исемгә кайтып кала. Моны «төрек улы» дип аңлатулар да очрый. Т ү р ә г у л о в — түрә кол (чагыштыр: Бикчура, Байчура) һ. б. ш.

[4] Ч у р а — төбендә «малай» дигән сүз була (мәсәлән, чуваш телендә), соңыннан ул «кол» (чагыштыр: холоп-хлопец, раб-робенок-ребенок), кол — крепостной, кол — әсир һәм хәтта «герой, батыр» мәгънәләренә дә күчә (чагыштыр: молодой-молодец!); Чура батыр һ. б.

[5] Мамадыш районындагы Т ә б е р д е авылының исеме: «Тәңребирде — тәңри бирде» дигән кеше исеменә кайтып кала (чагыштыр: Богдановка, Федоровка — шулай ук).

Элек гомумән исем кушу руханилар кулында булу һәм ата-ананың грамотасызлыгы сәбәпле, ягымсыз дини исемнәр күп таралган. Бөек шагыйрь Г. Тукай:

*«Без — Габдулла, ягъни ниндидер бер алла бәндәсе. Без — Гобәйдулла, ягъни ниндидер ходай колчыгы.*

*Без — Гыйбадулла, ягъни ниндидер алла коллары. Менә бу ямьсез, мәгънәсез, тозсыз исемнәр һәммәсе дә безнең диндар хәзрәтләребез хезмәте... Мин телимен ки, киләчәктә мондый ямьсез исемнәр татар балаларына кушылмасын»*, дип, исемнәрнең үсеш юнәлешен әнә шулай билгеләгән.

**Яңа исемнәр.** Чыннан да, халык моны аңлый һәм Айдар, Айрат, Батыр, Илдар, Урал, Энҗе, Миңсылу, Миңлегөл, Миңленур, Карлыгач, Сөембикә, Миләүшә, Чулпан кебек үз исемнәрен яңадан яратып куша башлый.

Яңа тормыш исемнәребезгә дә яңа эчтәлек алып килә: Азат, Ирек, Алмаз, Алсу, Айаз, Бүләк, Гыйлемдар, Гөлшат, Гөләндәм, Илгизәр, Илшат, Фәнил, Фәния һ. б. һ. б.

Гарәп һәм фарсы исемнәреннән үзләшкән, мәгънәсе ачык, гади һәм матур яңгырашлылары гына актив кулланыла: Бәян, Булат, Вәкил, Галим, Газиз, Гөлчирә, Дилбәр, Зәйтүнә, Зөфәр, Зөбәрҗәт, Зиннәт, Зирәк, Зөлфә, Илһам, Искәндәр, Камил, Кадрия, Ләлә, Ләбибә, Наил, Наилә, Нурия, Нәфисә, Рәисә, Раушан, Рәшид, Сәйар, Сәфәр, Сәлим, Самат, Шәүкәт, Шамил, Фәрид, Фәйрүзә, Фәүзия, Җәлил, Җәмил[1] һ. б.

Октябрь революциясеннән соң, рус һәм Көнбатыш Европа телләреннән кергән исемнәр дә шактый урын алды: Альфред, Альберт, Венера, Заря, Идея, Идеал, Рим, Римма, Казбек, Луиза, Лариса, Лена, Марс, Резеда, Розалия, Розалина, Светлана, Фиалка, Эдуард, Эльмира, Эльза һ. б. ш. Бөек Ватан сугышына кадәр мондый исемнәр белән беркадәр мавыгу да булган иде.

Шунысы кызык: исемнәрнең матурлык чамасы бик үзгәрүчән, субъектив нәрсә. Аны һәркем, һәр катлау, һәр халык үзенчә аңлый. Заманында ягымлы танылган исемнәр, икенче бер чорда ямьсез, хәтта көлке тоелырга, ә артык мавыгу белән яхшы нәрсәне дә бозарга мөмкин. Чит исемнәр белән мавыгу еш кына үз илеңә-халкыңа игътибарсызлык, өстен карау белән бергә янәшәрәк йөри.

**Халыкара исемнәр.** Әмма бу әле һич тә алынма исемнәрне бөтенләй инкарь итү дигән сүз түгел. Исемнәр дә, культура әйберләре кебек ук, бер халыктан икенче халыкка күчә. Хәтта халыкара исемнәр дә бар. Тик аларны сайлап, тирән белеп, иҗади рәвештә үзләштерергә кирәк. Бигрәк тә гомуми-кешелек культурасы, фән-әдәбият мирасыннан алынган, тарих, мифология һәм сәнгатькә бәйле булган исемнәрне куллану өчен, ул культура истәлекләренең, әсәрләрнең үзләре белән дә таныш булу әйбәт. Мәсәлән, Зөһрә, Фәрхәд, Ширин, Ләйлә, Рөстәм, Таһир, Рафаэль кебек әдәбият һәм сәнгатькә бәйле исемнәр, Марат, Клара, Эрнст, Вил, Вилен, Карл, Энгель, Салават, Муса һ. б. ш. революция каһарманнарының исемнәре — кешегә җитди җаваплылык йөкли.

Кайбер исемнәр чын мәгънәсендә интернациональ булып киткәннәр. Мәсәлән, **Йосыф** исеме Европа һәм Азиянең бик күп телләрендә кулланыла:

| | |
|---|---|
| **еврейчә Йосәф** | **полякча Юзеф** |
| **грекча Иосиф** | **инглизчә Җозеф** |
| **немецча Йозеф** | **итальянча Җузеппе** |
| **испанча Хозе** | **татарча Йосыф, Йосып** |
| **португалча Хузе** | **гарәпчә Юсеф** |
| **русча Осип** | **төрекчә Юсуф** |

Шулай ук Исхак — Исаак, Якуб — Яков, Мәрьям — Мария, Рәйсә — Раиса, Сара — Сарра, Рәхилә — Рахиля, Ибраһим — Авраам кебек борынгы мифологиядән килгән халыкара исемнәр дә очрый. «Иван» исеменең кардәшләре исә тагын да күбрәк:

## УНТУГЫЗ ИВАН

**Европада сөзәк тауда**
**Үсә бер имән;**
**Имән төбендә утырган**
**Унтугыз Иван:**

[1] «РСФСР халыкларының исемнәре» (Мәскәү, 1966 ел) дигән китапта хәзерге вакытта актив кулланыла торган татар исемнәре дә бар.

**Ваня, Вано, Аванес,**
**Янка, Янел, Ян,**
**Янус, Януш, Ионас,**
**Хуан, Жуан, Жан,**
**Янис, Иоһан, Иоан, Ион,**
**Жанис, Джонни, Джон.**
**Уртак хистә бергә тибә**
**Унтугыз йөрәк.**

**Җырлыйлар имән янында**
**Тынычлык теләп:**
**Әйтәбез бүген бергәләп**
**Дөнья, син инан:**
**Бер-беренә мылтык атмас**
**Унтугыз Иван!**

*(Ш. МӨДӘРРИСТӘН.)*

**Тәрдәш исемнәр.** Төрле телләргә кергән исемнәр һәр телнең фонетик законнары буенча үзләштерелергә мөмкин. Мәсәлән, җанлы телдә: Гафифә — Әпипә, Гөлчәһрә — Гөлчирә, Маһитап — Майтап. Кайбер исемнәр хәтта танымаслык булып үзгәрергә дә мөмкин: Апуш (Габдулла), Мокамай (Мөхәммәт), Мирза (Әмирзадә — Әмир улы дигәннән).

Гади сөйләмдә кайбер кушма исемнәр уңайлык өчен теге я бу өлеше кыскартылып кулланыла. Мәсәлән, Нәби (Нәбиулла), Шәмси (Шәмсетдин), Фәйзи (Фәйзулла, Фәйзерахман), Рахман (Хәбибрахман), Наһар (Шәмсенаһар), Сандыр (Александр). Өлкән кешеләр исә мондый «иркенлек»не кабул итә алмыйлар һәм «Мөхәммәдрәхим», «Миңлеәхмәд» кебек тулы рәвешенә китереп сөйлиләр. Рәсми документларда да, күбесенчә, мондый исемнәрнең тулы формалары йөртелә. Матур әдәбият, билгеле, үзенең киң-тормышчан колачы белән исемнәрнең һәртөрлесеннән иркен куллана.

**Фамилия һәм отчестволар.** Элек көнчыгышта гомумән һәм төрки-татар кабиләләрендә аеруча фамилияләр булмаган. Бер үк исемле берничә кешене ата исеме белән яки кушаматы белән аерып йөрткәннәр. Мәсәлән, Тимеркәй Гаптенуры, Әмирҗан Гаптенуры һ. б. ш. Өстен катлау үзләрен данлыклый торган кушамат ала торган булган: Котлу Әхмәд, Тимер Котлугъ. — Монда Тимер — исем, Котлуг «бәхетле, счастливый» — кушамат, ул фамилия ролен үти. Чагыштырыгыз: шәрыкта — Тимер Арслан, Алып Арслан[1]; Европада — Ричард Львиное сердце һ. б. ш.

Элек кеше үзенең нәсел-нәсәбен (ягъни бөтен ыру-фамилиясен) җиде-тугыз бабасына кадәр[2] санап йөрткән. Мәсәлән, «Минем бабаларым биләгән җирләр — дип язылган бу ярлыкта — заманасында Болгар дәүләтенең базарбашы булган бабамыз Сәед Тигәнәй милке саналмыштыр. Соңра 1623 нче елда ак падишаһ чар Михаил Федрич ярлыгы белән тугызынчы бабамыз йомышлы татар Ишмөхәммәткә беркетелмештер. Аның атасы Хангильде морза, аның атасы Байтирәк кенәз, аның атасы Хуҗа Әхмәд, аның атасы Сәлим Гәрәй, аның атасы Сәед Тигәнәй улы Шәһри Болгар газыйлары нәселеннәндер» (К. Нәҗми. Язгы җилләр).

XVII—XVIII йөзләрдә татар морзалары арасындагы хөкүмәт-администрация белән рәсми эш йөртү сәбәпле: Тәвкилев, Яушев, Акчурин кебек фамилияләр күренә башлый. Октябрьдан соң **ов-ова, ин** кушымчалары белән фамилия ясау төп норма булып китә. Бу киң халык массаларының иҗтимагый активлыгы, гражданлык хокуклары һәм вазифалары киңәю белән бәйләнгән[3].

Фамилияләр ничек, нинди юллар белән ясала соң? Бездә алар күбесенчә ата яки баба исеменә **ов-ова, ев-ева, ин-ина** кушымчалары ялганып төзелә һәм еш кына **Вәлиев** Сәфәргали **Вәли** улы, **Гатина** Минҗиһан **Гата** кызы... кебек фамилия белән ата исеме охшаш була. Оныклардан башлап: **Вәлиев** Илдар Сәфәргалиевич кебек «чын» фамилияләр дәвам итә.

Рус телендәгечә Иванов Иван Иванович[4] кебек тезмәләр бездә юк. Петухов ке-

---

[1] С. Е. **Малов** татарларда очрый торган «Алпаров» фамилиясенең чыгышын: а л п э р (б а т ы р и р) — Алпар, дип аңлата һәм бу тел законнарына туры килә. А л ы п б а т ы р, а л ы п к е ш е л ә р турындагы әкият һәм тарихи легендаларны да искә алганда, моның шулай булуы бик мөмкин.

[2] Телебездәге «җиде баба», «җиде ят» дигән тәгъбирләр шуннан килә торгандыр. Әйтик к и л е н ыруы өчен, к и я ү нең ыруы беренче туганлык җепләре беленмәслек, ерак булырга тиеш булган икән, димәк, кияү ыруының «җиде ят» булмый хәле юк.

[3] Димәк, исем-фамилияләрдә социаль үзгәрешләр дә чагыла, шуңа күрә иҗтимагый фәннәрдә кеше исемнәре «тарихи чыганак» итеп файдаланыла.

[5] Мәскәүдә генә, мәсәлән, меңләп Иванов Иван Иванович барлыгы мәгълүм.

бек кушамат-фамилияләр дә бездә кагыйдә буларак очрамый[1]. Аюханов (чагыштыр: Медведев) кебекләр исә профессия белән бәйләнгән булуы мөмкин. Турыдан-туры русчадан алынган Волков, Жданов, Сметанин кебек фамилияләр көнбатыш диалект вәкилләре арасында беркадәр күренгәли. Профессия исемен чагылдырган фамилияләр бездә шактый очрый: Азанчеев, Балтачев, Тимурчеев, Урманчиев (Урманчы), Крымчеев. Рус, немец һ. б. телләрдә исә мондый профессиональ фамилияләр аеруча күп: Дьяконов, Кузнецов, Топоров, Вальдман (урман — кеше — урманчы), Штейнман (ташчы), Шмидт (тимерче) һ. б. рустагы кебек халык исемнәреннән килеп чыккан Мордвинов, Немцев, Чувахиндай фамилияләр безнең телдә бик сирәк. Башка телләрдә исә милләт, халык, шәһәр исемнәреннән алынган фамилияләр бик еш очрый.

Рус телендә һәм чит телләрдә парлы фамилияләр шактый таралган күренеш (хәрби-аристократик катлауларга, сәнгать, әдәбият һәм фән эшлеклеләренә хас). Бездә бу төр дә сирәк очрый: мәсәлән, Гыйззәтуллина-Волжская, Фатих Сәйфи-Казанлы һ. б. Аларның гадәттә беренче өлеше — тумыш фамилия, икенчесе — урын исеменнән алынган псевдоним була. Ике өлеше дә фамилиядән торган: **Арсланова-Сафиуллина** кебек формалар безнең телдә, ахры, ныклап урнашып китә алмыйлар.

Исем-фамилияләрдә тарихи һәм этногенетик процесслар да чагыла (кабилә һәм халыкларның бер-берсе белән катнашуы, керешүе). Алар үзләренең юлдашлары — конкрет шәхесләр, кешеләр белән бергә бер халыктан икенчегә күчәләр, үзгәрәләр, үзләшәләр. Мәсәлән, рус телендә бик күп кавказ һәм төрки-татар фамилияләре бар. Соңгыларына мисал итеп: Ахматов, Аксаков, Аксанов, Абадулин, Асанов, Асланов, Русланов (Арсланов), Баскаков, Бурнашев, Беклемишев, Бичурин, Хантимерский, Рахматов, Извеков (Үзбеков), Уразов, Исупов, һ. б. ш. күрсәтергә мөмкин.

Кайбер фамилияләрнең хәзерге һәм тарихи вариантлары искиткеч күбәеп китә: Мухаметов, Мухаммедов, Магомаев (Мокамай?), Магомедов, Мамедов, Мамутов, Маматов, Мамаков, Магомедзянов, Мамаджанов, Мөхәммәдҗанов, Магмедзянов, Әлмөхәммәтов, Альмухаметов, Альмагбетов, Альмаметов, Альмамедов, Альмаматов, Альметов, Альметьев һ. б. ш.

Фамилияләрнең әле «яңарак күренеш» булуы сәбәпле күп кенә буталыш очрый, бу хәл исә идарә һәм финанс эшләрендә шактый уңайсызлык тудыра. Бездә бер үк фамилияләрнең кимендә ике варианты яшәп килә: 1) Язма, әдәби телдә (Мөхәммәтов); 2) Русча рәсми документларда (Мухаммедов). Боларның ике вариантына да ныклы кагыйдәләр кую һәм унификацияләү кирәклеге сизелә. Югыйсә безнең фамилияләрдә вариантлылык көчле, тотрыклылык, стабильлек бик аз. Дөрес, бер вариантны яклаучылар да очрый, ләкин күпчелекнең фикеренчә алай эшләү реаль чынбарлыкка туры килми кебек.

Аталык исемнәре, ягъни отчестволарда да шундый ук хәл күзәтелә. Традицион «фәлән улы» «фәлән кызы» дигән формалар артык рәсми һәм китапча булып, кешегә турыдан-туры мөрәҗәгать итү өчен уңайсыз[2]. Шуңа күрә хәзерге көндәлек аралашу практикасына «овичь» — «овна» кебек стандарт калыплашкан формалар да кереп бара. Һәм бу инде теге я бу рәвешчә әдәбиятта да чагыла башлады. Димәк, монда да ниндидер тәртипләштерү таләп ителә[3].

**Әдәби образ исемнәре һәм псевдонимнар.** Исем-фамилияләрнең әдәби функциясенә дә бераз кагылып үтик. Иң элек псевдонимнар хакында.

XII—XIII гасырлардан башлап, культура, фән һәм әдәбият үсеше белән бәйле рәвештә аерым әдипләр, шагыйрь, галимнәр үзләренең милләте, туган җире, укыган, сәяхәт иткән, яшәгән урыннары буенча, псевдонимнар (нисбә) алуны кулланышка кертәләр. Гали-әл-Болгари, Котби, Сәяди, Утыз Имәни, Мөхәммәдъяр Болгари, Шиһаб

---

[1] Абалаков кебек кайбер кушаматка охшаш фамилияләрнең, төбендә, авыл исеменнән алынган псевдоним-фамилия булулары мөмкин (мәсәлән, Татарстандагы һ. б. өлкәләрдәге Ябалак исемле авылларны карагыз).

[2] Шуңа күрә бу очракларда теге я бу исемгә кушып әйтелә торган: абый, апа, абзый, ага кебек мөрәҗәгать формалары кулланыла.

[3] Бәлки, беренче адым итеп, «Сабир улы», «Сабир кызы» кебек традицион формулаларны сызыкча аша язуны кертергә кирәктер. Киләчәктә телнең җыйнаклашу, гадиләшү тенденциясе нәтиҗәсендә аларның чын-чыннан отчество формасы булып оешулары да мөмкин.

Мәрҗани, Курсави, Гали Чокрый һ. б. (грамматик яктан болар гарәп изафәсе белән төзелгәннәр). Кайбер борынгы шагыйрьләр үзләрен **Кол Гали, Гыйбад Мәүләви** (алла колы)... дип атап, специфик шәрыкъчә «автор тыйнаклыгы» күрсәткәннәр. Янәсе, алар «мәүлә» биргән «сүз куввәсе» белән ул боерганны башкаручы коллар гына. Шуна күрә борынгы әдәбиятта «тел ачкычы» сорау күп кенә әсәрләрнең стандарт керешен тәшкил итә. Мәсәлән, «Йосыф кыйссасы»ында:

**Мәүлям саңа сыгынырмын мән бер зәгыйфь...**
**...Тәүфикъ сәндән уманырмын мән зәгыйфь кол.**
**Бән зәгыйфә илһам, тәүфикъ каве виргел,**
**Мәңа хикмәт капусын ачу виргел...**

Менә боларны исәпкә алганда, «Мәүля колый» белән Меллагол дигән шәхси исемне аеру мәсьәләсенең бик үк гади булмавы ачыклана. Кайчандыр Ф. Туйкә милкендә булган кульязмадан шагыйрьнең исемен һәм нисбәсен таба алмагач, Г. Сәгъди һәр хикмәттә кабатланган традицион «мәүля колый» гыйбарәсен алып, шуны псевдонимлаштырган булса кирәк. Ш. Абилов шагыйрьнең конкрет шәхси исемен ачыкларга тырыша икән, безнеңчә, бу фәнни тикшеренүдә бер яңалык. Меллаголмы, башкамы — эзләргә кирәк, ә эзләгән таба.

Г. Саттаров «Шагыйрьнең исеме кем» («Казан утлары» журналы, 1966 ел, 1 сан) исемле мәкаләсендә бу мәсьәләгә икенче яктанрак туктала, аның күп кенә позитив һәм тәнкыйть фикерләре белән килешергә мөмкин. (Мәсәлән, «кол» сүзеннән ясалган исемнәр, топонимнар һ. б.) Ләкин болар гына әле Мәүля Колый яки Меллагол булуны раслый да, инкарь да итә алмыйлар. Иң кыены шул: «...**Мәүля Колый** сүзле дуслар» дигән соңгы юл туксан алты хикмәтнең һәркайсында кабатлана. Нинди автор үз исемен шулкадәр кабатлар икән? Тезмәнең грамматик ягы да монда татар изафәсе булуын күрсәтә: Мәүля Колый — алла колы дигән сүз генә булып чыга [1]. Авторның яшәгән чоры, мөхите, карашы, юнәлеше дә шул хакта сөйли. Г. Саттаров иптәш раслыларга омтылганча, шагыйрьнең исеме **«Мәүля»** һәм аның **«Кол»** авылы кешесе булуын исбат итү бик авыр. Безнеңчә, тагын да киңрәк, төгәлрәк тикшерүне дәвам итәргә кирәк.

XVIII—XIX йөздә гарәп нисбәте формалары белән русча ов-ев формалары очраша һәм параллель кулланылалар. Насыров — Насыри, Ильясов — Ильяси һ. б. Хатын-кыз әдипләрдә — Насырия, Мозаффария һәм башка формалар күренгәли.

XX йөздә сәнгать-театр эшлеклеләре арасында Ашказарский, Камский, Болгарская кебек псевдонимнар алу модага керә һәм аларның кайберләре соңрак фамилиягә әверелә. Казанлы, Уфалы, Иделле формасындагы псевдонимнар исә киң тарала алмадылар.

Ниһаять, XX йөздә һәм совет чорында **фамилияләрне кыскарту юлы белән** әдәби псевдонимнар ясау урнашып китә: Г. Камал(етдинов), Г. Тукай(ев), Һ. Такташ(ев) Ф. Кәрим(ов). Кайбер очракларда иске традицион алымнар да дәвам итә (М. Гафури, Ф. Кәрими, Җ. Вәлиди) яки традицион һәм яңа алым бергә кушыла (М. Фәйзи, К. Нәҗми).

Әдәби образларга исем сайлау һәм табуның никадәр кыен, четерекле иҗади эш булуы язучыларга бик яхшы мәгълүм [2].

Чөнки ничек кенә булмасын, исем образны теге я бу рәвешчә чагылдыра. Әдәбият укытучылары бу моментны истә тотсалар, образларның үзенчәлекләрен ачу өчен тагын бер өстәмә белгедән файдалана алырлар иде. Мәсәлән, Г. Ильясиның «Бичара кыз» драмасында бер яктан — Җантимер (тиран, җаны тимер), икенчедән — Җанбай, Җанъяр (җанга яр) исемнәре юкка гына алынмаганнар. Таҗи Гыйззәт драмаларында Малтабаров, Җансаттаров, Иманкол мулла, Әскарик, Шәрифәбикә, Батырҗан кебек гаять кыска һәм тапкыр әйтелгән тасвири исемнәр бер үк вакытта образларга характеристика булып та яңгырыйлар.

---

[1] **«Мәүля Колы» дигән тезмә башка әсәрләрдә дә очрый, ләкин моңа карап без аларны Мәүля Колый дигән автор язган дип раслый алмыйбыз.**

[2] **Әсәрнең үзенә исем табу күп эзләнүләр таләп итә, шуңа күрә тиешле исемне табу юлында әсәрнең беренчә исеме барлыкка килергә мөмкин. (Мәсәлән, Ш. Камалның «Томан арты» — «Габбас Галин» драмасы.)**

Меңләгән еллык тарихы булган зур әдәбият образларны исемләүдә дә бер традиция тудыра, билгеле. Һәр язучы шул традициягә иярергә мәҗбүр һәм үзеннән яңалык өстәргә дә омтыла. Мәсәлән, Ш. Камалның «Матур туганда», «Ныклы адымнар»-ындагы үсмер малай Габделгалләм шул чорның малайларына гына хас булган гадилеге һәм нечкә юмор белән сурәтләнгән. Әгәр бүгенге автор бу исемне үзенең яңа әсәренә кертә икән, алдан ук уйланырга тиеш: укучының хәтеренә егерменче еллардагы Габделгалләм образы килеп төшмәсме? Яңа Габделгалләм элеккесеннән көчлерәк, тәэсирлерәк булырмы? Яки бу исемне бик җитди, олы кеше образына алырга мөмкинме кебек сораулар туа.

Жанр һәм юнәлешләрнең дә исемнәр сайлауда үзенчәлекләре бар. Критик реализм әдәбиятында һәм драматургиянең мәгълүм бер чорларында «ярлык исемнәр» яки «рупор исемнәр» кую гадәт була. Хәзер мондый исемнәр, башлыча, балалар әдәбиятында һәм сатирада гына урын ала: Мыраужан, Сөтбикә, Бибкәй, Әшнәкәй...

Күтәренке рухта язылган әсәрләрдә каһарманнарның исеменә махсус әдәбилек, пафос, шигъри мәгънә белән өртелгәнлек һәм кайчакта беркадәр претензиялелек хас булучан. Мәсәлән, Ф. Әмирханда Хәят, Г. Ибраһимов әсәрләрендә Зыя, Мәгъсүм, Һ. Такташта Әминә, Матильда, Г. Кутуйда Искәндәр, Галия, Кадрия, Г. Әпсәләмовта Илдарский, Гөлшаһидә кебек образ исемнәре очрый.

Җитлеккән проза һәм драматургиядә образларның исемнәре реальрәк — тирәнрәк нигезләрдән чыгып сайланыла. Монда тарихи-социаль җирлек, милләт, диалект, урын колориты, яшь-чор үзенчәлекләре исәпкә алына. Татар әдәбиятыннан моңа бик күп мисаллар табарга мөмкин: «Язгы җилләр»дән Мостафа һәм Юныс Вәлишин; «Намус»-тан Айтуган карт, Тимери, Нарспи, Әпипәләрне хәтерләгез.

Нейтраль һәм тасвири исемнәрне әдәби әсәрнең образлар тукымасында урынлы һәм оста куллану ягыннан Ә. Еникинең соңгы еллардагы хикәяләре күзгә ташлана. Наҗия һәм Майпәрвәз исемнәрен алыйк. Алар турыдан-туры «менә син кем» дип төртеп күрсәтмиләр, әмма укучының үзенә сиздермичә генә «назлы», «май», «пәрәвез» сүзләрен искәртәләр. Чынында исә, бу исемнәрнең мәгънәсе бөтенләй икенче төрле (Наҗия — коткаручы хатын-кыз, Маһипәрвәз-ай йөрешле, ай әйләнешле дигән сүз). Телләрне белгән кешегә мондый нечкә эффект аеруча көчле тәэсир итә, билгеле. (Чагыштырыгыз: исем белән образ арасындагы иронияне!) Яшь язучыларга монда өйрәнер үрнәкләр бар. Ләкин шунысы ачык: бер әсәрдә андый исемнәрне артык күп куллану килешми. Бары тик нейтраль исемнәр фонында гына бер яки ике исем белән тиешле эффект тудырырга мөмкин.

Әдәбиятта уңай образларга карата тапкыр бирелгән гади һәм матур яңгырашлы исемнәр укучы масса аша реаль тормыштагы исем кушу процессына да уңай йогынты ясый, халкыбызның зәвыгын, культурасын күтәрә.

**Нинди исем кушарга?** Ата-ана теләсә нинди очраган исемне битараф рәвештә алмый, билгеле. Үзенең зәвыгы, уй һәм фикерләреннән чыгып сайлап ала. Әгәр булганнары гына канәгатьләндермәсә, телдәге сүзләрдән файдаланып яңа исемнәр дә ясый. Гөлгенә, Илнур — бу исемнәрдә балага никадәр мәхәббәт чагыла! Димәк, ата-ана **объектив зарурлыкка** үзенең субъектив мөнәсәбәтен, хисен, карашын да куша. Ул бит баласында, әлбәттә, яхшы сыйфатлар — матурлык, батырлык, патриотлык күрергә тели һәм шундый мәгънәле исемнәр бирә: Илсөяр, Илбатыр, Илдар (ләкин иң әһәмиятлесе баланы шулай тәрбияләү). Исем кушканда нинди нигезләрдән чыгып эш итәргә соң?

Иң беренче шарт: модага иярүдән, очраклы, тотрыксыз исемнәр кушудан саклану. Чөнки мәгънәсе артык бәрелеп тора торган исемнәр белән мавыгу еш кына уңышлы булып чыкмаска мөмкин.

Гадәттә, исемнең гади, тыйнак һәм матур яңгырашлы булуы күздә тотыла.

Аннары баланың киләчәге турында да уйланырга, ягъни исемнең бала вакытта да, олыгайгач та әйтергә килешле булуына, фамилия һәм отчество ясау өчен уңайлыгына игътибар итәргә кирәк.

Әгәр дә олы мәгънәле, тарихи-революцион яки әдәби-поэтик исемнәр кушыла икән, баланы шуңа тегe яки бу дәрәҗәдә лаек булырлык итеп тәрбияләргә дә кирәк. Чөнки, асылда, кешене исем бизәми, кеше үзе исемен бизи.

# ЧИТ ИЛ ЯЗУЧЫЛАРЫ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ТУРЫНДА

## ТУКАЙ — ЧИТ ТЕЛЛӘРДӘ

*(Фин галиме Г. Тагерның Казанда булуы уңае белән кайбер фикерләр)*

Әдәбиятыбыз титаны Тукәйның 80 еллыгына багышлап быел июнь аенда үткәрелгән юбилей көннәре олы бәйрәмнәргә генә хас шау-гөре, мәшәкатьләре һәм куанычлары белән артта калды. Ул көннәр күңел түрендә беркайчан да җуелмаслык эзләр сызып үттеләр. Юбилей вакытында табигать тә ямьле, хозур иде, чалт аяз күктән һәр көн кояш көлеп торды, шагыйрь истәлегенә багышланган тантаналар татар халкының борынгыдан килгән хезмәт бәйрәме — сабан туй тантаналары белән аралашты.

Тукай юбилее, милли әдәбият кысаларын һәм Казан чикләрен үтеп, башкалабыз Мәскәүгә барып җитте, шагыйрь тарафыннан сөеп җырланган Кырлайга таралды, юбиляр исеме күрше республика һәм өлкәләрдә хөрмәт белән искә алынды. Урта Идел һәм Урал буйларыннан, Урта Азия һәм Кавказ якларыннан Казанга килгән тугандаш халыкларның атаклы язучылары, галимнәре Тукайны үз әдәбиятларына иң якын торган, күп кенә язучылар иҗатына уңай йогынты ясаган бөек һәм интернациональ рухлы шагыйрь итеп тануларын сөйләделәр. Төрки халыклар әдәбиятында Тукайның якты урын тотуын без элек тә күпмедер белә идек. Әмма юбилей көннәрендә — Казанда һәм Мәскәүдә узган очрашулар, фәнни сессияләр дәвамында — Тукайның киң колачлы һәм куәтле шигърияте тугандаш әдәбиятлар үсеше өчен рухландыргыч, шифалы бер чыганак булуын без беренче мәртәбә бөтен тулылыгында ишеттек. Безнең өчен бу билгеле дәрәҗәдә ачыш булды, әдәби бәйләнешләрнең традициясенә, үзенчәлекләренә киңрәк, тирәнрәк карарга ярдәм итте, яңа фәнни бурычлар билгеләргә мөмкинлек ачты. Шул бурычларның берсен «Тукай — чит телләрдә» дип атарга мөмкин булыр иде. Аңлашылса кирәк, сүз Тукай иҗатының СССР халыклары әдәбияты белән бәйләнеше, шагыйрьнең тугандаш халыкларга никадәр таныш булуын өйрәнү турында бармый. Бу мәсьәлә, югарыда әйтелгәнчә, елдан-ел киңрәк тикшерелә, ачыклана бара. Әмма Тукайның көнбатыш Европа телләрендә, мәсәлән инглиз, немец, француз һ. б. телләрдә басылган әсәрләре турында, шагыйрьгә багышлап шул телләрдә язылган мәкалә яки хезмәтләр турында без нәрсә беләбез? Сүз менә шул хакта бара. Әлегә хәтле татар совет галимнәре игътибарыннан һаман читтә калып килгән, ләкин җитдилеге белән көн тәртибеннән төшми торган әһәмиятле проблемаларның берсе бу. Аның әһәмияте әдәби-эстетик рамкалар эчендә генә калмыйча, идеологик бер төс һәм политик яңгыраш ала.

Тукай турында һәм гомумән татар халкының Октябрьга кадәрге һәм совет чорындагы культура тормышы, әдәбияты, сәнгате, аерым язучылары турында Европада һәм Америкада әледән-әле аерым хезмәтләр, мәкаләләр чыгып тора. Әмма моңа хәтле без ул әйберләрнең библиографиясен туплаудан ерак китә алмадык. Аларда халыкның культура тарихы, әдәби-иҗтимагый хәрәкәт, Тукай һәм башка күренекле язучылар иҗаты дөрес бәяләнгәнме, әгәр дөрес түгел икән, әдәбият, культура тарихын бозучыларның позицияләрен, асыл максатларын, чын идеологик йөзләрен без үз вакытында фаш итеп барабызмы? Кызганычка каршы, бу сорауларга уңай җавап бирү кыен. Чит телдә чыккан әйберләрнең нинди хезмәтләргә таянып язылганын да, аларда совет галимнәренең тикшеренүләре ничек файдаланганлыгын да без бик аз беләбез. Боларны җентекләп һәм фәнни нигезләп өйрәнү, яхшыны яманнан аерып күрсәтү өлкәсенә безнең галимнәр моңа хәтле гафу ителмәслек кыюсызлык күрсәтеп килделәр. Шушы уңай белән Тукай турында соңгы ун ел эчендә басылган хезмәтләргә күз төшерик. Г. Халит һәм М. Гайнуллин, Р. Башкуров һәм И. Нуруллин, Р. Ганиева һәм Ә. Исхак китапларында, шагыйрьнең иҗтимагый-социаль карашларына бәя биреп үтелгән хезмәтләрдә (К. Фасеев, Р. Нафигов китаплары), аерым мәкаләләрдә, фәнни җыентыкларда, ниһаять, Тукайның татарча дүрт томлыгында, русча ике томлыгында, сайланмаларында без күп төрле чыганаклар белән танышабыз. Ләкин бер генә урында да шагыйрьнең чит телдә басылган әсәрләре, аның хакындагы әдәбият исәпкә алынмый. Ә бит андый әдәбият бар. Әле 1914 елда ук Англиядә Вильямсонның «Россия мөселманнары» дигән мәкаләсендә Тукай турында мәгълүматлар бирелә һәм шагыйрьнең «Пар ат» шигыре инглизчә тәрҗемә ителеп басыла. Аңа кадәр Тукайның тормышы һәм иҗаты турындагы мәкаләләр Истамбулда «Төрек йорты»

журналында чыккан була. 1921 елда Будапештта чыга торган журналларның берсе шагыйрь иҗатына зур гына урын бирә. Хәзерге вакытта библиографлар туплаган материаллар нигезендә без Тукайга багышланган мәкаләләрнең, аның шигырьләренең утызынчы еллардан алып бүгенге көнгә кадәр төрле илләрдә, төрле телләрдә һаман басылып килүен беләбез. Моны раслаган кайбер өстәмә фактлар шагыйрьнең 80 еллыгын билгеләп үткән көннәрдә мәгълүм булды.

Тукай юбилеена килгән хөрмәтле кунаклар арасында бер чит ил кунагы да бар иде. Гомәр әфәнде Тагер безгә төньяктагы күршебез — Финляндиядән килде. Ул Финляндиядә яшәүче аз санлы татарлар арасыннан чыккан бер галим, Хельсинки университетында алтай-төрки халыклары телләрен укытучы. Үзенең остазы, угро-фин һәм төрки телләр белгече Мартти Рясянен тәкъдиме буенча ул докторлык диссертациясе өчен тема итеп Г. Тукай иҗатын сайлаган. Казанга килгәч, Гомәр Тагер әфәнде шул хезмәте өчен материаллар җыйды. Тукай архивын өйрәнде, фәнни китапханәләрдә шагыйрь иҗатына караган диссертацияләр һәм китаплар белән танышты. Юбилей көннәрендә үткәрелгән фәнни конференциядә катнашудан тыш, ул башка кунаклар белән бергә Кырлайга барды, шәһәребез белән танышып йөрде.

Гомәр Тагерның Казанда үткәргән көннәреннән иң истәлеклесе Тукай иҗатын өйрәнүче әдәбиятчылар белән очрашу булды. Нәкъ менә шул очрашу вакытында шагыйрь иҗатын чит телләрдә өйрәнү мәсьәләсе яңа бер яктылыкта һәм проблема буларак калкып чыкты. Гомәр Тагер бу очрашуда үз хезмәтен әүвәл фин телендә язып, соңыннан инглиз телендә китап итеп әзерләргә ниятләнүен белдерде. «Тукай турындагы тикшеренүемнең татар совет галимнәре язган хезмәтләр белән аваздаш булуын теләр идем», — диде ул. Фин галиме безнең әдәбиятчыларны диссертациясенең планы белән таныштырды, хезмәтенең кереш өлешендә Тукай турында чит телләрдә чыккан чыганакларга тукталачагын әйтте. Андый чыганакларның бер өлешен Г. Тагер үзе белән алып килгән иде. Арада утызынчы-кырыгынчы елларда немец, венгр, төрек телләрендә чыккан мәкаләләрдән тыш, татар телендә басылган бер җыентык та бар иде. Кечкенә күләмдәге бу җыентык әле быел гына Тукайның 80 еллыгы уңае белән Финляндиядә басылган. Анда шагыйрьнең лирик әсәрләре белән беррәттән публицистик иҗатыннан да үрнәкләр бирелгән.

Татар галимнәре Г. Тагерның эш планын нигездә уңышлы дип таптылар, хезмәтен фәнни яктан камилләштерү өчен файдалы киңәшләр бирделәр, уңыш теләделәр. Очрашу вакытында әйтелгән кайбер фикерләрне искә төшерик. Профессор Х. Госман болай диде: «Тукай безнең өчен ачылган, әмма көнбатыш дөньясы өчен ул әле ачылмаган. Сезнең хезмәтегез татар әдәбиятын көнбатыш әдәбияты белән бәйли торган бер күпер булсын иде. Тукайның гыйбрәтле тормыш юлын, киң колачлы иҗатын Европа халыкларына дөрес итеп күрсәтү бик әһәмиятле мәсьәлә». Профессор М. Гайнуллин: «Яшегез олы булса да, Тукайны өйрәнү Сезне яшәртер, Гомәр әфәнде. Игътибарыгызны Тукайның чит телләрдә өйрәнелү мәсьәләсенә юнәлтеп дөрес эшлисез. Әмма монда чит ил матбугатында басылган әйберләргә тәнкыйть аша карарга кирәклеген онытмаска кирәк». Тукай белгечләреннән Г. Халит тә диссертация планын хуплап чыкты һәм үзенең бер теләген белдерде. «Сез безнең хезмәтләрдән иркенләп файдаланыгыз, киләчәктә дә киңәшергә безгә килегез. Сезнең иҗатыгызны чикләргә җыенмыйбыз, Тукай дәрья кебек ул», — диде. Фольклорчы Х. Ярми хезмәттә Тукайның халык әдәбияты белән бәйләнешен күрсәтү буенча киңәшләр бирде. Очрашуда яшь галимнәрдән Р. Башкуров, Р. Ганиевалар да чыкты.

Гомәр Тагер әфәнде соңгы сүзендә татар галимнәренә күп рәхмәт әйтеп, Финляндиягә кайткач, андагы татарларны безнең әдәбият, сәнгать, культура тормышы белән якынрак таныштыру өчен «Тукай җәмгыяте» оештырырга теләге барлыгын белдерде. Татарстан республикасында культура тормышының кайнап торуы, бай булуы, милли әдәбият, сәнгать, фән өлкәсендәге искиткеч уңышларга соклануын да яшермәде кунак. Мәскәүдән Хельсинкига китәр алдыннан безнең институт дирекциясенә җибәргән телеграммасында Г. Тагер шулай яза: «Бөек Тукай туган җирдә күрсәтелгән кунакчыл ихтирам өчен Татарстан республикасы хөкүмәтенә, институт дирекциясенә, татар филологларына чын күңелдән рәхмәт. Командировкам файдалы булды. Татар халкының фән, культура өлкәсендәге зур уңышларын үз күзем белән күрдем. Тагы да килергә өметем бар. Татар галимнәренә яңа иҗат уңышлары, яхшы сәламәтлек телим».

Г. Тагер әфәнде хәзер Финляндиядә. Без аның фәнни эшчәнлегендә уңышлар телибез һәм бөек шагыйребез Г. Тукай иҗатын чит телләрдә өйрәнү өлкәсендә башлаган хезмәтенең чын мәгънәсендә фәнни булуын, халыклар дуслыгын ныгытуга, әдәби бәйләнешләрне баетуга бер өлеш булуын өмет итәбез.

И. НАДИРОВ

# ШАГЫЙРЬ ТУРЫНДА ШАГЫЙРЬ

*Мөхәммәт Садри*

## АРФА МОҢНАРЫ

Шагыйрь Илдар Юзеевның «Поэмалар»[1] китабын укып чыккач, үзенне арфа моңнарын йотлыгып тыңлагандай хис итәсең. Менә китап битләре ябылды — йөрәктә яшьлек хисләре артты һәм бу хисләр ниндидер әкияттәге алсу кошлардай канатланып биеклекләргә менәргә, тормыш ямен күрергә, илеңә тагы да тырышыбрак хезмәт итәргә, кешеләргә яхшылык күрсәтеп яшәргә рухландыргандай булдылар. Менә тагын уйланасың һәм ул уйларың яңадан китаптагы яхшы, саф күңелле кешеләргә кайта, аларның әйбәт язмышларына шатлана, җәмгыятебез үсешенә, яңалыкка каршылык күрсәтергә маташучыларга нәфрәтләнә. Кыскасы, шагыйрь иҗат иткән, шагыйрь уйнаткан арфа моңнары йөрәккә кереп урнаша, дулкынландыра. Чынлап та, поэмалардагы Миләүшә, Шамил, Таймас, Кадрия, Нур кебек саф күңелле яшьләр, Бөек Ватан сугышында чыныккан, «телләр» аулап йөргән разведчик Галләм абзый, дөньяның ачысын-төчесен татыган ана — Гөлчирә образлары укучыда якты тәэсир калдырып, бигрәк тә яшьләрне шул гүзәл кешеләрчә яшәргә өндиләр, аларга дөрес юнәлеш бирүдә ярдәм итәләр. Тормышка аек акыл белән карап, алга, яңага кыю баручы кешеләр арасында әле кыюсызлары һәм куркаклары, алай гына да түгел, кычыткандай чагучылары, кое агулаучы явызлары һәм балга дегет салып бутаучы тинтәкләре дә яши икән. Автор, безнең алдыбызга Хәмзә, Нәфис, Дим Бикхуҗин кебек кире типларны нәфрәт тудырырлык итеп китереп бастыра, яшьләрне Фазылҗандай куркак булмаска, тормышның җиңел якларын гына эзләмәскә чакыра.

«Миләүшә» поэмасында, сабан туе ыгы-зыгысы вакытында, Хәмзә исемле егет, ат белән килеп, «Коммунизм» колхозы кызы Миләүшәне үз авылына урлап китә. Бу күңелсез хәбәр бик тиз мәгълүм була. Миләүшәнең сөйгән егете, колхоз председателе шоферы Шамил, Галләм абзый белән бергәләп, «Волга» машинасында әлеге каракны куа китәләр. Галләм абзый, никах укырга килгән мулла булган булып, Хәмзәдән ишек ачтыра һәм разведчикларга хас җитезлек белән каракка капчык кидереп өлгерә:

Тыпырчынма, кияү егет,
Узынма,
Киттек, Шамил, газуй
Коммунизмга! —

ди ул, Шамилне ашыктырып. Шулай итеп кыз урлаучы тотыла, капчыктагы Хәмзәне сабан туе мәйданына алып килеп, бөтен халык алдында фаш итәләр.

---

[1] Илдар Юзеев. Поэмалар. Татарстан китап нәшрияты. Казан, 1966. Редакторы Х. Камалов.

Драматик поэзия әсәре формасында язылган «Таймас» поэмасы күләме белән дә зуррак һәм катлаулырак та. Анда, бу чын йөзен яшергән кеше икән, халык дошманнары улы икән, дип Таймасны укыган җиреннән, ВУЗдан чыгаралар. Соңыннан барысы да ачыла: Таймасның әти-әнисе яла ягу аркасында кулга алынганнар, ә аларга яла ягучы Дим Бикхуҗин дигән бәндә икән. Аның йөзе Таймас белән Кадрия туенда ачыла. Ә Кадрия Дим Бикхуҗин кызы була. Туй башланганда, кыз белән ата арасында драматик диалогтан соң, Кадрия икейөзле этисеннән баш тарта. Әлеге ата үзенең кызыннан:

— Алай булгач, сиңа кем ата? — дип сорауга, Кадрия:

— Стенада сүзсез карап тора

Чын коммунист!

Миңа шул ата! — дип җавап бирә һәм, яла ягу корбаны булган Алмас ягына — Таймасның этисе ягына күчә. Бу вакыйганың шулай чишелүенә, хаклык җиңүенә чын күңелдән ышанасың.

«Өчәү чыктык юлга» дигән поэмада сүз өч егет язмышы турында бара. Автор поэмада халык әкиятен искә төшерә:

Егет бәхет эзләп киткән, ди,  
Ике юл чатына җиткән, ди,  
Баганага такта кагылган,  
Ә тактага болай язылган:  
«Уңга китсәң — авыр,  
Әмма  
Бәхет ишеген ачар, ди икән,  
Сулга китсәң — җиңел,  
Әмма  
Бәхет синнән качар», ди икән.

Өч егетнең берсе, Фазылҗан исемлесе, «тормыш көймәсе»ннән төшеп ярга чыга да, «уф, арыдым», дип дусларыннан аерылып кала, ул үзенә җиңел юл эзли.

Без калдык уйлап кына,  
Син киттең уйнап кына:  
«Әйттер, типтер, сиптер, әйдә,  
Без җирдә кунак кына!»

Шуннан соң инде Фазылҗаннан «бәхет кача», ул судка эләгә. Ул нәрсә өчен судка эләккән, нинди җинаять эшләгән? Анысы шагыйрь эше түгел. Дусларыннан аерылып җиңел юлдан китәсең икән, изге теләгеңә, бәхетеңә ирешә алмыйсың, дигән фикерне куәтли шагыйрь.

Баштагы ике поэмада автор күбрәк чынбарлыкның җанлы күренешләрен, төрле характерны һәм типларны поэтик гәүдәләндереп бирсә, соңгысында яшьлек хисләре белән талпынып, аның дәртле омтылышын романтик фантазиясе белән баетып чагылдыра.

Шагыйрьнең халыкчанлыгы, тыйнаклыгы, поэтик аһәңе, шигъри теле, тормышка актив карашы, киләчәктә аның тагын да тирәнрәк, катлаулырак, Ватаныбыздагы зуррак вакыйгаларны чагылдырган поэтик әсәрләр иҗат итә алуына ышаныч тудыра. Арфа кыллары остарак чиертелсеннәр, халык моңнарын, хисләрен һәм теләкләрен поэзиянең яңа биеклекләрендә ишеттерсеннәр!



# Юмор һәм Сатира



*Фатих Хөсни*

## САБАН ТУЕ

### Хикәя

Бүтән кешеләрнеке ничек булгандыр, безнеке, чама белән әйткәндә, менә мондыйрак булды:

Файдаланылмаган бер ял көнем дә бар иде, шуны да кушып, иртәгә сабан туе якшәмбесе дигән көнне, хатынымны алып, хатыным янына тагы кечерәк кенә бер кул чемоданы да алып, тузан коеп кайту нияте белән, Арча ягына сәфәр киттек (сүз арасында кыстырып үтүем: мин үзем шәһәр сабан туйларын яратмыйм — исеректән һәм исерек ирләрен арттан игәүләп йөрүче хатыннарыннан башка, фу, нәрсәсе бар соң аларның!). Әйе, шулай. Әйе, киттек Арча якларына...

Бер ише кешенең безнең кулыбыздагы әлеге кечкенә чемодан белән кызыксынуы мөмкин: янәсе, нәрсә алдылар болар үзләре белән? Төрлечә юрауларга урын калдырмас өчен, чемоданны башта ук ачып күрсәтәм. Астрахань якларыннан күчтәнәч булып килеп төшкән берничә баш бик шәп вобла, хатын пешереп тыккан жиде-сигез пәрәмәч, аннары тагын... аннары тагын хатыннан яшереп тыккан бер савыт коньяк. Дөрес, мин үзем, аллага шөкер, эчемлек белән мавыга торган кеше түгел, әмма ләкин сабан туе вакытында, җитмәсә тагы аяк астыннан берәр таныш та очрап куйса, эчне тишмәс. Әйе, шулай. Әйе, киттек Арча якларына...

Казан белән Арча арасында йөри торган пригородный поездны күз алдыгызга китерә торгансыздыр. Комфорт дигәннәре әллә ни түгел, әмма озынлыгы бар. Озынлыгы, мин сиңайтим, кәгазьгә карап сөйләнә торган эчпошыргыч доклад хәтле. Бер очыннан икенче очына кадәр барам дисәң, берничә мәртәбә туктап су эчәргә кирәк. Кемгә-кемгә, әмма хатыным Саимә белән миңа таныш инде бу озынлык. Ник дисәң, бушрак урын эзләп, вагоннарның әлек берсенә, аннары икенчесенә башыбызны тыга-тыга, койрыктан паровозга хәтле, аннары, шул ук тәртип белән, паровоздан койрыкка барып чыкканчы икеме, өчме үткән кешеләр без. Шулай да күңелебезгә ятышлы, яки, һич югы, Саимәм миңа, мин Саимәм-җанкисәгемә янтаеп барырлык урын таба алмадык. Басса да басар икән поездны кунак! Ярты Казан Арча ягына агыла диярсең. Бөтенесенең дә, минем кебек, файдаланылмаган ял көннәре булдымы икән, әллә кайберләре, эшне казага калдырып, ял көннәрен алдан — аванс тәртибендә файдаланырга уйладылармы икән? — бу кадәресен һич ачыклап булмады. Әйе, шулай. Әйе, киттек Арча якларына...

Мин үзем бөтен вагоннар өчен дә җавап бирә алмыйм, мин хәтта үзебез утырып барган вагондагылар өчен дә җавап бирә алмыйм — нәрсә булмас Арча сабан туена китеп барганда. Мәсәлән, җыр, гармун кычкырту яки карар күзгә тәүфыйклы гына бер егетнең, әйтик, үзе белән рәттән утырып баручы чибәр генә бер туташка искәртмәстән генә орынып куеп, бичара кызны чырылдатып кычкыртып җибәрүе — моның ише вактөякләрне кем исәпләп торган инде анда. Күрердәен күрдем шулай да: мәсәлән, бер гуҗы вагонга кереп утыруы белән тотынды тавык ите ашарга, кешегә ләм-мим сүз катмады, бүтәннәр көлгәндә, көлеп вакытын әрәм итмәде, юл буе — тавык артыннан тавык — тәки ашады да барды. Сәбәбе дә булган икән, хәер. Вагоннан төшкәндә барлык кызыксынган кешеләргә берьюлы, анда да артык көч сарыф итәргә теләмәгән кебек, кыска гына итеп серне ачты бу:

— Йөдәттегез, хәер. Көрәшкә чыгарга әзерләнә торган кеше әллә ач барырга тиешме, сезнеңчә? Көрәшкә чыгарга дип барам мин!

Әйе, шулай. Әйе, барабыз Арча якларына...

Кунаклар арасында шау-гөр килеп бара торгач — безме күреп алдык, алармы безне күреп алды — якында гына утырган ирле-хатынлы кешеләр белән танышып киттек. Сез

кайдан да, без шуннан. Сез кая да, без шунда — күпме кирәк юлда танышып китү өчен. Үтә ачык чырайлы сузчән кешеләр булып чыктылар болар, ире Бишбалтадагы кайсыдыр бер әртилдә тегүче булып эшли икән, хатыны — шул ук әртилдән өйгә алып кайтып эшләүче, әйтүенә караганда, «җенләнеп тотынса, айлыкны унбиш көндә әйләндереп сала» торган, ә хәзергә исә «җене», туган авылына сабан туена кайтып, кардәш-ырулары арасында бер гөрләп алу ягына таба кузгалган бер адәм икән. Сабан туе вакытында туган авылга кунакка кайту — ай-һай ла, рәтең «рөхсәт итсә», моннан да хуп нәрсә бармы соң татарың өчен. Бусы аның шулаен шулай да, бик үк шулай булып җитмәгәне бар, менә хәзер шуңарга якынлашабыз. Үзләре шундый киң күңелле ходай бәндәләре булып чыктылармы, сөйләшә торгач, безнең бирәр үзебез белмәгән сөйкемле сөягебезне капшап таптылармы, кайта торгач, дөресрәге, үзенең туган-үскән Кәче авылына җитәрәк, моның хатыны, Кәче кешеләренең барысына да диярлек хас булган рыясызлык һәм катгыйлык белән, безнең алга мәсьәлә китереп куйды:

— Бүген сабан туе Арчада түгел, абый, — дип башлаганда ук бик тә өздереп башлады бу ачык чырайлы хатын, — бүген сабан туе безнең Кәчедә. Хәзер без менә болай итәбез: бергәләп безнең Кәчегә төшеп калабыз, бергәләп безнең Кәче сабан туен карыйбыз, иртәгә бергәләп Арча сабан туена менеп китәрбез, аннан күз күрер тагы...

Бу сүзләрне әйткәндә, ичмасам, я иренә, я безнең икебезнең беренә карасын, безнең ул тәкъдимне ничек каршы алуыбыз белән кызыксынсын икән. Әйтерсең, бу шулай әллә кайчан сөйләшенеп, хәл ителеп куелган. Әйтерсең, бу турыда ике төрле уйлауның булуы мөмкин дә түгел! Дөрес, бәлки үзем, бәлки, бу бик тә җайлы тәкъдимгә каршы да түгелдер түгеллеккә. Бәйрәмдә алтмыш коймак бер тиен, дигәндәй, шушы яшемә җитеп, Кәче авылында бер кич кунганым да, бер чүмеч суларын да эчкәнем юк. Шундый киң күңелле кешеләр үстергән Кәче авылында юл уңаеннан бер кич кунып, туры килсә, бер мунча кереп киткәннән җир җимерелмәс. Шулай да минем белән генә эш бетми, минем бит әле алны-артны бик тә уйлап эш итә торган хатыным, Саимәм-җанкисәгем бар, бу шаккатыргыч тәкъдимгә аны ничек күндерергә икән? Күндереп булырмы икән? Аннары тагы мәсьәләнең икенче ягы да бар: бу киң күңелле Кәче тумасы кеше өенә кунак чакырырга батыр батырлыкка да, әмма теге ни... без кайтып ишелергә тиешле өйнең хуҗалары булырга тиештер бит әле: алар ничек карар без юлдан табылган кунакларга?

Хәер, озак уйлап торырга вакыт булмады, безнең поезд бер генә служебный йорттан һәм берничә торак каралтыдан торган Кәче разъездына килеп тә туктады. Килеп туктавы булды — кайда монда озак сатулашырга вакыт — ханым безнең әлеге кечкенә чемоданны кулына алып, минем икеләнебрәк калган Саимә-җанкисәгемне икенче кулы белән җилтерәтеп, шул арада иренә «әйберләрне калдырма!» дигән каты фәрманын да биреп, вагон ишегеннән чыгарга да өлгерде. Үзегез хөкем йөртеп карагыз, мин нишли алам, ди андый вакытта? Ягъни көпә-көндез Саимә-җанкисәгемне кулымнан тартып алып киткән вакытта? Әлбәттә, мин дә тизрәк сикереп төшү ягын карадым.

Дөресен әйткәндә, безгә җиргә төшеп озак торырга, хәтта як-ягыбызга карарга да туры килмәде, шундук тимерле арбага тук кына алаша җиккән берәү, ут уйнатып, килеп тә җитте. Шау да гөр, туганнарча кочаклашу, күрешү. Бу ат белән алмага килүче Мәсрүрәнең энесе булып чыкты, ә Мәсрүрә дигәнем — минем Саимәне җилтерәтеп алып китүче, ә мин — үзегез беләсез — Саимәм-җанкисәгем итәгенә тагылган итагатьле ир. Энесе боларның үзләренә караганда да ачык, киң күңелле, кунакчыл бер адәм булып чыкты. Бернинди сорашу, анкета тутырып тору булмады, күз ачып йомганчы безне тимерле арбаның түренә, палас белән түшәлгән йомшак печән өстенә менгезеп, Саимәм белән рәттән, аякларыбызны төреп утырттылар болар. Апасы белән җизнәсе ике як үрәчәгә ничек кирәк алай эләгеп өлгерде һәм китте элдереп әлеге тук алаша, китте элдереп... Күз ачып йомганчы без инде аларның ишек алдында идек.

Монда да шулай бик тә кызу тоттылар безне. Өйнең хуҗасы Латыйп — Мәсрүрәнең энесе була инде ул — әшне апасына караганда да кызурак тота торган кеше икән. Бәйрәм көн итеп алдан да чак кына кыздырып өлгергән иде булса кирәк, төптән юан чыккан, трактор кебегрәк бер кеше. Танышкач белеп алдык, үзе дә шул трактор бригадасы бригадиры икән. Куырырга өйрәнгән, «әйдәгез, мәйданга хәтле бер утырып алабыз» дип кенә тора. Үзе шунда тагы каударлану аркасында булса кирәк, киресен дә сукалап ташлый: «Мәйданы да качмый, обшом, бездән берсе дә качмаячак... Иркенләп бер утырабыз да, ат безнең карамакта, тояләбез дә китәбез мәйданнарына», — кемнең кем артыннан керергә тиешлеген чамалап торган юк, барыбызны да берьюлы куа бу өстәл артына. Кыскасы, ун-унбиш минуттан без инде түгәрәк өйнең түрендә идек. Коймак, кабартма, салкын ит, кайнар ит, әче бал, төче бал, шәльяулык, шәрә муен, пичәтлесе, кисмәклесе, чакырып килгән кунак, юлдан табылган кунак — барысы бергә буталып беткән иде инде. Безнең теге бәләкәй чемодандагы байлык та, әлбәттә, ярап куйды. Бигрәк тә вобласы. Латыйпның хатыны, яшь кенә киленчәк, үзе тел язмады — олылардан ояла, янәсе. Бичараның балага узып йөргән вакыты икән, тансык аш вобланы күргәч, бөтенләй такатьсез калган теге. Шулай да Латыйбына тел язмыйча булдыра алмаган. Ә Латыйбы — хатыны дигәндә минем кебек җилъяграк бер адәм икән — аны-моны уйлап тормастан, табыннан вобланы дәррәү алып китү ягын карады.

— Бу малга башка бер афтаритетлырак урыннан бик каты сорау бар, егетләр, — диде ул, тантаналы рәвештә белдерү ясап, — гаепләштән булмасын, хәзергә ликвидировать итеп торам мин моны.

Озын сүзнең кыскасы шул, Астраханьнан кайткан вобла аркасында безнең бәя тагын да күтәрелә төште монда. Хәтта, әйтергә мөмкин, юлдан табылган кунакларның кадере, чакырып кайтарылган кунакларның кадеренә караганда, бермә-бер үсеп китте. Һәм, гомумән, китте, малай, эшләр ходка!

Әйе, шулай. Әйе, йөрибез Кәче җирләрендә фырт-фырт басып. Монда без юлдан табылганнар файдасына эшли торган тагы бер тарих килеп чыкты, анысы турында, тиле кеше әйтмешли, туктап, билбауларны чишеп сөйләмичә булмый.

Шулай, бик түгәрәкләнеп, шау-гөр килеп, сыйланып, кемнең кайда хезмәт итүе белән танышып һәм, баш бик каты эшли башлагач, базарны күтәрү өчен ара-тирә борчак та сипкәләп, кыскасы, кәеф тәмам килгәч, мәйданга барырга җыйнала башладык. Менә шунда кунак хатын Мәсрүрә үзенең хәләл кияве Хәйрине, Кәче авылы кешеләренә аеруча шәп итеп күрсәтү нияте белән булса кирәк, бездән аерып, чоланга алып кереп китте һәм бичараны, арттырып җибәргәнлеге өчен, нык кына пешекләде. Чолан тактасы аркылы аларның барлык сүзләре дә безгә ишетелмәде, хәер, ишетелгән булса да, чыгармас идем — бергә ашап-эчкән кешенең гайбәтен сату килешәме соң! Кыскасы, чоланнан чыкканда Мәсрүрә ханымның Хәйри-бәгырькәе тәмам һушына килгән, артыкны бер сүз дә сөйләми, хәтта хатыны сораганда кирәген дә әйтми, шулай да Мәсрүрәсе аны, авылдашлары алдында матур күрсәтәсе килеп, чын-төзек итеп, баштанаяк өр-яңадан киендереп чыгарган иде.

Хатын-кыз әйләнә алмыйча калдымы дип әйтим, әллә теге чоланда Мәсрүрә белән Хәйри кияү арасында булып алган «пышылдашу» тәэсирендә инде, нәрсә булса да булгандыр, без — ирләр мәйданга, ничектер, аерымрак киттек. Бүгенгедәй күз алдымда: кояш төшлектән авышкан, әмма шулай да көн бик эссе, мәйдан булачак болын әлсерәп яткандай күренә һәм шул әлсерәп яткан болынның әле теге тугаеннан, әле бу борылышыннан безне чакырган да, үртәгән дә кебек булып Казанка суы елтырап килеп чыга иде. Безнең йорт хуҗасы, барысын да белә, барысын да алдан чамалый торган әлеге шул тракторчы Латыйп:

— Әле мәйданга иртә. Әллә, егетләр, мәйданга хәтле су кереп, салкын җыеп алабызмы? Безнең монда бик шәп бер тугаебыз бар, — дип, искәртмәстән генә күңелне иләсләндереп куймасынмы! Күпме кирәк кешегә очып китү өчен. Бигрәк тә сабан туе вакытында. Бигрәк тә өстән кояш, эчтән теге «шайтан суы» кыздырып торганда. Без, әлбәттә, Латыйпның тәкъдимен бер тавыштан күтәреп алдык. Ә Латыйпның җизнәсе — әлеге теге Мәсрүрә ханым чоланга алып кереп пешекләп һәм өр-яңадан киендереп чыгарган кеше — болай үзе бер дә артык очынган кебек түгел иде. Күрәсең, барысы да эчендә булгандыр. Килеп җитүебез булды тугайга, борылып карарга да өлгермәдек, чишенеп-мәшәкатьләнеп тормыйча, әле генә киенеп чыккан өр-яңа өсте-башы белән, өч метрлы ярдан туп-туры чоңгылның нәкъ күзенә барып төшмәсенме!

Җитмәсә тагы рәтләп йөзә дә белми икән. Бер калкып чыкты бу, ике калкып чыкты, өченче мәртәбә өзек-өзек тавыш биреп куйды, аннары башындагы береты калкып килеп чыкты һәм шуның белән киявебез-бичара тәмам... дип нишләргә белмичә торганда, бар икән тәвәккәллек хуҗабыз Латыйпта: туп шикелле ыргылды бу суга. Аның артыннан без ыргылдык. Береты кадалып китсен, аягындагы сандалеткаларының да берсе агып киткән, әмма җыйнаулашып эзли торгач, кияүне ничек кирәк алай чоңгыл төбеннән тартып чыгардык, әй. Күзгә ташланганы тагы шул булды: бу вакыйгадан соң барыбыз да, бигрәк тә кияү үзе, дәррәү айнып калган идек.

Әлбәттә, ул көнне сабан туен рәтләп күреп булмады. Без кияүнең эченә кергән Казанка суын һәм Казанның үз «суын» ничек кирәк алай бушатып, аның өстен-башын киптерешеп, һәрхәлдә, бичараны азмы-күпме адәм кыяфәтенә кертеп, мәйданга барып җиткәндә, соңгы чүлмәкне ваталар иде инде. Шулай да без — бүтәннәребез — көрәшне, балалар чабышканны карарга өлгердек. Тик Хәйри кияүгә генә күрү насыйп булмады. Күзгә күренүе белән аны Мәсрүрә ханым, тырнагына каз бәбкәсе эләктереп киткән тилгән кебек эләктереп, өйгә алып китте һәм кичкә хәтле чоланга бикләп куйды.

Кич белән терелеп, өстен-башын алыштырып чыккан иде, хәер. Хәтта тәмам акылга утырып, хатыны Мәсрүрә ханым белән, кала кунаклары сыйфатында, култыклашып авыл карап, шул бер уңайдан, авылга үзләрен күрсәтеп йөрергә дип тә торалар иде. Кулына-аягына «кунак» дип атала торган тышау салынгач, үз теләгең белән йөрерсең, бар. Кичкә Латыйпның өлкән абзыйсы чәйгә дәште. Алардан чыгуга Латыйпның хатыны ягыннан бабалары көтә, имеш. Алардан чыгуга шул ук Латыйпның югары очтагы кендек әбисенә... Алты почмаклы яңа өй җиткергәннәр, өй туе белән сабан туе бергә булачак, имеш, ди.

Ярый инде, аларның үз эше. Туган-тумача шушындый зур бәйрәмдә бер җыелган икән, әйдә, йөрешә бирсеннәр. Ләкин, мин кем монда? Минем Саимәм кем? Ни өчен мин өйдән өйгә кунакка йөреп, азап чигәргә тиеш? «Барысы да синең аркада. Син ныграк торган булсаң, без мондый чытырманлыкка килеп капмаган булыр идек», дип басылдыйм хатынга кеше күрмәгәндә генә. Ә хатыным авызын ерып тик тора. Түр башында кунак булып утыруга тәмам иләшкән. «Ник алай дисең, картым? Рәхәт ич, кеше белән бергә, шау-гөр килеп, кунак булып йөрү» дип теленә салына. Рәхәтен рәхәт тә, шулай да кем соң без монда? Менә нәрсә эчтән кимерә мине.

Аптырагач, чакыра килгән кешеләрнең берсенә шулай дип әйтеп тә караган булган идем. Авыз да ачтырмады. «Кем булсаң да бул, син бүген безнең кунак. Ә бездә кунактан анкета тутырту гадәте юк», дип кенә җибәрде.

Шундый язмышка дучар булганбыз икән, нишләмәк кирәк, тузәргә туры килә шул. Бер йорттан икенчесенә, икенчесеннән өченчесенә кучә-кучә һәм, әйтергә кирәк, барысында да түр башында — иң дәрәҗәле урында утырып, булдыра алган хәтле акыллы сүзләр сөйләп, ә тулаем алганда, булган барлы-юклы акылыбызны да югалтып, сәгать төнге берләр тирәләрендә көч-хәл белән кайтып аудык. Әлбәттә, рәтләп йокы алмады, чөнки почетлы кунак итеп, Саимәм-җанкисәгем белән миңа урынны өйгә, өйнең дә нәкъ түренә — мамык түшәк белән мамык ястык түшәлгән кроватька салганнар иде. Иртәдән алып, көннең-көн буена ризык, аш-су пешкән өйдә болай да эссе иде, инде килеп күпертеп җәелгән мамык түшәк белән мамык ястык өстенә Саимәм-тимер мичем белән рәттән менеп кунаклагач, бөтенләй түзәр әмәл калмады. Җитмәсә тагы чак кына яктылык сирпелә башлау белән — элек берсе, аннары икенчесе, аннары бишенчесе, аннары унбишенчесе — чебен кузгалды.

Юк, шунда мин, кунаклыкның бөтен шартларын җимереп, аякка бастым.

— Булмый, — дидем мин, Саимәмнең баш очында пышылдап, — син теләсәң нишлә, мин печәнлеккә менеп ятмыйча булдыра алмыйм.

Көндез лапас түбәсендәге тезмәдә кипкән печән күргән идем, бер нәрсә дә алмыйча, киттем шул печәнлеккә. Бераздан мышкылдап Саимәм-җанкисәгем дә менеп җитте. Хуш исле яшь печәнгә башларыбызны куеп, рәхәтләнеп йоклап киткәнбез.

Озак йоклаганбыздырмы, бер заман шау-шуга уянып киттем. Аста, өй-келәт арасында хатын-кызның, тыела төшеп, ләкин шулай да тәшвишле тавыш белән, берсеннән берсе таптырулары ишетелә:

— Кайда булдылар соң? Әллә, ходаем, җәеп куйган урыныбызны ошатмадылар микән? — ди берсе.

— Ире аның кичнең кич буе «китик-китик!» дип кымырҗытып торды, әллә иртәнге салкын белән китүләре шул булдымы? — ди икенчесе.

Өченчесе, минем урындык аркасына киертеп куйган костюмны күреп алган булса кирәк, берьюлы кистерде:

— Әнә ич кәчтүне эленеп тора, кәчтүн-чалбарсыз кая китсен, ди, кеше.

Кайда монда йокы, безне — почетлы кунак итеп — яңа гына өлгергән чиста мунчага әзләүләре икән. Башыңа төшкәч, бер нишләп тә булмый — күзебез ачылыр-ачылмас көйгә, киттек шул Саимәм-җанкисәгем белән мунчага. Дөресен генә әйткәндә, бөтенесе дә Хәйри кияүнең кичә артык шаукымга бирелүе аркасында. Өр-яңа өс-баш белән суга сикермәгән булса, югыйсә, бүген чиста мунчага Мәсрүрәсе белән аны җибәрергә тиеш булганнар. Күпме кирәк соң күздән гөшү өчен!

Мунчадан чыккач, кичәге тәртип белән диярлек, янә башланып китте. Элек, әлбәттә, хуҗаларның үзләрендә мунча чәе. Аннары аларның уң як күршеләре дәште, алардан чыгуга өлкән хуҗаның, ягъни Латыйпның әнисе — туган-үскән йортка — бармый кара андый олы урынга.

Алардан кайткач, «Безгә дә безгә!» дип, тагы өч кеше чиратка басканнар иде дә, ул арада Латыйп — яшь хуҗа арага керде:

— Берегезгә дә түгел, хәзер Арчага сабан туена менәбез, — диде ул, сузыла башлаган сүзләрне трактор гусеницасы белән өздергән кебек итеп.

●

Арча сабан туенда күргәннәрне сөйли яки яза китсәң, китап бастыра торган «Дом печать» дигән биш катлы йортның кәгазе төтмәс, я булмаса сменама соңга калырмын. Сабан туе булгач — сабан туе инде: шау-шуы да, җыры-гармуны да, аяк тыпырдатып биюләр дә, ат чабышлары да, көрәш тә булды. Көрәш дигәннән, теге безнең белән бер вагонда юл буе тавык ите төеп килгән кеше дә көрәшкә чыккан иде, хәер, озак чуалып йөрергә бирмәделәр. Берәүне ничек кирәк алай әүмәкләп, әтәчләнеп тагы кереп баскан иде, икенче бер йомры гына адәм моны баш аркылы шундый томырды, мәйдан халкы «ма-ла-дис!»диргә генә өлгереп калды. Беренче алган белемем шул булды: юк икән, гуҗлык белән генә алдырып булмый икән сабан туенда.

Икенче ишеткәнем тагы шул булды: кичәдән бирле безне кунак иткән Латыйп, фамилиясен дә кушып әйткәндә, Латыйп Шакирҗанов гади трактор бригадасы бригадиры гына түгел, Арча районындагы алдынгы бригадирларның берсе икән! Аның бригадасы язгы чәчүне, иң яхшы күрсәткечләр белән, иң алдан ерып чыккан. Латыйпның исеме орденга куелган, имеш. Кара әле син кешене, утыра синең белән, сөйләшә синең белән, сыйлый сине, ә үзенең нинди шәп кеше булуы турында ләм-мим. Сабан туе комиссиясе председателенең мәйданны ачканда сөйләгән речьennән ишетеп калмасам, тәки белмичә китәчәк икәнмен. Бар шул әле бездә килеп җитмәгән яклар.

«Китәсе» дигәннән, китү ягын мин чынлап та коры тоттым. Кәчедә кунакка чакырып чиратка баскан кешеләр дә күңелгә курку салган иде, иртәгә иртүк эшкә дә барасым бар, ачып кергән ишекне вакытында ябып чыга да бел. Хәер, без кергән ишектән түгел, — ул ишеккә яңадан әйләнеп кайтсак, безгә тиз генә чыгу юк иде. Кунакчыллыгы өчен Латыйпка, аның вобла яратучы яшь кәләшенә, аның аш-суга бик оста әнисенә, аның киң күңелле кардәш-ыруларына бик күп, бик күп рәхмәтләр әйтеп, күңел өчен үзен дә шунда кулдан килгәнчә сыйлап, Арча аркылы үзебезнең Казаныбызга кайтып киттек.

Әйе, шулай. Әйе, булдык без Арча якларында. Күрдек без киң күңелле әйбәт кешеләр.

Июнь, 1966.

*Басыйр Рафиков*

## Анның хыялы

Түбәтәенә тормаслык
Бер карт үзе,
Сөйләшкәндә авызыннан
Чыкмый сүзе.
Ә карасаң, күкрәгендә
Алтын медаль.
Соң бит аны тагып йөрү
Минем хыял!
Минме инде эшләмәдем
Бу колхозда.
Булып тордым председатель дә,
Завхоз да,
Завферма да, бригадир да,
Әллә кем дә...
Чабып йөрдем колхоз диеп
Көн дә, төн дә.
Эшләдем мин халык өчен
Янып-көеп,
Һәр урында боерык яздым
Өеп-өеп.

Бирмәделәр төпләнергә
Бер урында.
Күчерделәр бер урыннан
Бер урынга.
Сөйләделәр минем турыда
«Сала» диеп,
Колхозыбыз шуңа артта
Кала диеп.
«Салган» өчен колхоз эше
Каламыни?
«Дус-ишләр»сез тормыш алга
Барамыни?
Көтүченең күкрәгендә
Алтын медаль, —
Нигә аңа эләккәндер
Минем хыял?
Медаль түгел, рәхмәт сүзе
Алалмадым,
Аңламыйм мин, халыкка ник
Ярамадым.

●

Иҗат итте
Җилкуар
Мемуар.

Китабында
Һичкем юк,
«Мине» бар.

## Гаҗәпләнгән кычыткан

Амбар артындагы бушлыктан
Бал кортына сөйли кычыткан:
— Икебез дә кеше чагабыз,

Бу бит безнең саклык чарабыз.
Нигә мине генә кимсетәләр,
Әйтче, нигә сине үрчетәләр?

## Белмәсен бала-чага

Мин яшь чакта — яшел чакта
Танышымнан сорадым:
— Нигә өйдә сөйләшәсез
Русча гына, туганым?
— Хатын булгач, — диде миңа, —
Шалтырый савыт-саба.

Кирәген, кирәкмәсен дә
Белмәсен бала-чага.

Картайгачтын танышларым
Күчкәннәр татарчага.
Сылтаулары һаман шул ук:
«Белмәсен бала-чага».

## Швейцар фикере

Үзе алырга яраткан
Начальник
Швейцарга төртми калмас
«На чай»лык.

## Тиз өлгергән тел белгече

Журналдагы чиле-пешле
Тәрҗемәне күргән дә:
— Татар теле — ярлы тел, — дип
Сукырана бер бәндә.

# РЕДАКЦИЯ ПОЧТАСЫННАН

## НИЧЕК АҢЛАШТЫЛАР ИКӘН?

Шушы елның май ае башларында Фәргәнә өлкәсендәге Тап районында була бу хәл.

Уң яктагы текә ярына басып, халык Сыр-Дәрья елгасында суның күзгә күренеп арта баруын кызыксынып күзәтеп тора. Су акрынлап аргы яктагы иңкү җирләрне басып, калкурак урыннарны кечкенә-кечкенә утрауларга әверелдерә бара. Акрын гына утлап йөрүче хайваннар да шундый утрауда бүленеп калалар.

Бу хәлне сизеп булса кирәк, иң элек сарыклар тынгысызланырга тотына. Олы сарыклар, су янына килеп, борыннарын суга төртеп карыйлар да, борылып, арттә калган бәрәннәрен «чакыралар». Бәрәннәре, куркыныч барын чыннан да төшенгәндәй итеп, тиз генә әниләре янына йөгереп киләләр. Аннары, аяклары җиргә тигәндә — йөреп, тимәгәндә — йөзеп, тәркем, бердәм төстә, куркынычсыз урынга чыга.

Алар артыннан ишәкләр, сыерлар кузгала. Ә су һаман арта бара.

Хәзер теге утраучыкта ике генә җан иясе — бия һәм аның колыны гына кала. Бар кешенең карашы шуларга төбәлгән. һәркем алар өчен борчыла.

Ә бияне ис дә китми — рәхәтләнеп имеп торучы колынын иснә һәм ялый бирә...

Карап торучы кешеләр ах та вах киләләр. Теге хайваннарны коткарырга бернинди дә чара күрә алмауларына хафаланалар.

Кинәт күңелгә дә килми торган могҗиза була шул чакта: бия колынын иснииснә һәм койрыгын болгый-болгый дүрт аягына тиң тезләнә, ә колыны, аякларын киң җәеп һәм титак-мыйтак кына атлап, әнисенең сыртына менеп атлана да башын аның ялына сала. Аннары бия тора һәм «җайдагын» утырткан килеш суга кереп, башын югары күтәреп, йөзә башлый. Йөзеп су басмаган урынга барып җиткәннән соң ярга чыккач, бия янә тезләнә. Колын, аяклары җиргә тигәч җайсызрак кына атлап, анасының башы өстеннән чыгып китә һәм булдыра алганча нык итеп селкенеп — тиресен калтыратып ала.

Бу хәлне күреп торган кешеләрнең кайберләре: «Колын анасы өстендә чакта аның ялын тешләп барды»,— дип сөйлиләр. Әмма шундый яшь колынның ничек алай эшли алуы һич тә башка сыймый. Белмим, ничек үзара аңлашты икән ул бия белән колын?!

М. ИШМӨХӘММӘДОВ.
*Фәргәнә.*

—●—

# Укучыларыбызга җавап

«Кадерле дуслар!

Без сезнең «Казан утлары» журналын бик яратып, кызыксынып укып барабыз. Анда басылган хикәяләрне, повестьларны, романнарны һәм шигъри әсәрләрне, хатыным Рәзифә белән бергәләп, кичләр буена чиратлашып укыйбыз. Анда басылган әйберләрне укыганда, үзебезне туган якта йөргәндәй хис итәбез. Сезнең журналда әсәрләрен бастыручы язучыларга чын күңелебездән рәхмәтләр укыйбыз. Озын сүзнең кыскасы шул: туган Татарстаныбызда басыла торган «Казан утлары»н бик яратабыз без.

Әмма безнең, ул журналдан тыш, татарча китаплар да укыйсыбыз килә. Тик аларны кайдан һәм ничек алдырырга мөмкин булуын белмибез. Татарстан китап сәүдәсенең «Книга — почтой» бүлегендә нинди татарча китаплар бар һәм аларны нинди адрес буенча алдырып була икәнен журналыгызда язып чыксагыз иде».

Кемерово өлкәсендәге Ленинск-Кузнецк шәһәреннән шахтер Гыйният Гаффаров җибәргән бу хатны. Иптәш Гаффаровның һәм, редакциягә мөрәҗәгать иткән тагын бик күпләрнең үтенечен искә алып, без Татарстан китап сәүдәсенең «Книга — почтой» бүлегендә комплектлау эшен башкаручы Сәҗидә Зиятдиновага мөрәҗәгать иттек. Ул безгә менә шушы исемлекне бирде һәм монда теркәлгән барлык китапларны да СССРның теләсә кайсы почмагыннан хат язып, соратып алдырырга мөмкин икәнлеген әйтте:

Кави Нәҗми. Сайланма әсәрләр. 3, 4 томнары. 1 с. 75 т.
Гомәр Бәширов. Сайланма әсәрләр. 2 нче том. 80 т.
Гариф Гобәй. Без үскәндә. Повесть. 60 т.
Идрис Туктар. Ике егет. Роман. 46 т.
Фатих Хөсни. Утызынчы ел. Роман. 73 т.
Шакир Мөхәммәдов. Сайланма әсәрләр. 70 т.
Рафаил Төхфәтуллин. Тамчылар ни сөйли. Повесть. 32 т.
Гадел Кутуй. Сайланма әсәрләр. 67 т.
Афзал Шамов. Яңгырлы кичтә. Хикәяләр. 62 т.
Нәби Дәүли. Яшәү белән үлем арасында. Повесть. 55 т.
Нәби Дәүли. Җимерелгән бастион. Повесть. 46 т.
Фатих Хөсни. Минем тәрәзәләрем. Повесть. 39 т.
Аяз Гыйләҗев. Зәй энҗеләре. Повесть. 52 т.
Салих Баттал. Сигезенчесе кем! Повесть. 46 т.
Муса Җәлил. Моабит дәфтәрләре. Шигырьләр. 44 т.
Нәкый Исәнбәт. Татар халык мәкальләре. 2 нче том. 2 с. 53 т.
Лев Толстой. Анна Каренина (Татар телендә). 1—2 нче томнар. 1 с. 57 т.
Газиз Иделле. Язучы һәм аның китабы. Тәнкыйть мәкаләләре. 50 т.
Әхмәт Фәйзи. Сайланма әсәрләр. 1—2 томнар. 2 с. 23 т.
Габдрахман Әпсәләмов. Алтын йолдыз. Роман. 1 с. 19 т.
Һади Такташ. Сайланма әсәрләр. 82 т.
Галимҗан Ибраһимов. Сайланма әсәрләр. 1, 2, 3 нче томнар. 75 т.
Татар халык җырлары. 1 с. 26 тиен.
Татар халык әкиятләре. 1 с 14 т.
Зәки Нури. Батырлар һәм матурлар. Очерклар. 12 т.
Вахит Монасыйпов. Сак булыгыз. Сатирик һәм юмористик хикәяләр. 6 т.
Гариф Галиев. Курайлы елга. Хикәяләр. 35 т.
Ләбибә Ихсанова. Космонавтлар урамы. Хикәяләр. 29 т.
Әдип Маликов. Кембригә юл салучылар. Очерк. 25 т.
Ибраһим Нуруллин. Тукай Петербургта. Пьеса. 18 т.
Хәй Вахит. Карлыгач канат кага. Пьеса. 15 т.
Риза Ишморат. Давылга табан. Пьеса. 36 т.
Таҗи Гыйззәт. Комедияләр. 80 т.
Русча-татарча сүзлек. 1, 2, 3, 4 томнар. 1 с.
Нурихан Фәттах. Бала күңеле далада. Роман. 86 т.
Әмирхан Еники. Өч повесть («Рәхмәт, иптәшләр», «Саз чәчәге» һәм «Рәшә» исемле повестьлар). 75 т.
Атилла Расих. Маҗаралы повестьлар. 69 т.
Шәүкәт Галиев. Уены-чыны бергә. Шигырьләр. 13 т.
Габдулла Тукай. Фотоальбом. 3 с.
Гариф Ахунов. Хыялый Хәйруш егетләре. Повесть һәм хикәяләр. 33 т.

**Бу китапларны түбәндәге адрес белән хат язып, соратып алдырырга кирәк:**

*г. Казань, ул. Баумана, 19, магазин № 1. отдел «Книга — почтой».*

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## СОВЕТ ВЛАСТЕНЕҢ 50 ЕЛЛЫГЫНА

Татарстан китап нәшрияты һәм Татарстан язучылары союзы Совет властеның 50 еллыгы хөрмәтенә «Тормыш матур дуслар белән» исемле әдәби җыентык әзерләде. Җыентык татар халкының бөек шагыйре Г. Тукайның рус һәм татар халыкларының дуслыгына багышланган шигыре белән ачыла. Анда Г. Ибраһимов, Г. Камал, Ш. Камал, М. Гафури, Ш. Бабич, Һ. Такташ, М. Җәлил, Ф. Кәрим, Х. Туфан, К. Нәҗми, М. Максуд, Г. Кутуй, Н. Баян, Г. Бәширов, М. Әмир, А. Шамов, Ш. Маннур, С. Хәким, С. Баттал, Г. Әпсәләмов, Ф. Хөсни, Б. Сирин, Ә. Исхак, З. Нури, Н. Арсланов, З. Мансур, Ә. Давыдов, Г. Хуҗиев, Ш. Галиев, Г. Латыйп, И. Юзиев, Ә. Юныс һ. б. татар язучыларының халыклар дуслыгына багышланган әсәрләре кертелде. Җыентыкның төзүчесе — Мөхәммәт Садри.

* * *

Татарстан язучылары коллективы бөек юлбашчыбыз В. И. Ленин турында «Һәркемнең күңелендә» исемле зур күләмле яңа китап әзерләде. Бу җыентыкка илебезнең тугандаш әдәбиятларыннан бөек юлбашчыга багышланган иң яхшы әсәрләр сайлап тәрҗемә ителде. Китапка рус язучыларыннан В. Маяковский, С. Есенин, К. Федин, А. Исбах, М. Шагинян, А. Твардовский, М. Исаковский, С. Шипачев, Н. Тихонов; Украина язучыларыннан — М. Рыльский, А. Малышко; белорус язучыларыннан — П. Бровка, М. Лужанин; казакъ язучыларыннан — Т. Жароков, С. Сәетов; Үзбәкстаннан — Мирмуксин, Т. Фәттах; әрмән язучыларыннан — С. Капутикян, Г. Эмин; Грузиядән — Г. Табидзе; эстон язучыларыннан — Ү. Лахт һ. б. милләт язучылары әсәрләре — барлыгы 200 дән артык әсәр кертелде.

* * *

Татарстан китап нәшриятында рус теленә бастырып чыгару өчен «Книга времени» исемле җыентыкка татар совет шагыйрьләренең Коммунистлар партиясенә, Ватанга, халкыбызның сугыштагы һәм хезмәттәге батырлыгына багышланган шигырьләре кертелде. Шигырьләрне рус теленә Ю. Окунев белән Вл. Соловьев тәрҗемә итте.

* * *

20 августта М. Горький исемендәге Культура һәм ял паркында, бөек Октябрьның 50 еллыгына багышлап, Бауман урамы бәйрәме үткәрелде. Паркта ял итүчеләр ул көнне Бауман урамының атаклы кешеләре, производство алдынгылары белән очраштылар, артистлар, композиторлар, үзешчән сәнгать коллективлары чыгышларын, спортчыларның уеннарын карадылар.

Ачык эстрадада әдәбият сөючеләр М. Садри, М. Хөсәен һәм Волгоград шагыйре Ю. Окунев белән очраштылар. Шагыйрьләр үзләренең Казан һәм Татарстан турындагы шигырьләрен укыдылар.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫНДА

Татарстан язучылары союзы каршындагы консультация бюросы июль—август айларында бер төркем яшь авторлар белән индивидуаль семинарлар үткәрде. Баулыда яшәүче Р. Ибраһимовның «Сулар ургә акса да» повестен, Чаллы районы Иштирәк авылыннан килгән Г. Метшин, Чиләбе шәһәре китапханә эшчесе С. Гәрәева, Уфа эшчесе Р. Фазлыев шигырьләрен, Казанның Ленин районы әдәби берләшмәсе члены З. Фәйзуллин хикәяләрен укып тикшерүдә Г. Галиев, З. Нури, Н. Арсланов, А. Әхмәт, М. Садри, И. Юзиев, Ә. Баянов, М. Хөсәен, Р. Гатауллин һ. б. лар катнашты.

## МУСА ҖӘЛИЛ ТУРЫНДА ЯҢА МАТЕРИАЛЛАР

Муса Җәлилнең утызынчы елларда ук илебезнең төрле почмакларында булуы, бик күп эшчеләр, колхозчылар, төзүчеләр белән очрашуы турында күп язылды. Ләкин аның Серов (элекке Надеждинск) ша-

һәрендә булуы турында бик аз кешеләр генә белә.

Свердловск өлкәсендәге Серов шәһәре элек-электән үзенең металлурглары, корыч коючылары белән данлыклы. Беренче бишьеллык елларында ук серовлылар үзләренең мактаулы эшләре белән бөтен илебезгә билгеле иде.

Татар металлурглары, эшчеләре өчен чыга торган «Эшче» газетасы 1932 елның җәендә эшче-хәбәрчеләр слетын үткәрә. Бу слетка катнашу өчен Мәскәүдән «Коммунист» газетасы сотруднигы Муса Җәлил килә. Слетка катнашкан 300 дән артык хәбәрчеләр алдында ул доклад ясый. Аннары завод, мартен цехларына юнәлә, эшчеләр белән совет матбугатының бурычлары турында әңгәмәләр үткәрә, аларга шигырьләр укый.

«Культура сарае каршында ул вакытта татар музыка, драма, хор түгәрәкләре эшләп килә иде,— дип яза «Серовский рабочий» газетасында (21 июнь, 1966 ел) укытучы-пенсионер Нәфисә Вәлиева. — Муса Җәлил кыска гына вакыт эчендә бу түгәрәкләрнең эшен җанландырып җибәрү өчен күп нәрсә эшләде. Аның инициативасы белән интернациональ-этнографик кичә оештырылды. Бу кичәгә руслар, татарлар, башкортлар һәм Германиядән килеп эшләүче немец белгечләре катнашты. Төрле телләрдә җырлар җырланды, төрле халыкларның музыкасы яңгырады».

Муса Җәлил татар драма түгәрәге күрсәткән «Башмагым» комедиясенә дә уңай бәя бирә.

Шагыйрь анда Беренче бишьеллык алдынгылары: тырыш хезмәте өчен илебезнең иң югары бүләге — Ленин ордены белән бүләкләнгән горновой Бикмансуров, өлкән горновой, илебез домналары арасындагы социалистик ярышта җиңеп чыгуы өчен җиңел машина һ. б. кыйммәтле бүләкләр белән бүләкләнгән Шәфигуллин, Сәгъдиев, Гыймранов һ. б. ударниклар белән таныша.

Шул ук вакытта М. Җәлил «Коммунист» газетасы өчен металлургия заводы турысында күп кенә материаллар җыя. «Коммунист» газетасы шуннан соң Надеждинск металлургия заводына махсус номер багышлый. Газетада күрсәтелгән кимчелекләрне бетерү һәм эшне җайга салу өчен эшче-крестьян инспекциясе комитеты махсус чаралар билгели.

## ТУГАНДАШ ӘДӘБИЯТ ВӘКИЛЛӘРЕ ТАТАРСТАНДА

Август аенда күренекле үзбәк драматургы Зиннәт Фәтхуллин, Казанда булып, Татарстан язучылары белән очрашты.

Үзбәкстаннан килгән икенче бер язучы — Әсән Рәхимов, бөек юлбашчыбыз В. И. Ленинның яшьлеге турында әсәр язу өчен материаллар өйрәнеп, Татарстанда Владимир Ильич белән бәйле урыннарда булды, музейлар белән танышты.

Каракалпак язучылары Т. Алланазаров, Г. Сәетназаров һәм У. Хужаназаров шулай ук В. И. Ленинга бәйләнешле материаллар җыю өчен Татарстанда булдылар, Кокушкинодагы һәм Казандагы В. И. Ленин музейлары белән таныштылар.

## ОЧРАШУЛАР, КОМАНДИРОВКАЛАР

Ибраһим Гази июль аенда Кама Тамагы районындагы үзенең туган авылында — Олы Карамалыда кунакта булды, авылдашлары белән очрашып, бүгенге татар әдәбияты турында сөйләде һәм яңа хикәяләрен укыды.

М. Горький исемендәге Казан культура һәм ял паркының әдәбият клубында И. Газиның «Онытылмас еллар» китабы буенча укучылар конференциясе булды. Конференциягә автор үзе дә катнашты һәм романның язылу тарихы турында энтәлекле чыгыш ясады.

Г. Бәширов сентябрь аенда Баку шәһәрендә булып кайтты. Ул анда Африка — Азия язучылары белән бәйләнеш комитетының Вьетнам халкына ярдәм мәсьәләсенә багышлап үткәрелгән утырышына катнашты.

А. Расих Арча районында, Р. Төхфәтуллин Азнакайда, С. Хәким — Питрәчтә, Г. Бакиров — Мамадышта иҗат командировкасында булып, укучылар белән очраштылар, бүгенге әдәбият турында әңгәмәләр үткәрделәр, үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

Әлмәт нефтьчеләренең Техника йортында Вьетнам халкына багышланган зур әдәби кичә үткәрелде. Кичәдә Мәскәү кунагы драматург И. П. Куприянов үзенең Вьетнамда булуы турында сөйләде. Язучылардан Г. Ахунов, Ә. Маликов, Г. Афзал, рус әдәби берләшмәсе членнары И. Винокуров, Д. Матвеев һәм А. Попов героик Вьетнамга багышланган әсәрләрен укыдылар. Шәһәр яшьләре исеменнән ВЛКСМның Әлмәт шәһәр комитеты секретаре Зиннуров чыгыш ясады. Туләүле кичәдән кергән акча Вьетнам халкы файдасына тапшырылды.

* * *

Драматург И. П. Куприянов нефтьчеләр арасында бер атна булды. Ул Муса Җәлил поселогы эшчеләре, лагерьда ял итүче пионерлар һәм шәһәр активы белән очрашулар үткәрде.

## КУБА АРТИСТЛАРЫ КАЗАНДА

Август аенда Казанга Кубаның Кече Мюзик-холл артистлары гастрольгә килде. Мюзик-холл коллективының Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында үткәрелгән чыгышларын Казан тамашачылары яратып каршыладылар.

Азатлык утравыннан килгән җырлар һәм биюләр, дәртле музыка Совет һәм революцион Куба халыкларының какшамас дуслыгы билгесе булып яңгырады.

## ТАТАР АРТИСТЛАРЫ МОНГОЛИЯДӘ

1966 елга Монголия Халык Республикасы белән Советлар Союзы арасында культура хезмәттәшлеге турындагы план нигезендә Монголиядә Татарстан АССР жыр һәм бию ансамбле гастрольдә булды. Ансамбль коллективы монгол дусларны татар халык җырлары һәм биюләре, татар композиторларының әсәрләре белән таныштырды. Совет артистларының чыгышларын Монголия тамашачылары зур кызыксыну белән карадылар.

## ТАШКЕНТ АРТИСТЛАРЫ КАЗАН ТЕАТРЛАРЫ СӘХНӘСЕНДӘ

Август аенда М. Горький исемендәге Ташкент рус драма театры Казанга килде. Казан тамашачылары бу театр артистлары башкаруында «Полк бара», «Караңгылык хөкем сөргәндә», «Йөрәк уч төбендә», «Илчене урладылар», «Буш җанлы кеше тарихы», «Ялганчы кирәк», «Иван белән Марья» һәм башка әсәрләр буенча эшләнгән спектакльләр карадылар.

## ЯШЬЛӘР СПЕКТАКЛЕ



*Золушка — Г. Калашникова, Принц — Р. Садыйков.*

Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры сәхнәсендә С. Прокофьевның «Золушка» балеты уңыш белән бара. Балетны башкаручылар — хореография училищесын күптән түгел генә тәмамлаган яшь артистлар. Золушка ролен ТАССРның халык артисткасы Г. Калашникова, артистка В. Гайсина, Принцны — ТАССРның халык артисты Р. Садыйков, артист Ф. Гильфанов, үги ананы — артистка Р. Новицкая, башка рольләрне С. Хантимирова, А. Фалинов, Е. Чуркина башкаралар. Спектакльне куючылар да яшьләр: балетмейстер — А. В. Луначарский исемендәге театр сәнгате институты дипломанты М. Арнаудова, дирижер — композитор Алмаз Монасыйпов, художнигы К. Андреев.

Театрның бу яңа спектакленә театр һәм музыка белгечләре уңай бәя бирделәр. Казан тамашачылары да аны алкышлап каршыладылар.

*Спектакльдән бер күренеш.*



## «ТОКИО-БАЛЕТ» ТРУППАСЫ ҚАЗАНДА

Август аенда республикабыз башкаласына Япониянең беренче классик балет труппасы — «Токио-балет» гастрольгә килде. Труппа бөек рус композиторы П. И. Чайковский исемен йөртә.

Казанлылар бу труппа башкаруында «Маримо», «Япония иртәсе», «Жизель», «Ало-лоали» һ. б. спектакльләрне карадылар.

Советлар Союзына беренче мәртәбә килгән бу балет труппасы Мәскәү һәм Ленинград шәһәрләрендә дә гастрольдә булды.

## «АЗАТ ХАТЫН» ЖУРНАЛЫНА 40 ЯШЬ

26 августта республикабызның партия-совет, культура һәм матбугат җәмәгатьчелеге «Азат хатын» журналының беренче саны чыгуга 40 ел тулу көнен билгеләп үттеләр. КПСС өлкә комитетының конференц-залында шул уңай белән тантаналы кичә булды. Кичәдә журналга карата бик күп мактау сүзләре әйтелде, котлау адреслары һәм телеграммалар укылды. Татарстан язучылары союзы идарәсе һәм «Казан утлары» журналы редакциясе «Азат хатын» журналына түбәндәге сүзләр язылган адрес тапшырдылар:

«Ягымлы дустыбыз, киң күңелле куршебез һәм сердәшебез, сугышчан фикердәшебез һәм тәрбия фронтында ышанычлы көрәштәшебез булган «Азат хатын» журналын, аңа 40 яшь тулган көндә, чын күңелдән котлыйбыз һәм аңа матур әдәбиятны пропагандалау эшендә, әдәбиятчыларның яшь кадрларын, бигрәк тә хатын-кыз авторларны үстерешүдә даими һәм актив эшчәнлеге өчен мең-мең рәхмәтләр яудырабыз.

Бәйрәм көнеңдә синең йөрәктә һәр вакытта да заманга аваздаш булып тибәсе кайнарлык, синең каләмгә һичкайчан да тупасланмый торган үткенлек телибез.

Иҗат яшьлегең әле бик күп буыннарны куандыра алырлык дәвамлы булсын.

Безнең дуслык букетыбызны кабул ит һәм әдипләрнең аны тапшырганда һәрберсе аерым-аерым әйткән сүзләрен онытма!»

Журналга 40 яшь тулу белән «Азат хатын» журналы редакторы А. Ф. Хәсәновага Татарстан Верховный Советы Президиумы Указы нигезендә «Татарстан АССРның атказанган культура эшлеклесе» исеме бирелде, журналның элеккеге редакторы Г. З. Гафурова, язучы, журнал редколлегиясе члены Ләбибә Ихсанова Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Почет грамотасы белән бүләкләнде. КПСС-ның Татарстан өлкә комитеты һәм ТАССР Министрлар Советы журналның бер төркем актив хәбәрчеләрен, редакция сотрудникларын Почет грамоталары белән бүләкләде.

—◆—

## Алдагы саннарда:

**С. Таҗетдинов. Үлемнән яшәүгә.** Документаль повесть. Дәвамы.

**И. Гази. Тургай картаямы икән?** Хикәя.

**Вьетнам язучылары хикәяләре.**

**Бөек Октябрьга багышланган шигырьләр.**

**С. Хәким, Г. Латыйп, Ә. Баянов, Х. Камалов, Р. Фәйзуллин** шигырьләре.

**С. Сараи. «Китабе Гөлстан бит-төрки»нең татарчага тәрҗемәсеннән өзекләр, назыйрәләр, шигырьләр.**

**К. Рәхим. Бәйрәкә авылының революцион үткәне турында очерк.**

**Ә. Таҗетдинов. Культура төзелеше мәсьәләләре.** Публицистик мәкалә.

**Р. Мостафин. С. Хәкимнең иҗат портретына эскизлар.**

**Г. Ибраһимовның тууына 80 ел тулуга карата материаллар.**

**Рецензияләр.**

**Хатлар.**

**Җырлар.**

Җаваплы редакторы **Рафаэль Мостафин**

Редколлегия: **Хәй Вахит, Ибраһим Гази, Әмирхан Еники, Гази Кашшаф, Шәйхи Маннур, Габдрахман Минский, Сибгат Хәким, Нил Юзиев**

Производствога бирелде 15/VIII-1966 ел. Басарга кул куелды 26/IX-1966 ел. ПФ 15044. Кәгазь форматы $70 \times 108^1/_{16}$. Учетн.-изд. табак 12,2. Басма табак 10(14). Тираж 34 800 экз. Заказ Н-1129. Бәясе 40 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19, 1966 ел.

## *ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАРЫБЫЗ!*

Хәзер бөтен илебездә газета-журналларга, шул исәптән «Казан утлары» журналына да, подписка кабул итеп башлады. Әгәр «Казан утлары» 1967 елда күңелегезне яктыртып барсын дисәгез — аңа вакытында язылып калырга тырышыгыз! «Казан утлары» — Бөтенсоюз каталогына 73210 нчы индекс белән теркәлгән һәм аңа СССРның теләсә кайсы элемтә бүлегендә һәм «Союзпечать» агентлыгында чикләүсез язылырга мөмкин.

Язылу бәясе:

1 елга — 4 сум 80 тиен.
6 айга — 2 сум 40 тиен.
Аерым саны — 40 тиен.

Хөрмәтле иптәшләр! Журналга язылган вакытта подписка кабул итүче кешеләрдән квитанцияләргә адресларыгызны төгәл һәм аңлаешлы итеп язуларын таләп итегез. Югыйсә, журналны подписчикларга таратканда кыенлыклар килеп чыгуы мөмкин.

*РЕДАКЦИЯ*

Бэясе 40 тиен
Цена 40 коп.

Индекс
73210

*Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал*

**КАЗАН УТЛАРЫ**

*(Огни Казани)*

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ